
ISSN 0206—4189



# КАЗАН УТЛАРЫ

3.1988





Кол Гали

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

1988

3

(785)

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН


## *Бу санда*


УКУЧЫЛАР СОРАВЫ БУЕНЧА

КОЛ ГАЛИ. **Кыйссаи Йосыф** 3

Ф. ФӘСИЕВ. **«Кыйссаи Йосыф» һәм аның авторы турында** 91

ПРОЗА ҺӘМ ПОЭЗИЯ

Я. ЗӘНКИЕВ. **Иртеш таңнары.** *Роман* 98

К. БУЛАТОВА. **Югалтмаска!** *Шигырьләр* 139

Ф. ЗЫЯТДИНОВА. **Хөкемдар.** *Шигырьләр* 141

Б. РӘХИМОВА. **Яшьләр.** *Шигырьләр* 142

С. ЗЫЯТДИНОВА. **Сөю туганда.** *Шигырьләр* 143

Ф. ҖАМАЛЕТДИНОВА. **Яшәү.** *Шигырь* 145

Ф. МӨСЛИМОВА. **Сица.** *Шигырь* 145

Д. САЛИХОВА. **Син әллә кеше...** *Шигырьләр* 146

Н. АКМАЛОВ. **Ким, гырлама.** *Хикәя* 147

ПУБЛИЦИСТИКА

М. НАСЫЙБУЛЛИН. **Хөкем** 153

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

М. Ш. ХӨСӘЕНОВ. **Ленин юлыннан** *(Питрәч районы)* 160

БӘХӘС ДӘВАМ ИТӘ: «ЗАМАН ҺӘМ ШИГЫРЬ»

С. ХАФИЗОВ. **Үзеңне тап, шагыйрь** 163

УФАДА КУЛЬТУРАБЫЗ ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

А. ТИМЕРГАЛИНА. **Элеккеге Дворяннар собрание бинасы** 168

Х. ГОБӘЙДУЛЛИН, Җ. МИҢНУЛЛИН. **Истәлекле бина** 169

М. ГОРЬКИЙ ТУУЫНА 120 ЕЛ

М. МӘҺДИЕВ. **Давыл хәбәрчесе — Иделдә** 170

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

ӘХӘТ ГАФФАР

МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ

АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ

МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ

МӘДИНӘ МАЛИКОВА

САЛИХ МАННАПОВ
*(баш редактор урынбасары)*

ТУФАН МИҢНУЛЛИН

ФЛҮН МУСИН

РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ

РӘФЫЙК НӘФИКОВ

НУРИХАН ФӘТТАХ

РИЗВАН ХӘМИД

НИЛ ЮЗИЕВ

АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60.
баш редактор урынбасары —
53-07-69.
җаваплы секретарь — 53-07-65.
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61.
тәнкыйть, фән, сәнгать.
хатлар —53-07-63.

САНГАТЬ

В. ГОРШКОВ. **Гай Таһиров һәм татар балеты** 179

БИБЛИОГРАФИЯ

Э. НИГЪМӘТУЛЛИН. **Хәтердә саклап** 183

ЮБИЛЕЙЛАР

Л. ИХСАНОВА. **Дәрҗия Аппакова** *(тууына 90 ел тулу уңаеннан)* 186

М. ЮНЫС. **Чишмәләрнең сафлыгы** *(Рәис Даутовка 60 яшь)* 188

**Культура тормышы көндәлеге** 191

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

По многочисленным просьбам читателей публикуется «Кысса-и Йусуф» (Сказание о Йусуфе) булгаро-татарского поэта КУЛ ГАЛИ.

«Кысса-и-Йусуф» представляет собой первый известный нам крупный письменно-литературный памятник в Поволжье, истоки которого восходят к эпохе Волжской Булгарии. Написанная в начале XIII века, эта величавая лиро-эпическая поэма вот уже восьмое столетие продолжает активно жить в письменно-литературном и фольклорном наследии татарского народа, пользуясь неизменной любовью и популярностью среди широких слоев населения.

Переложение на современный язык, научные комментарии и заключительная статья подготовлены кандидатом филологических наук Ф. ФАСЕЕВЫМ.

Окончание романа Я. ЗАНКИЕВА «Зори Иртыша», рассказ Н. АКМАЛОВА «Не храпи, Ким».

К Международному женскому дню представлены стихи К. БУЛАТОВОЙ, Ф. ЗИЯТДИНОВОЙ, Б. РАХИМОВОЙ, С. ЗИЯТДИНОВОЙ, Ф. ЗАМАЛЕТДИНОВОЙ, Ф. МУСЛИМОВОЙ, Д. САЛИХОВОЙ.

Публицистика. Очерк М. НАСЫБУЛЛИНА «Суд».

В рубрике «Татарстан — родной мой край» выступление первого секретаря Пестречинского райкома КПСС М. Ш. ХУСАИНОВА.

Продолжение дискуссии: «Время и поэзия»: статья С. ХАФИЗОВА «Найти себя».

Памятники татарской культуры в Уфе — здание бывшего Дворянского собрания, в котором в начале века проходили вечера татарской литературы и музыки.

К 120-летию со дня рождения А. М. Горького — статья М. МАГДЕЕВА «Буревестник — на Волге».

«Искусство» — статья В. ГОРШКОВА «Гай Тагиров и татарский балет».

«Библиография» — рецензия Э. НИГМАТУЛЛИНА на книгу Р. Мустафина «Муса Джалиль. Жизнь и творчество».

В номере отмечаются 90-летие Д. Аппаковой и 60-летие Р. Даутова.

На наших обложках: иллюстрация к поэме Кул Гали «Кысса-и Йусуф» (автор Т. ХАЗИАХМЕТОВ), здание Союза композиторов Татарии.

Җаваплы секретарь *Флүс ЛАТЫЙПОВ*

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Т. Сибгатуллина, Г. Салихҗанова*.

Производствога бирелде 4.1.1988 ел. Басарга кул куелды 18.2.1988 ел. ПФ 05060. Офсет ысулы белән басыла.
Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 66749. Заказ А-2. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1988 ел.

Кол Гали

# КЫЙССАИ ЙОСЫФ



Мәшһүр шагыйрь Кол Галинең
атаклы «Кыйссаи Йосыф» әсәре
болгар-татар язма әдәби традициясенең
чишмә башында тора.
Әдәбиятыбызның
иң әүвәлге сәхифәләре
шушы әсәр белән ачыла.
XIII гасыр башларында иҗат ителгән,
татар халкының язма әдәби мирасында
һәм фольклорында ныклы урын алып,
сигез йөз елга якын
халкыбызның рухи дөньясына
даими тәэсир итеп килгән ул
«Кыйссаи Йосыф».
Ул һаман да халкыбыз тормышына
нур һәм ямь биреп торган
иң асыл әдәби җәүһәрләрнең
берсе булып кала килә.
Күпсанлы укучыларыбыз соравы буенча
журналның бу санында
гасырлар буе
халкыбызның җан азыгы булган
әнә шул бөек язмышлы әсәр
тәкъдим ителә.



## Кереш

*Бисмилляһи-р-рәхмани әр-рәхим*[1]

*(«Мәрхәмәт иясе ул рәхимле алла исеме белән» сүз башлыйм)*

Мактау, шөкер, дан булсын: ул бар вә бергә,[2]
мөлке бетми торган даим ул мәүләгә,[3]
мөлкәтендә[4] мохтаҗы юк шарикләргә[5]—
аны мәңге бөек хуҗа дип белдек инде;
Аннан соңра — аның дусты Мөхәммәдкә,
ул сайланган рәсүлләрдән иң хөрмәткә,
ике җәя[6] генә ул калган хак мәликкә —
аңа бик күп мактау, алкыш[7] булсын инде;
Аннан — әүвәл мостафаның[8] сиддикына[9],
мәгарәдә иң тугры яр булганына,
гарь итмәгән, әзер торган ярдәменә —
тугрылыгы барчасыннан артык инде;
Аннан соңра янә Гомәр Хәттаб углы[10],
дөнья ара мәшһүр булды аның гаделе,
йөз мең ирдән артык иде аның кадере —
дүрт мең дүрт йөз мәсҗед бина кылмыш инде.
Изге Госман[11] — шәһид киткән өченче яр,
сыйфатларын Коръәндә яд иткән җәббар[12],
үткен гакыл бүләк иткән аңа гаффар[12]—
җыйма Коръәнне хатасыз төземеш инде.
Аннан соңра — Гали батыр[13], сәясәткәр,
йөз меңләгән гаскәрләргә ул башгаскәр,
мәшһүр аның үткен кылычы зөлфекар[14]—
«Галидән дә батыр ир юк!» дирләр инде.
Аның күңел парәсе иде ике егет,
икесе дә ирдәм[15], тугры, кыю егет,
берсе Хәсән, берсе Хөсәен[16]— ике шәһид —
яшьли көе җәннәт әһле булган инде.
Аннан килеп барча тугры хәлифләргә,
голяма[17] вә табигыйннәр[18], шәһидләргә,
һәр өммәттән[19] олуг изге шәхесләргә —
һәммәсеннән тәңре риза булсын инде.
Аннан ары — бәхет иясе ул ирләргә,
хак сөйгәне мостафаны күргәннәргә,
һич ким түгел, утыз өч мең ияргәнгә —
һәркайсын юл башлаучы дип белик инде.

---

*Әсәрнең текстын һәм аңлатмаларны филология фәннәре кандидаты* **Фазыл Фәсиев** *әзерләде.*

*Кулъязманың журнал вариантын* **Җәүдәт Миңнуллин, Рәдиф Гатауллин** *редакцияләде.*

*Тышлыкның беренче битендәге һәм текст эчендәге иллюстрацияләрне Татарстанның халык художнигы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты* **Тавил Хаҗиәхмәтов** *эшләде.*

Әсәрне журналга әзерләгәндә Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән түбәндәге басмалар искә алынды:
1. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. Казан, 1983 (хәзерге әдәби телгә күчерүчеләр: Фазыл Фәсиев, Алмазия Нуриева һәм Әхмәт Исхак; махсус редакторы тарих фәннәре докторы, профессор Миркасыйм Госманов, нәшрият редакторы Рәис Даутов).
2. Борынгы татар әдәбияты. Казан, 1963.
3. Госман Х. Борынгы төрки-татар әдәбиятының чыганаклары. Казан, 1981.

Аннан соң бер күтәрелгән гыйлем кяне[20],
аның белән зиннәтләнгән ислам дине,
анык-ачык беләсезме сез ул ирне —
Сабит углы Ногман[21] аңа дирләр инде.
Һәм һиммәтле дин башлыгы ирәннәргә,
иман юлын, ислам нурын белгәннәргә,
хакдан даим ирешсеннәр рәхмәтләргә —
күп меңнәрчә афәриннәр әйтик инде.

*(Илһам алиһәсенә мөрәҗәгать)*

Мәрхәмәтле илаһыма сыенмый нишлим,
рәхим итеп ярлыкавын өмет итим,
теләгәнем булыш-ярдәм аннан көтим —
теләкләрне үтәү аңа җиңел инде.
Сиңа, тәңрем, сыенамын мин бер зәгыйфь,
тәүфыйк өмет итәм синнән мин бер шәех,
хәтеремне яктыртсана, иям лятиф[22] —
кодрәтеңлә зирәк акыл бирсәң инде!
Синнән уңыш үтенәмен мин зәгыйфь кол,
сине дәлил тотканнар[23] тик башкара юл,
әгәр уңыш бирим дисәң, кодрәтең мул —
бу бәндәңә җитәкләүче булсаң иде!
Мин зәгыйфең хикмәт таба юналдерсәң,
киңәш-нәсихәт әйтергә син кандырсаң[24],
илһам шәмен күкрәгемә син яндырсаң
зиһенем ачып, күңлем нурга балкыр инде.
Күңелемә фикер йөртмәк сәләте бир,
кодрәтеңлә тел вә хикмәт куәсе бир,
мин зәгыйфькә илһам-тәүфыйк куәте бир —
син кадирсең[25], «Бул!» дигәнең була инде.
Зиһенемнең сүлпәнлеген чишеп җибәр,
күкрәгемә хикмәт төшен сачеп җибәр,
миңа уңыш капуларын ачып җибәр —
гакылым — саф, телем татлы кылсаң инде.
Уңыш бирче хикмәт юлына кайтырга,
гакыл колларның хәтерен баетырга,
Йосыф нәби[26] әхвәлен тәгал әйтергә —
гыйльмем камил, телем нәфис кылсаң инде.
Ул Йосыфка хәлләр ничек килгәнлеген,
кардәшләре аңа ниләр кылганлыгын,
Мисырда олы хөкемдар булганлыгын —
назым белән әйтием, аңлагыз инде.
Бу дөньяга килгән иде Йосыф нәби,
атасы аның хак сөйгәне Ягъкуб нәби,
бабасы исә Исхак нәби — дин табибе,
алла дусты Ибраһимның углы инде[27].
Моннан соңра хикмәт таба күчәрмен дим,
гөл вә рәйхан, энҗе-мәрҗән сачәрмен дим,
газиз Йосыф әхвәлләрен ачармын дим —
мөэминнәргә[28] гыйбрәте күп, аңла инде.
Кыйссалардан, хикмәтләрдән күркәмлесе,
ялыкмастан тыңлау өчен иң тәмлесе,
Коръәнгә дә шиксез аның кергәнлеге —
ошбу кыйсса икәнлеге мәгълүм инде.

[1] Традицион башлам
[2] Ягъни: бер алла
[3] Алла, тәңре
[4] Бөтен дөнья, галәм
[5] Мәҗүси аллалары
[6] Мөхәммәд күккә ашканда алла белән арасы шулай булган имеш
[7] Фатиха
[8] Бирегә: Мөхәммәд
[9] Беренче хәлифә Әбүбәкер күздә тотыла
[10] Икенче хәлифә
[11] Өченче хәлифә
[12] Җабер итүче һәм гафу итүче алла
[13] Дүртенче хәлифә
[14] Гали батырның легендар кылычы
[15] Батыр
[16] Галинең олы һәм кече улы
[17] Галимнәр
[18] Пәйгамбәр сүзен ишетеп тапшыручылар
[19] Дин, җәмәгать, милләт
[20] Казылма чыганак, хәзинә
[21] Ягъни: Әбү Хәнифә — галим-юрист
[22] Бирегә: ярдәмчел
[23] Алла иркенә тапшырылу
[24] Туендыру
[25] Кодрәтлесең
[26] Пәйгамбәр, ил олысы
[27] Ягъни кыскача шәҗәрәсе: Йосыф — Ягъкуб — Исхак — Ибраһим
[28] Ышанган, иман кабул иткән (кеше)



## I бүлек. Йосыфның төше

Газиз Йосыф[1] тәмам унбер яшәр иде,
Ягъкуб нәби итәгендә йоклар иде,
йокысында бер гаҗәп төш күргән иде —
төш мәгънәсен атасыннан сорый инде:
«Туар кояш[2], тулган ай һәм унбер йолдыз
сәҗдә кылдылар[3] төшемдә миңа төп-төз,
бу төшемне шулай күрдем һич гомансыз —
йә, эткәем, моңа юрау әйтче инде.
*Бу төшемнең бир мәгънәсен миңа ачып[4],
ахыр хәлдә ни буласын әйтеп анык,
күрекле тәгъбир[5] белән миңа бир аңлатып —
бу төшне син изге уйлап юра инде.»
Ягъкуб уйлап, Йосыфның төшен тәгъбир кыла:
«Мәгънәсе бик — диеп әйтә — котлы килә,
ярдәм итә синең өчен кадир мәуля —
сиңа гыйззәт, бөеклекләр күренә инде.
Өмет бар ки, тәңре сиңа биреп мөлкәт,
кодрәт белән насыйп итәр бик күп нигъмәт,
кардәшләрең бөтенесе итәр хөрмәт —
унбере дә сиңа хезмәт итәр инде.
Бөтен дөньяга исемең мәшһүр булыр,
мәшрикъ[6], мәгърип[7] олуглары сине белер,
кыяматкә тиклүк атың мәңге калыр —
бабаларың дәүләте[8] күренә инде.
Олуг исем — пәйгамбәрлек алачак син,
һәм дә мәмләкәт иясе булачак син,
шатлык, рәхәт, сөенечләр табачаксың —
бу төшеңнән зур бәрәкәт күренә инде.
Әй, угылым, инана күр шиксез миңа,
бу төшеңдә солтанәт[9] күренер сиңа,
мактау-шөкер, рәхмәт укы сөбханыңа —
ул сиңа күп игелекләр кылыр инде.
Әмма ләкин әманәтем — яхшы тыңла:
һичбер кемгә бу төшеңне мәгълүм кылма,
кеше-кара кинә тотмасын, шуны уйла —
адәмнәргә шайтан дошман булыр инде.
Кирәкмәс кем, бу серләрдән хәбәр алса,
кардәшләрең бу төш асылын әгәр белсә,
алар сиңа шуның өчен хөсет[10] кылса —
моның башы безгә михнәт булыр инде».

*(Сернең ачылуы)*

Ягъкубның һәм бар иде бер үги кызы,
ул ишеткән бу икенең ошбу сүзен,
(гайбәтләрдән сакласын бер ходай үзе)
агаларына барып ул әйткән инде.
«Кардәшегез Йосыф кичә бер төш күргән,
унбер йолдыз, ай, көн аңа сәҗдә кылган,
Ягъкуб-ата котлы, изге юрау биргән —
мин ишеттем: яхшы мәгънә әйтте инде».
Кардәшләре[11] моны ишетеп кинә кылды,
көнчелек вә үчлекләре өстен булды,
һәр кайсының башына гүя кайгы яуды —
җыйлып бергә явыз ният кора инде.
«Әгәр ул төш, дип, җиренә килер булса,
Йосыф олы падишаһ ук булыр булса,
һәммәбез дә аңа хезмәт кылыр булсак —
бу бит безгә каты гарьдер!» диләр инде.

[1] Әйтелеш варианты Йусеф (атасы Ягъкуб, Динә һәм Зөләйха сөйләмендә)
[2] туар (кояш) — даими сыйфат, эпитет
[3] Сәҗдә кылу — табыну
[4] Киң редакциядәге өстәмә тезмәләр йолдызчык белән бирелә
[5] Төш юравы, юралышы
[6] Көнчыгыш

«Без Йосыфны янибызга өндәп алыйк,
ни төш күргән, әйтеп бирсен, сорап карыйк,
шуңа лаек берәр чара эзләп табыйк —
бу әхвалнең чын дөресен белик инде!»
Өндәп анда ул Йосыфны китерделәр,
ун карендәш егълашынып утырдылар,
түбәнчелек белән барсы үтенделәр:
«Ни төш күрдең, безгә әйтче!» диләр инде.
Йосыф төшен аларга тик әйтеп бирми,
ата сүзен бозарга һич кабул күрми,
җуеп-яшереп ялган сүз дә ул сөйләми —
хәйран булып, аптырап ук тора инде.
Кардәшләре җөмлә аягүрә торып,
икәү-икәү килде янә сорау биреп,
катлы-кабат һәммәсе дә күп ялварып —
һәр берсе түбәнчелек кылыр инде.
«Күргән төшең, диләр, бездән яшереп торма,
гөман-сагыш эчендә син борчылып йөрмә,
әй, карендәш, безне болай дошман күрмә —
нинди юрау кылды, әйтче серең инде?!»
Кардәшләре хәтерен ул калдыралмады,
яшереп-җуеп бүтән хәйлә әйтәлмады,
тугры иде, һич ялган сүз сөйләмәде —
чарасыздан ачып бирде серен инде.
Моны ишеткәч, баягыдай булмадылар,
Йосыфка инде ышаныч кылмадылар,
күргән төшен раст диеп белмәделәр:
«Хакыйкатьтә бу төш ялган!» диләр инде.
*«Без сәхрәдә көне-төне мал көтәбез,
елкы-сыер, куй куып имгәк итәбез,
ә Рәхиләнең Йосыфы — сез ишетәмсез —
төшләр сөйләп үзен артык сөйдерә икән!
Әйдә барыйк атабызга, сөйләп карыйк,
ул Йосыфны атабыздан теләп алыйк,
алып-илтеп берәр төрле гамәл кылыйк —
йә үтерик, йә еракка сатыйк инде».
Атабызның каршында без калыр идек
вә һәмишә[12] сөеклесе булыр идек,
атабызга яхшы тәрбия кылыр идек —
без өлкән дә, хөрмәтле дә булып инде.
Хәзер исә аны бездән артык сөя,
күрмәдисә аның йөзен, артык көя,
мирас бирсә Йосыфка ул артык бирә —
икеләтә бездән артык сөя инде.
Сәлам биреп, хөрмәтләп аңа килделәр,
шәфкатьле йөз-чырай биреп сөйләделәр,
Исраилдән[13] Йосыфны бик теләделәр;
«Безнең белән ул да барсын» диләр инде.
«Йусефең, дип, безнең янга сәйран чыксын,
безнең белән куй катында уйнап йөрсен,
фәһме артсын, күңелләре бер ачылсын —
кичен янә хезмәтеңә кайтыр инде.
Төрле җирләр, агар сулар — барын күрсен,
йөреп яшел сәхраләрдә чәчәк җыйсын,
күргәненнән сезгә килеп хәбәр бирсен —
ул сөйләр вә сез тыңларсыз», диләр инде.
Ягъкуб моны ишеткәч бик сагышланды,
күңле кайгы белән тулды, бәгъре янды,

[7] Көнбатыш
[8] Байлык, бәрәкәт
[9] Бөек дәрәҗә, халыкара мәшһүрлек
[10] Көнчелек, үч
[11] Яһүдә, Раувил, Шамгун, Леви, Равлун, Йәшҗәр, Дан, Яфсал, Җадун (Галун), Ашир. Кечкенә Ибне-Ямин (Йосыфның үз энесе) бирегә булмый, билгеле
[12] Һәрвакыт
[13] Ягъкубның кушаматы

әүвәл бер төш күргән иде, исенә алды —
рөхсәт бирми, Йосыфны җибәрми инде.
Аларга әйтә: кичә бер төш күргән идем,
төшемдә, ди, унбер кузый көтәр идем,
көтә идем — бересен тик мин алдырдым —
бүре килеп кулдан кабып алды инде.
Алар исә: «Йосыфны, ди, нык сакларбыз,
энебезне ник бүредән каптырабыз,
бетерәбез, дөнья бүресен кырабыз —
Йосыф өчен, ва-аллаһи!» диләр инде.
«Бу эш,— диеп Ягъкуб әйтә,— алай булмас,
сезнең белән, ди, Йусефем ай-һай бармас,
андый эшне күңелем һич кабул кылмас —
ул юк исә җаным тынгы тапмый инде!»
Аннан килеп Йосыфны алдадылар:
«Атабыздан үзең рөхсәт ал, диделәр,
син сәйранга безнең белән бар, диделәр —
гөл-сачәктә кошлар кунып сайрый инде!»
Йосыф әйтә: «Рөхсәт бирсәң, үрә торыйм,
олы агаларым илән анда барыйм,
сәйран иткән сәхраләрен үзем күрим —
кичкә янә хезмәтеңә кайтыйм инде».
Тик әткәсе «Йусефенә» рөхсәт бирми,
беравык та айрыласы аннан килми,
алданганның күңле купкан, тынгы белми —
муенына сарылып ук сорый инде.
*Йа, әткәем, яратасың мине, беләм,
яратуың дәлилләрсең тик ни белән,
айрылмаса сүзең синең гамәлеңнән —
агаларым белән мине җибәр инде».
*Ишетеп моны башта аягүрә торды,
аннан Йосыф аягына ул егылды:
«Йа, Йусефем, хак хөкеменә риза булдым —
ничек сүзең тыңламыйча куйыйм инде!
*Иртән агаларың белән җибәргәнче,
бәгыремә кысып сине бер сөеймче,
туйганчы һәм күрекле йөзең бер күримче»,—
диеп егълап бөгелеп җиргә төшәр инде.
Каза килер булса, күзең ул сукрайта,
акыл күзе томалана, эш чуалта,
илаһыдан хөкем килсә, көймә бата —
һичшиксез ки, аның хөкеме була инде.
Мескен Ягъкуб бу чарага риза булды,
җибәрергә дип Йосыфны күңел куйды,
һәм тел язып, улларына вәгъдә кылды:
«Иртә белән бәлкем барса барыр инде...»
«Иртәгә, ди, Йусефемне болай илтәсез,
юл буе сез нәүбәтләшеп күтәрәсез,
яхшы тәрбия, кадер-хөрмәтләр итәсез —
үзе пакь һәм күңеле шат булсын инде».
Исраилдән моны ишетеп сөенделәр,
ун карендәш янә бергә җыелдылар:
«Үтерәбез Йосыфны, дип ант эчтеләр,
фетнәсеннән котылабыз!» диләр инде.
«Аннан кайтып атабызга без килербез,
һәммәбез дә егълашып аһ килербез,
бүре ашады Йосыфны, ваһ диербез —
атабыздан битәр зари кылып инде.

Аннан дүнеп, хатабызны без танырбыз,
гөнаһны икърар итеп, табынырбыз,
һәр даимән гайбадәттә булынырбыз —
тәүбәбезне тәңре кабул кылыр инде».
Ул төн кичте, ярен янә иртә булды,
ун карендәш иртә таңнан үрә торды,
Исраилгә килеп барсы сәлам бирде —
йомшак сөйләп Йосыфны сорыйлар инде.
Моны ишетеп, Ягъкуб нәби «барсын» диде,
егълый-егълый үзе урыныннан торды,
үз кулыннан Йосыфының башын юды —
майлап-тарап озын чәчен үрер инде.
Үз кулыннан су эчерде, аш җидерде[14],
иңнәренә төрле төсле тун[15] кидерде,
күлмәкләрен җофар белән исләндерде —
күзләренә сөрмә нәфис тартты инде.
Ибраһимның чалмасын башына чалып,
Исхак бабасы кәмәрен[16] биленә буып,
кәрзиненә төрле азык-ризык салып —
күн сабага[17] сусынга су коеп инде.
Тапшырды ул Йосыфын үбә-коча
(алды алар кулдан-кулга, очтан-очка):
«Кайтыгыз, ди, бүген берүк калмый кичкә —
аһ, ул кичләр кайчан килеп җитәр инде?!
Әманәтем — Йусефне саклап йөртәсез,
нәүбәтләшеп иңегезгә күтәрәсез,
һәр берегез яхшы тәрбия итәсез»,—
дигән сүзләр белән озатып кала инде...
*Диде алар: «Кабул иттек бөтен сүзең,
кайгырма ки, ялгызлыктан бүген үзең
(тамашабыз Йосыф булсын бу көн безнең) —
кояш баймас, хозурыңа килер инде».
*Ягъкуб күзендә Йосыфны Рауил алды,
соң — Яһүдә, аннары соң — Шәмгун алды,
иңнәренә алып алар китеп барды —
Ягъкуб елап, аһлар орып калды инде.
*Ул Йосыфын озатарак бераз барды,
бер таучыкның түбәсенә ашып бакты,
бер өзлексез күзләреннән яше акты —
колынын җуйган тәвәдәй иңрәр иде.
*Кайчан Йосыф карасы күренмәс булды,
елап-егълап өенә таба ул борылды,
«Ярабби, Йусефне тапшырдым, диде —
мине фиракъ[18] утында яндырма инде».
*Кайчан Ягъкуб күзеннән югалдылар,
шул җирдә Йосыфны иңнән салдылар...
Ягъкуб әле һаман юлга карап ала:
күренми шул угланнары ни чак кара;
бик дәртләнеп Йосыфны алар алып бара —
шулчак Динә елап чыгып йөгерә инде.
Ягъкуб әйтә: «Кызым, кая йөгерәсең,
ни сәбәптән ике күзең яшь түгәсең,
йөгерсәң дә Йусефка син җитәлмәссең —
агалары тамашага илтә инде»...
Динә кире борылмады, йөгереп җитте,
җиту белән Йосыф кулын килеп тотты:
«Әйа, Йусеф, кайтыек!» дип күп ялварды —
кардәшләре читкә борылып пошынып иде.

[14] Ашатты
[15] Бирелә кием
[16] Кыйммәтле билбау
[17] Савыт
[18] Аерылу

Ярлы[19] апасы ялварадыр — Йосыф кайтмый
(туганнары пошынганын ул аңгартмый) —
Динә һаман кулдан тарта, асла куймый
инәләдер: «Әйа, Йусеф, кайтыйк инде!»
Аны шулчак җәһәт алып күтәрделәр,
бер кашлакның түбәсеннән ашырдылар;
Ягъкуб мескен карый һаман елап зар-зар —
Динә дәхи елый-елый кайта инде.
«Йа, әткәем, ди, мин бераз яткан идем,
үксеп-үксеп йокымнан уянып киттем,
аһ, төшемдә мин ун явыз бүре күрдем —
кулыбыздан Йусефне талыйлар инде!...»
Ягъкуб күңлен чолгап алды авыр кайгы,
бу хәсрәттән аның тәмам йөзе сулды,
биргәненә Йосыфны пошаман булды —
икесе дә үкенеп аһ-зар егълый инде.

*(Йосыфның җәбер-җәфа күргәннәре)*

Йосыфны бер тау-түбәдән ашырдылар,
аннан ашкач, этеп җиргә төшерделәр,
азыкларын эткә биреп ашаттылар —
күн сабадан суын да түгәләр инде.
Мескен Йосыф яннарыннан җәяү җилә,
кардәшләре үч иткәнен инде белә,
башына аның төрле шомлы уйлар килә —
гөман белән хәлнең асылын сорый инде:
«Әйтсәгез лә, әй туганнар — өмидләрем,
ничөн болай итенәсез, газизләрем,
нидән мондый ниятегез, кардәшләрем —
сезнең алда ни гайбем бар?» дия инде.
Әйтә алар: «Син бер ялган төш күргәнсең
вә әткәйдән аны изгегә юраткансың,
хәйлә белән сөеклесе син булгансың —
бу көн шуның җәзасыдыр, бел син инде!»
Мескен Йосыф елый-елый, ардым диер,
сусызлыктан бигрәк хәлсез калдым диер,
аякларым бик авырта, талдым диер —
кардәшләре ишетми дә бакмый инде.
Ул Шәмгунга сыенып исә — каршы каба,
Раулл-явыз төя-төя чәчен тарта,
бүтәннәрнең моннан битәр үче арта —
һәр бересе сугар өчен куа инде.
*Күзләренә багып, тилмереп карады,
тик берсе дә кызганмады, аямады,
аяу түгел, килеп-килеп яңаклады:
«Ялган төшең ярдәм кылсын» диләр инде.
*«Ачыктым — аш, сусадым — су бирегез, ди,
агаларым, миңа шәфкать кылыгыз, ди,
аякларына егылып ук ярдәм эзли —
«Ялган төшең ризык булсын!» диләр инде.
*Уйларының явызлыгын аңлап алды,
олы агасы Раулгә сыенмак булды:
«Коткар мине болардан, дип күп ялынды —
Атам кебек агам бит син», диеп инде. (...)*
*Һичбер яхшы сүз Рауилдән алалмагач,
Шәмгунга карап тилмереп, зар егълады —
ул бәгырьсез аны чалт-чалт яңаклады —
Йосыф җиргә әйләнеп үк төште инде.

[19] Мескен
* Кайбер өстәмә тезмәләр кыскартылды

*(Агалары һәм шайтан)*

*Йосыф каты өн салып елый башлады,
Яһүдәнең аягына килеп ауды:
«Миһербаным син барсыннан — дип ялварды —
мескин энең аясаң ни була инде?!»
*Шул сәгатьтә килеп керә әллә кайдан,
туганнарның арасына мәлгунь шайтан,
үч учагын сүндермәскә өсти утын —
аларны ул яман юлга тарта инде:
...«Ул ялганчы угланны сез үтерегез,
ялган төшнең юравын тиз бетерегез,—
җәзагызны җиренә сез җиткерегез»—
Иблис килеп, шулай коткы сала инде.
*Моны ишетеп, үчлекләре битәр булды,
ачулары аның саен үсәр булды,
газиз җаннан Йосыф өмет кисәр булды —
эшнең ахры ни буласын сизә инде.

*(Йосыфның агаларына әйткәннәре)*

«Минем татлы җанымнан сез туйдыгызмы,
мәлгунь Иблис коткысына оедыгызмы,
яисә булган үчегезне куйдыгызмы —
туганлыкны кистегезме миннән инде?!
Касед[20] кылгач, инде мине үтерегез,
тулган айдай йөземне һәм сулдырыгыз,
әткәйгә тик ничек хәлне белдерерсез —
сорар исә җавап бирү кирәк инде».
Исраилне хәсрәт утына куясыз,
хәсәд[21] белән аның бәгърен көйдерәсез,
Әй кардәшләр, белмисезме тәңрене сез —
мондый эшне ул һич мәгъкуль күрмәс инде.
Хәлем мөшкел, тәнем яра, гамьле күңлем,
көтмәгәндә бу михнәткә төштем мәзлум,
аһ, аяныч, атам Ягъкуб калды мәхрүм —
моннан ары мине кайда[22] күрә инде?
Үзем сиддикъ, атам Ягъкуб, бабам Исхак,
туганнарым җәфасыннан тәкатем такъ,
унавысы хәсәд кылды миңа нахак —
явыз касед кылды барысы миңа инде!»
Моны ишеткәч, Шәмгун каты зәһәрләнде,
пычак тартып Йосыф өстенә кизәнде,
үткен пычак ялтыранып һөҗүм кылды —
Йосыф күреп, каһкаһәләп көлә инде.
«Әй, син Йосыф!— диде Шәмгун — нидән көлдең?
Үткен пычак күрүгәме син шат булдың?
Моннан элек елап бик күп зари кылдың —
бу көлүең серен безгә аңлат инде!»
Йосыф әйтә: «Өлкәннәрем, мин көлгәнем —
өйдә чакта бер уй-фикер кылган идем;
инде беләм тәкъдирен ул сөбханымның —
без колларның уе тугры килми инде!
Уйлый идем: гайрәтле ун кардәш барын,
ул баһадир, ул мәһабәт туганнарым,
әзер чакта минем бу арысланнарым —
кайсы дошман миңа тияр, диеп инде.

[20] Үчлек
[21] Каныгу
[22] Ягъни: бу доньядамы, тегесендәме...

Аһ, иң каты дошман миңа сез булдыгыз,
миңа нахак авыр җәфа сез кылдыгыз,
ахры, миннән гаеп-хата ни таптыгыз?—
бу гыйбрәтне тыңларга бер ярар иде.
Өйдә чакта мин бер ваем кылган идем,
сезнең хакта бераз шиккә калган идем,
янә дүнеп ул фикремне куйган идем —
«Кардәшләрем нигә тисен!» диеп инде.
Менә хәзер ул гөманым килде анык:
тәнем-саным яралыдыр, рәнҗем артык,
изгеләргә ошбу эшләр булмас лаек —
мондый эштән саклану яхшырак инде.
Әмма ләкин сезләр мәслихәт күрсәгез,
мин үлүдән морад хасил була дисәгез,
әгәр минем йөз мең җаным булыр исә —
бөтенесен сезгә фида кылам инде!»

*(Яһүдә Йосыфны яклый)*

Бу сүзләрдән Яһүдәнең җаны көйде,
аяу хисе кайнап чыкты, бәгъре янды,
яман эштән кире дүнеп тәүбә кылды —
«Үтермәгез Йосыфны!» дип әйтә инде.
Сузылып тиз Йосыфның уң кулын ала,
аны үзенең итәгенә сыендыра,
явыз үчтән аны шулай саклап кала —
карендәшлек шәфкатен күрсәтеп инде.
Касед итеп кайчан тугызы кул тигерде,
Йосыф мескен Яһүдәдән шәфкать күрде,
(аяулы итте ул балага аны тәңре) —
ачуланып Яһүдәгә, диләр инде:
—«Син, Яһүдә, антыбызны ничөн боздың?
— Ни сәбәпле шартыбыздан кире дүндең?
— Ни дип аны аядың, шәфкатьле булдың?
— Вафасызлык[23] күрсәттең син безгә инде!»
Яһүдә әйтә: «Бу эшегез дөрес булмас,
карендәш карендәшне һич үтермәс,
моны кылган тәңредән һич тынгы күрмәс —
иң яхшысы — тәүбә кылып дүнү инде!
Тәңре күрер, үчлек белән каныксагыз,
ахирәттә кыен килер, кан түксәгез,
оҗмах биреп, тәмуг утын сез алсагыз —
мәңге тәмуг кисәве буласыз инде.
И кардәшләр, ошбу эшне сез кыласыз —
атабызның каргышына тап буласыз,
шиксез тәңре рәхмәтеннән айрыласыз:
ул нияттән кайтып, тәүбә кылыйк инде.
Моның олы бабасы иде мәшһүр Хәлил[24],
утка аткан аны ул Нәмруд[25]-җаһил[26],
ут эчендә саклап калган аны җәлил[27] —
аның өчен утны бөстан[28] итеп инде.
Аннан аңа вәхи[29] иңгән: «Әйа, Хәлил!»
Ибраһим колак салган, биреп күңел:
«Минемчөн... сөйгән углың... корбан биргел»,—
дигән өннәр аңа ишетелгән инде.
Ибраһимга ул ялкын һич кагылмады,
Исмәгыйльгә ул пычак зыян кылмады,
Хак[30] мәүляга Ягъкуб һич гөнаһ кылмады —
сезгә дә тиеш тәңредән курку инде!»

[23] Тугрылыксыз булу
[24] Ибраһимның кушаматы
[25] Легендар патша
[26] Биредә: әдәпсез, алласыз
[27] Алла
[28] Бакча
[29] Алла сүзе
[30] Алла

Аның сүзен асла колакка алмыйлар,
тәүбә-тәүфыйк юлына һич борылмыйлар
вә ахирәт газабыннан курыкмыйлар —
тугызы да Йосыфка үч тота инде.
Яһүдә аларга тәэсир кылалмагач,
үгет белән асла киртә булалмагач,
кулларыннан Йосыфны йола алмагач —
чарасыздан аерым әмәл эзли инде.
«Алайса, ди, моңа тимә, үтермәгез,
кардәш канын өстегезгә күтәрмәгез,
һич булмаса, бер коега төшерсәгез —
йә ул үләр, йә еракка китәр инде...»
Бу әйткәне аларга бик ярап куйды,
сүзен аның һәммәсе дә кабул күрде,
бу әмәлгә җөмләсе һәм разый булды —
Йосыф мескен ялварыплар елый инде.



## II бүлек. Йосыф коесының сыйфатлары

Ошбу кое борынгыдан калган иде,
аны әүвәл Гад кауме[1] казыган иде,
төбе тирән, суы бик ачыган иде —
аның суын кеше эчмәс иде инде.
Тора-бара ахры аның суы кипкән,
елан-чаян җыелып аны оя иткән,
төрле-төрле кортлар анда тулып беткән —
нинди генә хәшәрәтләр анда инде!
Бер дәрвиш купкан икән ул заманда,
Йосыф күркен белгән укып китапларда,
аның киләсен белдергән халыкларга —
ишеткәннәр гаҗәепкә калган инде.
Китаплардан бу әхвәлне анык белеп,
күңеленә аны күрү хыялы килеп,
халикына бик күп дога, сәҗдә кылып —
ошбу дәрвиш озын гомер теләр инде. (...)
Халиктан аңа вәхи-рөхсәт иңгән:
«Әгәр син, дип, Гад коесына барып керсәң,
анда Йосыф килгәнен син тәмам көтсәң —
сиддыкымның[2] җәмален[3] күрерсең инде».
Килә, керә ул дәрвиш Гад коесына,
көнен-төнен сәҗдә кыла тәңресенә,
гомер бакый дога кылып буен сона —
бар теләге ул Йосыфны күрү инде.
Ә ризыгы һәр кичәдә бер нар[4] иде,
алдында һәм нурдан кандил янар иде,
гомере исә мең ике йөз яшәр иде —
ниһаять, ул Йосыфны һәм күрде инде.

*(Йосыфны коега салулары)*

Алар Йосыф беләнә бау тактылар,
үзләренең күңеленә ут яктылар,
«Шул коега ташлыйк!» диеп җан саттылар —
ялварды исә һәр кайсысы сүгәр иде.
*«Минем берни языклы эш кылганым юк,
моның кеби айруклы төш күргәнем юк[5],
моның кадәр гаепле һич булганым юк»—
мескен Йосыф шулай дип ялвара инде.
Алар Йосыф аһ-зарына бакмадылар,
багу түгел, колакка да алмадылар,
Яһүдәнең киңәшен дә тотмадылар —
тарыгудан ачулары кайный инде.
*Йосыфны сөйрәп-өстерәп китерделәр,
Гад коесының өстенә күтәрделәр,
ага күзеннән мескеннең канлы яшьләр —
кардәшләре күрми, исе китми инде.
«И кардәшләр, дия, мине иңрәтмәгез,
шайтан сезне аздырадыр — иярмәгез,
киемем суеп, тәнем ачып гарь итмәгез —
ата хакын, кардәш миһрен саклагыз инде.
Бу көн үлсәм, кая миңа кәфен кирәк,
инде миңа кәфен булсын ошбу күлмәк.»
Агалары каты бәгырь, суык йөрәк —
күлмәген дә тәненнән суйдылар[6] инде.
*«Андаен сүз,— диешәләр,— безгә әйтмә!
— Ай-һай, Йосыф, бездән рәхим-шәфкать көтмә!
— Ай һәм кояш, унбер йолдыз әнә күктә...
(ягъни: шулар ярдәм итсен диләр инде).

Биленә бер бау урап китерделәр,
ул Йосыфны тар коега иңдерделәр,
шәфкать кисеп, йөзләрен дүндерделәр —
берсе килеп, бавын чабып өзде инде!..
Йа, илаһем,— диде Йосыф,— кәрим[7] мәүлям,
бичаралар өмите син, рәхим аллам,
калмады һич ышанычым кардәшләрдән —
миңа ярдәм син кылсана үзең инде!»
Моны ишетеп агалары елаштылар,
искә төшереп аллаһыны шаулаштылар,
җыенысы күп догалар кылыштылар —
«Илаһыбыз, ярдәм синнән!» диеп инде.
Бичаралар таянычы — улдыр рәхман[8],
ирке белән Җәбраилгә бирде фәрман:
«Ирештер, дип, Йосыфка тиз булыш-ярдәм —
һәм рәсүллек сөенечен күндер инде».
Фәрештәләр башчысы ул мөхбир хәзрәт,
кадир аңа бүләк иткән шундый куәт:
очты Йосыфка — иреште шул ук замат,
суга җитми аны тотып калды инде.
Диде аңа Җәбраил: «Әй, Йосыф-сиддикъ,
мәүләң сиңа күндерә сәлам, игелек,
сөенчең зур: сиңа бирә пәйгамбәрлек —
бу дәрәҗәң хуш-мөбарәк булсын инде».
Йосыфка очып Җәбраил килү белән,
ул хәбәрче фәрештәне тану белән,
хак сәламен, сөенечен алу белән —
боек күңеле куанычка тулды инде.
Кое төбендә бик олы бер таш бар иде,
Җәбраил тиз ул ташны өскә чыгарды,
су өстендә батмаенча калкып торды —
Йосыф килеп анда җайлап утыра инде.
Ул таш аңа хәтфәдән дә йомшак булды,
хак тәгалә шулай ярдәм-шәфкать кылды,
Йосыфның яктысына кое тулды —
тирә-юньгә нуры балкып чыгар иде.
Хак таңредән Җәбраилгә әмер булгач,
шул мизгелдүк оҗмах таба сәфәр кылгач,
яхшы кием, азык-төлек алып килгәч —
Йосыф киенеп, тәмле ризык ашый инде.
Хөллә киде[9], азык капты, шөкер кылды,
йөзләрендә йөз мең төрле нур балкыды,
өстәвенә Җәбраил нуры һәм кушылды —
җирдән күккә нур сузылып агар инде.
Ул карт дәрвиш аягүрә торып килде,
үз күзе белән Йосыфны шунда күрде,
күпме еллар көткәненә бу көн ирде[10] —
күрешү белән хакка шөкер әйтер инде.
«Әйа, Йосыф — диде дәрвиш — кайгырма әле,
күңелеңне кардәшләрдән аерма әле,
аларга явыз дога син кылма әле»—
Йосыф әйтә: «Үз әхвәлең сөйлә инде!»
«китаплардан укып, ди, васфең[11] белдем,
белү белән үзеңне хас[12] күрмәк булдым,
мең ике йөз ел тәмам мин сәҗдә кылдым —
ул морадым[13] бу көн хасил булды инде».
һәм дәрвиш карт Йосыфка үгет бирә,
Йосыф аның әйткәннәрен кабул күрә,

[1] Борынгы гарәп кабиләләре
[2] Ягъни: Йосыфымның
[3] Күркәмләгән
[4] Гранат җимеше
[5] Төш юравы белән чынбарлыкның туры килмәве
[6] Салдырдылар
[7] Олы җанлы, юмарт
[8] Мәрхәмәтле
[9] Оҗмах киеме
[10] Бирәдә: ирештә
[11] Сыйфатларың
[12] Шәхсән
[13] Олы максат

шул дәкыйка[14] ул дәрвишкә әҗәл килә —
янә кайгы-хәсрәттә ул кала инде.

*(Җәбраил һәм Йосыф)*

Мәүля-җәлил Җәбраилгә бирде әмер:
«Бар, Йосыфка тагы да син, йа Җәбраил,
җиткер сәлам, игелегем, үгетләр бир —
күңеленнән кайгы-сагышын юсын инде.
Коедан ул чыгарылгач сатыласы,
аннан соң да нахак яла күп буласы,
янә килеп зиндан эченә салынасы —
һәр хәлендә йөртүче[15] мин булам инде!
Аннан соңра кыеннардан котылдырам,
хакыйкатьтә атасына кавыштырам,
дәүләтен һәм мал-мөлкәтен мин арттырам —
таҗ вә тәхет, солтанәтләр[16] бирәм инде.
Үч кылганнар аңа хезмәткә килерләр,
алар гаять хурланырлар, гарьләнерләр,
пошаманга калып, тәмам үкенерләр —
Йосыф — олуг, алар гамьле[17] була инде!
Шулук сәгать Җәбраил анда килде,
бу әхвәлне, сәламнәрне ирештерде,
Йосыф хәлне төшенү белән шөкер кылды —
казасына риза кулын бирде инде.

[14] Мизгел
[15] Ягъни: язмышын билгеләүче
[16] Биредә: олылык, дәрәҗә
[17] Кайгы-хәсрәтле, үкенечле



## III бүлек. Йосыфның агалары өйгә кайта

Алар китә, кич булгач, өйгә кайтып,
бер бәрәнне бугазлагач берсе тотып,
канын Йосыф күлмәгенә болгаштырып —
аһ-ваһ килеп, елашып кайталар инде.
Юл буенда ялгыз агач тора иде,
Ягъкуб аның төбендә утыра иде,
һавадан ерактан бер тавыш килде —
тыңлады исә, «Житме-еш-ш!» дигән кебек инде.
Ягъкуб уйлый: «Аһ, бу житмеш көнме икән,
һай, аяныч, юкса житмеш аймы икән —
әллә исә житмеш үк елмы икән —
кичегүе Йусефемнең?!» диеп инде.
*Үзе карый: кай яктан өн-аваз килә,
фирак уты[1] йөрәген талый, бәгърен телә,
елап-иңрәп юл өстенә күзен тегә —
Йосыфымны күрмәмме, дип эзли инде.
Күңеле тарыгып, егълый-егълый өйгә керде,
улларыннан шикләнеп ул гөман кылды,
явыз үчлек иткәннәрдер диеп белде —
намаз-ниязын да иңрәп укыр иде.
Угланнары елашырга ант иттеләр,
якын килгәч өйгә, үкреп яшь түктеләр:
«Абау алла Йосыф!» диеп аһ иттеләр —
«Вай, алдырдык бит Йосыфны!» диләр инде.
Ягъкуб ясту намазыны укый иде,
угъланнары өйгә егълап кайтып килде,
колагына каты елау өне керде —
ашыгып торып, каршыларына чыкты инде.
Аны күргәч, елау-иңрәү битәр булды,
һәммәсе киемен ертып, чәчен йолды,
һәрберсе Йосыф өчен аһ-зар кылды —
«Ай, Йосыфны алдырдык шул» диләр инде.
Моны иштеп, Ягъкуб картның акылы шашты,
бер аһ килеп бөгелеп үк жиргә төште,
моны күреп, балалары кайгырышты:
«Ай, үкенеч, хата кылдык!» диеп инде. (...)
Ул төн кичте, ярен тагы иртә булды,
Ягъкубның ис-акылы башына килде,
угъланнарын дәштереп янә сорады:
«Кая минем Йусефем!?» дип ачыныр инде.
Угланнары елый-елый жавап бирде:
«Барыбыз да тик берәр ук аткан идек,
укларыбыз алырга дип киткән идек —
Йосыф калды әйберләрне саклап инде.
Без килгәнче аңа авыр каза тигән,
аһ, ул жиргә бик явыз бер бүре килгән,
шул бүредер, ахры, Йосыфыңны жигән»[2],—
диеп әйтә аңа алар жавап инде.
«Әгәр шулай,— диде Ягъкуб,— булган булса,
Йусефемне бүре һәлак кылган булса,
әгъзасыннан берәр нәрсә калган булса —
китерегез миңа аны табып инде!
Табыгыз, ди, кәфен сарып, гүр кылырмын,
өстенә бер нәкышләп бина корырмын,
үзем даимән Йусефка яр булырмын —
гомерем бакый аның өчен кичсен инде».
Жаваплары: «Йа, атакай, күп карадык,
унызбыз да ул тирәдән күп арадык[3],

[1] Аерылу, кавыша алмау
[2] Ашаган
[3] Эзләдек

әгъзасыннан бер һичнәрсә табалмадык —
бүре явыз барысын кабып киткән инде!»
Канлы күлмәк берсе куйныннан чыгарды,
алдына ук атасының китереп салды,
ачып-ачып күрсәттеләр аңа канны —
Ягъкуб күргәч, һуштан яза янә инде.
Исенә килеп, ул күлмәкне кулга алгач,
үбә-коча, елый-елый күп актаргач,
һич ертылган бер төшен дә табалмагач:
«Миһербан бер бүре ашаган...»— дия инде.
*«Йусефемнән мине аерып мәхрүм куйса,
умрып газиз тәннәрен ул канын эчсә,
һич ертмыйча күлмәкләрен бөтен куйса...—
монда берәр хикмәт бар»,— дип уйлый инде.
Әйтте: «Бу дип, сезнең явыз ниятегез,
сез бит миннән Йусефемне теләдегез,
алып илтеп анда һәлак иткәнегез —
ялган хәлдә елашасыз бит сез инде!
Ул бүрене барыгыз, эзләп табыгыз,
аны тотып минем алга китерегез,
ошбу сүзгә һичберегез карышмагыз —
бу әхвәлне без аңардан сорыйк инде!
Югыйсә, мин һәммәгезгә каргыш кылам,
сезгә бик зур афәт сорап, теләк кылам,
хак тәгалә кабул кыла барча догам —
мәзлумнәрнең догасы куркыныч инде!»
Моны ишетеп, алар дәррәү кузгалдылар,
тауда куып, бер бүре тотып алдылар,
аузын канга буяп, сөйрәп китерделәр:
«Шул бүредер, Йосыфыңа тигән инде».
Ягъкуб мескен ул бүрене күрде исә,
хәсрәт белән каршысына килде исә:
«Йусефемне, ник ашадың, кызганмыйча,
нигә ашадың, яшермичә әйт син инде?!
Йа, бүре, әйт: «Йусефемне нигә ашадың,
бөтен калган күлмәге, ничек ертмадың?
Ничек алай таңредән син курыкмадың —
пәйгамбәрне кайгыларга салдың инде!
Шул вакыт бүрегә хактан хәбәр килде,
«Исраилгә[4] хәлең әйт!» дип әмер кылды,
шул авыкта мескен бүре телгә килде —
әдәп-хөрмәт белән генә сөйләр инде.
«Валлаһи, ди, мин Йосыфны күргәнем юк,
һәм дә аның кайдалыгын белгәнем юк,
күкләр[5] шаһит, минем аңа тигәнем юк —
бу эштә мин гөнаһсызмын, белсәң инде!
Син үзең күкләр илчесе, пәйгамбәрсең,
олуглыклар иясе һәм аксакал син,
күкләр сиңа белдерер һәм белерсең —
пәйгамбәрләр ите безгә хәрам инде...
*Теләр исәң син боер, мин барыем,
ошбу җирнең бүреләрен мин җыйыем,
җыеп барсын каршыңа китерием —
хәзрәтеңә танык бирсен алар инде.
*Аларның да Йосыфны һич күргәне юк,
Йосыфка үч беркайчан да кылганы юк,
сезгә — оят, таңрегә — фетнә булганы юк:
пәйгамбәрләр ите безгә хәрам инде.

[4] Ягъкуб
[5] Ягъни: алла тәхете

Мин үзем дә Мисырдан тик яңа килдем,
бар иде бер имчәк чагам[6], аны җуйдым,
хәсрәтемнән авызым тәгам йотмас булдым —
ун җиде көн лөкъма[7] ризык капмам инде.
Гаҗиз итеп, бер тауда куып тоттылар,
үзләре үк борыныма кан сөрттеләр,
золым белән хозурыңа китерделәр —
гаебем юк, моны ачык белсәң инде!»
Аның сүзе хак икәнен Ягъкуб белде,
үз кулыннан ул бүрегә ризык бирде:
«Бу казаны җибәргәндер миңа тәңре».—
дип озатып калды, дога кылып инде.
«Бу казаларны җибәргән ходам-җабир[8],
газизләрне сабырсызлык итәр җәбер;
мин кыламын инде моңа күркәм сабыр —
сабыр белән морад хасил була инде.
Яһүдә исә ул япанга чыгар иде,
һәр көн барып, ул коега багар иде,
Йосыф белән хәбәрләшер, тыңлар иде —
һәм аңа да хәл-әхвәлне әйтеп инде.

[6] Бала
[7] Бер кисәк тә
[8] Каза бирүче



## IV бүлек. Дәгыйр углы Маликның төш күргәне

Мисырда бер бай сәүдәгәр яши икән,
аның исме Малик бине Дәгыйр икән,
Дәгыйр углы ул Малик бер төш күргән —
мәгънәсене юраучыдан сорый инде.
«Бу кичәдә, диеп аңа, бер төш күрдем,
төшемдә, имеш, Кәнганга[1] барыр идем,
Гад коесы тирәсендә йөрер идем —
шул чак кояш күктән җиргә иңде инде.
«Кояш төште — ачык күрдем — күктән иңеп,
куйныма кереп, якамнан чыкты килеп,
энҗе-мәрҗән яуды күктән явым кебек —
мин шуларны итәгемә җыям, имеш.
Сөенә-сөенә итәгемә җыям, имеш,
җыеп-җыеп сандыгыма куям, имеш,
шулай күрдем, һич гөмансыз, бу гаҗәп төш —
йа, тәгъбирче[2], моңа юрау бирче инде?!»
*«Әгәр разый булыйм дисәң юравыма,
килеп утыр,— ди юраучы,— уң ягыма,
ике кызыл алтын[3] һәм куй бу яныма —
төшеңне котлы-мөбарәк юрыйм инде.
Әгәр чын да шундый бер төш күргән булсаң,
ул төшеңдә син Кәнганга барган булсаң,
Гад коесы тирәсендә йөргән булсаң —
бер асыл кол синең кулыңа төшәр инде.
Ул колны бик очсыз гына алырсың син,
сатып аны бик күп нигъмәт табырсың син,
мөлкәт вә дәүләт иясе булырсың син —
шул сәбәптән күп бәрәкәт күренә инде.
Бу сәбәптән олуглыкка тиенәсең,
халыкның һәм берлегенә инанасың,
яңлыш мәзһәп[4] михнәтеннән чигенәсең —
дөнья-ахирәт дәүләте күренә инде».

*(Маликның Кәнганга сәфәрләре)*

Моны ишетеп Малик Дәгыйр сәфәр кылды,
кәрван белән Кәнган иленә килде-керде,
Гад коесы тирәсендә йөк төшерде —
ул төшендә күргән җирне эзли инде.
Колларына боеру белән таралдылар,
ул коеның тирә-юнен арадылар[5],
бөтен җиргә җәелеп актардылар —
Малик үзе һәр иңкелдән эзләр инде.
Эзләр иде, иңкүлектән аваз килде,
ул Маликның колагына ишетелде:
«Төгәл илле ел чынлыкта вакыт калды —
ул угланны алмага..» диеп инде.
«...Һич ким түгел, нәкъ илле ел көтеп торсаң,
аннан соңра бу урынга янә килсәң,
угланны аз бәһагә син алырсың —
сатып, асыл кыйммәтен белерсең инде».
Моны ишетеп Малик Дәгыйр тагын күчте,
аннары соң ул илле ел тәмам кичте,
Дәгыйр углы бу мәнзилгә[6] янә төште —
«Вәгъдә җитте!» диеп ул бик сөенер инде!
Бу коега фәрештәләр килгән иде,
кошлар кебек Йосыфка иш булган иде,
кое эченә һәммәсе җыелган иде —
алар очып чыга өер-өер инде.

[1] Палестина
[2] Төш юраучы
[3] Алтын акча
[4] Мәҗүсилеккә ишарә
[5] Ягъни аралап эзләделәр
[6] Тукталыш

Оча кошлар — Малик Дәгыйр үзе күрде,
фәрештәләр икәнен ул белмәс иде,
(ул чагында Малик әле мәҗүс[7] иде) —
кош атам дип, ук-җәя алып китә инде.
Якын килә — ул кошлар шунда югала,
исе китә, Малик Дәгыйр хәйран кала,
бакты исә — ул коедан нур тарала —
гаҗәпсенеп, ушы китеп тора инде.
Акылына-исенә ул шундук килә,
аңсыз түгел, чатырына йөгереп килә,
колларыннан икесенә әмер бирә:
«Шул коедан су алып килегез инде!»

*(Йосыфның коедан чыгарылуы)*

Бәшир[8], Бөшра[9] — икесе бер чиләк алып,
йөгерәләр коега таба җәһәт чабып,
төшерәләр чиләкләрен бәйләп салып —
Йосыф исә барсын күреп тора инде.
Икәү бергә ул чиләкне иңдергәндә,
мөлдерәмә булсын диеп тутырганда,
хак боера Җәбраилгә: «Тиз бар анда —
якты дөнья сөенчесен җиткер инде!»
«Йа, Йосыф,— ди,— син көзгегә бакканмы идең?
Күркең күреп, масаеп ук әйткәнме идең:
«Мин сатылыр кол булсам,— дигәнме идең,—
кем җиткерер минем бәһам!» диеп инде?
•Йосыф: «Әйе,— ди,— көзгедә бер күргән идем,
күреп күркөм, шул чагында әйткән идем:
«Әгәр булсам сатылыр кол,— дигән идем,—
минем бәһам кем җиткерер икән инде?»
«Вакыт җитте,— ди Җәбраил,— үзең хәзер
ни бәһагә сатылырсың, күзең күрер;
сатучылар, алучылар тора әзер —
үргән бауга нык ябышып чык син инде!»
Куәт белән икәү тарта Бәшир, Бөшра,
килеп ябыша бауга Йосыф һәм шул ара,
кадир мәүля язганына юктыр чара —
кем таркатсын?— аның хөкеме була инде!
Менә кое төпкеленнән чыгып килә,
тулган айдай нурлы йөзе туып килә,
Малик аны күреп исе-ушы китә:
«Йа, сөенеч, бу шул углан!» дия инде.
Ул Малик һәр вакытта әйтер иде,
колларына һәр даим сөйләр иде:
«Аны әүвәл кайсыгыз күрер исә —
азат итәм, шуңа кызым бирәм инде».
Бәшир килеп аңардан сөенеч алды,
Малик Дәгыйр бик куанып каршы барды,
шатлык белән Йосыфны кулына алды —
китереп аны әйбер ара яшерә инде.
Кардәшләре тауда көтү көтәр иде,
кәрван төшкән ул урынга — алар күрде,
бер-бер артлы йөгереп, ашыгып анда барды —
карасалар — коеда юк Йосыф инде.
Анда алар эшнең асылын аңлап ала,
алка итеп ул кәрванны чолгап ала:
«Монда безнең бер колыбыз качты, кана[10] —
шиксез аны, сез алгансыз!— диләр инде.

[7] Утка табынучы
[8] Сөенеч китерүче (исем)
[9] «Бәшир»нең күплек формасы
[10] Кая

«Бирсәгез бир,— диде Рауил,— миннәт белән[11],
югыйсә бер сөрән салам куәт белән,
һәлак була барчагыз да михнәт белән —
өнем ишеткән адәм җансыз кала инде!»
Малик — хәйлә иясе, ул саклык кылды,
Йосыфны шундук боларга кире бирде;
алар исә үз арада киңәш корды:
«Моны кол дип боларга сатыйк инде...»
Алар болай бу хәлдә гамәл иттеләр,
гыйбричәләп[12] Йосыфны нык кисәттеләр;
«Үтерербез югыйсә» дип өркеттеләр —
«Сине кол диеп сатарбыз, буйсын инде!»
Малик Дәгыйр зирәк иде, хәлне белде
(эчтән күңеле өмет-шатлык белән тулды),
алар — сатыр, ә ул сатып алыр булды —
Йосыф ишетеп, үксеп-үксеп елар инде.
«И кардәшләр, мине шулай сатармысез,
аерып ук чит җирләргә атармы сез,
үзегездән, йә миннән шик тотармы сез —
антлар эчәм, серегезне ачмыйм инде!
Сатмагыз ла, кяфер[13] колы булмас идем,
атабызны хәсрәтләргә салмас идем,
бәгыренә аерылу уты якмас идем —
ата-баба хөрмәтен саклагыз инде!?»
«Без сине,— дип әйтәләр,— зинһарладык,
атабызга «бүре ашады» дип алдадык,
Исраилгә[14] авыр сүзләр күп сөйләдек,—
Йа, Йосыф, син ул өметең ташла инде!»
Үгетләде аннары соң Яһүдә дә:
«Бу казаны биргән тәңре үзе сиңа,
болар бик нык тора, дип, явыз касдендә —
югыйсә бел, үтермәгәй алар инде...
Яхшырактыр — кабул күрсәң сатылуны,
бу усаллар фетнәсеннән котылуны,
хәсрәт белән Исраилдән аерылуны —
кавыштыручы кауштырыр алда инде».
*Әйтәләр: «Бу кол сатыла бүген сиңа,
шул шарт белән, сатар булсаң ерак җиргә,
инде күрик, нинди хак бирәсең безгә —
һич шиксез без сатачакбыз аны инде».
Малик сорый: «Углан колмы, йә әйтегез,
ни сәбәпле сатасыз, бәян итегез,
ни гаебе бар, нигә качты, тугры әйтегез —
акылы-күрке юкса сездән артык инде».
«Аны кече чакта атабыз сатып алды,
тора-тора безнең белән юлдаш булды,
тора-бара бу углан бик усалланды —
качып килеп, бу коега кергән инде!»
Малик әйтә: «Бар хәлләрен аныклагыз,
ничә төрле гаебе бар, таныклагыз,
монда һич бер шик вә шөбһә калдырмагыз —
шартын китереп, дөрес сәүдә кылыйк инде».
Алар әйтә: «Һичбер шик юк, углан колдыр,
колыбызның өч төрле гаебе бардыр:
кулы озын, ялганчы ул һәм качкындыр —
шул өч төрле гаебе белән алсаң инде».
«Ни диярсез, барысын да аңлыймын, ди,
асылында бу колны мин аламын, ди,

[11] Яхшылык белән
[12] Борынгы еврейчә
[13] Бу урында: потка табынучы
[14] Ягъкубка

гаебе берлән аны кабул кыламын,— ди,—
аңа нинди бәя алырсыз, белик инде.
Вә ләкин кулымда һич алтыным юк,
мал-туарым, комачым, һәм атласым күп,
бар бер кадәр ярмак акчам[15], кыйммәте юк —
ничек сәүдә кылышабыз?»— диер инде.
Йосыф уйлый: «Сәүдәләре уңмасайде,
кардәшләрем аз бәягә сатмасайде,
сәүдәгәр һәм зур бәягә алмасайде —
мескен үзем кол булмасам иде инде».
Болар әйтә: «Алай эш кыла алмабыз,
колыбыз өчен комач товар без алмабыз,
мондый сатуга һич риза булалмабыз —
күпме бирсәң дә, тик акча булсын инде!..»
Малик әйтә: «Ярмагым тик унсигез,— ди,—
алтыным юк, әйтәм чынлап, белегез,— ди,—
канигъ[16] булып әгәр шуңа күнсәгез,— ди,—
ә калганын миңа бүләк итеп инде».
Алар күнде: «Без унсигез ярмак алдык,
синең белән бу сатуны тәмам кылдык,
бу сәүдәгә барчабыз канәгать булдык —
ә калганын сиңа бүләк иттек инде».
Аннан Малик янә Йосыфтан сорашты:
«Болар сине, колыбыз дип, миңа сатты,
ошбу эшләр, ошбу сүзләр, расмы, хакмы?—
син таныклап, чын дөресен әйтсәң инде».
«Әйа, Йосыф, коллыкка син табигъ бул[17],— дип,—
телең белән раслап, үзең таныклык бир,— дип,—
«Юк» дидисәң — үтерербез, аның бел! — дип,
гыйбрәчәләп алар янап тора инде.
Йосыф каты янаулардан куркып калды,
ни чарадан бичара ул риза булды,
«колмын» диде, күзләреннән яшьләр акты —
нияте исә «тәңре колы» димәк иде.
«Йа, сәүдәгәр,— ди тегеләр,— моңа инан,
колның бу чак әйтүенә тотма гөман[18],
тик богавын чишә күрмә аягыннан —
Мисыргача ул богауда барсын инде.
Ялганчыдыр, һич сүзенә ышанмагыз,
аяп аны, миһербанлык һич кылмагыз,
аңа һичбер игелекле эш кылмагыз —
тамагына арпа икмәге җитәр инде».
«Сүзегезгә,— диде Малик,— мин ышанам,
колыгызны риза булып сатып алам,
шул өч төрле гаебе белән кабул кылам —
сәүдәбезгә тик бер язу кирәк инде».
Агалары ошбу сүзне хаклы күрде,
килешү язып бирүгә барсы күнде,
явыз эштә ахырынача бик нык торды —
кабала[19] язып кул куярга әзер инде.
Шәмгун үзе аны кулы белән язып,
һәммәсе дә имза куйды шәфкать өзеп,
кардәшлектән йөз дүндерде тәмам бизеп —
кол дип алар пәйгамбәрне сатты инде:
«Һәммәбез дә бу сәүдәгә риза булып,
унавыбыз — фәлән, фәлән... гакед[20] кылып,
колыбызны төгәнчә ярмакка биреп —
аны Малик Дәгыйргә тапшырдык инде».

[15] Көмеш я бакыр коелмадан ясалган
[16] Канәгать
[17] Буйсыну, ирексездән риза булу
[18] Бу очракта аңа шик тотма
[19] Коллыкка сату турында килешү
[20] Килешү язмасы

*(Йосыф агалары белән хушлаша)*

Йосыф моны ишетү белән кан-зар елый,
хәсрәт уты көйдерә эчен, бәгърен талый,
егълап-егълап хуҗасыннан рөхсәт тели —
«Боерсагыз, яннарына барыр идем...
Бирсәң рөхсәт яннарына мин барыем,
агаларымны туйганчы бер күрием,
языгымны кичерсеннәр, үтением —
бәхилләшеп айрылыек безләр инде!»
Маликның да моны иштеп бәгъре кайный,
аннан дәхи битәррәк ачынып елый,
бу эшләрен Йосыфның тик аңлый алмый —
бу хәлләргә гаҗәп-хәйран кала инде.
«Әй, бала,— дип Малик Дәгыйр җаваплады,—
күрмисеңме, алар сиңа ниләр кылды,
синең өчен бик тә очсыз бәһа алды:
ник барасың, алар сине сөйми инде.
Сатты алар сине бигрәк ким ярмакка,
теләкләре анык — синнән аерылмакка,
лаек түгел алар янына син бармакка —
хөрмәтең һәммәбездән артык инде».
Арзан иде ул чак бәясе ярмакның:
мең дә дүрт йөз ярмакка тиң берәр алтын —
шундый очсыз бәягә генә алганын
ачык итеп ул Йосыфка әйтә инде.
Аңа Йосыф елый-елый җавап бирде:
«Алар шулай эшләмәгә савап[21] күрде,
теләкләре, морадлары шулай иде —
һәр бер кеше үз лаегын эшли инде».
Аннан Малик Йосыфка рөхсәт бирә,
мескен Йосыф хәсрәт илә кире йөгерә,
ун карендәш барысы тора аягүрә —
һәр бересен үбә-коча егълый инде.
«Бизар[22] булып, миннән тәмам туйдыгызмы,
оҗмах биреп, тәмуг сатып алдыгызмы,
газиз атамнан мәңге аердыгызмы —
кавышулар, аһ, бик ерак калды инде!
Аһ, аяныч: газиз идем, бетте кадрем,
кардәшләрдән ничек дошманлыклар күрдем;
абау аллам, әткәемне мәхрүм куйдым —
егълый-егълый ике күзе күрмәс инде.
Моннан соңра миңа тәрбия кем итәсе,
елар исәм күз яшьләрем кем сөртәсе,
хәсрәт килсә, миңа кемнәр иш буласы —
өстем-башым, киемем кем юар инде!?
Озын чәчем тарый-тарый кемнәр үрер,
карыным ачмы, ялангачмы — кемнәр белер,
ахырында бу хәсрәтем кем китәрер —
азат башым коллыкка мин төштем инде?!.
Атам мине иңнәренә алыр иде,
йокым килсә, ястыкларга салыр иде,
уянды исәм төрле ризык бирер иде —
мул нигъмәттән бу михнәткә төштем инде!..
Аһ, коллыкта инде ничек хезмәт кылам,
даим кяфер кулы астында ничек торам,
агаларым, инде сезне кайда күрәм?—
аерылырга безгә тәкъдир җитте инде!

[21] Биредә: кулай
[22] Тарсыну, тар күңел

Бу язмышны тәңредән дип белмәк кирәк,
хак хөкеменә коллар риза булмак кирәк,
җәзасыны тәмам өскә алмак кирәк —
казасына ахырынача түзәм инде».
Ярлы Йосыф күзләреннән кан-яшь ага,
аерылалмый, кардәшләрен үбә-коча,
һәр кайсына дога кылып саубуллаша —
Малик Дәгыйр түнә-түнә егълый инде.
Кардәшләре моны күреп егълаштылар,
яман олы хәсрәт белән аһлаштылар —
зари кылып, үкенепләр иңрәштеләр —
эшләреннән пошаманга төшеп инде.
«Аһ, сине без кире өйгә илтәр идек,
кулың алып, барча тәүбә итәр идек,
сәүдәбезне дәхи инкяр итәр идек —
атабыздан гарьләнмәсәк»,— диләр инде.
«Атабызга һаман ялган әйтә алмыйбыз,
Исраилгә сине кире илтә алмыйбыз,
ошбу эшкә бүтән чара итә алмыйбыз —
бу михнәткә сиңа түзмәк кирәк инде!»
Диде Йосыф: «Әйткән сүз һич кире кайтмас,
хак язмышы ничек икән, кеше белмәс,
монда хәзер кол чарасы дөрес булмас —
фәрманына риза булмак кирәк инде.
Бу тәкъдир тәңремнәндер, белегез мәгълүм,
эткәм Ягъкуб хәсрәт йотып калды мәхрүм,
гафил калды кече энем Ибне-Ямин —
моннан ары мине кайда күрер инде?!»
Айрылышып кардәшләре китте ерак,
(ошбу эштә алар булды каты йөрәк),
Йосыф мескен калды бер ялгызы елап —
елый-елый борылып артка карый инде.

*(Ана кабере янында)*

Тотып алып тупас кием кидерделәр,
палас бөркәп, бер дөягә мендерделәр,
кулын бәйләп, бик нык итеп беркеттеләр —
«Бушанып кача күрмәсен!» диләр инде.
Бер хәбәши[23] кол бар иде Кылыч атлы:
хезмәтчеләр арасында иң гайрәтле,
кара йөзле, усал, каты сәясәтле[24] —
тапшырдылар Йосыфны шул колга инде.
Озак тормый кәрван аннан китте-күчте,
бер каберлек кырыеннан үтә-кичте,
Йосыф бер кабер янына егълап төште —
ул анасы Рәхиләнең гүре инде.
Зар елады: «Әйа, анам, Рәхилме син,
минем хәлем ничеклеген үзең күр син,
сатты мине агаларым, анык бел син —
азат башым бу коллыкка төштем инде.
Хәсәд[25] кылып, мине атамнан аердылар,
аерылу уты бәгъремә яндырдылар,
гидай туны иңнәремә каердылар[26] —
кул-аягым зынҗыр[27] белән баглы инде.
Кардәшләрем кылды миңа рәнҗү-зәхмәт,
кечеклектән төште ничек ошбу михнәт,
тәңрем генә игелек итеп кылса шәфкать —
бар өметем сөбханыма[28] гына инде.

[23] Абиссиниле
[24] Биредә: каты куллы
[25] Үчлек
[26] Ягъни: чит-ят җирләрдә каңгырып йөрергә мәҗбүр итү
[27] Богау
[28] Алла

Йә, энкәем, минем хәлем күрсәң ахыр,
коллыкларга сатып алды мине кяфер,
бу тәкъдирне кылды миңа мәүлям гафур[29] —
мәгәр янә ул ук рәхим кылса инде!
Абау алла, газиз анам, син гүреңдә,
күрәсеңме, газиз балаң ни хәлендә,
беләсеңме, углың хода ярдәмендә —
аяклары-куллары богаулы инде.
Анасының кабереннән аваз килде:
«Йа, Йусефем, хәлең ничек болай булды,
кардәшләрең бу җәфаны нидән кылды —
ничек гафил[30] бу бәлагә төштең инде?
Җаным-углым, бу җәфага нидән калдың,
сиңа залим булганнарга ни эш кылдың,
гүр өстемә бу хәлеңдә ничек килдең —
җаннарымны парә-парә телдең инде!
Атаң Ягъкуб бу әхвәлне белмәдеме,
ул зәгыйфькә хәлең мәгълүм булмадымы,
Ибне-Ямин синең белән килмәдеме —
ничек гафил бу бәлагә калдың инде?
* Балакаем — атаң Ягъкуб, бабаң Исхак,
ата-бабаң тугры рәсүл[31] булды һәр чак[32],
син дә аның шәфкатенә лаексың хак —
өмет өзмә, шатлыклы көн җитәр инде».
«Йа хода,— ди,— бу хаҗәтем сиңа мәгълүм,
өмет тота сиңа даим барча мәзлүм,
залимнәргә дучар булган минем углым —
мәрхәмәтең белән үзең коткар инде?!»
Анасының сүзен ишетеп, һушсыз калды;
тәңре Рәхил теләген кабул кылды,
мөнаҗәте[33] Йосыфка ахыр тугры килде —
таҗ-тәхетле, солтанәтле[34] булды инде.

*(Кылыч Йосыфка золым итә)*

Кылыч бакты: Йосыф һич күренмәгәч,
ары чабып, бире чабып табалмагач,
үзе генә эзләп алып киләлмәгәч —
хуҗасына әхвәлне белдерә инде.
«Әй, хуҗам,— дип өн сала,— туктасын кәрван!
Ай-вай ла,— ди,— качып киткән ул кол углан».
Бөтенесе туктап кала, шул арадан
кәрван халкы Йосыфны эзлиләр инде.
Кылыч шундук аргамак ат менеп китте,
тизрәк ул һәммәсеннән килеп җитте,
җитү белән Йосыфка бик каты сукты:
«Нигә качтың?— качмассыңмы?!»— диеп инде (...)
«Йа, илаһым,— ди Йосыф,— мин ни кылыем,
бу михнәттән инде ничек котылыем,
бу залимнән котылу өчен, йа ходаем,
ниләр итим — кодрәтеңлә коткар инде!
Ходәвәндәм, әгәр хата кылган булсам,
әмереңне куеп, сиңа гыйсъян[35] кылган булсам,
атам-бабам хезмәтеннән калган булсам —
бик үкенәм, тәүбә итәм сиңа инде.
Әгәр сиңа асла гыйсъянчы булмасам,
гаепләрдән, хаталардан азат булсам,
бер гөнаһсыз бу җәфага төшкән булсам —
бу кавемгә бер галәмәт[36] күрсәт инде?!»

[29] Гафу итүче
[30] Белмәстән, искәрмәстән
[31] Алла илчесе
[32] Ибраһимның хәтта олы улы Исмәгыйлне алла өчен корбан итәргә дә әзер торуына ишарә
[33] Биредә: дога, ялвару
[34] Зур дәрәҗәле
[35] Буйсынмау, баш күтәрү
[36] Биредә: гаҗәеп билге

* Кылыч шулчак Йосыфны алып килде,
алып килеп хуҗасына аны бирде,
Малик төшеп аттан янә зынҗырлады —
кат-кат бәйләп, дөя өстенә атты инде.

*(Туфан вакыйгасы)*

Хак тәңредән шул чагында әмер була,
кодрәт белән күктә кара болыт куба,
җилләр исә, карлы-бозлы яңгыр килә —
яман каты дәһшәт белән ява инде.
Башларына тиде исә — яра итә,
тәннәренә тиде исә — гарип итә,
кычкырына һәммәсе дә, фөрьяд [37] итә —
һич кем кая сыеныр урын тапмый инде.
Һич бер кеше берсен-берсе күрмәс булды,
дөм караңгы — һәммәсе таң катып калды,
күк күкрәп, яшен-елдырым каты орды —
моны күреп, Малик дер-дер тетри инде:
«Аһ, хәлебез нидән икән булды вәйран [38],
ярабби, нидән купты ошбу туфан?
Арабызда бардыр, ахры, бер мәзлүм [39] җан —
һәрберебез телик гафу аннан инде.
Ахры, кемдер бездән золым-җәбер күргән,
ул мәзлүмнең аһ-теләге күккә ашкан,
гареш иясе [40] безгә каты каһәр кылган —
тәүбә итегез, юкса һәлак булдык инде».
Шул арада әлеге Кылыч хәзер килде,
үзе танып хатасын ул икърар кылды:
«Суккан идем бая ул гыйбри угланны [41] —
миннәндер бу гөнаһ, мәгълүм булсын инде».
Малик хуҗа боерды ул кара колга:
«Бар Йосыфның аягын үп, гозер телә,
йомшат күңлен яхшы-ару сүзең илә —
безгә изге дога кылсын зинһар инде!»
Каршысына Йосыфның ул Кылыч килде,
елый-елый аңа гаять зарый кылды,
хата-гөнаһ итүләрен икърар кылды —
башын орып Йосыф аягын үбәр инде.
Малик үзе аның белән бергә барды,
тезен чүгеп, хезмәтенә кул кушырды,
зарый кылып, ул Йосыфка күп ялварды:
«Хата — бездә, кичерсәнә!» диеп инде.
Моны күреп Йосыфның да күңле тулды,
шул авыктук кул күтәреп дога кылды,
догасы һәм тәңресенә кабул булды —
җилләр кимеп, кар-яңгырлар бетәр инде. (...)
Моны күргәч, Малик гыйбрәт алып төште,
Йосыфның ул бау-богавын барып чишсте,
хуҗа-коллар һәр берсе ялварышты —
һәммәсеннән артык Малик үтенә инде.
Паласларын салдырып ул тун [42] кидерде,
дөясеннән төшереп яхшы ат мендерде,
олысына-кечесенә нык белдерде:
«Хода шаһит — кәрван Йосыфныкы инде!
Сез җөмләгез тик Йосыфка буй сонасыз,
карт-яшегез бердәй үк хезмәт кыласыз,
моннан ары башлык дип аны беләсез —
һаман аның әмереннән чыкмагыз инде!»

[37] Аһ килеп, ярдәмгә чакыру
[38] Харап, начар
[39] Җәберләнгән
[40] Тәңре
[41] Еврей малае
[42] Өс киеме

Аннан соңра Йосыф хөкеме [43] булды фәрман,
зур дәрәҗә бирде аңа тәңре сөбхан,
һичбер кеше чыкмас булды әмереннән —
Малик Дәгыйр үзе төшеп эшләр инде.
Сөйләгән саен Йосыфның фәһме арта,
сүзе — татлы, өне — ачык, гакылы арта,
йөзен ачса, җиһан эчен нур балкыта —
үзен күргән җәмаленә туймас иде.

*(Потка табынучылар шәһәрендә)*

Аннан үтеп бер шәһәргә алар керде,
шәһәр әһле җөмләсе тик мәҗүс [44] иде,
алар анда ул Йосыфның күркен күрде —
һәммәсе дә таң-гаҗәпкә кала инде.
Барысы аның янына җыелышалар,
хак сәнгатен [45], Йосыф күркен таңлашалар,
бик күп сүзләр аның белән сөйләшәләр —
хәл вә әхвәл аңардан сорап инде.
«Әйтсәңче, дип, сине болай кем яратты,
мондаен ла күрекле җәмал кем төзәтте,
йөзләреңә бу нәкышләр кем бизәтте?—
ул остага без дә табыныр идек инде!»
«Яраткан кем мине, диде, халикдыр ул,
колларына күктә, җирдә азык бирер,
бар галәмне туйдыручы маликдер [46] ул —
сезне, безне ул яраткан, белегез инде».
Йосыф сүзе хаклыгына инандылар,
һәммәсе дә бер тәңрегә табындылар,
пәйгамбәр дип Йосыфны һәм таныдылар —
ихлас мөэмин [47] булып калды болар инде.
Аннан күчеп, үзгә шәһәргә керделәр,
кала әһле Йосыфның күркен күрделәр,
күреп күркен аңа, охшаш бер сурәт кылдылар —
шул сурәткә табынырга барсы инде.

*(Кодес шәһәрендә)*

Аннан алар Кодес [48] шәһәренә килде,
шәһәр бәге төшендә үк күргән иде,
күреп шәһәр әһленә ул дигән иде:
«Кәрван килә, чыгып каршы алыйк инде!»
Кодес бәге гаскәр төзеп, каршы барды,
«Бу кәрванның башлыгы кем?»— дип сорады,
кәрванчылар җөмләсе бер җавап бирде:
«Безнең бәгебез Малик Дәгыйр!»— диеп инде.
Кодес бәге уйлый хәлне, исе китә:
«Һәр ел, диеп, бу сәүдәгәр моннан үтә,
бу кәрванның быел ни хикмәте икән —
каршы алырга нигә фәрман булды инде?»
Йосыфны ул күреп ала, якын килә,
хөрмәт белән башын иеп сәлам бирә,
Йосыфтан ул сорый хәлен әдәп илә —
«Кем икәнең безгә мәгълүм итсәң инде?»
Йосыф аңа болай диеп җавап бирде:
«Мин улдыр ки, сиңа төштә белдерелде,
каршы алып, хезмәт кыл дип боерылды —
һич гөмансыз мин шул кеше!»— диер инде.
Бу сүзләрне ишетәрәк таңга кала,
Йосыфны ул мәҗлескә чакырып ала,

[43] Киңәш-фикерләре
[44] Күп аллага табынучы
[45] Биредә илаһи иҗат
[46] Ия, хуҗа
[47] Иман китергән кеше
[48] Иерусалим

юлдашлары белән бергә кунак кыла —
газиз күреп, кадер-хөрмәт итә инде.
Әңгәмәдә әйтә ул бәк: «Ни диярсең,
ниндәй миңа үгет-нәсихәт кылырсың,
әйа, Йосыф, миңа ниләр боерырсың —
син боерсаң, ә мин аны кылсам инде!»
Йосыф әйтә: «Алай исә сүзем тыңла,
үгетемне тотып, кер син тугры юлга,
синдәй бәккә нигә потка табынырга —
мөэмин бул да санәмнәрне ташла инде!»
Кодес бәге: «Ошбу сүзең кабул кылам,
ул син әйткән бер тәңрегә мин буйсынам,
хак пәйгамбәр диеп инде сине белəм —
потханәгә [49] вә ләкин бер керик инде!
Әгәр санәм сиңа түнеп сәҗдә кылса,
карап сиңа җавап сөйләп, икърар кылса,
хак пәйгамбәр диеп сине ул таныса —
һичбер шиксез, мөэмин булам»,— дия инде.
Йосыф күнде: «Мин ризамын, әйдә барыйк,
әүвәл без потханәгә кереп карыйк,
санәм хален-әхвәлен без сорап белик —
күрик әле, ничек җавап бирер икән?..»
Йосыф белән потханәгә ул бәк керде,
керү белән Йосыфны ул санәм күрде,
тибрәнеп ул Йосыфка сәлам бирде:
«Чын хакыйкать — син пәйгамбәр!»— диеп инде.
Әлеге санәм Йосыфка сәҗдә кылды,
моны күреп Кодес бәге әхвәл белде,
берлегенә тәңренең ул икърар кылды —
мөэмин булып, билдән зөннар [50] чишә иде.
Кодес бәге Йосыфны шәп кунак итте,
асыл халат, йөгерек ат бүләк итте,
алтынлаган кушак [51] биленә бәйләтте —
гыйззәтләве, хөрмәтләве арта инде.
Алдына төрле нигъмәт аш китерде,
кулын сонып, берәр кабым Йосыф җиде [52],
өч йөз туксан кеше ашап-эчеп туйды —
нигъмәтләре һич кимеми калды инде.
Аннан әйтә Кодес бәге ул маликка:
«Бу кол безгә лаек булыр рәислеккә,
кол димәгез моның кебек хөрмәтлегә —
ни кадәрле акылы бездән өстен инде!»
Дәгыйр углы Малик бәккә җавап бирде:
«Әйе, безнең юлбашчыбыз Йосыф,— диде,—
рәислеккә ул миннән дә лаек,— диде,—
ә мин аның коллыгына әзер инде»...

*(Куа чыгучыларны җиңгәч, Йосыф масая)*

Кузгалдылар — кәрван янә керде юлга,
шунда гына Кодес бәге килде аңга:
«Ул углан, ди, китте бездән, чыгыйк куа —
куып җитик, кулларыннан алыйк инде!»
Атка менеп ун ике мең ир киттеләр,
ул угланны алабыз дип ант иттеләр;
«Ай, Йосыф,— ди Малик күреп,— җитә болар!»
Йосыф аңа: «Һич курыкма!» дия инде.
Кайчан гаскәр ул кәрванга якынайды,
Йосыф борылып, аларга бер караш салды,

[49] Мәҗүсиләр гыйбадәтханәсе
[50] Чуклы билбау
[51] Алтын-көмеш белән зиннәтләнгән билбау
[52] Ашады, капты

бер караудан һәммәсе дә һушсыз калды —
һуштан язып аттан түнеп төште инде.
Унике мең кеше барысы авып төште,
һәммәсенең ушы китеп, акылы шашты,
кәрван күчте — ул арада өч көн кичте —
алар һаман айный алмый ята инде.
Кәрван халкы күреп моны хәйран кала —
Йосыф күңлен бераз горур биләп ала,
(мәгъруриять мәйданында гизеп ала):
«Миңа тиңдәш беркем юктыр»,— диеп инде.
Шул ук сәгать ул Җәбраил килде хазер,
җибәргәндер Йосыфка аны мәүля кадир [53]:
«Ничек болай әйтә алдың, әй, Йосыф,— дияр,—
масайдың син — тәңре сәнгатен күр инде!»
Өченче көн кәрван бер шәһәргә керде,
шәһәр халкы һәммәсе дә пәри [54] иде,
кайчан Йосыф пәриләрнең йөзен күрде —
һәр бересе Йосыфтан да күркәм инде.
Кол уйлаган һәр үк вакыт туры килми,
бу шәһәрдә Йосыф күркен һичкем күрми,
һич бересе йөзен багып гаҗәпсенми —
һәммәсе дә Йосыфтан күп күркәм инде.
Һәр берсенең йөзе Йосыфтан күп нурлы:
ул зифа буй, якты чырай төрле-төрле,
көллесенең [55] гакылы камил, үзе гарьле —
моны күреп Йосыф боегып йөри инде.
Халикыннан аңа шундый вәхи [56] килде:
«Кодрәтемне күр, Йосыф!— дип ишетелде,—
күркең белән масаюдан дүн син инде —
хакыйкатьтә күрек бирүче мин бит инде!»
Йосыф белгәч, бу әхвәлнең асылын анык,
дип: «Масаю, мин-минлекләр бик зур язык»,
сәҗдә итте тәңресенә зарый кылып —
«Тәүбә тәүбә!»— дип үтенә аңа инде.
Аңа тәңре янә булыш-ярдәм кыла,
Йосыфның ул күркәмлеген кире бирә,
Эчке-тышкы сөйкемлеген бергә үрә —
«Әйа, Йосыф, башың күтәр!»— дия инде.

*(Нил елгасы буенда)*

Анда кәрван ул шәһәрдән үтә киткәч,
бара-бара Мисырга бик якын җиткәч,
Нил ермагы кырыена алар төшкәч —
Малик Дәгыйр Йосыфка ялына инде:
«Йа, Йосыф,— дип әйтә аңа,— барсаң иде,
Нил елгасын, менә инде, күрсәң иде,
киңәшемне тотып, суына керсәң иде —
тәннәреңнән юл тузаны китсен инде!»
Хуҗасының әмерен Йосыф кулай күрде,
Нил елгасы ярына ул якын килде,
кул күтәреп халикына дога кылды —
«Кодрәтеңлә бер пәрдә бир»,— диеп инде.
Шул сәгатьтә теләгәне кабул була,
су өстендә бер гөмбәз һәм пәйда була,
кереп гөмбәзнең эченә су коена —
буен-тәнен һич бер мәхлук күрми инде.
Анда бер бик олы балык яшәр иде,
ул судагы балыкларга әмер бирде,

[53] Кодрәтле алла
[54] Биредә чибәр җан иясе
[55] Барысы
[56] Имеш, алладан күңелгә, телгә фикер килү

«Хакның тугры илчесе,— дип,— суга керде —
әдәп саклап, аңа күз салмагыз инде!»
Моны ишетеп балык халкы барсы качты:
оялылар оясынук кереп ятты,
һичбер кайсы Йосыфка күз атмады —
һәммәсе аның хөрмәтен саклап инде.
Әлеге балык Йосыфка янә килеп,
үз хезмәтен аңа янә тәкъдим кылып,
ул балыкның аркасына Йосыф менеп —
утырып ук ул юына анда инде.
Ул балыкка утырган да Йосыф коена,
нуры балкый, мең мәртәбә артык була,
шул сәгать үк Җәбраил дә хазер килә —
хак сәламен, хөллә тунын китерә инде.
Йосыф тәмам юынып ук бетергәндә,
аруланып, пакьләнеп чыгып килгәндә,
ап-ак киенеп, шатлык күңелен тутырганда —
балык аңа үтенечен әйтә инде.
Шунда әйтә ул үтенеч сүзен балык:
«Бирде миңа,— дип,— халикым бик күп байлык,
бирде миңа, рәхим кылып, солтанәтлек —
барча балыклар патшасы итте инде.
Солтаны мин балыкларның, дәүләтлемен,
һаман да тик бер теләктә хәсрәтлемен,
бала өчен, әй Йосыф, мин мохтаҗ бүген —
минем өчен син бер дога кылсаң иде!
Яраткучы синең сүзең кабул кылыр,
кодрәте илә миңа угыл рузи кылыр [57],
балам миңа соңында күп дога кылыр —
үлә калсам минем өчен»,— дия инде.
Йосыф шунда кул күтәреп дога кыла,
халик аның теләгәнен кабул кыла:
ул балыкның соңра ике углы була —
икәве дә дәүләт иясе булган инде.
Риваятьтә [58] кәрамәтле икесе дә:
берсе саклап Юнысны ул йоткан, диләр,
икенчесе шул йөзекне тапкан, диләр —
ул Сөләйман йөзеге дип мәшһүр [59] инде.
• Йосыф ошбу балык белән саубуллашып,
аерылышты, икесе дә бәхилләшеп,
төпкә төшеп китте балык та хушлашып —
һәм дә Йосыф кәрван таба кайта инде.
Йосыф нәби кайтып килә, шат вә күркәм,
йөзе балкый иңендәге ак киемнән,
нуры арткан меңәр кабат элеккедән —
нурдан терәк җирдән күккә аша инде.
Аның кайтып килгәнлеген Малик күрде,
колларына шул заман ул әмер бирде,
сандыгыннан җитмеш төрле тун чыгарды —
Йосыф кисен дип әзерләп куя инде!
Малик Дәгъйр үзе каршы ала барды,
Йосыф иңендә бик асыл кием күрде,
«Кем кидерде моны?»— диеп сорау бирде —
тотып карый, гаҗәп-таңга калып инде.
Йосыф әйтә: «Мәүлям бирде бу хәлгәтне [60],
бүләк кылды иям миңа бу дәүләтне,
аннан таптым янә мин бу рәхәтне —
минем серемне ул анык белә инде».

[57] Бүләк итә
[58] Легендар
[59] Риваятьләргә ишарә
[60] Аеруча хөрмәт билгесе итеп, патшалар үз иңеннән салып бирә торган кием

*(Кәрван Мисырга керә)*

Ул урыннан кәрван күчеп тагын китте,
Мисырга [61] ул бер куныш җир якын җитте,
Мисыр халкы һавадан бер өн ишетте:
«Мисырга бер газиз шәхес килә инде!
Кәрванчының сараена сез килергә,
тырышыгыз ул угланны бер күрергә,
ул охшашлы күкләрдәге фәрештәгә —
адәмидән һич тиңдәш юк аңа инде.
Аның килүе сезнең өчен булыр котлы,
гакылы камил, әйткән сүзе гаять татлы,
үзе гарьле, хуш холыклы, асылы затлы —
ашыгыгыз аны күрү өчен инде!»
Мисыр халкы моны ишеткәч сөенешеп,
һәр кайсысы җәһәт-җәһәт җыенышып,
олы-кече, ир вә хатын җыелышып —
һәр бересе каршы чыгып карый инде.
Кәрван илә атлы гаскәрләр дә килә,
алар һәммә — фәрештәләр, күктән иңә,
«Йосыфка иш булсын» диеп тәңре бирә —
Мисыр халкы бу килешне [62] күрә инде.
* Сафларында килә Йосыф хөллә киеп,
йөзләреннән тирә-юньгә нурлар сибеп,
озаталар шулай зурлап, хөрмәт итеп —
мәһабәте һәммәсеннән артык инде.
Мисыр халкы аны күреп калды хәйран,
«Бу түгелдер,— диешәләр,— адәмидән,
бу, мөгаен, фәрештәдер күктән иңгән»,—
диеп барысы аңа сәҗдә кыла инде.
Кайчан кәрван Мисырга ук килеп керде,
Йосыф исе белән шәһәр эче тулды,
шәраб-тәгам бик ләззәтле, тәмле булды —
төрле әйбер гамбәр [63] кеби аңкый инде.

*(Йосыф — сәүдәгәрнең сараенда)*

Малик Дәгыйр сараенда калу белән,
Йосыф кереп, анда урын алу белән,
йөзен ачып, пәрдәсен салу белән —
сарайдан нур тышка балкып чыга инде.
Моны күреп мисырлылар җыелдылар,
кәрванчының сараена агылдылар,
теләкләрен ул Маликка әйтә болар:
«Колыгызны бер күриек!» диләр инде.
«Ул морадка,— диде Малик,— ирешмәссез,
сараема сез минем һич керәлмәссез,
ул Йосыфның гүзәллеген күрәлмәссез —
бирмиенчә һәркем берәр динар инде».
Рази булып, берәр динар китерделәр,
рөхсәт алып, сарай эченә керделәр,
Йосыф йөзен, ниһаять, алар күрделәр —
тик бер күргән җәмаленә [64] туймас иде.
Икенче көн Мисыр халкы тагын килде,
һәр кайсысы икешәр алтын алып килде,
Йосыф йөзен күрергә дип арзу кылды [65]—
күргән бере гаҗәп-хәйран булыр инде.
Өченче көн, дүртенче көн, бишенче көн —
арттыралар һәр көн саен берәр алтын,

[61] Биредә: Мисырның үзәк шәһәре
[62] Ягъни: тантаналы процессия
[63] Хуш исле май
[64] Гүзәллегенә, чибәрлегенә
[65] Теләк белдерде

теләкләре Йосыфны бер күрү өчен —
күргән барыбер багып күңле туймас инде.
Шулай итеп, инде унынчы көн килде,
һәр кайсысы унар алтын ул көн бирде,
олы-кече һәммәсе дә аны күрде —
күргән берсе истән авып төшәр инде.
Кайберләре тышкы сурәтен хуш күрде,
кайберләре эчке хасиятен хис кылды,
кайберләре рәсүллеген бик хуп белде —
һәрбер төркем үзенчә юш күрер инде.
Сурәтен хуш күргән — малын фида кыла,
холкын хуп күргәне — җанын фида кыла,
егерме мең адәм анда шаһит була —
рәсүллеген күргән иман китерә инде.

*(Йосыфның базарда сатылуы)*

Әүвәл тәңре боерганы анык килде:
Малик Дәгыйр ул Йосыфны алып килде,
алтыннан бер көрси анда хәзер кылды —
Йосыф килеп шул көрсигә утыра инде.
Өндәүчеләр тирә-якка кычкыралар:
«Бу угланны әй, кем сатып алыр?— диләр,—
— Кемдер моның чын кыйммәтен белер?— диләр,
— Кем бәһасен җиткерсә, шул алсын инде!»
Ишетеп моны, Мисыр халкы барсы килде,
олы-кече, бай-фәкыйре хазер булды,
хәлвәчеләр, икмәкчеләр өмет кылды —
һәр берсе: «Һай, мин алсам!»— дия инде.
Ә бер карчык киләпле җеп алып килгән
(алыр өченме Йосыфны әллә килгән,
күрер өченме ул шундый хәйлә корган) —
сәбәбе бар: ул Йосыфны күргән инде.
Риваять бар: бер кыз анда килгән имеш,
исеме Бинте-Табиюн [66] аңа диләр имеш,
бу хәбәрне ул да ишетеп белгән имеш —
«Алып кайтам Йосыфны»,— дип киткән инде.
Мең дөялек кәрванына мал йөкләнгән,
һәм кол-кәнизәкләрен дә ат мендергән,
һәр берсенә затлы-асыл кием кидергән —
башларында җәүһәрле тадж-чалма инде.
Шул рәвештә ул Мисырга килә-керә,
Йосыф йөзен күрә ул үз күзе илә,
хәйран була, рәсүллек нурын күрә —
хак сәнгатен [67], рәсүл күркен данлый инде.
Һәм сораша Йосыфтан: «Нинди углан син?
Белеп торам, син чынлыктан кол түгелсең,
нәселең кем, әйтче миңа, кем углы син —
кайсы солтан баласы син, әйтсәң инде?!
Тиеш түгел мондый хәлдә син калырга,
муафыйк түгел һич тә кол дип сатылырга,
лаек түгел һичбер кем сине алырга —
кем җиткерсен чын бәһаңне синең инде?!
Нидән болай кайгың бик күп, күңелең тар,
иш булгандыр зур хәсрәтләр сиңа, и яр,
әйтче миңа, бу арада ни хикмәт бар —
әхвәлеңне бәян итеп белдер инде?!
Җиһанда һич синдәй адәм булганы юк,
сиңа охшар һичбер задә [68] туганы юк,

[66] Ягъни Табиюн кызы (табигун — буйсынган халык)
[67] Биредә кодрәт
[68] Дәрәҗәле кеше баласы

син сыйфатлы һичбер кеше булганы юк —
әллә син бер фәрештәме!?»— дия инде.
«Сине ишетеп, илемнән дә мин айрылдым,
күрим, алыйм дип ашыгып монда килдем,
барча малым синең өчен фида кылдым —
вә ләкин бәя җиткерә алмам инде!»
Йосыф аның сүзләренә җавап бирде
(ишеткәннәр һәркем хәйран калыр иде),
күзләренә энҗе кебек яшьләр килде —
күркәм телдән саф сүзләрен сөйли инде.
Әйтер: «Минем хәлемне халик [69] белер,
аның хөкеме колларына лаек торыр,
ни кылса да, ул кылганы лаек булыр —
бу тәкъдирне миңа да ул кылды инде.
Кодрәт белән мине болай ул яратты,
күркәм буй-сын минем өчен ул ясатты,
ул һәм бирде минем өскә бу афәтне —
аның хөкемен һичкем ега алмас инде.
Әгәр кол кирәк икән, син сатып ал,
күпме лаек, шул бәһалек бирерсең мал,
мәгәр малың җитми икән, бу эштән кал —
бу хәлемнең тәфсыйлен сорама инде!»
Моны ишетеп Йосыфның уң кулын алды,
инанып һәм бер тәңрегә күңлен салды,
Йосыф аңа мөселманлык игълан кылды —
кыз үз теле белән иман китерә инде.
Кадир мәүля ошбу кызны ярлыкады,
ул кыз малын дәрвишләргә [70] багышлады,
тәгат кылды [71], дөньялыкка катышмады —
калган гомре мәгарәдә [72] узды инде.

[69] Алла
[70] Ярлы-гидайларга
[71] Буйсынып дога кылу
[72] Гыйбадәтханә



## V бүлек. Зөләйха турында хикәят

Колак тотып тыңлагыз сез ошбу сүзне,
ул Зөләйха — маликзадә [1], Тәймус кызы,
тулган айдай балкыр иде аның йөзе —
оҗмахтагы хур кызына охшар инде.
Тәймус ул Мәгърип [2] иясе, патша иде,
гаскәрләре йөз мең ирдән арта иде,
күк тәңресе бик зур байлык аңа бирде —
дөньяда зур патшалардан берсе инде.
Җир йөзенең күп байлыгы анда икән,
шул хәлдә дә үзе потка табына икән [3],
бердәнбер газиз кызы Зөләйха икән —
хикәятнең асылы шул, аңла инде.
Ул Зөләйха Тәймус малик кызы икән,
ястыгы һәм атасының тезе икән,
беркөн Йосыф сурәтен ул төштә күргән —
чын хакыйкать диеп аны белгән инде.
Ничек Ягъкуб Йосыфын бик сөяр иде,
Йосыф аның итәгеннән китмәс иде,
Зөләйха да атасына шулай иде —
бәлки тагы да артыграк сөяр инде.
Зөләйха бер көн ятып йоклый икән,
Ул Йосыфның сурәтен төшендә күргән,
күрү белән шул мәлдә үк гашыйк булган —
уянуга үксеп-елап килә инде.
«Йа, кызым,— дип сорый Тәймус,— ник егълыймсың,
күңелеңнән ниләр кичә, ни телимсең,
төшләреңдә ниләр күреп өмсендең син —
морадыңны миңа белдерсәңче инде?»
Зөләйха әйтә: «Мин бик оеп йоклый идем,
төшемдә, һай, бик асыл бер сурәт күрдем,
уянып китсәм — янымда һич табалмадым —
шул сәбәптән үкенепләр елыйм инде.
Аһ, ул сурәт! Күзләремә ачык килде,
һушым китте, күңелемне әсир кылды,
сабырым-түземем калмады, гакылым алды —
җаным-тәнем аны эзли, тели инде».
«Аны соң мин,— ди атасы,— ничек күрим,
кем икәнен, кайдалыгын ничек белим,
мал-мөлкәтем ничек итеп фида кылыйм —
кавыштырыр өчен, кызым, сиңа инде?!»
Ул Зөләйха йокылардан мәхрүм калды,
ай кеби күрекле йөзе, чырае сулды,
ашау-эчү, ял-сәйраннан бизәр булды —
көне-төне тик Йосыфны уйлар иде.
Бу хәлләрдә тагы бер ел тәмам булды,
ул сурәтне Зөләйхабыз янә күрде,
сурәт аңа үгет белән болай диде:
«Йә, Зөләйха, киңәш сүзем тыңла инде!
Ачык аңла: син — минеке, мин — синеке,
миннән үзгә һич булма син беркемнеке,
хәтереңнән син чыгарма бу гыйшыкны —
миннән үзгә беркемгә күз салма инде!»
Зөләйха бик риза булып «ярар» диде,
йокысыннан уянып тиз карар иде,
төштә күргәнен янында табалмады —
аһлар килеп, һушсыз авып төште инде.
Ата кеше бу хәлләргә калды хәйран,
гыйшык сәбәпче икәнен белде бәян,

[1] Патша кызы
[2] Марокко, Алжир һәм Тунисның тарихи уртак исеме
[3] Мөселман гарәпләр еш кына христианнарны да потка табынучы дип саныйганнар (икона сурәтләрен күздә тотып).

шифаханәдә кылдырды төрле дәрман —
гакылы кайтмый, берни файда итми инде.
Истән ауган: ятса йокылары алмас,
китерсәләр әзер ризык — аны капмас,
сөйләшим дип кеше белән авыз ачмас —
табибләр моңа һич дәва тапмый инде.
Өченче ел ул сурәтне янә күргәч,
исенә килеп аһлар итеп, антлар биргәч:
«Әйтче,— диде,—илең кайда, кем син, әй яшь?
Ис-акылымнан мине мәхрүм иттең инде!»
Сурәт әйтә җавабында: «Күрим дисәң,
йа, Зөләйха,— кил Мисырга, мине сөйсәң,
мин булам Мисыр газизе[4], шуны бел син —
шиксез мине Мисырда табарсың инде.
Сабыр белән эшлә ләкин ошбу эшне,
сабыр белән була изге эшләр башы,
тиз җитәдер морадына сабыр кеше —
син бу эштә күркәм сабырлык ит инде!»
Зөләйха инде аягүрә торып килә,
фәһмен[5] җыеп, акылына, телгә килә,
әхвәленнән атасына хәбәр бирә:
«Минем дәртем[6] — Мисыр газизедер инде».
Бау-богавын чиштерде, акылы кайтты,
сүзе-теле әүвәлгедәй булды татлы,
үзе ягымлы, ул йөзендә нуры артты —
әмма ләкин уенда гел Йосыф инде.

*(Зөләйхага яучылар килүе)*

Туган җире Зөләйханың Мәгърип иле,
Мисыр белән ул Мәгърипнең ераклыгы,
чабар булса әгәр җайдак көне-төне —
ул Мисырга ай ярымда җитә инде.
Егерме җиде илдән киләдер яучылар,
башларында һәммәсенең алтын таҗлар,
китерәләр чиксез бүләк, алтын хачлар —
Зөләйханы барысы да сорый инде.
Һәркайсы бер илдән килгән өлкән ирләр,
Зөләйханы үз ханына сорап димләр,
Зөләйха тик әткәсенә бер сүз сөйләр —
«Мине Мисыр газизенә бирсәң иде!»
Атасы һәм бик күп күргәч бу хәлләрне,
Мисырга ул илче юллап, хат күндерде,
һич яшерми әхвәлен тәгәл белдерде:
«Бер кызым бар... даим сине эстәр инде!
Тәймус ибне Талус мин — бел син анык,
бардыр минем бер кыз балам, сиңа лаек,
ахры, язган аны сиңа тәңрем халик —
теләр исәң, илчеләрең җибәр инде!
Солтаннардан сораучы күп — теләмидер,
бүтәннәрдә күңеле юк — өнәмидер,
хәтереннән сине һич тә китәрмидер —
риза булсаң, безгә хәбәр җибәр инде!
Мин кызымны, хакыйкатьтер, сиңа бирәм,
дөягә мең мәһәр-җиһаз төяттерәм,
мең качырга янә малын йөкләттерәм —
нечкә ефәк, асыл парча булыр инде.
Янә мең кол, мең карауаш[7] өстәвенә,
алар әзер һәр даимән хезмәтенә,

[4] Баш вәзир
[5] Аң, акыл
[6] Мәгъшукым
[7] Хезмәтче

аяк өсте, һәр заман хөрмәтенә —
кайсы руми[8], кайсы хатәми[9] булыр инде».

*(Зөләйха Мисырга килә)*

Мисыр газизе ул вакытта Кыйтфир иде,
илчеләр дә хәбәр белән аңа килде,
хатны укыгач ул хуп күреп, риза булды —
җавап язып, илчесен җибәрә инде.
«Әгәр дә ул килер булса, мин хәзермен,
ихлас-күңелем белән эстәп мин алырмын,
малым-мөлкем барчасын фида кылырмын —
чын күңелдән кабул итәм»,— дигән инде.
Ул Кыйтфирнең илчеләре килү белән,
җавап хатын Тәймуска бирү белән,
аны укып, хәл нихәлен белү белән —
Зөләйхаңы җиһазлап озата инде.
Мең дөялек кәрванга мал йөкләттерде,
мең кәнизәк, янә мең кол атландырды,
шулай Мисырга Зөләйха килде-керде —
тәхет корып сарайда утыра инде.
Асыл кия, таҗ урый, анда утыра,
күңеле шат, куанычтан йөзе ачыла,
гүя айның үндүртенче көне тула —
кояш кебек йөзе аның балкый инде.
«Теләгемә, дип сөенә, ирешәмен,
газиз-Мисыр йөзен инде мин күрәмен,
дәрвишләргә[10] бөтен малым өләшәмен —
морадымның шөкранәсен[11] кылып инде!»
Шул сәгатьтә бәкләр белән газиз[12] килә,
бәкләр китә, газиз анда ялгыз кала,
Зәләйха аны күреп фөрьяд кыла:
«Бу нинди ир? Нигә калды?» — диеп инде.
Зөләйхага әйтә хәлне хезмәтчеләр:
«Мисыр газизе Кыйтфир бу, сине теләр,
хакыйкатьтә бу бит ирең синең,— диләр,—
әдәпсезлек кыла күрмә, зинһар инде».
Моны ишеткәч Зөләйхаңың акылы шашты,
аһлар килеп, ачынып-бөгелеп җиргә төште,
хезмәтчеләр аһ-ваһ килеп көенеште —
хәлне күреп, Кыйтфир дәхи егълар инде.
*Аннан янә ул Зөләйха исенә килә,
нинди хәлгә төшкәнен сизенә, белә,
кәтмәгән бу хәсрәтеннән йөзе сула —
хәл сәбәбен кәнизәкләр сорый инде.
«Йа, ханбикә — диләр,— синдер безнең солтан,
кирәк түгел безгә синсез ошбу җиһан,
күргәч аны, авып-бөгелеп төштең нидән —
эшең аслын безгә ачык әйтсәң инде!»
«Аһ, калды,— ди,— ерак җирдә туган илем,
ялгыш булды, аһ, нидән бу яман хәлем,
вай аяныч, күпме рәнҗү ерак юлым —
михнәт чигеп килүләрем заигъ[13] инде.
Мин төшемдә күргән егет бит бу түгел,
белегез,— ди,— бу ир минем мәхбүб[14] түгел,
күргәнемә охшашы юк, һич хуп түгел —
акылы-күрке аның болай идеме инде?!
Тулган айдай балкыр иде күркәм йөзе,
бал-шикәрдән татлы иде сөйләр сүзе,

[8] Римлы
[9] Хатәм кабиләсе кешесе
[10] Ярлыларга
[11] Игелек
[12] Мисыр газизе
[13] Зая, бушка
[14] Сөеклесе

кайгыларны тарата иде нурлы йөзе —
ансыз миңа бу дөнья хуш түгел инде.
Ныклы вәгъдәсен ул миңа биргән иде,
ни сәбәптер вәгъдәсенә хилаф кылды,
бу сәфәрем, дәртем рәнҗем заигъ булды —
илем-шәһрем[15] еракларда калды инде.
Тирәсендә барча өлкән хезмәтчеләр
бик җай гына Зөләйханы үгетлиләр:
«Әйа, хатун, сабыр кыл,— дип, киңәшлиләр,—
Сабыр иткән морадына җиткән инде».
Белмәссең дә — халик[16] сәбәп кылган булса,
күргән төшеңнең юравы чынга килсә,
бер көн бәлки ул морадың хасил булса —
теләкләрне үтәү аңар җиңел инде».
Зөләйха бу нәсихәтне кабул кыла,
газиз-Мисыр сараенда торып кала,
бу серне һич үзгә кеше белми кала —
хәтта Кыйтфир эшнең аслын сизмәс иде.
Үтә-китә күп вакытлар аннары соң,
Зөләйхабыз Кыйтфирдән нык саклый үзен,
арзулары[17] сулдыра тик күркәм йөзен —
бер өзлексез ул Йосыфын уйлар инде.
Ул Кыйтфирдән Зөләйханы тәңре саклый,
(Йосыф өчен билгеләгән инде аны)
Кыйтфир белми һәм сизми дә бу хәлләрне —
кирәк чакта бер пәри кыз[18] килер инде.
Зөләйха һич тә Кыйтфиргә буен бирми,
буен бирми, үзен бирми, якын килми,
Кыйтфир үзе бу әхвәлнең аслын белми —
Зөләйха дип пәри кызын кочар инде.
Аннары соң нәкъ җиде ел тагын кичте,
хәл үзгәрде, бик күп айлар килде китте,
ниһаять, Йосыф Мисырга килеп төште,
кол дип аны сатуга куйдылар инде.
Өндәүчеләр базар буйлап йөгрешәләр:
«Бу колны кем сатып ала?»— диешәләр,
күркәм йөзеннән пәрдәсен күтәрәләр —
йөз нурлары көн яктысын тотар инде.
Һичбер кеше аны сатып ала алмады,
бәя җиткереп һич якын килә алмады,
Мисыр малы аңа бәһа була алмады —
«Дөнья малы моңа җитмәс!» — диләр инде.
Шуннан соңра газиз Кыйтфир әмер кылды,
сарай алды мәйданын ул бизәттерде,
нәфис хәтфә келәмнәрен түшәттерде —
тирәсенә бик күп көрси корыла инде.
Сарай халкы мәйдан тирә утыралар,
шул чагында ул Йосыфны китерәләр,
олы-кече бик күп афәрин кылалар —
Йосыф мәйдан эчендә көрсидә инде.
Йосыф утыра — бөтен мәйданны балкыта,
нуры белән сарай эчләрен яктырта,
карап шуннан[19] Зөләйха аны күреп ала —
тану белән һуштан язып егыла инде.
Карауашлар барсы аңа йөгереште,
хәлне күреп, бөтенесе гаҗәпләште:
«Ханым,— диләр,— нидән һушың китеп төштең?»—
әле берсе, икенчесе... сорый инде.

[15] Ил-җир
[16] Алла
[17] Гыйшык дәрте
[18] Чибәр кыз
[19] Ягъни: сарай тәрәзәсеннән

«Җибәрегез,— ди Зөләйха,— мин төшием,
ничә еллык хәсрәтемә кавышыем,
аерылу хәлен-әхвәлен сорашыем —
хакыйкатьтә кавышу көне җитте инде!
Белегез инде — улдыр минем сөяр ярым,
алыгыз аны минем өчен биреп малым,
ни кадәрле сорасалар — бөтен барын —
малым түгел, җаным фида аңар инде!»

Өндәүчеләр яр салып[20] игълан итәләр:
«Бу угланны, һай, кем сатып ала? — диләр,
Унар төрле һөнәре[21] бар моның»,— диләр —
һөнәрләрен берәм-берәм әйтеп инде.
«Әүвәл шулдыр: буе зифа, үзе гарьле,
икенчедән,— сылу, күркәм, йөзе нурлы,
өченчедән — телгә оста, сүзе тугры —
җитмеш ике телне тәмам белер инде.
Дүртенчесе — игелекле, кешелекле,
бишенчесе — алып йөрәкле вә һиммәтле[22],
алтынчысы — ул бик котлы вә куәтле —
кырык ирдән ирдәмлеге[23] артык инде.
Җиденче шул — дине бөтен, диянәтле,
сигезенче — хаин түгел, әманәтле,
тугызынчы — киң холыклы, теле татлы —
унынчы — ул — нәселе пәйгамбәрдән инде».
Газиз-Кыйтфир ишетеп бик хәйран калды,
ул Йосыфның йөзенә бер караш салды,
ихтыярсыз сабыры китеп, һуштан калды —
берәр сәгать һушы китеп торды инде.
Исенә килгәч: «Моны миңа сатыгыз,— ди,—
энҗе-мәрҗән, гәүһәр-якут алыгыз,— ди,—
аның өчен бирәм кыйммәт малыбызны —
чын бәһасен ачыклап әйтегез инде» (...)

«Куйсаң үлчәүгә,— ди Малик,— әгәр алтын,
бу угланның авырынча куй тик ансын,
куйсаң төрле малдан, җәүһәр йә якутын —
һәрбер төрен аның хәтле сал син инде».
Газиз Кыйтфир бу сүзләргә риза булып,
шул сәгать үк хәзинәгә үзе барып,
биш йөз мең салды үлчәүгә алтын алып —
шул алтын да Йосыфка тиң тартмас инде.
Үлчәвенә көмештән һәм дәхи куйды,
үлчәделәр — Йосыфка һич тиң килмәде,
алтын-көмеш хәзинәдә һич калмады —
барча малы Йосыф тикле тартмас инде.
Ефәк-атлас, мишек-ганбәр[24] — барсын куйды,
җәүһәр-якут, энҗе-мәрҗән — ансын куйды,
Кыйтфир инде бу бәһадән гаҗиз булды —
һәммә малы Йосыф кадәр тартмас инде.
«Ахры безнең сәүдәбез,— ди,— булмас икән,
бәя җиткереп, шартын китереп булмас икән,
дөнья малы моңа тәңгәл килмәс икән —
мәгәр калган өлешен бүләк итсәң инде.»
«Бу сәүдәгә,— диде Малик,— риза булдым,
һәр малыңнан җиткән кадәр бәһа алдым,
җитмәгәнен инде үзеңә багышладым —
бу угланны иркем белән бирәм инде».

[20] Сөрән салу
[21] Төрле сыйфатлары
[22] Гайрәт, егетлек
[23] Ирлек
[24] Хуш исле майлар

*(Сәүдәгәрнең үкенүләре)*

Газиз Кыйтфир инде Йосыф кулын алды,
Малик Дәгыйр аңа соңгы караш салды,
шул ук мәлдә пәйгамбәрлек нурын күрде —
«Нигә саттым!» дип пошаман калды инде.
«Аh, үкенеч! Кайда минем ул дәүләтем?!
Моны ничек элегрәк белмәгәнмен,
[маңгаенда] ошбу нурны күрмәгәнмен —
бүген бу эш, hай, кулымнан китте инде?!»
«Йа, Йосыф,— дип үкенә Малик,— йөзең нурлы,
фәрештәләр сыйфатлы син, сүзең татлы,
күргәнем юк адәмнәрдә бу сыйфатны —
әйтче миңа, син кем?»— диеп сорый инде.
«Ярый инде,— диде Йосыф,— сиңа әйтим,
әхвәлемне ахыр сиңа бәян итим,
вә ләкин шул шарт белән генә сөйлим —
бик нык сакла, фаш итмә бу серне инде!
Кем икәнем инде әйтәм сиңа ачык,
мин буламын хакыйкатьтә Йосыф сиддикъ,
олы бабам тәңре дусты иде анык —
атам минем Исхак углы Ягъкуб инде!»
Моны ишетеп, Малик Дәгыйр хәсрәтләнде;
элегрәк, белмәгәнмен ошбу хәлне,
сиддикымнан аерылдым, аh, бу мәлне —
пәйгамбәрне коллыкка ук саттым инде!
hай, үкенеч, әүвәл гәрчә белсә идем,
болай синең белән сәүдә итәрме идем,
азат итеп сине атаңа илтер идем —
үзем даим сиңа коллык итеп инде».
Йосыф әйтә: «Хәзер ул эш кулдан китте,
тәңренең хөкеме килде, чара бетте,
күрер күзләрне күрмәстәй гаҗиз итте —
хак әмеренә буйсынырга кирәк инде».
Малик янә: «Әй, Йосыф,— ди,— хак пәйгамбәр,
үтенәмен — углым юктыр, кызларым бар,
минем өчен бер дога кыл бүген зинhар —
синең догаң шиксез кабул булыр инде».
Йосыф[25] күтәреп кул дога кыла,
тәңре аның догасын хуп-кабул кыла,
ул Маликның егерме дүрт углы туа —
hәр кайсысы дәүләт иясе булыр инде.
Малик Дәгыйр аңа тагын сорау бирде:
«Сине миңа сатканнар ул кемнәр иде,
нигә сатты, нишләп болай очсыз бирде —
бу серләрне ачып бирсәң, белсәм иде?»
«Мин моны hич,— дия Йосыф,— әйтә алмыйм,
хакны куеп, ялган сүзләрката алмыйм[26],
гайбәт сөйләп, шайтан күңелен шат итә алмыйм —
бу серне мин ача алмыйм, калдыр инде.
Җитте вакыт айрылырга, ачык син бел.
миннән риза булсын инде синең күңел,
күрдем диеп, Йосыфны сөйләмә, тыел —
әманәтем: бу серләрне сакла инде».

*(Хәзинә вакыйгасы)*

Аннан соңра Кыйтфир бик нык уйга калды,
Йосыфны ник алганына поша калды:

[25] Пәйгамбәр
[26] Кушып-өстәп сөйли алмыйм

«Бөтен малым, хәзинәм, дип,— бушап калды —
бөлеп беттем, мохтаҗлыкка төштем инде».
«Солтаным,— ди Йосыф аңар,— әмер кыл син,
хәзинәдар[27] хәзинәгә барып килсен,
ни калгандыр, күзе белән багып күрсен —
аннан килеп сиңа хәбәр бирсен инде».
Хәзинәче хәзинәгә барып керә,
хәзинәдә ни хәл барын күреп белә,
хуҗасына йөгереп килеп хәбәр бирә:
«Хәзинәдә мал туп-тулык!»— дия инде. (...)
*Газиз Кыйтфир бу гаҗәби хәлне уйлый,
монда бер-бер хикмәт бардыр, диеп юрый,
«Буш хәзинә ничек тулсын — диеп сорый —
бу кәрамәт[28], бу бәрәкәт каян инде?!»
*«Ошбу серне,— ди казначы,— әйтә алмыйм,
уйлап һич бер сәбәп фәһем итә алмыйм,
аслын моның һич кемнән дә белә алмыйм —
бу серләрне углан белсә белер инде...»
Йосыф әйтә хуҗасына: «Әйа, солтан,
бардыр минем кадир иям, олуг сөбхан,
игелекләр һәммәсе тик килә аннан —
юкларны бар итү аңа җиңел инде.
Белсәгез бел — аңардандыр бу бәрәкәт,
кодрәт белән ясагандыр бу кәрамәт,
аңар даим мин әйтәмен шөкер-миннән[29] —
ә сезгә мин һич бурычлы түгел инде!» (...)

*(Йосыфны Зөләйхага тапшыру)*

Газиз янә ул Йосыфка сорау бирде,
сораштырып хәлен, янә кадрен белде,
үз кулыннан илтеп Зөләйхага бирде:
«Бу мөбарәк угланны сакла инде!
Йа, Зөләйха, бу балага ит син хөрмәт,
аңа лаек гаять олы кадер-гыйззәт,
тәрбиялә аны миннән артыграк —
Йосыф безнең угылыбыз булсын инде».
Аның сүзен Зөләйха хуп-кабул күреп,
кадерләде Йосыфны күп хөрмәт кылып,
аңа өч йөз алтмыш төрле тун[30] тектереп —
һәр көн саен бер төрлесен кидерер иде.
Йосыф әйтә: «Бу эш ничек лаек булыр
(ягъни колга бу киемнәр муафыйкмыдыр),
бу эш, бәлки, күпләргә гаеп тоелыр —
хуҗа үзе дә мондый кием кими инде?!»
Зөләйха әйтә: «Аңла син, әйа, сөеклем,
газизгә дә хуштыр синең киенүең,
ул кушканга хәзерләнде һәр киемең —
кайчан кисәң, нур өсте нур булсын инде!»

*(Зөләйханың гыйшкы)*

Үз кулы белән Йосыфның башын тарар,
җәүһәр-энҗеләрен тезеп чәчен үрер,
шул хәлләрдә күңле йомшап, китә кәрар[31]
гыйшкы җиңә, һич сабыры калмый инде.
*Зөләйхабыз Йосыф күркен чагыштыра,
һәм тәкатьсез, би-чара[32] ул гаҗиз кала,

[27] Хәзинә мөдире
[28] Могҗиза
[29] Рәхмәт әйтү
[30] Өскә кием
[31] Ихтыярсыз калу
[32] Чарасыз

ахры тәмам Йосыфка ул гашыйк була –
көннән-көнгә гыйшык дәрте арта инде.
Мөшкел хәлгә төшерде Зөләйха үзен:
күрми торса бер сәгатькә Йосыф йөзен,
калмый сабыры, аңгармый һич кеше сүзен —
ни сөйләсә «ай, Йосыф!» дип әйтә инде!
Кай вакытлар ул тәненнән кан алдырса,
табиб килеп пәке[33] белән тамырын ачса,
шул вакытта каны агып җиргә тамса —
җир өстенә «Йосыф» дип язылыр инде.
Кайчагында күкләр таба күзен текСә,
күк йөзендә чулпан-йолдызларны күрсә,
шундук аның күңеленә Йосыф килсә —
йолдызлар да «Йо-сыфф» дип җемелди инде.
Җитте шуңа — бар тәкатен, сабырын җуйды,
ул Йосыфка үз хәләтен ачмак булды,
сузылып кына угланның уң кулын алды —
кулын алып, потханәгә[34] керер инде.
«Әй, санәм,— ди,— мин хаҗәтле бу көн сиңа,
ошбу углан бигрәк инде лаек миңа,
бер ярдәмең күрсәтсәңче мин колыңа —
моның күңлен миңа күндәм итсәң инде!»
Санәменә ялварадыр, егълап аһ-зар,
җиңгән аны гыйшык дәрте, сабырын аулар,
калмады эчендә һич бер яшерен серләр —
чарасыздан ялынып сәҗдә кыла инде.
Йосыф нәби дога кыла моны күреп,
санәм сына, уала ун парә булып,
шунда санәмгә тәңредән әмер килеп:
«Хак пәйгамбәр — Йосыф!»— дип ул әйткән инде.
*Хак сәнгатен Зөләйха үзе күрү белән,
санәм телгә килеп әйтеп бирү белән,
бу гаҗәеп кодрәти хәл булу белән —
моның асылын Йосыфтан ул сорый инде.
«Ничек, нидән — ди Зөләйха,— болай булды,
бөтен санәм нилектән ун парә булды?»
«Моны тәңрем,— диде Йосыф,— шулай кылды —
ниятеңне өнәмәде синең инде».
«Ай-һай, бу эш,— ди Зөләйха,— бик гаҗәптер,
тәңрең синең бу санәмне ничек күрер,
санәмемә бу хурлыкны ничек кылыр —
ул бит өйдә өсте өртүле тора инде.»
*Йосыф әйтә: «Ул шундый кодрәтле хуҗа,
колларының һәрбер эшен күреп тора,
яшерен эшләрнең һәммәсен белеп тора —
аңа кайда, кем ни кылган, ачык инде».
«Әгәр дә ул,— ди Зөләйха,— алай икән,
халикыңнан килсен инде безгә ярдәм,
баягыдай бөтен булсын иде санәм —
Әйа, Йосыф, син теләсәң, була инде.
Куркамын,— ди,— потханәгә Кыйтфир керер,
санәмнең ул унга ярылганын күрер,
бу хәлләргә гаепле дип безне белер —
кирәкмәс, кем, без гөнаһлы булмыйк инде».
Шул ук мәлдә Йосыф нәби дога кылгач,
тәңре аның теләгәнен кабул иткәч,
санәм шунда баягыдай бөтен булгач —
ул Зөләйха моңа хәйран кала инде.

[33] Биредә: ланцет күздә тотыла
[34] Гыйбадәтханә

*(Зөләйханың авыруы)*

Аннан соң да гыйшыклыгы әсәр кыла,
көннән-көнгә мәхәббәте арта тора,
мәхрүм калып йокысыннан йөзе сула —
ашау-эчү кайгысын да белми инде...
Көннәрдә бер газиз-Мисыр аңа керә,
күреп хәлен, аңа табиб алып килә,
табиб сузылып, Зөләйханың кулын ала —
тамырын тотып, рәнҗү хәлен сорый инде.
*Табибтан хәлен Зөләйха яшермәде,
Кыйтфир исә анда берни төшенмәде:
керфек сирпеп, табибкә хәл белдергәнен,
Кыйтфир сизми, аңышмый да торып инде...
Табиб әйтә: «Мондый сырхау мин белмимен,
моңа нинди дәва кирәк — әйтә алмыймын,
бу рәнҗүнең аслына һич төшенә алмыймын —
йөрәк хәстәлеге булса кирәк инде...»



## VI бүлек. Дая Зөләйханың хәлен сораша

Ул Зөләйха бер көн ятып оер иде,
бер даясе[1] кереп аның хәлен белде:
«Ханым-бикәм, сиңа нәрсә, ниләр булды —
ни мәгънәдән син бу хәлгә төштең инде?
Хуҗабикәм, ни сәбәптән күңелең тар,
йөзең сары, зәгъфрандай, ни кайгың бар,
рәнҗүең миннән яшермә, сөйлә, зинһар —
хәлең зәгыйфь, каефең дә хуш түгел инде».
Зөләйха ул даясенә җавап сөйли,
эч серләрен әйтә аңа, һич яшерми,
үзгәләрдән саклавын тик аннан тели:
«Әманәт бел, зинһар, серем чишмә инде!
Йа, инәкәм, беләсең ич инде аны,
Кәнган иленең әлеге кол угланын[2],
бу хәлләргә төшергән тик улдыр мине —
гыйшкымнан мин ошбу хәлгә калдым инде».
«Әйе, бу хәл,— ди дая,— түгел тикмәгә,
нигә хәлең әйтмәдең соң әүвәл миңа,
мәслихәт эш кылыр идем уңнан сулга —
теләгәнең мәгәр хасил булыр иде.
Гыйшык хәле, мәгълүм инде, ансат булмас,
һичбер табиб ул дәрткә бер дәрман тапмас,
бөтен галәм көлсә дә һич гашыйк көлмәс —
һәр сулышында сөйгән ярын уйлар инде.»
«Әйа, даям,— ди Зөләйха,— хак сөйлисең,
бигрәк миңа туры килгәнчә көйлисең,
тик бу көннән минем өчен ни уйлыйсың —
юкса бу дәрт мине тәмам үтерә инде.
*Синең һәрбер киңәшеңә алдан күнәм,
нинди чара кирәк дисәң, аны кылам,
ничек итеп бу рәнҗүдән мин котылам —
ничек итеп морадыма ирешәм инде?!»
Дая әйтә: «Байлык сарыф итмәк кирәк,
гашыйк кеше малын фида итмәк кирәк,
мал-мөлкәттән тәмам күңел бизмәк кирәк —
гашыйк булгач, хәзинә дип торма инде!»
Зөләйха ди: «Әйа, даям, риза булам,
синең һәрбер үгетеңә күңлем куям,
малым-мөлкем һәммәсен дә фида кылам —
ни кирәксә минем өчен, әйтче инде!»

*(Бакчасарай салдыру)*

Дая әйтә: «Төзүчеләр хәзер килсен,
лаеклы бер сарай сиңа бина кылсын,
шундый булсын — күргән һәркем хәйран калсын,—
диварлары төрле нәкыш булсын инде.
Дивар эче энҗе-мәрҗәнлә түшәлсен,
кызыл алтын агачлар белән бизәлсен,
ботаклары тирә-якка җәелеп торсын —
җимешләре төрле төсле булсын инде.
Төрле-төрле тирәкләр ул анда тексен,
һәм берничә тирәкләре энҗе булсын,
берничәсе тирәкләрнең ахак булсын —
берничәсе кызыл мәрҗән булсын инде.
*Ул тирәкләр арасында куак үссен,
ул куаклар һәммәсе дә алтын булсын,
һәр тирәкнең төбендә бер үгез кылсын —
ул үгезләр һәм көмештән булсын инде.

[1] Имезеп үстергән хатын
[2] Үсмер егет

Саф кызыл алтыннан бер ат ясалсын,
гәүһәр-якут, энҗе-мәрҗән нәкыш кылсын,
тирәсендә төрле-төрле агач булсын —
җимешләре салынып тәлгәш-тәлгәш инде.
Агачларның өстенә ул кош кундырсын,
ул кошларның һәр берсе төрле булсын,
ул сарайның эч нәкышен шундый кылсын —
диварлары сандал[3] гөлдән генә инде.
Аның эчен җофар белән бизәсеннәр,
түшәмнәргә җәүһәр кандилләр элсеннәр,
гуд вә ганбәр, мишек[4] белән төтәтсеннәр —
һәм нәкышле, һәм хуш исле булсын инде.
*Бизәк-бизәк ясалсын ул түшәмнәре,
тирәк-тирәк бизәлсен дүрт дивар бары,
синең сурәт һәм дә Йосыф кара-каршы
бер-берегезгә күз текәшеп торсын инде.
Ул күшкеңнең[5] уртасына тәхет куеп,
иңнәреңә нечкә-нәфис ефәк өртеп,
башыңа һәм асыл ташлы таҗың киеп —
айдай балкып үзең анда утыр инде.
Хезмәтеңә аяк өсте кәнизәкләр
тотып торсын шәрабле алтын касәләр,
төтәтсеннәр мишек-җофар, гуд вә ганбәр —
түшәмнәре алтыннан булсын инде.
Дәштерерсең Йосыфыңны — килеп керер,
бу мәһабәт, бу бизәүне күзе күрер,
һәммәсеннән нурлы нәзик сине күрер —
ничак сабыры булса булсын — эрер инде!
Сине күрә — тәкатьсез акылы югала,
өметтәр ки, буйсына, күңле уяна,
ният иткән дәртләреңә дәрман таба —
теләгәнең шунда хасил була инде».
Даясенең бар киңәшен кабул күрде,
ул хәлендә үзе бик тә зәгыйфь иде,
бер көн Кыйтфир шәфкать илә аңа керде:
«Рәнҗең нидер, ни телимсең?»— дия инде.
Хатын әйтә: «Оста төзүчеләр килсен,
миңа лаек бер шәп сарай бина кылсын,
эче-тышы гаҗәепләр нәкыш булсын —
бакчасында чылтырап сулар аксын[6] инде».
Кыйтфир шундук кемгә тиеш әмер бирә,
төзүчеләр, нәкышчеләр хәзер килә,
иң осталар төзеп тиз үк тәмам кыла —
бик бизәүле, төзек сарай булды инде.

*(Йосыф Зөләйханың аулак сараенда)*

Ул Зөләйха көдрәләрен, чәчен үрде,
энҗе-мәрҗәннәрен кушып зиннәт бирде,
төзәнеп һәм ясанып ул килеп керде —
сарай эче йөз нурыннан балкыр иде. (...)
Боеру белән тиз Йосыфны өндәделәр:
«Сине ханым чакырадыр, бар»,— диделәр,
гафил итеп аны шулай алдадылар:
«Безгә газиз[7] үзе кушты»,— диләр инде.
Ашыгып килеп, ул сарайга Йосыф керә,
тәхетендә Зөләйханың үзен күрә,
тиз абайлап туктап кала, кире дүнә —
сизеп хәлне, чыгып китмәк була инде.

[3] Каты һәм хуш исле агач
[4] Хуш исле матдәләр
[5] Бакчасарай
[6] Фонтаннар
[7] Ягъни Кыйтфир

*Хәвефләнеп Йосыф туктап калу белән,
кергәненә пошаман булып борылу белән,
Зөләйха тиз хәлне төшенеп алу белән —
җиде ишекне бикләтеп үк куя инде.
Башында — таҗ, күз уйната, керфек кага,
сүзен әйтсә, күкрәгеннән хуш ис ага,
бер хур кызы, гүя, җәннәттән ул бага —
аягында мәрҗән чулпы чылтырый инде.
Уйлый Йосыф: «Ходәвәндә, ходәвәндә,
синең хөкемең китерде мине монда,
мондый фетнә төшкән колга сабыр кайда —
кодрәтеңлә күркәм сабыр бирсәң инде!»
*Бәс, Зөләйха тезгенне һәм үзенә ала,
гыйшкы өчен үзе һөҗүмгә ташлана:
йөгереп килеп, Йосыфны җитәккә ала —
ашкынып тарта үзенә таба инде.
«Сине мин,— ди,— әүвәл үк төшемдә күрдем,
шуннан бирле җәмалеңә[8] гашыйк идем,
бөтен малым-мөлкем синең өчен бирдем —
теләгәнем бүген хасил кылам инде».
Зөләйха тоткан, җибәрми Йосыф кулын,
яна йөзе, исәпли тик кавышу уен,
Йосыф уйлый бу хәлдән тик котылу юлын —
зари кыла «Коткар!» дип тәңрегә инде.
«Йа, ходай,— ди,— аулак сарай бизәлгәндер,
хурлар кеби Зөләйха хуп төзәнгәндер,
Иблис-ләгыйн аздырмага озангандыр[9]—
үзең сакла аның тозагыннан инде!» (...)
Вәхи килде:[10] «Ярдәм теләп миңа килдең,
әүвәл-ахыр[11] булышчың дип мине белдең,
кайгырма һич, фетнәләрдән имин булдың —
һәм коткарам, һәм мөхтәрәм итәм инде».
Йосыф әйтә: «Куйчы кулым, йа, ханбикә,
хакка каршы барып, алмыйк язык өскә,
без сакланыйк, болганмыйк ул бозык эшкә —
сабыр кылсаң, шайтан ким-хур була инде».
Зөләйха тик ишетми дә каршы тора,
гүзәллеген мактап һаман сайрый бирә,
күркәмлеген берәм-берәм тасвир кыла —
мактауларын артканнан-арттырып инде.
«Йа, миһербан,— ди Зөләйха,— мәхәббәтле
холкың ипле, йөзең якты, сүзең татлы,
бу сарайны төзеттем синең сыйфатлы —
бакчы, аның нәкышенә бер күз сал инде».
Бакты — сарай нәкышен күреп, гаҗәпләнде,
«Бигрәк матур сарай»,— диде, бик ошатты.
«Ләкин монда газиз нишләп күренмәде —
хатыны белән ул да бергә булсын иде».
Зөләйха тик һаман да бер сүзен сөйләр:
«Бу сарайда ул газизнең ни эше бар;
бу сарайда бөтен нәкыш сиңа охшар —
аны синең өчен атап төзедек инде».
*Аннан битәр бакчасарай сиңа лаек,
ихлас әйтәм, мәҗаз[12] түгел, сүзем аек,
гыйшкың татлы күңелемә хуш синең холык —
синең гыйшкың мине әсирә итте инде!»
«Газиз мине,— ди Йосыф,— коллыктан йолды,
аңа минем фигылем-холкым хуп тоелды,

[8] Күркәмлек
[9] Омтылган
[10] Тәңре сүзе
[11] Һәрчак, һәрвакыт
[12] Кинаят

һәм ул мине угыллыкка кабул кылды —
бу атама ничек хаин булыйм инде?!
Хыянәтче адәмнәрне тәңре сөймәс,
дошманнардан газабын һич китәрмәс,
дәргяһенә[13] килгән кешене җибәрмәс —
куркып аннан, сабыр кылып үтен инде».
Зөләйха һич аның сүзләрен аңламый,
күңел куймый, үгетләрен һич тыңламый,
аңа лаек килердәй сүз теленә алмый —
үз дигәнен генә кабат сөйли инде.
«Әйа, Йосыф, синең телең-сүзең татлы,
ялыкмый һич тыңлар өчен бик рәхәтле,
йөзең нәфис, сүзләрең хуп, мөрәүвәтле[14] —
ишетте исәм, кәефләрем арта инде.
Синең белән бер кавышу җан рәхәте,
йөзең нуры кояш кеби, гыйшкың каты —
сының зифа, үзең нәфис, сүзең җете —
хәнҗәр кеби үзәгемнән үтәр инде.
Сиңа охшаш һичбер кемне мин белмәмен,
синсез калсам, бер дәкыйка[15] түзә алмамын,
синнән аерым сулышымны да ала алмамын —
аерылсам җаным тынгы белмәс инде.
Яңа туган айга охшар кашларың бар,
энҗеләргә охшар синең тешләрең бар,
гаҗәп хуш ис, мүшек-җофар[16] чәчләрең бар —
кулым белән үзем тарап үрер идем.
Гаҗәп нәфис кара бөдрә ул чәчләрең,
сөйләр исәң тәмле, ягымлы сүзләрең,
ым какты исә өздереп ала күзләрең —
керфекләрең йөрәгемә үтә инде. (...)
Якут кеби синең алсу яңакларың,
яшь алмадин нәфисрәк иякләрең,
бал-шикәрдин ләззәтлерәк иреннәрең —
ике ирнең күңлем үртәп яна инде.
Яңа үскән талчыбыктай бармакларың,
энҗе-мәрҗәндәй тезелгән тырнакларың,
кяфүрдән[17] дә аграк синең беләкләрең —
кул учларың ефәктән дә йомшак инде.
Син, хакыйкать, алдың җаным тәкатене,
үтә гомер, кайчан җитәр каушу көне,
һич айрылмый күреп торыр идем сине —
күрми торсам, сабырым түземем калмый инде.
Әйа, Йосыф, сөйләвең хуп, үзең гарьле[18],
күрмәгәндер һичбер мәхбүб[19] синдәй ярны,
күргәнем юк адәмидән синдәй нурлы —
аналардин синең кеби тугмас инде».
Бу сүзләрне ишеткәчтен Йосыф сиддикъ
Зөләйханың уй-ниятен белеп анык,
җавап бирде шәфкать белән хәтерен табып —
йомшак кына үгет-киңәш әйтә инде.
Әйтә инде: «Йа, Зөләйха, сүзем тыңла,
ни диярмен, ишет яхшы, үзең аңла:
зифа тәннән җан чыкты исә — син абайла —
нуры күркәм йөзләрнең һич калмас инде.
Нуры калмас, кәфен сарып гүргә керсә,
җир астында күп тә түгел, өч көн торса,
кайсы дусты аны каберендә күрсә —
күрмәс өчен, йөзен чөйреп качар инде.

[13] Каршысына
[14] Кешелекле
[15] Мизгел
[16] Хуш исле матдәләр
[17] Камфара
[18] Тыйнак
[19] Гашыйк

Гүр эчендә күркәм йөзнең күрке китәр,
елан-чаян, корт-кырмыска ашап тишәр,
озын чәчләр корыгандай коелып төшәр —
тәне-саны сизми, тоймый ятар инде.
Җете күзләр һич күрмәслек сулып калыр,
энҗе кеби ап-ак тешләр дә коелыр,
алтмыш сөяк какшап-корып тузан булыр —
тәне-ите череп вәйран булыр инде. (...)
Матур, ямьсез — җөмләсе юк булачактыр,
гүр эчендә ябылып ук калачактыр,
кем ни кылса шул кылганын табачактыр —
уңнан-сулдан фәрештәләр язар инде.
Инде белдең хәлләр болай була икән,
колларына мәүля[20] хисап кыла икән,
кол ни кылган, анда әҗрен ала икән —
яман эштән саклану кирәк инде».
«Минем дәртем,— ди Зөләйха,— үзгә, айрук[21],
алай куркып ваз кичәргә дәрманым юк,
бик күп йоттым фиракъ[22] сагышын, тәкатем юк —
каушу шәүкы сабырымны җуйды инде!» (...)
«Әйтче миңа,— ди Зөләйха,— исәпләрең,
күңлеңдә ни, нидер синең өмидләрең?
йа, әйтсәңче — кемнән синең өркүләрең —
ир-егетлек насибең[23] һич юкмы инде?!»
«Курыкканым,— дия Йосыф,— тик тәңредән,
чиклим, тыям үз-үземне гөнаһ эштән,
уйлап ахирәт хәлләрен саклык итәм —
шуңа күрә сиңа хилаф кылам[24] инде».
*Зөләйха исә: «Карышма, ди, әйа, углан,
күпме җәфа чигерәсең мине һаман,
кил яныма, инде тәвәккәллек кылам —
син — әфәндем, мин — хезмәтчең булыйк инде».
Кулын алып, хатын үзенә җәлеп итә,
Йосыф та аңа елмая — ымсынып китә,
шул мизгелдүк кисәтүле өн ишетә —
«Якын барма азгынлыкка!» диеп инде. (...)
Гүя атасы Йосыфка күренеп китте:
«Нәфесеңне тый яманнан!» — диеп әйтте,
аны күреп Йосыф сиддикъ сабыр итте —
тәңресеннән куркып нәфсен тыя инде. (...)
Мәүля хөкеме иңеп аңа мәгълүм булгач,
һәрбер сүзе хәвефтән нык кисәттергәч,
бозыклыктан котылмага ярдәм килгәч —
хакка оеп[25] яман эштән качты инде.
*Зөләйха төште тәхеттән, таҗын салды,
килеп Йосыф муйнына беләгең сарды,
бу кочыштан Йосыф тәмам гаҗиз калды:
«Ярамый бу, тәңре күрер!» — дия инде.
Бер санәме күшк[26] түрендә тора, иде,
Зөләйха аны тәңресе дип белә иде,
йөгереп барып күлмәге илә бөркәп килде —
«Өсте япкан,— диеп уйлый,— күрмәс инде».
Йосыф сорый: гаҗәпсенеп бу әхвәлне:
«Ни мәгънәдән бөркәп куйдың ул санәмне?»
«Оялганга ... бөркәдем,— ди,— тәңремне...
күрер дип»,— Зөләйха җавап бирә инде.
Йосыф әйтә: «Әй, Зөләйха, син ни кылдың —
бу гаҗизне тәңре диеп ничек белдең?

[20] Алла
[21] Аеры ук
[22] Аерылу
[23] Өлеш, сәләт
[24] Каршы тору
[25] Риза булып, күнеп
[26] Бакчасарай

Син санәмең күлмәк белән өртеп куйдың —
мин алламны ничек өртеп куйыйм инде?!
Санәм — көчсез, бер сын гына ул ясалган,
күрми, белми, бер файда да юк аңардан;
һичкем качалмый яраткучы ул кадирдан[27] —
һәр ни яшерен эшләр аңа ачык инде.
Санәм — гаҗиз, хаҗәт түгел аны ябу,
яңлыштыр тәңрене куеп, аңа табыну,
Хәлилулла мәсләгенә[28] ялгыш кату[29] —
вә-аллаһи, ул эш дөрес булмас инде.
Тәңре күрер, күргәнен ул һич ялгышмас,
тәкъдирендә ни язганын кол аңламас,
аның угы килеп тисә, һич уңалмас[30] —
каза угы диеп аны аңла инде».
Зөләйханың һаман гыйшык дәрте кызды,
ишетеп Йосыф сүзләрен ул мәкер корды,
җибәрмичә итәгеннән тотып торды —
китмәгәе диеп шөбһә кыла инде.
«Ник китәсең, бу күшк хуп түгелме әллә,
сурәтләре күңеленә хуш түгелме әллә,
үзем сиңа газиз мәхбүб[31] түгелме әллә —
егетлектән һич өлешең юкмы инде?!»
Тәңресеннән тели Йосыф: «Гафу — синнән,
табалмыймын котылырга һичбер дәрман,
коткара күр кодрәтеңлә мине моннан —
сабырымны җиңә моның фетнәсе инде!» (...)
Рух-әл-әмин[32] бик тиз килеп җитте үзе
(нурга тулды ул килүгә бар җир йөзе),
Йосыфка ул ирештерде тәңре сүзен,—
җилкәсеннән сыйпап аңа әйтә инде: (...)
«Кодрәтле мин: нәүбәт илә кавыштырам,
ярдәм биреп икегезне сөештерәм,
ул хәсрәтле үзегезне очраштырам —
дусларың шат, дошман гамьле булыр инде. (...)
Ул Мисырда падишаһлык син кылырсың,
Зөләйханы никахлап ук син алырсың,
ул — синеке, син аныкы һәм булырсыз —
син — олуг хан, ул — ханбикә булыр инде».
Вәхи килде[33]: «Йөз дүндереп качу — синнән,
кодрәт белән җиде ишекне ачу — миннән,
коткарамын Зөләйханың фетнәсеннән —
мөшкел эштән сиңа котылу килә инде».

*(Зөләйханың куа чыгуы)*

Тәңресенә сыенып ул чыгып чапты,
кодрәт белән җиде ишекне халик ачты,
исән-имин котылуына сөенеп качты —
Зөләйха аны артыннан куа инде.
Менә Зөләйха Йосыфны куып җитә,
куып җитеп итәгеннән сузылып тота,
арт итәге Йосыфның ертылып китә —
бер-бер артлы алар килеп чыга инде.
Ишек алды: Кыйтфир хәлне күреп алды,
Зөләйханың төсе киткән күкле-аклы,
сизеп сорый болардан, кем языклы —
җавап эзли, төпченеп тикшерә инде.
Әүвәл аңар Зөләйха йөгереп килде,
«Кол углан, ди, миңа яман тәкъдим кылды,

[27] Алла
[28] Ислам дине
[29] Катнаштыру
[30] Төзәлмәс
[31] Кадерле могъшука
[32] Җәбраил
[33] Алла сүзе

бу гаепкә ни җәза? — дип сорау бирде —
зинданмы, йә каты газапмы инде?!
*Угланны, ди, богаулатып зинданга сал,
куркыт, яна, кисәтеп тугры юлга сал,
бер сүзенә инанма, миңа колак сал —
әдәпсезлек кылмасын ул!» — дия инде.
Газиз әйтә: «Әйа, углан,ниләр кылдың,
мондый эшне син ничек дип, мөмкин күрдең?!
Вафасызлык[34] белән үзең гөнаһлы булдың —
безне илгә хур вә рисвай иттең инде!»
Йосыф әйтә: «Әйа, хуҗам, ул гөнаһлы,
хакыйкатьтә мин арумын, ул языклы,
Зөләйханың шаһиты юк, мин шаһитлы —
кече олан миңа таник булыр инде».

*(Нарасый баланың таныклык бирүе)*

Газиз әйтә: «Ул бик яшьтер, сабый олан,
ул — унҗиде көнлек кенә, яңа туган,
бу хәлендә сөйләмидер һичбер инсан[35] —
ничек итеп ул таныклык бирсен инде!»
Йосыф әйтә ул газизгә: «Әйа, солтан[36],
куәтле һәм кодрәтледер иям сөбхан,
ул сөйләтсә, сөйләр шиксез сабый углан —
хаклыгыма ул таныклык бирер инде».
Шулчак анда газиз Кыйтфир әмер кылды,
ул сабыйны әнкәсе тиз алып килде,
газиз аны күтәреп кулына алды —
ягымлы итеп аңа сорау бирә инде.
*Сабыйга әйтә сорап: «Әйа, наным[37],
булмагандыр дөньяда синең мисалең,
бу хәлеңдә ни белерсең, ничек хәлең —
күргәнеңне безгә сөйләп бирсәң инде».
Телгә килеп, матур, дөрес сөйли бала,
газиз исә тыңлап тора карап аңа,
сөйләвенә бөтен галәм таңга кала —
ни күргәнен, хак тел белән әйтә инде.
Әйтә бала: «Ике йөзле мин булалмыйм,
нахак сөйләп хакка гыйсъян кыла алмыйм,
ялган таныклык итүгә бара алмыйм —
таңре күреп, үз хөкемен бирер инде.
Әйа, газиз, чын хак сүзне ишет миннән,
аңласаң ки, бу серләрнең асылы нидән,
мәгълүм була бу эш Йосыф кулмәгеннән —
арт итәге ертык кеше гаепсез инде».
Ничеклеген хәлнең газиз анык күрде:
арт итәге Йосыфның нәкъ ертык иде,
сабыйның һәм таныклыгын лаек күрде —
Зөләйханың языклыгын әйтә инде.
Әйтә аңа: «Әй, Зөләйха, сүзең ялган,
ачыкланды — син икәнсең гөнаһ кылган,
гаепле син, гозер телә бар Йосыфтан,—
тәүбә итеп, ул ниятең ташла инде...»
*Йосыфка да Кыйтфир аннан үгет бирде,
бу әхвәлдән гыйбрәт итеп киңәш бирде,
яхшы, йомшак сүзләр белән бик үтенде —
«Зинһар сакла Зөләйханың серен инде!»

[34] Ышанычсызлык
[35] Кеше
[36] Югары катлау вәкиле
[37] Нәнием



## VII бүлек. Зөләйха гайбәтен сөйләгән хатыннар

Мисырдагы ул берничә байбикәләр
моны иштеп бер-берсе илә сөйләшәләр,
гаеп итеп Зөләйхаыны көлешәләр —
һәр берсе шул бер сүзне сөйли инде.
Зөләйха, дип, үз колына гашыйк булган,
колы аңа буйсынмаган — рисвай булган,
ире газиз бу әхвәлне анык белгән —
колын куа чыкканын да күргән инде.
•Зөләйханы гаепләшкән ул хатыннар,
һәр берсе төрле сүзләр таратканнар:
«Газиз хатыны шундый эш кылган,— диләр,—
ил алдында ким-хурлыкка төшкән инде!» (...)
Бу гайбәтләр Зөләйхага ишетелгәч,
гаять зур бер мәҗлес корып дәгъват[1] кылгач,
бөтенесе анда дүрт йөз хатын килгәч,
һәр берсе түргә утырмак була инде.
•Зөләйха әйтә: «Йа, Йосыф, син аңла инде,
бу юлы син сүземне бер тыңла инде,
дәшү белән син килеп кер анда,— диде,—
бу хатыннар күркеңне бер күрсен инде!»
Йосыфны ул бик зиннәтләп киендерде,
һәм үз кулы белән тарап чәчен үрде,
һәм кулына кызыл алтын табак бирде —
күтәреп аны мәҗлескә илтер инде.
Ул хатыннар көрсиләргә утырдылар,
берәр пычак, берәр әфлисун китерделәр,
биреп кулга: «Әрчегез!»— дип боердылар —
нәкъ шул чакта Йосыф килеп керер инде.
Килеп керде — борылып аңа карадылар,
җамаленә исләр китеп таң калдылар,
багып-карап күзләрен һич алмадылар —
бармакларын әфлисун дип киссә дә инде!
Багып һаман Йосыфка һич туймадылар,
бармакларын кисә-кисә турадылар,
пычак белән ни кискәнне тоймадылар —
үз-үзләрен онытып алар карый инде.
•«Валлаһи бу,— диешәләр,— адәм түгел,
моның кеби кол булуы мөмкин түгел,
моны күреп, ничек шашмый түзсен күңел —
бу — фәрештә, күктән иңгән!» — диләр инде.
Ди Зөләйха: «Инде үзегез күрдегезме,
минем йөзем нидән сулган, белдегезме,
бер күрүдүк кулларыгыз кистегезме —
акылыгызны җуйдыгызмы сезләр инде?!»
«Мин Йосыфны күргәнемә нәкъ җиде ел,
Гыйшкым һаман көчәядер һәркөн саен,
үзем мескен бер чарасыз һәм гаҗизмен —
шулай да әле сабрым сездән артык инде.
Күрдегезме, минем рәнҗем аслы нидән,
бу угланның йөзе күркәм нурлы көннән,
буе зифа, теле татлы күп меңнәрдән —
йөзен күргән җанын фида кылыр инде».

*(Йосыфның зинданга салынуы)*

Ахыр әйтте: «Йә әмремә ул буйсына,
шулай итеп бу рәнҗемә бәлзәм[2] була,

[1] Чакыру
[2] Бальзам

4*

буйсынмаса мәхбүс кылам, тоткын була —
бөтен гомере тар зинданда үтәр инде...»
Йосыф үзе дә ялвара тәңресенә:
«Салдырт мине,— дип,— Кыйтфирның төрмәсенә,
куркам төшүдән Зөләйханың фетнәсенә —
гөнаһ эштән миңа зиндан артык инде». (...)
Халик аның теләгәнен кабул кылды —
Иблис мәлгунь ниятенә киртә корды,
Зөләйханың фетнәсеннән һәм коткарды —
«Нәфсе ерак булсын вәсвәсәдән инде».
«Әйа, Йосыф,— ди Зөләйха,— ни кыласың:
әллә минем әмеремәме буйсынамсың,
әллә мәңге зиндандамы син каламсың —
йә әйт, кайсын ихтыяр иттең инде?!»
Җавабында: «Тәңрегә гайсъян кылганчы[3],
азып-тузып мәңге оятка калганчы,
кыямәт көн хак кашында хур булганчы —
бу көн миңа зинданың яхшырак инде».
Моны ишетеп Зөләйханың ачуы чыкты,
гаре килде, күңеленә хәйлә төште,
шундук Йосыф биленнән кәмәрен[4] чиште —
асыл киемен салдырып ук алды инде.
Мәлик Рәййан хозурына ашыгып килә,
патшага ул Йосыфтан шикаять кыла:
«Буйсынмый һич,— диеп,— бер кол углан миңа —
боерсагыз, зинданга аны салам инде.
Аны кыйммәт бәягә мин алган идем,
бөтен малым аңа фида кылган идем,
әмма бик күп әдәпсезлек аннан күрдем —
ышанычсыз, әйткәнемне кылмас инде».
«Буйсынмаса, әгәр сиңа колың углан,—
диеп аңа хөкемен әйтте малик Рәййан —
бик тиештер ул угланга төрмә-зиндан,
әмер бирәм, аны мәхбүс кыл син инде».
Әмерен алып, Зөләйха тиз кире кайтты,
осталардан анда бер сандык ясатты,
Йосыфны шул сандык эченә салдыртты —
йөкче аны зинданга ук илтә инде.
Газиз Кыйтфир бу әхвәлдән хәбәр белеп,
бик пошынып, Зөләйхага каршы чыгып:
«Ул гаепсез,— диде,— синдә барча гаеп»,—
ул сандыктан Йосыфны чыгартты инде.
Чиштереп бау-богавын әмер кылды:
ефәк-атлас түшәкләр һәм түшәттерде,
тирәсенә үз хезмәткәрләрен куйдырды —
«Тиз чыгартам, һич курыкма»,— дияр инде.
Аннан соңра озак тормый, бераз көннән,
җанын алды ул газизнең мәлик Рәхман[5];
карендәше бар иде аның мәлик Рәййан —
солтанәте ул Рәййанга калды инде.
*Коткарды күп тоткыннарны мәлик Рәййан,
Йосыфны тик чыгартмады ул зинданнан,
Җәбраилен җибәрде аңа мәлик Рәхман —
хак сәламен, үгетләрен җиткерә инде.
*Җәбраил бер аппак энҗе алып килде,
алып килеп Йосыфка йотарга бирде —
төш юрау вә хикмәт гыйльмен анда белде,
кәрамәтле[6] пәйгамбәр ул булды инде.

[3] Каршылык итү
[4] Затлы билбау
[5] Алла
[6] Могҗиза ясаучы

*(Икмәкче һәм шәрабче хикәяте)*

Ул Мисырга Йәмәннән бер шымчы килгән,
бик күп маллар китереп ул ришвәт биргән,
икмәкчене, шәрабчене ант иттергән —
Рәййанга агу бирергә диеп инде.
Мәлик Рәййан бу әхвалдән хәбәр ала,
икмәкче һәм шәрабчене хибес кыла[7],
байтак көннәр тар зинданда алар кала —
тоткын булып кайгы-хәсрәт чигәр инде.
Бу шәрабче ул зинданда бер төш күреп,
сорый икән: «Төш юраучы бармы?» — диеп,
Йосыф сиддикъ анда аңа җавап биреп: —
«Төшеңне әйт, мин юрармын» дия инде.
«Мин күргәнем,— ди шәрабче,— бик гаҗәп төш:
пешкән йөзем, тик өч тәлгәш, сыгам имеш,
сыгып алтын кәсаләргә коям имеш,
соңып бирәм Рәййанга аны — эчә инде».
«Мин дә бер төш күрдем әле,— ди икмәкче,—
баш өстемә күтәргәнмен өч икмәкне,
мин Рәййанга аны имеш, ди, илтмәкче —
кошлар килеп, баш очымнан чукыр инде...»
Бу икенең төшен Йосыф юрап бирде,
шәрабченең төшенә котлы юрау килде:
«Сөенчең зур, сиңа ирек якын,— диде —
Рәййан сиңа зур дәрәҗә бирер инде».
Икмәкчегә диде: «Хәтәр синең төшең,
әй, аяныч, бигрәк мөшкел синең эшең,
шундый яман фал чыкты[8], бетәр башың —
Рәййан, шиксез, сиңа җәза бирә инде.»
Моны ишетеп ул икмәкче фөрьяд кыла,
күрмәдем мин андый төш дип инкяр кыла,
Йосыф Коръән аяте илә дәлил кыла:
«Хак әмре илә килгән каза китмәс инде».
Ул шәрабче Йосыфның хаклыгын белде,
әйткәненә инанып һәм мөэмин булды,
зиндан халкы Йосыф тугрылыгын күрде —
икмәкче исә кяфер булып калды инде.
Өч көн узды шул арада бу хәлләрдән,
икмәкчене дарга астырды мәлик Рәййан,
һәммәсе дә калды моңа гаҗәп-хәйран —
күзен-башын кошлар килеп чукыр инде.
Аннан — Рәййан шәрабчене котылдырды,
иңнәренә төрле төсле тун кидерде,
шәрабчелек дәрәҗәсен кире бирде —
Йосыф аңа аманәт сүз әйтер инде.
Әйтә Йосыф: «Рәййанга бер искәртсәнә,
әхвәлемне ул мәликкә[9] белдерсәнә,
бер гөнаһсыз икәнемне сиздерсәнә —
алларында мине телгә алып инде».

*(Гарше күкләрдән[10] Йосыфка шелтә)*

Шул ук сәгать күк иясе олуг сөбхан[11],
дөньядагы бар мәликкә кадир солтан[12],
җибәрде ул Җәбраилен, иңде күктән —
сәлам китереп Йосыфка ул әйтә инде:
«Ягъкубтан,— дип әйтә,— сине кем сөйдерде,
кардәшләрең фетнәсеннән кем коткарды,

[7] Төрмәгә яптыра
[8] Юрау
[9] Патшага
[10] Алла даирәсе
[11] Алла
[12] Күк патшасы

ул тар кое төпләреннән кем чыгарды —
кем иркенлек, рәхәт тормыш бирде инде?!
Зөләйханың мәкереннән кем котылдырды,
кодрәт белән ул сабыйны сөйләттерде,
ул бикләүле җиде ишектән һәм чыгарды —
бозык эштән кем соң йолып калды инде?!»
Йосыф әйтә: «Бу игелекләр бер тәңремнән,
бу кадәре мәрхәмәтләр килә аннан,
һәрчак күрәм шәфкать-ярдәм гафурымнан —
михнәтләрдән ул коткарды мине инде».
«Алай булгач, сыенмадың ник аллага,
аның хөкемен Рәййан патша ничек ега?!
Хак боерса гына адәм чара кыла —
чын кадирлек тик бер хакка лаек инде!»
Йосыф анда үз гаебен аңлап белде,
шул сәбәпле каты хәсрәт-кайгы җыйды,
әйткәненә үкенеп бик тәүбә кылды —
тәңресенә сәҗдә итеп ялына инде.
Аннан соңра ул Җәбраил янә килде,
тәңресеннән Йосыфка күп сәлам кылды:
«Башың күтәр, теләкләрең кабул булды —
халикыңа кыл син шөкер-догаң инде.
Берничә ел тик зинданда,— ди,— калырсың,
ахыр чыгып, рәхәт-нигъмәтләр табырсың,
ул Мисырның мәликлеген һәм кылырсың[13]—
бу михнәткә сабыр итсәң» дия инде.

[13] Хөкемдарлык кылу



## VIII бүлек. Кәнган[1] гарәбе турында

Ул зинданда Йосыф әле озак калды,
шул арада Кәнганнән бер гарәп килде,
тәрәзәдән карап аны Йосыф күрде —
дөя куып, ашыгып ул үтәр иде.
Ул гарәби зинданнан бик якын узды,
Йосыф анда икәнлеген дөя сизде,
дөя бузлап Йосыфка һәм мәгълүм кылды:
«Мин Кәнганнан киләмен»,— дип әйтер инде.
«Анда атаң Ягъкубны мин күреп килдем,
аның хәле авырлыгын белеп килдем,
хәсрәт йотып зар елавын сизеп килдем —
көннән-көнгә кайгысы аның арта инде.
Синең хәсрәтеңдә Ягъкуб даим яна,
аңа синнән газизе юк бу дөньяда,
сине уйлап, егълый-егълый җиргә ава —
берни хәлләр һушсыз калып ята инде.
Егълый-егълый ике күзе күрмәс булды,
зәгыйфьлектән буыннары тотмас булды,
һични эшкә кулы-көче җитмәс булды —
һәр даимән «Йусеф!» диеп агълар инде.
«Йусефем!» дип һәр даимән егълаганнан,
көнен-төнен сиңа өмет баглаганнан,
каушу көтеп, фиракъ[2] йотып агълаганнан —
яшь урнына күзеннән кан ага инде!
Һаман кайгы йортында ул, көн-төн егълый,
аның зари кылуларын галәм таңлый,
рәхим мәүля рәхмәтенә өмет баглый —
каушу көтә, һич өметен өзми инде».
Мескен дөя Йосыфка бик якын килгәч,
Ягъкуб хәлен ул мәхбускә[3] хәбәр кылгач,
Йосыф өне колагына ишетелгәч —
дөя чүгеп, капка төбендә калды инде.
Дөя бузлап, хәлне игълан кылу белән,
бу хәбәр Йосыфка мәгълүм булу белән,
Ягъкуб хәле ничеклеген белү белән —
Йосыф егълап, йөзе белән егыла инде.
Шул сәгатьтә ул гарәби анда килгәч,
дөясен ул капка алдына чүккән күргәч,
агач алып сугам диеп, ният кылгач,—
шундук аның аягын җир тота инде.
Ул гарәби ни кыласын белалмады,
аягын һич җирдән тартып алалмады,
кымшатырлык та көч-дәрман табалмады —
аптыраудан нишләргә дә белмәс инде.
Йосыф күреп: «Йа, гарәби, ни диярсең,
кайдан килеп, кайларга,— ди,— юл тотасың,
бер гөнаһсыз ул дөяне ник орасың —
кайдан үзең, хәбәрең ни — сөйлә инде?»
Ошбу гарәп Йосыфны тиз күреп алды,
аңа Йосыфның сөйләве әсәр кылды,
үз хәленнән Йосыфка ул зари кылды —
«Аягымны җир тотты бит!» дияр инде.
«Әй, гарәби,— диде Йосыф,— ниятең нәдер?
Аякларың тотылуы — фигылеңнәндер,
бу дөяне кыйнарга теләвеңнәндер —
ул касдеңне[4] күңелеңнән чыгар инде».
Үз гаебен аңлап гарәп тәүбә кылды,
җир җибәрде аягын һәм азат булды.

[1] Палестина
[2] Аерылу
[3] Тоткын
[4] Яман ниятеңне

котылу белән ул Йосыфка якын килде —
кулын үбеп, сәлам-хөрмәт кылыр инде.
*Аннан Йосыф ул гарәптән хәл сорашты,
гарәби һәм әхвәлләрен хәбәр итте,
белгән кадәр берәм-берәм сөйләп китте —
гарәп сөйли, Йосыф егълап тыңлый инде.
«Мин Кәнганнан,— диде,— бүген таңда килдем,
бу шәһәргә йөк китереп, сәүдә кылдым,
берәр мисрый кызыл алтын[5] файда кылдым —
малым саттым, Кәнганыма кайтам инде».
«Аһ,— ди Йосыф,— син Кәнганнан киләсеңме!
Анда бар бер олуг агач — беләсеңдер,
тармак-тармак карт бер тирәк, күргәнсеңдер —
ботаклары уникеме төгәл инде?
*Аһ, аяныч, нинди ерак Кәнган иле,
аерылганнар өчен кыен үтәр юлы;
җилләр искәндә, һәр даим Кәнган җиле
ул агачтан хәсрәт исе китерә инде!»
«Төшенәм кебек,— ди гарәп,— бу сүзеңне,
фәһемләдем синең әйткән ул сереңне,
әмма торам гаҗәпсенеп мин үзеңне —
нинди хикмәт биредә бар, диеп инде.
Олуг агач дигән сүзең Ягъкубтыр ул,
унбер углы хезмәтенә әзер торыр,
уникенче — Йосыф атлы — хәзер юктыр —
белмәм чынмы, бүре ашаган, диләр инде.
Аннан бирле мескен Ягъкуб булды вәйран[6],
зари кыла кан-яшь белән егълап дәвам,
Йосыфы белән кавышуны эстәп һаман —
таңресенә һәмишә[7] ялвара инде.
Кайгы-хәсрәт йортыннан ул инде чыкмас,
күңле моң-зар, авызына бер ризык алмас,
күзен ачып бу җиһанга караш салмас —
егълый-егълый ике күзе күрмәс инде». (...)
Моны ишетеп Йосыф нәби бик егълады,
алып кулын гарәбинең сүз багълады:
«Әманәтем, кер Ягъкубка кайткач,— диде,—
ул мәзлүмгә миннән сәлам әйтче инде! (...)
*Озатканда гарәбине шулчак Йосыф,
салып бирде беләгеннән бер беләзек,
күрешүнең бүләге, дип, бер истәлек —
«Бу беләзек миннән ядкарь булсын инде!
Йа, гарәби, әманәтемне онытма,
сәламнәрем тизүк җиткер, озак тотма,
минем хәл-әхвәлләрем әйт син Ягъкубка —
минем өчен ул бер дога кылсын инде». (...)
«Кем икәнең,— ди ул гарәп,— белсә идем,
пәрдә ачып йөзеңне дә күрсә идем,
йөзең күреп уй-шигемнән чыкса идем —
әйтер идем кемлегеңне аңар инде».
Диде җавабында: «Моны әйтмәк өчен
һәм йөземнән бу пәрдәне ачмак өчен
һич рөхсәт юк, теләгәнең кылмак өчен —
рөхсәтсез эш асла котлы килмәс инде.
Инде сиңа ошбу биргән әрмаганны[8]
миннән ядкарь-әманәт дип сакла аны,
ул саф кызыл якуттандыр, кыйбатлыгы —
егерме мең алтынга тиң килер инде». (...)

[5] Мисыр акчасы
[6] Хәле мөшкел
[7] Һәрвакыт
[8] Күчтәнәч

*(Гарәби, Динә һәм Ягъкуб)*

Йосыф белән саубуллашып үрә торды,
рөхсәт алып кайтыр якка юлга керде,
бик ашыгып көне-төне сәфәр кылды —
бу хәбәрне җиткерергә диеп инде.
Кәнганга ул бик соң — кичен кайтып керде,
өендә күп юанмады, ял итмәде,
өнәмәде күңле, һич тынгы белмәде —
җыенып тиз Ягъкубка дип китте инде.
Ул гарәби Ягъкубка шул төндә килде,
кычкырып ул тыштан ук сәлам бирде,
Динә чыгып: «Кем ул анда йөри,— диде,—
кара төндә, ни эшләре калган инде?!»
«Хәбәрем бар,— дип җавап бирә гарәби,—
кая монда ул кайгылы Ягъкуб нәби?
Мин Мисырдан күреп килдем бер гыйбри —
аны сорап, күп-күп сәлам әйтте инде.
Моны ишетеп, Динә ашыгып өйгә керә,
Ягъкуб нәби намазында иде утыра,
намаз беткәч, уңга-сулга сәлам бирә —
«Ни бар анда?» — дип Динәдән сорый инде.
Өндәделәр гарәбине — өйгә керде,
Ягъкубка ул әхвалләрне сөйләп бирде:
«Мисырда бер гыйбри сорады,— дип,— сине —
зинданда ул тоткын; читтән килгән инде.
Моңлы-зарлы, гаҗизлектән тәкате такъ[9],
синең йөзең бер күрергә өмете хак,
хәер-дога синнән көтә икән озак —
дога кылсаң, ул котылып чыксын иде...»
Ягъкуб диде: «Син соң йөзен күрмәдеңме,
аты ничек, кайдагы ул — белмәдеңме,
ни сәбәптән тоткынлыкта, әйтмәдеме —
ничөн безне алай сагынып сорый инде?»
Гарәп сөйли: «Сорап исмен һич әйтмәде,
әхваленнән миңа берни белдермәде,
йөзеннән ул нәкабен[10] һич күтәрмәде —
алай да,— ди,— нуры балкып чыгар инде».
Ягъкуб нәби гарәбигә дога кылды:
«Бу сүзләрең,— дип,— миңа бик татлы килде,
моңлы күңлемә бу дәмдә[11] рәхәт бирде,—
сөенеч хәбәргә шөкрана[12] кирәк инде».
Гарәп әйтә: «Шөкранасы инде булды,
бар дөньялык морадымны хасил кылды,
бер беләзек ул,— ди,— миңа багышлады —
егерме мең динар аның хакы инде».
Үтенәдер ул Ягъкубка: «Йа, Исраил,
минем өчен ахирәтлек бер дога кыл,
ярлыкасын диеп мине мәүләм җәлил —
дөнья — фани, ахирәт — ул бакый инде».
Ягъкуб нәби кул күтәреп дога кыла,
халик[13] аның догасын кабул кыла.
Йосыфка аны Җәбраил мәгълүм кыла —
сөенечле хәбәр алып килә инде.
Килә, әйтә: «Ишет, аңла, әйа сиддикъ[14],
ирешә әткәң догасы, җиңде хаклык,
котыласың, бирә сиңа падишаһлык —
михнәтләрдән рәхәткә чыгасың инде!»

[9] Ягъни сабыры соңгы чиккә җиткән
[10] Йөзне каплый торган пәрдә
[11] Бу сулышта
[12] Рәхмәт, сөенче бүләге
[13] Алла
[14] Йосыф

Унике ел ул зинданда Йосыф калды,
ахыр, Ягъкубның догасы кабул булды
(ошбу хәбәр моннан әүвәл яд кылынды) —
шул сәбәптән аңа котылу ирешә инде.
Көннәрдә бер килә аңа ул Җәбраил,
җибәргән аны Йосыфка тәңре җәлил:
«Төштән иде михнәтләрең, хәзер син бел —
котылуың да төштән үк була инде».

*(Мәлик Рәййанның төше)*

Тәкъдир итеп[1] хөкме белән мәлик дәййан[2],
бер төш күргән Мисыр шаһы мәлик Рәййан,
юраучылар аптыраган, калган хәйран —
һич бересе моңа юрау тапмас инде.
Рәййан сөйли: «Җиде симез сыер күрдем,
һәркайсының аркасына менеп йөрдем,
һәм берсеннән берсенә мин күчеп йөрдем —
бу төшемнән гаҗәепкә калдым инде.
Янә күрдем җиде сыер, бик арыклар,
җидесе дә үтә зәгыйфь, бик ябыклар,
ачлыктан тик зәгыйфьләнгән ул арыклар —
симезләрен бер-бер артлы йота инде!
Җиде башак бодай янә туйган күрдем,
җиде башак бодай янә корыган күрдем,
ул бодайлар янә күккә очкан күрдем —
өч баш бодай җирдә янә калды инде».
Тәгъбирчеләр[3] моңа юрау табалмыйлар,
бу төшкә һич алар мәгънә бирәлмиләр,
һич аслына, серенә төшенә алмыйлар —
хәйран булып, аптырашып торырлар инде.

*(Шәрабче Йосыфны искә ала)*

Аларга бик пошып мәлик торганында,
йөгреп килеп ул шәрабче керде анда,
аның исенә килде Йосыф шул чагында —
тик үкенеп, аптырап ул калды инде.
Шәрабченең хәлен Рәййан алды күреп:
«Нидән,— диде,— калдың болай бик үкенеп,
бу кадәр борчуга төштең нидән,— диеп,—
монда нинди хикмәт бар, син әйтче инде?»
Шәрабче әйтә: «Ишетсәнә, шаһы җиһан[5],
зинданыңда синең бар бер гыйбри углан,
хикмәт гыйльмен бүләк иткән аңа сөбхан —
белсә тик ул төшең мәгънәсен белер инде.
Мәлик сорый: «Ул угланны ничек күрдең,
төш юравын аның син,— ди,— ничек белдең,
тәгъбирчелек кылганын син кайда күрдең —
аны кайчан син тәҗрибә иттең инде?!»
«Мин зинданда,— ди шәрабче,— булган идем,
анда чакта бер гаҗәп төш күргән идем,
ул угланнан юравын үтенгән идем —
миңа аның юравы юш килде инде.
Акылы камил, гыйльме төгәл, үзе гарьле,
буе сылу, холкы лятиф[6] меңәр төрле,
дине бөтен, эше итагать, йөзе нурлы —
пәрдә ачса, тирә-юньгә балкый инде».
Мәлик сорый: «Зинданга,— дип,— ничек кергән,



## IX бүлек. Йосыфның зинданнан чыгуы

[1] Язмыш буенча
[2] Алла
[3] Төш юраучы
[4] Патша
[5] Патша
[6] Нәфис, мөлаем

ягъни аның язысы ни, ул ни кылган?»
Шәрабче әйтә: «Тәңресе аңа каза биргән —
унике ел зинданда ул ята инде».
«Бар тизрәк,— шәрабчегә әйтте Рәййан,—
минем күргән төш мәгънәсен бел аңардан,
хезмәтенә торып аяк өсте, аннан —
житкер аңа котылу сөенечен инде».
«Бу эшкә мин,— ди шәрабче,— гажиз калдым,
чөнки аның каршында мин оят булдым,
хәлен сезгә белдерәм дип, вәгъдә кылдым,
жиде елдан гына исемә төште инде».
Үгетләде шәрабчене мәлик Рәййан:
«Бардыр аның бер хуҗасы, кадир сөбхан,
барча каза килгәнен ул белә аннан —
кайгырма һич, сине гафу итәр инде».

*(Шәрабче Йосыф янына бара)*

Шәрабче ул зинданга йөгереп килде,
керү белән ул Йосыфны күреп белде,
әдәп белән аңа сәлам-хөрмәт кылды —
оялып, җиңен йөзенә каплар инде.
Йосыф сиддикъ шәрабчене тәкъдир итте[7],
диеп аңа: «Бу казаны тәңрем бирде,
мәлгунь шайтан ара бозып касед итте[8]—
һич оялма, хата синнән түгел инде».
Аннан сөйли ул шәрабче хәл-әхвәлен,
мәликнең бер бик гаҗәеп төш күргәнен,
тәгъбирчеләр юрый алмый интеккәнен —
«Рәййан поша, һич кеше,— ди,— белми инде...» (...)
*Шәрабче Йосыф алдында кул кушыра,
хезмәтенә аяк өсте әзер тора,
бәйнә-бәйнә төшне Йосыф юрап бирә —
һичбер шиксез, берәм-берәм әйтә инде.
Әйтә инде: «Җиде ел бик очсыз була,
иген уңа, мал-байлыкка дөнья тула,
аннан соңра корылык килә, кытлык була —
җиде ел бик каты тарлык булыр инде.
Аннан янә рәхман[9] рәхим кылачактыр,
мәхлукларга шатлык-рәхәт киләчәктер,
ул арзанлык, төрле нигъмәт булачактыр —
муллык-байлык көннән-көнгә артыр инде».
Шәрабче тиз патшасына кайтып кире,
Йосыф әйткән тәгъбирләрен сөйләп бирде,
(мактап аны үз карашын һәм белдерде) —
сакый[10] сөйләр, Рәййан исә тыңлар инде.
«Шәрабдарем! — диде Рәййан,— тиз кире бар,
әмерем белән аны мәхбүслектән чыгар,
затлы киемнәр кидереп монда китер —
зиндан аңа һич муафыйк түгел инде!
Әгәр адәм бу сыйфатлы фазыл[11] икән,
гыйльме хикмәт[12] җәһәтендә камил икән,
дине дөрес, йөзе нурлы, гакыйль икән —
аңа гыйззәт вә ихтирам лаек инде.
Мин аңарга затлы кием кидерермен,
бик олуглы дәрәҗәгә менгерермен,
өстенлеген һәммәләргә белдерермен —
дөньяда ул хаслар хасы[13] булыр инде.
Шәрабче Йосыф янына тагын китте,

[7] Дөрес бая бирү
[8] Усал ният кылу
[9] Алла
[10] Шәрабче
[11] Булдыклы
[12] Хикмәтле белемнәр
[13] Аеруча дәрәҗәле

сәлам биреп, бик олуглап кулын үпте:
«Гамь-кайгыдан котылуың бүген,— диде,—
күңлеңә хуш сөенечләр килсен инде».

*(Бармакларын кискән хатыннардан сорау алу)*

Йосыф әйтә: «Йа, шәрабче, кире бар син,
кулын кискән Мисыр хатыннарын җый син,
мәлик Рәййан бу эш аслын төгәл белсен —
моны үтәп чыгу өчен тырыш инде.»
Сакый кайтты, ул Рәййанга хәбәр бирде,
мәлик Рәййан бу чараны мәгъкуль[14] күрде,
кулын кискән хатыннарны тиз җыйдырды —
Зөләйха да анда хәзер килгән инде.
Мәлик әмере: «Йә, сөйләгез хәлегезне,
ни сәбәптән кистегез сез кулыгызны!»
Зөләйха әйтә: «Гафу итсәң иде безне,—
гаеп — бездә, Йосыф гаепсез иде инде...»
Хәлне белгәч, мәлик Рәййан әмер итте,
Йосыфка дип зиннәтле күшк[15] төзетте,
эчен атлас-ефәкләр илә түшәтте —
шундый бик шәп сарай әзер кылды инде.
*Шәһәр белән ул зинданның аралыгы,
дүрт фәрсәхлек[16] булыр иде ераклыгы
шул кадәр иде Йосыфның үтәр юлы —
үтәр юлга мәлик гаскәр тезәр инде.

*(Йосыфның зинданнан чыгарылу тантанасы)*

Тезеп гаскәр, Рәййан атка атландырды,
килеп, зиндан алдында ул аттан төште,
Йосыфны чыгарып үзе алып килде —
хәлгәт[17] бирде, барчасы шат булыр инде.
Йосыф сиддикъ ул зинданнан чыгар булгач,
зиндан әһле елый-елый мәхрүм калгач,
алар өчен Йосыф бик күп дога кылгач —
догасы аның гарше күккә[18] ирешә инде.
Ирешә бик теләгәч ихлас күңелдән,
әмер итә коткарырга мәүле-рәхман[19],
азат итә инде аларны мәлик Рәййан:
«Багышлыймын Йосыф хакына»,— дияр инде.
Каршы алырга бөтен Мисыр халкы чыгып,
хас вә гавам[20] шатлык илә аңа багып,
күреп йөзен Йосыфның һәм ләззәт алып —
алтын-көмеш вә энҗеләр сибәр инде.
*Йосыф кылды догаи шөкер гафурына,
бик күп мактау-рәхмәт әйтте рәхманына,
аннан сәлам бирде әүвәл Рәййанына —
аңа җитмеш ике телдә[21] сөйләр инде.
*Сөйләп төрле телдә аны мәдех кыла[22],
сүзен ишеткән һәр кем моңа гаҗәпләнә,
ачлар туя, сусаганнар тәмам кана[23]—
йөзен күрсә, дөнья рәхәт була инде.

*(Йосыфның Мисырда идарә итүе)*

Рәййан күреп Йосыфның бу гүзәллеген,
гаҗәп сәләт, табигате, хуш фигылен,
бирде аңа бөтен малын вә мөлкәтен —
«Мөлкәтемә син боерык кыл!» — диеп инде.
*Мәүля бирде сиддикына дәүләт-бәхет,

[14] Акылга сыешлы
[15] Бакчасарай
[16] Җиде-сигез чакрым
[17] Аеруча хөрмәт йөзеннән бирелә торган өс киеме
[18] Ягъни: аллага
[19] Алла
[20] Һәркем (бай һәм ярлы)
[21] Йосыфның күп тел белүенә ишарә
[22] Мактый
[23] Канәгатьләнә

кодрәт берлә бүләк итеп мөлкәт-тәхет,
Рәййан бирде аңа инанып хөкүмәтлек[24] —
«Мәмләкәтем сиңа лаектыр»,— дип инде.
Таҗ урап, тәхеткә менде Йосыф нәби,
утыз яшәр егет иде ул чак гомере,
якты иде кояш кебек ул йөз нуры —
күргән кеше карап аны туймас иде.
Гакълы камил, гыйльме хикмәтләрне белә,
дәгъвачылар, фәтва сорап, аңа килә,
бай-ярлыга гадел-дөрес хөкем кыла —
һич кемсәгә җәбер-җәфа кылмас инде.
*Бер көн сөаль бирде аңа малик Рәййан:
«Ни сәбәпле гыйльмең күп-мул, изге углан?»
Йосыф әйтте җавабында: «Кадир сөбхан
рәхмәте илә миңа бүләк итте инде».
Рәййан патша Йосыфның әхвәлен белде,
рәсүл икәнен таныды вә инанды,
ислам динен лаек күреп кабул кылды —
кулын биреп, ихлас мөэмин булыр инде.
«Динең-юлың хак икәндер, гадел торыр,
сиңа моны бүләк иткән — тәңре торыр,
сиңа миннән бу мәликлек лаек торыр —
Мисыр иле Йосыф әмерен йөртсен инде!»

*(Мисырда Йосыф күргән чаралар)*

Даругалык[25] Йосыф хөкем кылыр булды,
иген-ашлык күп игәргә дип боерды,
башак көе кибәннәргә ул куйдырды —
сугылганы амбарларга тулар инде.
Мисырда җиде ел буе киңлек булды,
төрле нигъмәт-мөлкәт белән дөнья тулды,
ул хәл кичте — җиде ел корылык булды —
Йосыф иген икмәскә, дип, боерды инде.
Җиде ел күктән яңгырлар һич таммады,
йомшак-талгын җил искәне һич булмады,
җир өстендә яшел чирәм һич калмады —
каты эссе, корылык каршы торды инде.
Ул шәһәргә газиз[26] Йосыф хәбәр салды,
Мисыр халкы амбарларга хәзер барды,
алтын-көмеш биреп ашлык сатып алды —
кызыл алтын тәңкәләрен түләп инде.
Икенче ел бирделәр ат-качырларын,
өченче ел — ефәген вә комачларын,
дүртенче ел — терлек-туар, йорт-җирләрен —
бишенче ел — угылын-кызын бирер инде.
Үзләре һәм кол булдылар алтынчы ел
(Йосыфны ул сатканнары, карием[27], бел),
һәммәсе алар Йосыфка булдылар кол —
бөтен Мисыр аның колы булды инде.
Җәбраил аша халиктан вәхи иңде:
«Әй, Йосыф, син шөкер-догадамы[28],— диде,—
Мисыр халкы бөтенесе колың булды —
сине сатканнар сиңа кол хәзер инде!»
Алтынчы ел бик тарлыкта яшәп үтте,
ашлык-бөртек амбарларда тәмам бетте,
газиз Йосыф ахыр мөшкел хәлгә төште —
«Йа, илаһи, ярдәм синнән!» — диер инде.
Шул чагында мөхбир хәзрәт[29] килде хазир

[24] Ягъни: Рәййан исеменнән идарә итә башлый
[25] Бирелә: идарәче
[26] Мисыр газизе
[27] Укучым
[28] Ягъни: инде риза булып, миңа рәхмәт догаңны кылып торасыңмы
[29] Ягъни: Җәбраил, хәбәрче фәрештә

(җибәргән аны Йосыфка мәүля кадир[30]):
«Йөзен ачып халыкка,— дип,— кылсын заһир[31]—
кодрәтемне бу көн янә күрсен инде!»
Йосыф сиддикъ Мисыр әһленә белдерде:
«Иртән мәйданга чыгарсыз,— дип боерды,—
анда минем йөземне күрерсез,— диде,—
йөземне күргән ачлыктан туяр инде».
Олы-кече, түрә, гавам — барысы килде,
җөмлә Йосыф җәмаленә бакты, күрде,
ашау-эчү кайгысы һәм онытылды,—
күргән һаман күреп күзе туймас инде.
Аена бер Йосыф сиддикъ чыгар иде,
күрекле йөзеннән пәрдәсен ачар иде,
олы-кече, бай-юксылы багар иде —
һәм бер айга тикле ризык капмас инде.

[30] Кодрәт иясе
[31] Күренеп торган



## X бүлек. Йосыфның вәзире турында

Көннәрдә бер ул хәбәрче килде хазир
(җибәргәндер Йосыфка аны мәлик кадир):
«Йа, Йосыф, хак әмерен әйтәм,— диер,—
сәйранга чык сараең-лә иртән инде!
Һичшиксез хакыйкать дип шуны бел син:
кемгә генә очрасаң да, алып кил син,
алып килеп үзеңә хас вәзир[1] кыл син —
халик әмре диеп төгәл аңла инде!»
Йосыфның шәп толпар атлары бар иде,
гадәте бер аргамакның болай иде:
кайчан да ки иярләнсә, кешнәр иде —
Мисыр халкы җөмлә[2] аны ишетер инде.
Газиз Йосыф аена бер чыгар иде,
ат кешнәүгә җыела бар гаскәр иде,
Йосыф атын иярләтеп менәр иде —
яхшы атларда гаскәр белән китәр инде. (...)
Ике йөз мең ир барадыр уң ягыннан,
ике йөз мең ир бара һәм сул ягыннан,
ике йөз мең ир бара һәм гел алдыннан —
артыннан да ике йөз мең бара инде. (...)
Бу солтанәтне[3] күргәннәр таң калалар,
түрә, халык һәйбәт күреп сөйләшәләр,
дошманнары көчен күреп тетрәшәләр —
ишеткәннәр җөмлә хәйран кала инде.
Алар шулай һәйбәт[4] илә бара иде,
бер гидайга юлыктылар — Йосыф күрде,
ул мескеннең өсте-башы иске иде —
«Лаек түгел миңа» диеп уйлый инде.
«Бүгенге көн мин Мисырның шаһы исәм,
тәңремнән бу кадәрле дәүләт күрсәм,
мин үземә моны вәзир итеп куйсам,—
бу миңа һич туры килмәс,»— дия инде.
Шул сәгатьтүк Җәбраил хәзер килеп,
тәңресеннән Йосыфка сәлам җиткереп:
«Хәтереңнән бу кинәне китәр,— диде,—
бу исәбең сиңа лаек түгел инде.
Бозык эшкә Зөләйха сине тартканда,
хәйлә-мәкере өстеңә һаман артканда,
куа чыгып, арт итәгеңне ерткан да —
исеңдәдер, йа, Йосыф, ул хәлләр инде.
Ул заманда бу бер айлык олан иде,
синең хәлеңне бишектән күргән иде,
синең өчен таныклык ул биргән иде —
ни мәгънәдән сиңа лаек түгел инде?!»
Ул әхвәлне Йосыф исенә төшерде,
алып килеп, кыйммәт киемнәр кидерде,
һәм ышанып аны үзенә вәзир кылды —
шуннан бирле ихлас хезмәт итә инде.

[1] Ярдәмче
[2] Барысы да
[3] Биредә: тантана
[4] Биредә: гайрәт, мәһабәтлек



## XI бүлек. Зөләйхага никах белән өйләнүе

Бала чакта Йосыф бер төш күргән иде
(югарыда әйтелеп ул үткән иде),
аннары күп кайгы-хәсрәт чиккән иде —
төрле-төрле кыеннарга тарып инде.
Аннан соңра тәңресеннән рәхәт килде,
Җәбраил җитешеп аңа хәбәр бирде:
«Әйа, Йосыф, бу кыеннар ничөн булды —
халик сиңа мәгълүм кыла, тыңла инде.
Һич кешегә шәфкатеңнән син баш тартма,
тар коега мәҗрүхләрне[1] һич син атма,
яла сүзгә колак салып, бәла якма —
мәхбүсләргә миһербанлык ит син инде». (...)
Кыен көннәр үтеп рәхәт көннәр килде,
Йосыф Мисыр иленә хөкемдар булды,
тәңресе аңа олуг кодрәт-сәләт бирде —
бөтен эшен игелек белән эшләр иде.
Һәрбер айның башы яңа туган чакта,
гаскәр тезелеп, янына килгән чакта,
җайдак менеп, Йосыф сәйран кылган чакта —
сигез йөз мең гаскәр белән чыгар инде. (...)

*(Йосыф белән Зөләйханың яңадан очрашуы)*

Зәгыйфь булды, Зөләйханың күзе күрми,
ни киемгә, ни ризыкка күңле бармый,
карый булды, тик Йосыфны оныта алмый —
Йосыф исә асла хәбәр белми иде.
Йосыф үтәр юл өстенә килер иде,
кичә-көндез аны көтеп торыр иде,
газиз гомрен ул шулай кичерер иде —
шул хәлендә гыйшык дәртен йотып инде.
Һәр даимән[2] яңа ай туган чакта,
атлар кешнәп, җайдак гаскәр килгән чакта,
газиз Йосыф сәйран чыгып гизгән чакта —
ул Зөләйха юлда торыр егълап инде.
Егълап тора Зөләйха — Йосыф белми,
белми Йосыф, һич янына якын килми,
өн-авазы колагына ишетелми —
быргы кычкыра, барабаннар кагыла инде.
Һәм Зөләйха, кайгы йотып, кире китә,
көйдерәдер, хәсрәт уты, бәгърен өтә,
мәхрүм булса да никадәр, кавышу көтә —
өмет уты сүнмәсә дә сүнмәс инде!
Көннәр, айлар шул рәвешчә узар булды,
Зөләйха бу хәленнән би-зар[3] булды,
табына торган санәменнән бизәр булды —
«Күрмисең ич хәлем!»— дип шелтәли иде.
«Газизә[4] идем — кадерсез тол хатын булдым,
йөзем калды көл-күмергә, ким-хур булдым,
әхвәлемне сөйләп сиңа күп табындым —
синнән файда юк икәндер, белдем инде.
Мисырда бер дәрәҗәле ханым идем,
бик күпләргә башлык идем, олуг идем,
сине тәңре дип моңарчы таныр идем —
ник бер яктан игелегең тимәс инде?!
Йосыф сиддикъ ул чагында колым иде,
гыйбадәт гел илаһына кылыр иде,
һәр даим ул боерганча йөрер иде —
мәүлясе сәгадәт[5] бирде инде».

[1] Яралы, кайгылылар
[2] Һәрчак
[3] Интегү
[4] Дәрәҗәле хатын-кыз
[5] Бәхет, уңыш

Аннан дунде Зөләйха, мөслимә булды,
санәменә, потларга баш имәс булды,
ватты-кырды, барсын челпәрәмә кылды —
базар чыгып кисәкләрен сатар инде.
Аннары соң, янә яңа бер ай туа,
Йосыф янә атка атланып сәйран кыла,
Зөләйха аһ-зар илә егълап кала —
«Әйа, Йосыф, миңа бер күз салсаң инде!»
Зөләйхага халик анда ярдәм бирде,
фөрьяд аһын[6] Йосыфка ул ирештерде,
ишетеп тавышын, Зөләйханы Йосыф күрде —
юл чатында үрә карап тора инде.
Шундук Йосыф аргамагы башын бора,
якын килә ул карчыкның каршысына:
«Нә кешесең,— ди,— йомышың бармы миңа?—
теләгеңне үтәр идем, әйтсәң инде».
Җавап бирде: «Әйа, ишет олуг шаһым,
үзе зәгыйфь, күзе күрмәс,— дирсең,— бу кем?
Мисыр иясе газиз Кыйтфир җефете идем —
шул хәлләрдән бу хәлләргә төштем инде.
Мин улмын, кем сине сатып алган идем,
бөтен малым сиңа корбан кылган идем,
синең гыйшкыңа сабышып калган идем —
бу көн менә шундый хәлгә төштем инде!
Барча китте кулымнан күпме дәүләт,
берсе калмый җуелды мал вә мөлкәт,
вә ләкин сулмас икән күңелдә дәрт —
мәхәббәтем әле дә мине көйдерә инде.
Ихлас күңелдән инандым бер тәңрегә,
инандым һәм син Йосыф пәйгамбәргә,
калмады һич бер шигем мөэминнәргә —
үзем дә хак мөэминә булдым инде».
Йосыф күреп, Зөләйханы бик жәлләде,
тик шул хәлдә гыйшык дәртен гаҗәпләде,
сүзләренә бигүк ышанып җиталмәде —
сынау өчен, янә кайтып сорый инде:
«Йа, Зөләйха, кая синең даның-малың,
зифа буең, озын чәчең, хуп җамалең[7],
тулган айтик балкыр иде ул йөзләрең —
син ул хәлдән ничек моңа калдың инде?!»
Зөләйха әйтә: «Җамалем вә малым бирдем —
бөтенесен синең өчен фида кылдым,
бәхетемнән, тәхетемнән[8] аерылдым —
шуңа калдым гыйшкың әсәреннән[9] инде!»
«Дөрестән дә,— диде Йосыф,— гашыйк булсаң,
мәхәббәткә син һаман да тугры калсаң,
гыйшык дәртен, дәгъвасын кылыр булсаң —
раслау өчен бер дәлиле кирәк инде».
Зөләйха әйтә: «Әйа, Йосыф, якын ук кил,
рәхим итеп, кулыңдагы камчыңны бир,
йөрәгемдә гыйшык утын син күрерсең,
ялган булыр бу дәгъвам — күрмәсәң инде».
Йосыф аңа сузылып камчысын бирде,
Зөләйха бер «аһ» өреп, кире бирде,
ут тоташып сабына янганын күрде,—
ялкыннары Йосыф кулын өтәр инде!
Атып бәрде ул камчысын Йосыф сиддикъ,
(гыйшкына һәм Зөләйханың калмады шик),

[6] Ягъни ялварып чакыруын
[7] Искиткеч чибәрлегең
[8] Биредә: югары дәрәҗә
[9] Тәэсиреннән

расланды аның дәгъвасы, бу гаҗәп, дип —
толпарның тезгенен читкә тарта инде.
«Йә, күрдеңме,— ди Зөләйха,— аңладыңмы,
камчыга ут кабынды, таң калдыңмы,
үз колыңны пешергәнгә түзмәдеңме?—
кырык елдыр, ул ут миндә яна инде!»
*Бу гыйбрәткә гаҗәпсенеп Йосыф нәби,
Зөләйхага нәсихәт вә үгет бирде:
«Өзмә өметең, вәгъдә ирешәдер,— диде —
кыенлыклар үтәр, рәхәт килер инде».
Ә соңыннан ул Җәбраил иңде, килде,
ул Йосыфка тәңре сүзен ирештерде:
«Зөләйхага гакъде никах[10] кылсын,— диде,—
син — падишаһ, ә ул — ханым булсын инде!»
Йосыф моны Җәбраилдән инде белеп,
Зөләйханың торган җиренә янә килеп,
сөендерде шатлык хәбәр аңа биреп:
«Йа, Зөләйха, рәхәт көннәр җитә инде!»
Моны ишетеп, Зөләйха бик чикте ваем:
«Билгеледер, хәлем сиңа, йа ходаем,
малымнан вә күркемнән калдым аерым —
күзем сукыр, үзем карчык булдым инде!
Илаһымнан шундый хөкем булса иде,
күз нурларым янә кире кайтса иде,
йөз күркем һәм Йосыфка тиң булса иде —
өмет-догам, мәүлям, сиңа гына инде».
Шулук сәгать ул Җәбраил аңа килде,
канаты белән бер сыйпап дога кылды —
Зөләйханың күзе ачылды, япь-яшь булды —
тулган айтик йөзендә нур балкый иде.
Аннан — никах, туй бәйрәмен алар кылды,
Йосыф бик күп кунак өндәп, мәҗлес җыйды,
вәзир-түрә, өлкән бәкләр — җөмлә килде —
куаныч вә юаныч күп булды инде.
Ул икесе аннан килеп аулак калды,
Йосыф аның сафлыгына гаҗәпләнде,
Зөләйханың кулын алып сорау бирде:—
«Бу көнгәчә ничек саф кыз?»— диеп инде.
Зөләйха Йосыфына җавап бирде:
«Тәңре мине синең өчен саклап торды,
миңа охшаш пәри кызы килеп йөрде —
Кыйтфир аны мин дип белеп кочар иде».
«Хәтереңдәме,— диде Йосыф,— ул бер көнне,
бозык эшкә өндәгәнең ул чак мине,
хак сакласын, эшләсәйдек әгәр аны —
бу бәхеткә җитмәс идек бүген инде».
«Йа, Йусеф!— ди Зөләйха,— син бит нәби[11],
ормасаң ла йөземә ул гаебемне,
илаһыбыз саклап калды анда безне —
сине, мине ул фетнәдән тыеп инде.
Охшар иде тулган айга синең йөзең,
сөйләр исәң, тыңламага яхшы сүзең,
тәңре сиңа өләшеп биргән бар бизәвен —
күреп сине кемнең сабыры калсын инде!» (...)
Аннары соң ходай язган тәкъдир булды,
ул икесе калган гомерен бергә торды,
хак аларга унике угыл бүләк кылды —
олысына Мөсалим диерләр инде.

[10] Никах килешүе
[11] Пәйгамбәр



## XII бүлек. Ягъкубның уллары Мисырга бару

*(Кәнгандә ачлык)*

Кәнган ягында бик каты кытлык булды.
Ягъкуб җыеп угланнарын әмер кылды:
«Ошбу тарлык,— дип,— безгә нык тәэсир кылды —
ашлык эзләп, Мисырга барсагыз иде.
Илебездә азык-ризык һич калмады,
җиребездә иген-тарулар уңмады,
бу тарлык моңайтты йортны, хәл калмады —
йа оланнар, анда сәфәр кылыгыз инде!»
Анда ашлык сатып алып була икән,
падишаһы юмарт, дине ислам икән,
ул газизгә әйтегез күп сәлам миннән —
тик алтын юк — язуга алырсыз инде.
Унысы да бу сәфәргә риза булып,
унысы да дөя белән юлга чыгып,
Ибне-Ямин исә бармый өйдә калып
агалары Мисырга юнәлер инде.
*Юл барганда бер кәрванга ирештеләр,
асыл-нәселләр сорашып күрештеләр,
Исмәгыйль тамыры икән, белештеләр;
«Ә без Исхак токымыннан»[1],— диләр инде.
*Алар исә Ягъкуб хәлен сораштылар:
«Йосыфсыз,— дип,— ул мескен карт ничек тора?»
Яһүдә әйтә аларга җавабында:
«Ягъкубның хәле мөшкел»,— диер инде. (...)

*(Йосыф агаларының килүен белә)*

Мәүля җәлил Җәбраилгә әмер бирде:
«Җәһәт ireш Йосыфка, сөендер!»— диде.
(кардәшләре әле юлда бара иде —
унөч көннән генә житәселәр инде.)
Кайчан Йосыф Җәбраилдән хәбәр белде,
кардәшләрен күрәсенә бик сөенде,
иясенә мактау-шөкер бик күп, диде —
килүләрен күңеле хуп күрер инде.
*Алар житеп, шәһәр эченә керү белән,
янә килеп Җәбраил хәбәр бирү белән,
Йосыф багып, тәрәзәдән күрү белән —
«Аһ» диеп, сыгылып җиргә төшә инде. (...)

*(Кәнганлеләрне кабул итү)*

Йосыф боера — айрым сарай хәзер кыла,
төрле нигъмәт, ризык сайлап әзер куя,
кардәшләрен ул сарайга чакырттыра —
анда вәзир үзе хезмәт кыла инде. (...)
Фараз кылып үзарада гәпләштеләр:
«Мөгаен,— дип,— малик бездән алтын теләр,
шуннандыр бу безгә мондый игелекләр —
алтыныбыз юклыгын ул белмәс инде».
«Атабызны,— дия Шәмгун,— малик белер,
шуның өчен, ахры, безгә хөрмәт кылыр,
Ягъкубны ул пәйгамбәр диеп таныйдыр —
бу гыйззәтләр шуңа булыр безгә инде...» (...)
«Кызганадыр ул безне,— дип әйтә Рауил,—
бу падишаһ, мин сизәмен, гаять гадел,
юксылларга шәфкать кылыр һәр гадел ир —
безнең читтән килгәнебез мәгълүм инде».

[1] Ягъни гарәпләр һәм яһүдләр

*Йосыф моны ишетеп уфтаныр иде,
кардәшләрен аерым-аерым танып белде,
Яһүдәне, Шәмгунне тик аералмады —
аңа килеп, Җәбраил күрсәтер инде.

*(Мөсалим агалары белән)*

Аннан Йосыф әйтте углы Мөсалимгә:
«Су тутыр да, минем хас тустагыма[2],
илт син аны читтән килгән ул кавемгә[3]—
сусын биреп, хезмәт итеп тор син инде.
*Сусын-ширбәт биреп тор син, хезмәт кылып,
әманәт бу[4]— агаңнарга хөрмәт кылып,
аны-моны сөйләшсәләр, тәмам белеп —
сорашсалар кем икәнең — әйтмә инде...»
Яннарына ул Мөсалим килде хәзер,
абзалары хезмәтенә булды әзер,
һәрберсенең алдында ул үрә торыр —
тустаганнар тотып хезмәт кылыр инде. (...)
*Акылы камил, теле йомшак, мөрәүвәтле,
күңеле шәфкать, йөзе күркәм, үзе гарьле,
сылу буйлы, сүзе бигрәк нәфасәтле[5]—
бу углан безнең Йосыфка охшар инде!»
Сорашалар: «Әйа, олан, йөзең ямьле,
әдәплесең, нәселең затлы, үзең гарьле,
безгә хөрмәтләр кыласың йөзәр төрле —
кем син, кемнең баласы син?»— диләр инде.
Ул Мөсалим болай диеп җавап әйтер:
«Мисыр шаһы миңа шулай итте әмер,
анын күңле, ахры, сезгә шәфкатьледер —
мине сезгә хас[6] аякчы[7] куйды инде.
*Мисыр шаһы,— ди,— кунаклар яратадыр,
алар өчен һәрвакытта җан атадыр,
сезнең өчен дә күңеле кайгыртадыр —
шуңа сезгә хезмәтче итеп куйган инде.
*Һәр даимән мин монда булырмын,— ди,—
сезнең алда аяк өсте торырмын,— ди,—
сезнең өчен хезмәт-хөрмәт кылырмын,— ди,—
сезне күрү миңа да хуш кына инде!»
*Күреп Мисыр газизенең игелеген,
гыйззәт-хөрмәт күрсәтүен, кешелеген,
һәрберсенә бөтен икмәк бирелүен —
бу әхвәлгә исләре бик китә инде.
*«Һай, бу патша юмарт!»— диеп сөйләштеләр,
«Ай-һай, байлык-дәүләте күп!»— диештеләр,
ашлык-икмәк бәяләрен киңәштеләр:
«Бер почыгы[8]— ике йөз мең алтын инде!..»

*(Йосыф сараенда рәсми кабул итү)*

Аннан Йосыф җиһазлатты тәхет сараен,
түшәтеп вә нәкышләтеп диварларын,
як-ягына тезгәч коллар-сакчыларын —
«Кәнганиләр керсен!»— дип боера инде.
Ул арада инде өч көн үткән иде,
алар хәлен-әхвәлен тикшерткән иде,
һәрберенә ак атлас тун киерткән иде —
дүртенче көн — хозурына баралар инде.
Килеп алар ул сарайга керү белән,
Йосыфның бу мәһабәтен күрү белән,

[2] Тустаган
[3] Бу урында: төркем
[4] Ягъни ышанып тапшырам
[5] Нәфис
[6] Үзенә атап
[7] Аш-су биреп торучы
[8] 25-30 кадак сыешлы савыт

ул шәүкәтен-солтанәтен[9] белү белән —
унысы бердән аңа сәҗдә кыла инде.
Әйтте Йосыф: «Күтәрегез башыгызны,
һәм җыегыз бөтен булган гакълыгызны,
белдерегез яшермичә хәлегезне —
ни ихтыяҗ китерде монда сезне инде?»
Кардәшләре берәм-берәм баш калкытты,
һәр кайсысы акылын җыеп, күзен ачты,
унау бергә аяк өсте торып басты —
тәхет алдында кан калтырап тора инде.
Боерды — анда көрси китерделәр,
рөхсәт бирде — ун карендәш утырдылар,
курку-борчу сагышларын күп йоттылар:
«Аһ дәһшәт, аһ харап!»— диләр инде.
Йосыф карый кардәшләрен, барысын таный,
аерым-аерым үзе һәр кайсысын уйлый,
пәрдә эчендә яше ага бите буйлый —
Йосыф зарын алар белми, сизми инде.
Әйтә Йосыф боларга: «Кемнәр сез?»
Кайсы илдән килүегез, ни теләрсез?
Әүвәл-ахыр, сез бер тума кардәшмесез?—
Атагыз кем сезнең?»— диеп сорый инде.
«Без,— диделәр,— Кәнган иленнән киләбез,
Исхак пәйгамбәр токымы, изгеләр без,—
хакыйкатьтә унике туган идек без,—
атабызны Ягъкуб нәби диләр инде.
Ә беребез килә алмады — өйдә калды,
бер кечебез бар иде — бүре ашады,
атабыз сөяр иде бигрәк тә аны —
шул хәсрәттән ике күзе күрмәс инде».
Йосыф әйтә: «Йа, шәрифләр[10], хакмы бу сүз?!
«Атабыз пәйгамбәр» дип бер сөйлисез,
«Сөя иде беребезне артык»,— дисез —
пәйгамбәргә бу эш лаек булмас инде».
Алар әйтә: «Әйа, газиз, ишет бездән,
күрсә идең, ул кечебезне син бер күздән,
сөяр идең һәм үзең дә чын күңелдән —
син күрмәгәч, ничек тасвир итик инде?!
Аны әүвәл без дә бик нык сөяр идек,
күрми торсак, күрергә бик теләр идек,
ләкин ялган төш күргәнен аның белдек —
атабыз бик яхшы тәгъбир биргән[11] инде».
Йосыф сорый: «Ул кечегез ни төш күргән,
атагыз,— ди,— аңа нинди юрау биргән?»
Алар әйтә: «Төш мәгънәсе котлы килгән —
Мисыр иясе булырсың,— дигән инде.
«Атабыз аның төшләрен хак дип белеп,
Мисыр иясе булырсың дип тәгъбир кылып,
ул чагында безгә бу бик авыр булып —
без моны өнәмәдек!»— диләр инде.
Йосыф сорый: «Хәзер ул төш булмаганмы,
ягъни төшнең юравы юш килмәгәнме,
углан мисыр падишаһы булмаганмы —
ул-бу хәбәр белмисезме аннан инде?»
Диешәләр: «Хәзер ул углан кайда?!
— Һәлак итте аны бүре ул чак тауда!
— Мөгаендер, аның җаны оҗмахларда —
бу дөньядан күптән күчеп киткән инде...»

[9] Мәһабәтлек
[10] Затлы нәсел
[11] Юраган

«Әйа, газиз, хәлебезне белсәң ачык:
карт атабыз сиңа сәлам кылды бик күп,
безнең илне интектерде ошбу ачлык —
безләр Сездән азык эстәп килдек инде.
Мохтаҗ булып килдек Сезнең капугызга[12],
бик аз тауар белән килдек катыгызга,
бу хәлдә игелек кирәк Сездән безгә —
юмартлыкта дөньяга Сез мәшһүр инде!»
«Сүзебез,— ди Йосыф,— безнең болай булсын,
арагыздан берәү монда калып торсын,
икенче тапкыр килергә тотык[13] булсын —
кече энегез килеп танык бирсен инде.
Әгәр сездән тугры холык булыр исә,
ул энегез сезнең белән бергә килсә,
карт атагыз юлдаш итеп, сезгә бирсә —
ашлык бик күп түләүсез дә бирәм инде». (...)
Унысы да бу сүзләргә рази булды,
Шәмгун анда калырга дип буен сонды[14];
Йосыф әйтеп, дөяләргә йөк салдырды —
йөк эченә тауарларын яшерер инде.
Озатты үзе аларны Йосыф сиддикъ,
гаять хөрмәт белән күп игелек итеп:
«Атагызга бездән сәлам әйтегез,— дип,—
озак тормый безгә кире килегез инде!»
Кайчан алар ул Мисырдан чыкты исә,
ничә туктап, ничә юлга керде исә,
кемгә генә юлыгып эш күрде исә —
аларны бик зурлап кунак итәрләр инде.
«Гаҗәп,— диләр,— без һәр хәлдә йөрер идек,
бу җирләрдә, бу мәнзилдә[15] кунар идек,
әмма мондый кадер-хөрмәт күрерме идек —
бу юлы соң нинди хикмәт булган инде!?»
*Алар Мисыр юлы белән кайтып килә,
Йосыф исә алар белән ияреп килә,
артларыннан Иблис-мәлгунь җитеп килә —
Йосыф исен ул бетереп килә инде.
Кайчан алар күчә-күчә кайтып килде,
күрү белән аталары бик сөенде,
яшь аралаш Ягъкуб нәби бераз көлде —
янә түнеп, һуштан язып төште инде.
*Һушына килгәч, угланнары күрештеләр:
«Бу көлүең асылы ни?»— дип белештеләр.
«Йа, атакай, бер елмайдың,— диештеләр,—
аннан нишләп истән авып төштең инде?»
*Якъкуб әйтә: «Сүз-өнегез татлы килде,
Шул сәбәптән сөенечле булдым,— диде,—
арагыздан берәү янә ким күренде —
шуңа көенеп һушсыз калып төштем инде.
*Ул газиз[16],— ди,— сезгә ашлык ничек бирде,
белдегезме аны, кайсы милләт[17] иде?»
Угланнары аңа күркәм җавап бирде:
«Сезләрне ул бик ихтирам кыла инде!»
«Мисыр шаһы,— дип әйттеләр,— ул мөселман,
хөрмәтләде безне ул бик кылып әман[18],
бик тели ул Ибне-Яминне, һәм дә бездән
әманәтлек булып Шәмгун калды инде.
Моны ишетеп Ягъкуб нәби фөрьяд кылды:
«Аһ, нигә дип калдырдыгыз ул Шәмгунны,

[12] Капкагызга, ягъни каршыгызга
[13] Әманәт (заложник)
[14] Буйсынды, күнде
[15] Туктау урыны
[16] Мисыр газизе
[17] Бирелә: дин
[18] Имин тоту

кайчан бирәм сезгә ул Ибне-Яминне —
алданып бер Йосыфсыз мин калдым инде!»
Угланнары атасына җаваплады:
«Ул газиз,— дип,— синең хакта бик сорады,
зари кылды, синең өчен бик кайгырды —
күп-күп сәламнәр күндерде»,— диләр инде...
•Уйлый торгач, Ягъкуб болай чара күрде:
угланнарын җыеп барын ант иттерде,
кулларына шулчак кече углын бирде —
инану өчен һәр кайсы ант итәр инде.
•Җыена алар актарынып чуалларын[19],
табып ала йөкләреннән тауарларын
(бу хәл янә уйландыра аталарын) —
«Үзебезнең әйберләр үк кайтkан инде!»
Ягъкуб анда хәер-фатихасын бирә,
ун карендәш дәррәү кузгалырга тора,
Ибне-Ямин алар арасында бергә —
Мисырга юл алып алар китә инде.
Әйтеп кала: «Кайчан,— ди,— барып җитәрсез,
җыенуыгыз бер капудан сез кермәгез,
телдән-күздән исән-имин тик үтәрсез —
икәү-икәү һәр капуга бүленеп инде.»

*(Мисырга икенче килүләре)*

Җиткәч килеп, ниһаять, алар Мисырга,
икешәрләп таралдылар һәр капуга,
калды ялгыз Ибне-Ямин бер капуда —
бер юлдашсыз мәхрүм булып торыр инде.
Шам[20] ягыннан кергән капуга ул барды,
олылар вә кечеләрдән юл сорады,
тик беркем дә аның телен белә алмады —
гаҗизәнә ары-бире сугылыр иде.
Шул мәлдә килә Йосыфка Рухел-әмин[21],
җиткерә ул газизенә хак сәламен:
«Кальга[22] төбендә тора,— ди,— Ибне-Ямин —
килдем сиңа сөенечләп, куан инде!
Йа, Йосыф, бар, нәфис киемнәрең киен,
өстеңә бер палас янә бөркән,
дөя менеп, бар янына аның яшерен —
туган энең күрим дисәң, кузгал инде!
Шамнан кергән капка алдында йөреп торыр,
кемне күрсә, хәбәр сорап ул ялварыр,
тик беркем телен аңламас, гыйбри сөйләр —
бик аптырап, елый-елый йөри инде».
Шул рәвештә дөя менеп анда барды,
Шам капкасы төбендә үк тапты аны,
Ибне-Ямин Йосыф икәнен танымады —
бер дөяле йөзе япкан килә инде.
Килде, сорый: «Әйа, газиз, нинди ир син,
кай җирләрдән син килепсең, ни эстисең —
йомышың ни, ник елыйсың, ни телисең —
әхвалеңне миңа ачык әйтсәң инде?»
Ибне-Ямин: «Кәнганнан,— ди,— килер идем,
Мисыр шаһы хозурына йөрер идем,
бу шәһәргә керү белән мин адаштым —
Ягъкуб углы Ибне-Ямин булам инде.
•Ун кардәш,— ди,— килгән идек без Мисырга,
керде алар икәү-икәү һәр капуга,

[19] Йөкләр
[20] Сурия һәм Ливан
[21] Җәбраил
[22] Бирегә: шәһәр стенасы

ялгыз калдым бер юлдашсыз мин бусында —
үзем гамьле, күземнән яшь ага инде.
*Бар иде, минем янә бер кардәшем,
бер анадан тумыш идек, ул сөтдәшем,
аны искә алып ага бу күз яшем —
ни хәл итим, башым гаҗиз-вәйран инде![23]
Нәселең кем,— ди,— әйа, син мөрәүвәтле[24],
очрашудан күңелем булды хуш рәхәтле,
гыйбричә хуп сөйлисең — җан рәхәте —
бу телне,— ди,— каян, ничек белдең инде?».
Әйтә Йосыф: «Кәнгандә мин торган идем,
бер заманнар ул җирләрдә йөргән идем,
яшьлегемдә анда байтак булган идем —
шул чагында өйрәнмеш тел иде инде...»
Ибне Ямин: «Әй,— дип сорый,— шәфкатьле яр!
Синең йөзең бер күрергә теләгем бар,
Миңа хәсрәт әсәр кылган, тәкатем тар —
йөзең ачсаң, җамалең бер күрсәм инде?»
«Әлегә моны,— ди Йосыф,— һич кыла алмыйм,
ул пәрдәне мин йөземнән ала алмыйм,
бу хәлемдә әмереңчә була алмыйм —
морадыңда син сабыр кыл»,— дия инде.
Аннан соңра Йосыф аңа үгет бирде,
бер беләзек янә бүләк итеп бирде,
бәясе бик кыйммәт, мең динарлык иде —
саф кызыл якуттан ул торыр инде. (...)
Энесенә юлдаш булып, юл күндерде,
икәүләшеп шәһәр эченә килде-керде,
Ибне-Ямин кардәшләрен җөмлә күрде —
алар Йосыф сараена бара инде...
Әйтте Йосыф: «Инде миңа рөхсәт бирсәң,
кардәшләрең хозурына инде йөрсәң,
алар белән ул сарайга бергә керсәң —
кайгырма бик, күңлеңне хуш тот син инде».
Ибне-Ямин аннан аерыла алмый,
кардәшләре янына ул якын бармый:
«Аерылырга куркам синнән, җаным тартмый —
синең белән генә тынгы табам инде!»
Елый-елый, болай диеп ул үтенә:
«Әйткән сүзең, телең татлы күңелемә,
бәгърем тәмам эри синең киңәшеңә —
синнән гайре һичбер кем хуш түгел инде!
Синнән башка һич кешене күзем күрми,
синсез күңлем һичбер тынгы белми,
бер өметем бар, әйтергә телем кыймый —
сурәтең хуп... Йосыфыма охшый инде».
*Йосыф исә: «Әмма ләкин мин колмын,— ди,—
бардыр хуҗам, аның хөкемен тотамын,— ди,—
аның әмерен сындырудан куркамын,— ди —
боерганны гына эшләү кирәк инде.
*Кардәшләрең янына бар, бергә бул син,
гамьнәрең-кайгыларың читкә куй син,
дәртләрең-рәнҗүләрең онытып тор син —
җәрәхәтең бәлзәме, һай, булсам инде!»

*(Ибне-Ямин агалары белән)*

Ибне-Ямин кардәшләре янына килде,
килү белән барысына күреш кылды,

[23] Аптырыйм, кайгырам
[24] Кешелекле, ярдәмчел

кечесенең сөенгәнен алар күрде:
«Ни мәгънәдән шатлыгың зур? — диләр инде.—
Йосыф һәлак булганнан соң, көлмәс идең,
тешең ачып, елмая да белмәс идең,
элек бер дә куанычлы йөрмәс идең —
бүген ничек болай шат син?»— диләр инде.
Ибне-Ямин булганынча җавап бирде:
«Гаҗизәнә сездән аеры калган идем,
шул чагында бер дөяле килгән иде —
минем белән саф гыйбрича сөйләште инде.
*Гидай-гаҗизгә аяулы бик тә үзе
пәрдә белән каплаулы тик бите-йөзе,
телгә оста, тәмле итеп сөйли сүзен —
аны ишетеп күңелем шат булды инде.
Җиткергәнче сезнең янга ул китерде,
ядкарь итеп, мена бер беләзек бирде,
аны күреп, мин шат булдым, җаным эреде —
кайгыларым гүя тәмам сулды инде».
«Кая әле,— ди Яһүдә,— бир, карыек,
нинди беләзек икән ул, без таныек,
кадрен белеп, синең өчен без саклыек...»
дигән булып, энесеннән ала инде.
Яһүдә аны багу белән: «Пыяла!»— ди,
беләгенә кигертмәкче — ул ярамый,
Яһүдәдән янә Рауил алып карый...—
әйләнеп ул хуҗасына кайта инде.
Ибне-Ямин Рауилгә дә бирде исә,
ул да алып, беләгенә киим дисә,
ул беләзек аңа да тиң килмиенчә —
янә кире хуҗасына кайта инде.
Шул рәвешчә кардәшләре бер-бер алды,
һәр кайсысы беләзекне кимәк булды,
һич берсенең беләгенә тиң булмады —
Йосыф бүләге Ибне-Ямингә кайтты инде.



## XIII бүлек. Йосыф сарай салдыра

Йосыф боера: «Төзүчеләр хәзер килсен,
гаҗәп биек матур сарай бина кылсын,
кырык аршын аның буе, иңе булсын —
биеге дә кырыктан ким түгел инде.
Диварларга бизәлсен Ягъкуб сурәте,
янә тагын аның бөтен угланнары,
ун угылы Йосыфка ни кылганнары —
бәйнә-бәйнә булсын анда язган инде.
Алдап-йолдап атасыннан алулары,
үтерәбез, диеп, касед кылулары,
киемен суеп, тар коега салулары —
берәм-берәм дивар нәкыше булсын инде.
Коедан чыккач, йөгреп янә килүләре,
качкан кол дип ялган сәүдә кылулары,
сатып юкка, бик аз бәя алулары —
өч гаебе бар диюләре языла инде!..»
Анда газиз Йосыф олы мәҗлес җыйды,
гаҗәп нигъмәт белән сарай эче тулды,
кунакларга бик күп ризык-ашлар куйды —
кунак итеп туганнарын дәшә инде.
Кардәшләре ул сарайга килеп керә,
Раиул багып, сурәт-язуларын күрә,
ым кагышып, бер-берсенә хәбәр бирә —
«Безнең батыйль[1] гамәлебез...»— диеп инде.
«Атабыздан Йосыфны без алганыбыз,
һәм дә аңа гасый-җафи[2] булганыбыз,
һәрнинди эш Йосыфка без кылганыбыз —
бу сарайга язылган...»— дип көенә инде.
Бу ун кардәш ул сурәттә барсын күрә,
кылган явыз эшләренә соң үкенә,
языкларын танып алар тәүбә кыла —
ашау-эчү уе баштан китә инде.
Газиз Йосыф тәрҗеманга әмер бирде:
«Белеш, алар ничөн тәгам капмый,— диде,—
бигрәк каты елашалар, ни хәл тиде?»—
ул алардан килеп сорый әхвәл инде.
Алар болай тәрҗеманга җавап бирде:
«Безнең янә туган энебез бар иде,
күрке аның бу нәкышкә охшар иде —
хактыр, аны бүре ашады!»— диләр инде.
«Моны күргәч, хәсрәтебез яңа булды,
кайгыбыздан ашау-эчүләр онытылды»,—
дигәч, Йосыф аерым сарай бина кылды —
кардәшләрен анда кабул итәр инде.
Ун карендәш ул сарайга килде-керде,
анда төрле затлы тәгам әзер иде,
утырышып, барсы ризык җияр иде —
Ибне-Ямин берни капмый, елый инде.
«Ни мәгънәдән,— дия Йосыф,— күзең яшьле,
йөзең сары зәгъфрандай, бәгърең ташлы,
ни гамең бар, моның кеби ун кардәшле —
сөйләсәңче хәлең?»— диеп сорый инде.
Ибне-Ямин әйтер: «Кире барса идем,
рөхсәт белән ул сарайга керсә идем,
дивардагы нәкышләрне күрсә идем —
бер сурәте Йосыфыма охшый инде!»
Мәгълүм инде, аңа шундук рөхсәт була,
Ибне-Ямин ул сарайга кире килә,

[1] Явыз
[2] Фетнә

сурәтләрен бага, аңлый, аслын белә —
карый-карый хәсрәт белән егълый инде...

*(Мөсалим белән Ибне-Ямин)*

Йосыф әйтә Мөсалимгә: «Әй, углым, син
бар сарайга, агаң белән бергә бул син,
сорар исә, әхвәлең бәян кылырсың —
кем икәнең әйтсәң аңар ярый инде...»
Ул сарайга Мөсалим һәм килеп керә,
хезмәтенә аяк өсте әзер тора,
Ибне-Ямин бу угланны күрү белән —
елый-елый аннан әхвәл сорый инде.
«Кайгыларны таратырлык висалең[3] бар,
борчуларны юатырлык җәмалең бар,
Йосыфыма тиң килерлек сурәтең[4] бар! —
кем син, кемнең газизе син, әйтче инде?»
«Әйа, агам,— ди Мөсалим,— бел син анык,
миннән ишет ошбу серне, әйтәм ачып,
әткәм минем Мисыр шаһы, Йосыф сиддикъ —
Мисыр халкы аның иркендәдер инде.
Аны олуг солтан иткән тәңре җәлил,
атасы аның Ягъкуб нәби — ул Исраил,
даим хәбәр итәр аңа һәм Җәбраил —
арада ул илчелек йөртәдер инде».
Бер аһ орды Ибне-Ямин, моны ишетеп,
җиргә ауды, бер мизгелгә һушы китеп,
әйтер аңарга Мөсалим исе китеп —
«Нидән, агай, бу хәл сиңа булды инде!»
Ибне-Ямин җавап бирә Мөсалимгә:
«Бар иде,— дип,— бер кардәшем, аһ, минем дә!
син әйткәнчә Йосыф иде исеме дә —
шул мәгънәдән бераз башым ауды инде...»
«Әй, агаем,— ди Мөсалим,— тыңласана,
телем ачып әйткәнемне аңласана,
мин бит углы шул Йосыфның, кайсы сиңа —
карендәштер, бер анадан туган инде!
Әткәм Йосыф дөя менеп, сиңа килгән,
Шам капусы янында ул сине күргән,
кардәшләрең янына сине китергән —
кызыл якут беләзек һәм биргән инде».
Ибне-Ямин әхвәлгә инде төшенә,
гакылы китә, янә ул исенә килә,
сөенечтән йөзләрендә кояш көлә —
«Туганыма кавышам!» дип балкый инде.
*Ул Мөсалим төп сарайга кире кайтып,
хәл ни хәлен[5] атасына һәм аңлатып,
Йосыф аңа сөенеч өчен рәхмәт әйтеп:
«Хәсрәтлемә[6] кавышам!» дип атлый инде.

*(Йосыф белән Ибне-Ямин)*

Йосыф аерым сараена килеп керә,
нурлы йөзеннән пәрдәсен салып куя,
шул мизгелдә Ибне-Ямин аны күрә —
күрү белән һушы китеп ава инде.
Бераздан соң, ис-акыллар башка килгәч,
кара-каршы килеп икәү күреш кылгач,
табышудан, кавышудан күңел тулгач —
фәрештәләр хәйран калып тора инде.

[3] Биредә: ягымлы холык
[4] Биредә: кыяфәтең
[5] Хәл нечкәлеге
[6] Ягъни: хәсрәтле туганыма

Аннары соң утырдылар икәү аулак,
тәңрегә кылдылар күп-күп шөкер-рәхмәт,
сөйләшерләр баштан кичкән кайгы-хәсрәт,
егълый-егълый Йосыф әхвәл сорый инде.
Атасының хәлләреннән хәбәр сорый,
Ибне-Ямин бәйнә-бәйнә аңар сөйли:
«Күп елаудан күзләре,— ди,— берни күрми —
кайгы йортыннан һич чыкмый елый инде!
Йосыф дисә, күзләреннән кан-яшь ага,
фиракъ[7] хәсрәтеннән аның бәгыре яна,
тик күрешү өмете тота бу дөньяда —
кавышудан һич өметен өзми инде.
Ул зәгыйфә кыз кардәшең, мескен Динә,
һичбер яңа күлмәк кимәде чиңенә,
сине сорый, эндәшә һәр юл әһленә[8] —
шуннан бирле егълый, ул һич көлми инде».
«Әйа, кардәш,— дия Йосыф,— инде барсаң,
агаларыңа кушылып, бергә булсаң,
бераз вакыт алар белән бергә торсаң...»—
Ибне-Ямин курка, кире бармый инде.
«Әүвәл аңсыз,— ди,— сине югалткан идек,
шуннан хәсрәт-фиракъ уты йоткан идек,
җитмеш еллар егълап, инде бу көн килде —
бәгыремне пара-парә телдең инде!»

*(Ибне-Ямин үзенең уллары турында сөйли)*

*Аннан Йосыф янә сорый: «Өйләндеңме?
Йа, кардәшем, углан-кызларың булдымы?
Туйлар ясап исемнәрен куштырдыңмы —
ничек, нинди атлар атап куйдың инде?»
*Энесе әйтә: «Ходай боерганы булды,
ул миңа, ди, унике угыл ярлыкады,
һәр кайсына аерым-аерым ат куелды —
сине уйлап ният кылдым барсын инде.
*Диңгез дидем олы углымның исемен,
Курт[9] дип куйдым икенчесенең исемен,
Кайгы диеп — өченчесенең исемен,
дүртенчесен Кан диеп атадым инде!
*Диңгез яры буйлап егълап йөрдем,
таулар ашып, бүре тотып антлар бирдем,
алып канлы күлмәгеңне күп иңрәдем —
кайгы йотып күз яшьләрем түктем инде.
*Бишенчесенең атын Гүр дип куйдым,
алтынчысының атын Дәрт[10] дип куйдым,
җиденчесенең атын Гарь[11] дип куштым —
сигезенче улыма Арыслан дидем инде.
*Гүрстаннар [12] буйлап йөрдем, аһ-зар кылып,
эзләр идем гар-мәгарәләргә кереп,
дәрт-кайгыдан башларым әвәрә булып —
арысланнар тотып, сине сорый идем!
*Тугызынчысының атын Фәрид[13] дидем,
унынчы углыма Гариб[14] дидем,
унберенчесенә тагы Кайгы диеп —
уникенче улыма Кол дидем инде!
*Колларны мин күргәндә хуш тотар идем,
гарибләрне күргән чакта — егълар идем,
кайгылылар күргән чакта — сыкрар идем,—
колларга һәм миһербанлы булдым инде.

[7] Аерылу
[8] Юлаучы
[9] Бүре
[10] Бирелә сагыш
[11] Тау куышы
[12] Зират
[13] Тиңе юк
[14] Читтә каңгырап йөрүче

«Бу исемнәрне,— ди Йосыф,— ничек таптың?
ничек болай мәгънәле итеп хыял кылдың?!»
«Һәммәсе,— ди Ибне-Ямин,— синең кайгың —
синсез алар күземә күренмәс инде...»
Йосыф әйтә: «Инде артык кайгырма син,
кардәшләрең янына бар, айрылма син,
син каласың минем белән, шиксез бел син —
синең өчен бер-бер чара кылам инде.
Йөгеңә бер савыт салып куйдырырмын,
аны табып, сине угры дидерермен,
аерып алып, сине алардан калдырырмын —
минем белән бер сүздә бул!»— дия инде.

*(Ибне-Ямин агалары янына кайта)*

«Ибне-Ямин ул сарайга кайтыр инде,
шатлыгыннан йөзе нурлы балкыр иде,
күргәч аны танымады кардәшләре —
«Мин энегез, Ибне-Ямин!»— дияр инде.
Ибне Ямин якын килә яннарына,
сөенечтән йөзе нурлы, алсу яна,
«Синең күңлең,— диешәләр,— ник куана,—
йөзеңдә нур балкый тулган айдай инде!»
Йосыф кайта нәкаб белән йөзен каплап,
утырта ул кардәшләрен ишләп-парлап,
кунак итә ул аларны көйләп, сыйлап —
үз кулыннан төрле нигъмәт сонар инде.
Икәү-икәү кардәшләре кулын сузды,
табыннан ризык алырга ният кылды,
Ибне-Ямин ялгызлыкта мәхрүм калды,—
һич сый капмый, хәсрәт белән сыктар инде.
Йосыф әйтә: «Ник елыймсың, аша ашың,
куйсана,— ди,— агызма, һаман күз яшең,
алайса,— ди,— мин булыем бер кардәшең —
кил, икебез бергә тәгам кабыйк инде!»
Ибне-Ямин шатлык белән торып килә,
Йосыф аңа уң ягыннан урын бирә,
хөрмәт итә, килүен ул бик хуп күрә —
тәхеттә бергә тәгам жияләр[15] инде.
Кардәшләре һәммәсе анда кунак булды,
ашап туеп, алар рәхмәт-шөкер кылды,
Йосыф вә Ибне-Ямин утыра бирде —
шулай икәү бергә сыйланалар инде.
Ашадылар, бер алтын савыт китертте...
һәркайсының дөясенә йөк төятте,
Ибне-Ямин йөгенә савыт яшертте —
бу икедән гайре һич кем белмәс инде. (...)
Дога кылып, саубуллашып кузгалдылар,
юлда барып, бер мәнзилдә[16] туктадылар,
ул урында берникадәр юанды алар —
артларыннан Йосыф куып килә инде.
Килә куып, менә инде килеп житте,
житеп Ягъкуб угланнарын җөмлә тотты:
«Алтын савытым югалды!»— дип, шелтә итте —
«Сез караксыз!»— диеп тәшвиш сала инде.
Алар әйтә: «Билләһидер, без алмадык,
алла сакласын, угрылык һич кылмадык,
әүвал-ахыр[17] андый эшне һич белгән юк...»—
ай-вайларга бакмый кире куа инде.

[15] Ашыйлар
[16] Тукталыш
[17] Һичкайчан

Куып шәһре Мисырга ук кайтардылар,
йөкләрен һәм капчыкларын актардылар,
Ибне-Ямин йөгеннән табып алдылар —
һәммәсенең йөкләрен бушатып инде.
«Сез,— ди Йосыф,— тоз вә икмәк белмәдегез,
ни мәгънәдән миңа хөрмәт кылмадыгыз,
дүрт йөз мең динарлык савытым урладыгыз?!»—
каты ачу-үпкә белән әйтә инде.
Ишетеп моны, алар гаять оялдылар,
Йосыф дәһшәтеннән куркып ук калдылар,
бөтенесе бер тирәгә өелделәр —
кайсы ничек, ни әйтергә белмәс инде.
Йосыфка алар мондый җавап аннан бирде:
«Туганы да моның явыз углан иде,
ул да моның кеби урлый торган иде —
икесенең дә анасы Рәхилә[18] инде». (...)
*Угрылыгы риваятьтә болай дигән:
Йосыф, имеш, ашаганда нан[19] яшергән,
алып чыгып, юксылларга аны биргән —
аны угры диюләре тик шул инде.

*(Йосыф агаларын шелтәли)*

Йосыф аларның сүзенә җавап бирде:
«Әүвәл-ахыр явыз эшләр сездән,— диде,—
Ягъкуб нәби никадәрле хәсрәт күрде —
сезнең кулдан бозык гамәл чыга инде!
Сез ничаклы атагызны елаттыгыз,
алдап-йолдап кече углыннан аерттыгыз,
кол диеп, азат баланы сез саттыгыз —
хәрәм эшләр кылучы сез түгелме инде?!»
Әмер бирде шул сәгатьтә Йосыф сиддикъ:
«Тотыгыз,— дип,— савыт алганын ябып нык,
шәригать буенча аны хөкем кылыйк —
ике елга тар зинданда ятсын инде».
Аннан әйтте Йосыфка алар инәлеп:
«Бу угланны карт атабыз сөядер бик,
тапшырылды әманәткә, саклагыз, дип —
моны куеп, беребезне тотсаң иде!»
«Андый эшне,— ди Йосыф,— һич кыла алмыйм,
гадел хөкем итми залим була алмыйм,
гаепсезне тар зинданга нигә салыйм?»—
«Ул каракны ябыгыз» дип боера инде.
Алар дәрман табалмыйча гаҗиз кала,
барысы бер аулак җиргә җыелып ала,
ун карендәш нишләргә дип исәп кыла —
«Бер-бер чара кылмак кирәк!»— диләр инде.
Яһүдә әйтә: «Яшерен генә мин барыем,
яман каты дәһшәт белән кычкырыем,
Ибне-Яминне зинданнан чыгарыем —
кылыч тотып сез әзер торыгыз инде!
Кайчан өнем ишетерсез, килегез чабып,
кырыгыз сез, шәһәр әһлен кылыч чабып,
мин Яһүдәнең гайрәтен күрсен халык —
нәгърә[20] тавышым ишеткәннәр үләр инде!»
Йосыф исә болар касден[21] анык белә,
кече углы Мамиләгә әмер бирә,
Яһүдәгә күрсәтеп ул: «Бар да,— дия,—
сиздермәстән аркасыннан сыйпа инде!»

[18] «Балалары да Рәхилә кебек угры» димәкчеләр
[19] Пешкән ипи
[20] Дәһшәтле тавыш
[21] Явыз ният

Ул Мамилә җәһәт аның янына бара,
янында аның яшеренеп бераз тора,
искәрмәстән аркасыннан кул сыпыра —
Яһүдә исә берни сизмәс, тоймас инде.
Яһүдәнең гадәте иде: ачуы килсә,
ачуы килеп кычкырмага ният кылса,
берәү килеп аркасыннан сыйпар булса —
шул ук мәлдә ачуы басыла инде.
Вәгъдә кылган вакыт үтте, инде бик соң,
Яһүдәбез ник үкереп бер кычкырсын,
көтә алар, әмма ник бер аваз чыксын —
килеп, хәл ни булганын сорыйлар инде.
«Нигә,— диләр,— нәгърә орып кычкырмадың,
гайрәтеңлә шәһәр халкын син кырмадың,
вәгъдәбезне син җиренә җиткермәдең —
бу арада нинди хикмәт булды инде?»
Яһүдә әйтә: «Ахры, әхвәл болай булган,
йөргән иде бу тирәдә яшь бер углан,
сыйпагандыр сиздермәстән ул аркамнан —
бәлки, шуннан гайрәт чиккән булсам инде...»
Алар ишетеп, бу хәлгә бик гаҗәпләнде.
«Яһүдә,— дип,— бу әхвәлгә ничек төште?»
«Әллә бармы Исраилдән[22] бер-бер кеше?»—
диешеп алар аптырауга калды инде.
Шул чагында кычкыра ул Йосыф сиддикъ:
«Хыянәт әһеле сез, явызлар бик,
ниятегез мәгълүмдер миңа анык —
янау белән өркетмәкче безне инде». (...)
Ошбу илгә ике нәүбәт сез килдегез,
миннән байтак кадер-гыйззәт һәм күрдегез,
безнең йортта тоз-икмәкле идегез сез —
үзегезне Ягъкуб углы дисез[23] инде! (...)
Бәхетегез,— ди,— атагызны газиз күрәм,
югыйсә мин ничөн сезне җибәрттерәм?
һәммәгезне газап белән үтерттерәм!»—
ишетеп моны алар куркып тына инде.

*(Кәнганга икенче кайтулары)*

Аннары алар Йосыфка күп ялвара,
ахыр килеп, кыйтырга ул рөхсәт бирә,
Яһүдәдән аерылары юлга керә —
ә ул Ибне-Ямин белән кала инде.
Бер-бер артлы ашыгып алар кайтып килә,
бөтенесен Ягъкубка алар сөйләп бирә:
«Ибне-Ямин хәле гаять мөшкел,— дия,—
Яһүдәбез аның берлән калды инде».
Ишетеп бу әхвәлләрне белгәч Ягъкуб,
гамь-хәсрәтләрне чигә янә бик күп;
«Кылдымы хак,— диеп сорый,— ул угрылык,
үзегез соң күрдегезме моны инде?»
Улларыннан Ягъкуб мондый җавап алды:
«Шаһ юмарт,— дип,— безгә ул күп игелек кылды,
тик өеннән алтын савыты югалды —
Ибне-Ямин йөгеннән ул табылды инде».
«Бер тәңремә,— диде Ягъкуб,— үтенермен,
Йусефемне, иншалла, инде күрермен,
өч углымны инде тугры китерермен»,—
«Ничек бергә җыярсың?» ди алар инде.

[22] Ягъни: яһүдиләрдән
[23] Затлы нәсел дип әйткән буласыз

Аларга ди: «Ул рәхимнән тәүфыйк килсә,
кол алдына авыр-кыен эшләр төшсә,
кол сыенып таңресенә, сабыр кылса,—
михнәттән соң рәхәте дә булыр инде!»

*(Ягъкуб Шәмгуннән хат яздыра)*

«Әгәр ул эш,— диде Ягъкуб,— алай булса,
Мисыр шаһы аны тоткын кылган булса,
ә Яһүдә гайрәт белән нәгъръ орса —
Шәмгун егар иде кальгаләрен инде».
Ул Шәмгуннең көч-куәте хәтәр иде,
йөгреп җитеп арысланнар тотар иде,
башын өзеп гәүдәсеннән атар иде —
саннарын кисәк-кисәк аерып инде.
Акланалар: «Без гакъ шулай итә идек,
бездән көчле дип вә ләкин аны күрдек,
чарасыздан калып аңа без буй бирдек —
көч табалмый аңа һич түзәрлек инде».
Ягъкуб нәби Динәсенә әмер кылды,
Динә барып каләм-кара алып килде,
чакырттырды һәм Шәмгунне — хәзер килде:
«Әйа, Шәмгун, болай яз!»— дип әйтер инде. (...)
«Пәйгамбәрләр кеше малын алмас,— дип яз,—
мәгълүмдер ки, языкъ эшләр кылмас,— дип яз,
оланнары һич тә угры булмас,— дип яз —
андый гаеп безгә нахак яла инде.
Әүвәл, диген, иттегез күп хөрмәт вә сан,
бәрәкәте кимемәсен, арта торсын,
ул оланга усал гөман һич кылмасын —
берүк безгә кайтарып җибәрсен инде.
Рәнҗетмәсен мине, дип яз, хәсрәтемдә,
югыйсә мин дога кыламын сәҗдәмдә,
калыр бөтен нәселе аның михнәтләрдә —
мәзлүм җанның бәддогасы хәтәр инде».
*Угланнары Ягъкуб хатын алып китә,
юанмыйча юлда җәһәт аны илтә,
газиз Мисыр хозурына килеп җитә —
килеп аңа, баш орып бирәләр инде.

*(Йосыфның җавап хаты)*

Газиз Йосыф әманәтне алды, күрде,
ачмыенча үбеп аны, йөзенә сөртте,
аларга күз атып аннан сүзен әйтте:
«Сез беләмсез, ничөн болай итәм инде?
Әгәр солтан, ди, кайсы ки гадел булса,
изгеләрнең хас үз хаты аңа килсә,
аны үбеп, янә ул йөзенә силсә[24]—
теләгәнен иляһ кабул итәр инде!»
Йосыф сиддикъ атасының хатын укып,
белә хәлләр ни хәл булганлыгын анык,
аерылу утында бәгъре көеп-янып,
пәрдә астында яшерен күз яшь коя инде.
Шул чак янына Җәбраил килә хазер,
таңресеннән вәхи-киңәш итеп әйтер:
«Әйа, Йосыф, җавап хаты язып күндер —
тизүк аны Ягъкубка илтсеннәр инде».
Аннан Йосыф язды җавап атасына:
«Йа, Исраил, бу сүз ничек дөрес була?

[24] Йомшак кына сыпырса

Шөкер тиеш кол даимән тәңресенә -
хак хөкеменә риза булу кирәк инде.
*Йа, Исраил, бу эшеңдә ялгышкансың:
мәүләң каза биргәнен генә язгансың,
ахыр рәхәт бирәсен тик оныткансың —
без колларга истә тоту кирәк инде». (...)
Җавап хатын Кәнганга тиз җиткерделәр,
кайту белән Исраилгә китерделәр,
укып-ишетеп барсы мәдех әйләделәр:
«Пәйгамбәрләр сүзе,— диеп,— бу сүз инде!»
Моннан соңра әйтә Ягъкуб улларына:
«Җәһәт янә барыгыз,— ди,— сез Мисырга,
өмет итәм,— дия,— мин мәүләм гафурга —
Ибне-Ямин Йусеф илә анда инде!»

*(Йосыфның кардәшләрен куркытуы)*

Тагын да алар Мисырга әйләнеп килде,
диләр: «Сезгә Якъкуб нәби сәлам кылды,
әйа, солтан, хәлебез бик хәтәр булды —
безне яп та ул угланны чыгар инде.
*Безләр бик тә мохтаҗ булып килдек сезгә,
«Йусефемне табыгыз!» ди Ягъкуб безгә,
шундый мөшкел[25] кайгы төште бәгъребезгә»,—
хатны укып, Йосыф хәлне аңлар инде.
*Тәхетеннән төшеп Йосыф шул чак җиргә,
алар белән кылып бераз мөназәрә[26],
аннан соң бер язу биреп ул аларга —
«Бу язуны сез укыгыз әле!»— диде.
Ул аларга шундый хәтәр язу бирде,
һәр кайсысы багу белән укып белде,
бер-берсенә ым кагышып хәл белдерде —
«Безнең кылган гамәлебез» диеп инде.
Йосыф өстәп: «Без моны укый белмибез,
Мисыр халкы,— ди,— без моны аңламыйбыз,
ул язуның мәгънәсенә төшеналмибез —
сезнең телдә язылган бер язу инде».
Диешәләр: «Без дә моны белә алмабыз,
сезгә укып, һичбер җавап бирә алмабыз,
сезгә лаек юньле бер сүз әйтә алмабыз —
гаять начар язылган бу язу[27] инде».
Ә асылда үзләре үк язган иде,
кол дип кайчан Йосыфны алар саткан иде,
өч гаебе бар дип өстенә аткан иде,
мөштәригә[28] биргәндә ул язуны инде.
Ул соңыннан Йосыфның кулына төшкән,
ул язуны һаман бик нык саклап тоткан,
салып сандыкка пөхтәләп бикләп тоткан —
бу көнгәчә шулай саклап килгән инде.
Йосыф сорый: «Сез кол-углан саттыгызмы,
өч гаебе бар дип, йөзенә аттыгызмы,
ул шарт белән шундый язу яздыгызмы?»—
«Язмадык!»— дип алар инкяр итә инде.
Йосыф исә: «Җиз савытка,— ди,— сугыек,
ни дияр икән чыңгырап, без сыныек,
ни дисә дә без аңа буйсыныек»—
Алар әйтә: «Аллага тапшырдык инде!»
Әмер итә — зур җиз табак китераләр,
кызыл алтын таяк белән бер бәраләр,

[25] Бик авыр
[26] Бахәс
[27] «Танып булмый» димәкчеләр
[28] Сатып алучы (Малик Дәгыйр)

кодрәт белән чыңрап сөйли, ишетәләр —
болар кылган гамәлләрне әйтә инде!
Йосыф дия: «Хәзер инде танмыйсызмы,
савыт чыңрап әйткәннәрне таныйсызмы,
үзегезнең гөнаһыны аңлыйсызмы?» —
чарасыздан барсы икърар итә[29] инде.
«Сез икән,— ди,— ул Йосыфны алдаганнар:
безнең белән тамашага кил, дигәннәр,
гөнаһсызны үтерергә үч кылганнар —
бер Яһүдә аралап тик калган инде!..
Сөйгән улын атасыннан аерган — сез,
бәгыренә сагыш уты яндырган — сез,
килеп минем каршыма әйткән буласыз:
«Изге нәсел, имеш, хаслар[30] диеп инде!?»
Кистерәм дә сезнең берәр кулыгызны,
астырамын дар агачка барыгызны,
үлем җәзасы капласын гөнаһыгызны —
шулай сездән Йосыф үчен алам инде!»
*«Бәйләгез дә күзләрен,— дип,— фәрман бирде —
алтын агач ботагына асыгыз инде!»
Алар бик нык өркеп-куркып газап күрде —
аһ-зар белән егълашып ялвара инде.
Ялваралар иңрәп-сыктап: «Азат итсәң,
атабыз хакына гына шәфкать итсәң,
каты авыру хәлдә ул, исәп итсәң —
сукырайды елап ике күзе инде.
Ул бичара инде беребезне жуйды,
ике күзе кан-яшь түгеп, күрмәс булды...»
Йосыф ишетеп болардан һәм битәр көйде —
«Богауларын чишегез!» ди үзе үк инде.

*(Йосыф агаларын гафу итә)*

Ишетеп хәлне миһре[31] килде, ачуы китте,
Дөя менеп, якын килеп нәкаб[32] ачты,
үзе килеп һәр кайсының күзен чиште —
күргәч барысы: «Йа, илаһым!» — диләр инде.
— Йа, Йосыфка ни кадәрле охшаган син!
— Йосыф дисәк, нигә безне ят кыласың?
— Вә-аллаһи, әллә чын да Йосыфмы син?!
— Бак, чынлап та бу бит Йосыф! — диләр инде.
Йосыф әйтә, ниһаять: «Белегез анык —
мин буламын кардәшегез Йосыф сиддикъ,
шулай мине газиз итте иям халик —
мин — Йосыфмын, ә бу — бертуганым инде!»[33]
Моны ишетеп, барсы дәррәү җиргә ава,
танып алгач шаша, ис-акылдан кала,
ошбу хәбәр бөтен Мисырга тарала —
Мисыр халкы гаҗәепкә кала инде.
Йосыф әйтә: «Калкытыгыз башыгызны,
ярлыкадым сезнең батыйль[34] эшегезне,
кайгырмагыз, кичерәм инде гаебегезне —
гафу иттем бит мин сезне»,— дия инде.
Аягүрә торып килеп күрештеләр,
ачы күз-яшь, хәсрәт белән елаштылар,
җөмләсе аһ-ваһ килеп иңрәштеләр —
моны күреп фәрештәләр агълар инде.

[29] Тану
[30] Аеруча дәрәҗәлеләр
[31] Кызгану
[32] Йөзне каплый торган махсус пәрдә
[33] Ибне-Ямин
[34] Яман, бозык



Йосыф әйтә: «Инде болай чара күрәм,
атабызга мин бер күлмәк җибәрттерәм,
ул мәзлүмне куандырам, сөендерәм —
сез аңардан гафу үтенегез инде!»
Ни әхвәлдер, йөзеген биреп җибәрми,
үз кулыннан тамга-мөһерен күндерми,
үзгә бер нәрсә бирергә кабул күрми —
«Бу күлмәкне аңа илтегез!»— дия инде.
Сәбәбе бар: коега Йосыфны салганда,
Җәбраилгә халик фәрманын биргәндә,
оҗмахтан шул күлмәкне алып китергән дә —
ул ялангач Йосыфка киерткән иде. (...)

## XIV бүлек. Йосыфның Ягъкубка күлмәген җибәрүе

*(Ана белән Бәшир хикәяте)*

Анасы үлгәч, Йосыф яшьли калган иде,
Ягъкуб нәби бер кол хатын алган иде,
ул Йосыфка аны дая[1] кылган иде —
аның углын исә аерып сатты инде.
Зари-зари егълады мескен карабаш[2],
җитмеш тамчы түгә-түгә күзеннән яшь;
«Йа, илаһым, сиңа хәлем мәгълүмдер хуш —
оланымны аерып ул сатты инде!»
Вәхи[3] килде: «Мин бер хөкем, дип, боерырмын,
дәхи аны сөйгән углыннан аерырмын,
бәгыренә фиракъ уты яндырырмын —
җитмеш елга иңрәтермен аны инде.
Иң әүвәле — сиңа углың кавыштырам,
аннары соң — аңа углын күрештерәм,
кадирмен[4], вәгъдәмә һич хилаф кылмам —
минем вәгъдәм булмыенча калмас инде!»
Йосыф бер кол сатып алган Бәшир атлы,
(бу хикәят тыңлар өчен бигрәк татлы),
холкы күркәм, шәфәгатьле, миһербанлы —
төгәл эшен игелек белән эшләр инде.
Ул күлмәкне Йосыф хәзер аңа бирә,
кулына бер язу язып янә бирә,
күлмәкне алып Бәшир юлга керә —
Мисырдан ул Кәнган таба китәр инде.

*(Саба җиле)*

Саба җиле күкләр таба зари кылгач,
күк тәңресе кодрәт илә рөхсәт биргәч,
җил исеп, ун көн Бәширдән тизрәк килгәч —
Йосыф исен Ягъкубка җиткерде инде.
Иснәде исә Якъкуб нәби — шөкер кылды,
әч кайгылары бушанды — күңле булды:
«Һай,— ди,— бәнем Йусефемнең исе килде —
саба җиле мине сөендерде инде!
Әкрен исче, саба җиле, ник үтәрсең?
Күңлемә хуш, Йусефемнән ис төтәрсең?
Җәрәхәтем төзалмәгә син җитәрсең —
син искәннән мин куаныч табам инде.
Белдем хактыр, сөенче син, саба җиле,
Йусеф исе кимеми һич, син искәндә,
исен тоеп юанамын бу көн әле —
Йусефемнең исен синдә табам инде».
Моны ишетеп, сәерсенеп гәпләштеләр,
гаеп иткән булып яман сөйләштеләр:

[1] Имезүче хатын
[2] Хатын-кыз кол
[3] Алла сүзе
[4] Кодрәтле

«Кая ул синең Йусефең?!»— диештеләр —
бу куптәнге саташуың гына инде!»

*(Бәширнең анасы белән күрешүе)*

Аннары ун көннән соңра Бәшир килде,
кое алдында бер хатын кер юа иде,
куәт белән килеп, аңа сорау бирде:
«Кая ул,— ди,— Ягъкуб йорты, әйтсәң иде?»
«Ягъкуб өен,— ди ул хатын,— ник сорыйсың?
Каян килдең, йөрешең тиз — ни диямсең?
Ягъкубка син ул-бу хәбәр китерәмсең? —
Сөенчеләп килгәнсең, аһ, белдем инде!
Ягъкуб нәби мине сатып алган иде,
Йосыфына дая итеп куйган иде,
Бәширемне миннән айрып саткан иде —
җитмеш елдыр, шул хәсрәтем чигәм инде!
Мәгәр миңа вәгъдә-вәхи[5] иңгән иде:
«Сөендерәм әүвәл сине»,— дигән иде,
менә Ягъкуб сөенчесе килгән инде —
кая минем Бәширем, аһ, ник юк инде?!»
Бәшир әйтә: «Әйа ана, егъламасаң,
хәсрәт илә йөрәгеңне таламасаң,
хак вәгъдәсе җитмәде дип, гамь йотмасаң —
хакыйкатьтә, углың Бәшир ул мин инде!»
Ишетеп моны анасының акылы шашты,
зарлы хатын бөгелеп үк җиргә төште,
исенә килгәч, ана-угыл шат күреште —
куанычлы күз яшьләрен түгеп инде.

*(Ягъкубның күзе ачылу)*

Яшьне сөртеп, бер-бер артлы алар керә,
сөенә ана — йөзләрендә кояш көлә,
Бәшир килеп әманәт күлмәкне бирә —
Ягъкуб аны алып йөзенә китерә инде.
Алып үпте Ягъкуб аны, йөзенә сылде —
күз кабагы ачылып китте: «Кем син?»— диде;
Бәшир аңа: «Мин шулмын,— ди,— саткан идең
мине айрып, газиз әнкәемнән инде!»
Аннан — Ягъкуб ача, укый ул мәктүбен,
белә кайда икәнлеген хәсрәтенең,
булганын Мисыр солтаны Йосыфының —
шөкер итеп, хакка сәҗдә кылыр инде.
Анда Йосыф кардәшләренә хәлгәт[6] биреп,
алтын-көмеш, ат-качырлар хәйран биреп,
атасын алып килмәгә рөхсәт биреп:
«Каумегез белән килегез!»— дияр инде.
Алар кайтты, ата белән кавыштылар,
барысы да Ягъкуб белән күрештеләр,
иңрәп елап хаталарын сөйләделәр —
«Гөнаһыбыз ярлыкачы?!»— диләр инде.
«Хәйләләп синнән Йосыфны алган идек,
кол дип аны ераkларга саткан идек,
олуг солтан[7] булган, аны бу көн күрдек —
бөтен Мисыр әһле аның колы инде!»
«Хатагызны,— дия Ягъкуб,— ярлыкадым,
мин сезнең ул языкларны гафу кылдым,
үзем дә мин халикымнан рәхәт таптым —
сезнең күңелләр дә тыныч булсын инде».

[5] Алла вәгъдәсе
[6] Кыйммәтле өске кием
[7] Хөкүмәт башлыгы

Бер дөя китереп бирде һәм Җәбраил:
«Моны сиңа җибәрде,— ди,— мәүля җалил,
Мисырга син ашыга күр, йа Исраил —
тиз Йосыфка кавышмакчы булсаң инде».
Шөкер итеп, Ягъкуб ул дөягә менде,
тәмам җитмеш өч кеше илә юлга керде,
бөтен өе-нәселе белән күчеп китте —
киткән саен угланнары ялвара инде.
*Ягъкуб нәби, кул күтәреп, дога кылды,
угланнары барысы бердән «Амин!» диде,
догасын мәүля-тәүваб [8] кабул кылды —
угланнары һаман зар-зар егълый инде.

*(Мисырда Ягъкубны каршылау)*

Йосыф юлга гаскәр тезеп кую белән,
атасын каршы алырга чыгу белән,
уйнап быргы, барабаннар кагылу белән —
толпар атлар хуш өн белән кешнәр инде.
Ягъкуб нәби моны күреп шөкер кылды,
Йосыф нәби аттан төшеп каршы барды,
атасы да дөясеннән төшеп килде —
ата-уллы егълап күрешерләр инде.
*Чынга ашты Йосыф күргән бар төшләре
(кадир тәңре иркендәдер һәр эшләре):
кауме, йорты, ул хәсәдле [9] кардәшләре —
һәммәсе баш орып хезмәт кыла [10] инде.
«Йа, шөкрана,— ди Йосыф,— хур булды шайтан,
кардәшләремә янә дус кылды сөбхан [11],
бу көн үзем Мисыр иясе, газиз солтан»—
шөкер әйтеп шәһәргә алар керә инде.
*Якын килә анда Йосыф угланнары,
Ягъкуб нәби сөеп сораша һәм аларны,
Әйтә Йосыф: «Болар безнең улларыбыз —
Барысы да Зөләйхадан булмыш инде...»

*(Ягъкубка хөрмәт күрсәтү)*

*Зөләйха да хөрмәт белән хазер килә,
Ягъкуб нәби сораша һәм әхвәл белә,
килене өчен янә хәер-дога кыла —
Зөләйха шунда Йосыфыннан сорый инде:
*«Рөхсәт бирсәң, кунак итим Исраилне,
сараема чакырып алыйм ул рәсүлне?»
Йосыф әйтә: «Йа Зөләйха, бел тик хәлне —
пәйгамбәрләр кермәс зур сарайга инде».
*Зөләйха бер кечерәк сарай хәзерләтте,
төрле-төрле ризык-ниггъмәт әзерләтте,
пәйгамбәрне өндәп алып хөрмәт итте —
Ягъкуб анда гаҗәпсенеп әйтә инде:
*«Бу өйне, ди, миңа лаек төзеткәнсең,
күңлемә бик хуш килерлек бизәткәнсең,
Кәнгандәге үз өемә тиң иткәнсең.»—
Зөләйха әйтә: «Йосыфымнан белеп инде».
Ул рәсүлнең бөтен каумен өндәделәр,
Зөләйханың сараена һәм керделәр,
аш-су тәгам төрлесеннән китерделәр —
гаҗәпләргә калды Ягъкуб күреп инде.
Күреп әйтә: «Йөз егерме яшем торыр,
һәр дәвам, дип, гыйбадәттә эшем торыр,

[8] Тәүбәне кабул итеп кичерүче
[9] Үчле
[10] Бирелә: буйсына
[11] Алла

һәр даимән арпа икмәге ашым торыр —
пәйгамбәр дә мондый тәгам капмас инде.»
*Рәййан әйтте Йосыфка: «Әйа, сиддикъ,
Ягъкуб нәбине алып кил безгә дә,— дип,
җәмәгатем дә йөзен һәм күрсен,— диеп,—
аның белән без утырдаш булыр идек!»
*Йосыф әйтер: «Рәййан мине кадерләде,
азат итеп, зур дәрәҗә, дәүләт бирде,
синең белән аңа да бер барыйк инде?»—
Ягъкуб аңа: «Сүзең хата!» диер инде.
*«Бурычлы дип сизмә үзеңне Рәййанга,
сине халикың чыгарды ул зинданнан,
һәр кешегә уңыш-гыйззәт бер сөбханнан —
бары аңар шөкер-рәхмәт кыл син инде.»
*Йосыф сүзен тыңлап әмма Ягъкуб барды,
Рәййан бакты аңа,— нурлы чырай күрде,
«Гомерең ничә?»— диеп аннан ул сорады —
Ягъкуб: «Йөз егерме яшем»,— дия инде.
*Рәййан хәраменнән[12] бәрәү: «Артык!»— диде
(инанмады әйткәненә: «Бик карт!» диде);
аңа Ягъкуб кул күтәреп дога кылды —
ияге төште күкрәгенә салынып инде!
*Мәлик Рәййан бу хәлгә бик хәйран калды:
«Хәрамемнең,— ди,— ияге ник аерылды?»
«Пәйгамбәргә,— диде Йосыф,— шөбһә кылды —
көфер сөйләүнең җәзасын күрде инде!»
*Аннан Рәййан пәйгамбәргә күп ялварды:
«Бу хатынның яше-гомере байтак, диде,
дүнеп сезнең дингә дә ул кергән иде —
янә аңа изге дога кылсаң инде!» (...)
*Ягъкуб нәби кул күтәреп дога кылды —
ул хатынның шундук ияге утырды;
ул мескинә үз языгын аңлап алды —
«Исхак диеп мин белгәнмен» дия инде. (...)

[12] Хатыннар яши торган сарай



## XV бүлек. Ягъкубның Мисырдан чыгуы

Ягъкуб анда кырык елга кадәр торды.
Җәбраил бер көн килеп хәбәр бирде,
хак сәламен, вәхи сүзен ул җиткерде,—
әмер шулдыр: «Бу Мисырдан чыксын инде!»
Ягъкуб нәби хәбәр алгач бу әхвәлдән,
газиз Йосыфын дәштерде, кылды игълан,
Йосыф ишетеп моңга калды бу кайгыдан —
бәхилләшеп Ягъкуб юлга чыга инде.
Чыгарыннан әүвәл аңар үгет бирә:
— Йа, Йусефем, киңәшемне тотсаң,— дия,—
ахырда син бу Мисырдан чыксаң,— дия,—
мөэминнәрнең җае Мисыр түгел инде!»
Ягъкуб шулай Кәнган таба юлга керде,
газиз Йосыф аһлап-елап кире дүнде,
Мисырдагы түрә-вәзиргә белдерде:
«Ягъкуб нәби каумен җыеп китте инде!»
Ата-баба җиренә кайтып җитү белән,
күп тә түгел, берничә көн үтү белән,
гарше күктән[1] әмер-фәрман итү белән —
фәрештәләр килеп кабер казый инде.
Аны күреп Ягъкуб нәби сорый әхвәл,
тугры җавап бирә аңа фәрештәләр:
«Тәңренең бер дустына дип җиткән әҗәл —
гүр казыйбыз аның өчен, диеп инде». (...)
Фәрештәләр каберне тәмам иткәчтен,
гуд-ганбәр[2], зиба[3]-ефәк түшәгәчтен,
эчен-тышын гаҗәп күркәм бизәгәчтен —
Ягъкуб анда керергә дип теләр инде.
«Әгәр син,— ди фәрештәләр,— керер булсаң,
хакыйкатьтә бу урынны теләр булсаң,
бу тынлыкка[4] кавышуны эстәр булсаң —
йа Исраил, бу ширбәтне эчсәң инде!»
Кулын сонып Ягъкуб нәби алды аны,
«Бисмиллаһи» диеп эчте тустаганнан —
изге тәннән чыкты китте газиз җаны,
оҗмах таба мисле коштай[5] очар инде.
Җәсәден[6] ул фәрештәләр юып салды
һәм җәннәттән ак бүз китереп кәфен сарды,
шуннан соңра кавеменә хәбәр кылды —
йорты әһле[7] килеп зар-зар егълар инде.
Угланнары җеназасына җыелды,
фәрештәләр килеп янә намаз кылды,
дүртенче гүр ул җирдә һәм пәйда булды —
Халил[8], Сара, Исхак, Якуб анда инде.

[1] Алла ягыннан
[2] Хуш исле матдәләр
[3] Ефәк материя
[4] Үлем тынлыгына
[5] Кош кебек
[6] Җәсәде: мәет
[7] Гаиләсе, иң якын туганнары
[8] Халил — Ягъкубның бабасы, Сара — аның әбисе, Исхак — атисе



## XVI бүлек. Йосыфның Мисырдан чыгуы

Ул Җәбраил Йосыфка һәм хәзер килде,
халикыннан аңа сәлам, хәбәр кылды:
«Синең,— диеп, алтмыш ел гомрең калды —
шуңа лаек ярагыңны кылсаң инде.
Ошбу Мисыр халыкларын кыл син дәгъват,
исламга өндә аларны, китсен бидгать;[1]
пәйгамбәрсең син үзең, хаклыкка өндәп —
көфер юлдан дөрес юлга чыгар инде!»
Аннан Йосыф Мисыр халкын өндәп йөрде,
алар моны өнәмәде: «Көчләү!»— диде,
хәтта аңа Рәййан үзе шик белдерде —
«Исламга өнди ул безне!»— диләр инде.
Рәййан чакырып Йосыфны бик үгетләде:
«Мисыр халкы сөя сине гаять,— диде,
өндәмә тик боларны ул дингә,— диде —
кермәс алар исламга һич, куйчы инде!»
Йосыф аңа: «Белсәнә,— ди,— мәлик Рәййан,
моны миңа боерды ул кадир дәййан,[2]
аның әмерен генә сезгә иттем бәян —
үтәү тиеш тәңренең фәрманын инде!»
«Моннан ары,— ди,— мин болай һич кылмамын,
ахры, артык бу Мисырда[3] кала алмамын,
динсезләргә һаман күрше була алмамын —
безгә аерым тору кирәк булыр инде...»
Аннан Йосыф җәмгы мөэминнәрен җыйды,
күчеп китеп Мисырдан, бер шәһәр корды,
ул хуш җиргә «Нәһр-эл-гойун»[4] дип исем бирде —
бергәләшеп ул шәһрестанда[5] яшәр инде.
Ул хуп җирдә алар таба күп бәрәкәт,
елдан-елга арта һаман муллык-нигъмәт,
күренмидер һич ки анда көфер-низаг[6]—
шәһәр исме Имин[7] диеп мәшһүр инде.
Моны ишетеп Рәййан гаҗәепкә калды,
бу шәһәрне бер күрмәгә һәвәс кылды:
«Рөхсәт итсәң, шәһәреңә керсәм»,— диде —
Йосыф әйтә: «Монда көфер кермәс инде!»
Рәййан тыңлап Йосыфны мөселман булды,
ләкин тәңре аңа язмыш кылган иде,
кермәс борын ул шәһәргә Рәййан үлде —
берәүләр бүтән риваять әйтер инде.
Бәгъзеләр ди: «Рәййан озак гомер сөрде,
йөз дүндереп, мәҗүслеккә янә керде —
Муса пәйгамбәр Мисырда аны күрде —
ул чак аңа фиргавен Рәййан дирләр инде.
«Рәййан углы,— ди кайберләр,— Мөсгаб калды,
Ул Мисырда ике йөз ел хөкем кылды,
Мөсгаб углы фиргавен ул ләгыйн булды —
аңа Мөсгаб углы Вәлид дирләр инде.»

[1] Бозык дин
[2] Алла
[3] Биредә: башкала
[4] «Чишмәләр елгасы»
[5] Шәһәр-дәүләт
[6] Бозыклык һәм фикер каршылыклары
[7] Кол Гали Европа утопистларыннан әүвәлрәк «Утопия шәһәре»нең үрнәген бирә



## XVII бүлек. Йосыфның вафаты

Йосыф нәби ул шәһәрдә озак калды,
халик аңа бер көн әҗәл мәгълүм кылды.
Йосыф анда угланнарга үгет кылды:
«Саклагыз,— дип,— иманыгыз берүк инде!»
Аңардан элек Зөләйха вафат булды,
Йосыф аның хәсрәтеннән янды, көйде,
аннары соң янә бүтән өйләнмәде —
уллары ул тәрбия кылып яшәде инде.
Аннары соң Йосыфка да нәүбәт булды,
балалардан, туганнардан аерылды,
халик хозурына таба сәфәр кылды,
рәхим аңа мәрхәмәтләр кыла инде.
Кардәшләре, угланнары аһ-зар кылып,
ата-баба йоласы илә җеназа кылып,
ул сиддикъның табутын шәп җиһаз кылып —
мәетен һәм бер хуш җиргә күмде инде.

*(Йосыфтан соңгы хәл-әхвәл турында риваять)*

Бу тарафта булды бик күп муллык-нигъмәт,
адәмигә, бар җанлыга булды рәхәт,
вәләкин Мисыр ягында булды михнәт —
бик күп халкы ачлык-тарлык күрер инде.
Мәлик Рәййан Мөсалимгә илче йөртте,
Йосыф нәбинең табутын теләттерде.
Мөсалимгә, мәгълүм, бу сүз сәер булды —
«Атам гүрен ничек бирим?!» — диер инде. (...)
Аннары соң солых була ике арада,
Мөсалимгә үгет кыла кардәш-ага:
«Рәййан итте күп игелек,— дип,— атаңа —
сугыша күрмә, теләгәнен бир син инде!»
Рәййан килеп Йосыф нәби табутын алды,
яңа бик шәп төрбә корып, дәфен кылды[1],
ул тарафта[2] иркенчелек чиксез булды —
бу тарафка[3] кысынкылык килде инде.
Хәзер Рәййан Мөсалимгә кылды игелек,
Йосыф гүрен су эченә[4] куйды төшереп,
ул чагында Мисырга да булды муллык —
ике якка да бәрәкәт тулды инде.
Йосыф мәете кырык еллап суда калды,
Кәлимулла ниһаять Мисырга килде,
рәхим алла шул чагында әмер кылды:
«Сиддикымны су эченнән чыгар инде!»
Муса-кәлим Йосыф табутын эзләп йөрде,
белә алмады, бер карчыкны анда күрде,
килү белән Йосыф каберен ул күрсәтте —
шуңа аны белекле Мәрьям диләр инде.
•Муса[5] кайчан Йосыф каберен анык белде,
ул табутны су эченнән чыгарттырды,
таңресеннән һәм Мусага рөхсәт килде —
Мисырдан ул табутны алып китә инде.
Аннан Муса Кәнганга аны алып килә,
Ягъкубның каберен шунда эзләп белә,
Йосыфны да шул урынга җирләп күмә —
бүген анда зиярәткә[6] баралар инде.
Шөкер кылам, инде китап булды тәмам,
кадир мәүлям кылды илһам, рәхмәт аңа,
аңласагыз — меңәр төрле хикмәт монда,—
бу зәгыйфь[7] көйгә салып төзеде инде.

[1] Җирләү
[2] Ягъни: Мисыр ягында
[3] Ягъни: Мөсалим ягында
[4] Нил елгасына
[5] Муса — пәйгамбәр. Кәлимулла — аның кушаматы
[6] Исталеген яд итәргә
[7] Автор (традицион тәгъбир, бирегә физик зәгыйфьлек күздә тотылмый)

## Йомгак

Йосыф нәби кыйссасын хикәят кылдык,
гарәп-фарси теленнән аңлатып яздык,
укырга һәм тыңларга да булды анык —
укыганнар мактап дога кылсын инде.
Йосыф нәби кыйссасын һәр гакыйль укыр,
тыңлаган саен күңеле эрер, яше агар,
әгъзасыннан гөнаһлары сыгылып чыгар —
рәхман аңа рәхим шәфкать кылыр инде.
Белгән кеше бу назымны сөйләр булса,
гакыйль кеше колак тотып тыңлар булса,
укып-тыңлап безгә догаи хәер кылса —
тәңре аны шиксез кабул итә инде.
Укыганнар, тыңлаганнар дога кыла,
бу зәгыйфь дога көтә — халик белә,
хәер-дога гөнаһлыларны кичерә —
ярлыкауга лаеклы ул була инде.
Гәүһәр ташы[1] мәгәр әле гәүһәр булмас,
тикмә кеше гәүһәр кадерен таный алмас,
бу назымның кыйммәтен һич ахмак белмәс —
гакыйль кеше тыңлар, аңлар, белер инде.
Әй үкенеч, теләсә кем төзә алмады,
гыйльме, фикере ким кемсәләр яза алмады,
бу зәгыйфьнең ошбу назымы бозылмады —
дүрт юллыклы вәзенгә[2] тиң торыр инде.
Моны язган зәгыйфь бәндә Гали атлы,
егерме дүрт иҗеккә ул салып юлны,
ярлыкасаң, йа рәхим, бу гөнаһлы колны —
шәфкатеңнән өлеш өмет итәр инде.
Өмет тота бу языклы син мәүлягә,
син олуг, син шәфкатьле, син вәлигә[3],
мәрхәмәт кыл рәхим итеп Кол Галигә —
гамьле күңлен сөенечле итсәң иде.
Йа ходаем, бар хаҗәтем мәгълүм сиңа,
зарлы күңлем мөнаҗәте — тәңрем, сиңа,
йа рәхим вә рәхманым син, мәхрүм кылма —
соң сулышым иман белән үткәр инде.
Ул тәңредән булыш-ярдәм җиткәнендә,
олуг, изге рәҗәп ае утызында,
тарихның[4] һәм алты йөз дә тугызында[5]—
бу китабым төзеп тәмам кылдым инде.
Ярдәм, уңыш, фикри куәт аннан алдым.
аның илһам биргәненә шөкер кылдым,
бу арада китабымны тәмам кылдым —
«Сезгә, безгә ул файдалы булсын» инде!

*Тәмам*

[1] Ягъни: эшкәртелмәгән көе
[2] Шигырь үлчәве
[3] Биредә: яклаучы
[4] Биредә: ел исәбе мәгънәсендә
[5] 1212 елның 26 декабренә туры килә

# «КЫЙССАИ ЙОСЫФ» ҺӘМ АНЫҢ АВТОРЫ ТУРЫНДА

Хуш, әле генә «Кыйсса»ны укып чыккан кеше хәзер, мөгаен, әсәрнең заманы, җирлеге, мохиты турында уйлана булыр:

— Әдип кайда, кайчан туган? Гомер һәм иҗат юлы ничек булган? Дөньяга карашы, фикерләре нидән гыйбарәт? Ниһаять, кабере кайда?

Тик моннан сигез гасыр элек яшәгән автор хакында һәркемне канәгатьләндерерлек тулы-тәгал җавап бирү җиңел түгел: ул дәвердә автобиографияләр язу булмаган. Бердәнбер чыганак — әсәр үзе.

Шулай да күптән үк башланган фәнни эзләнүләр байтак сорауларны ачыкларга мөмкинлек бирде: әсәрнең төп чыганак нигезе булган кульязмалары җыйналып, төрле яктан тикшерелде; әсәрнең ышанычлы тәнкыйди тексты төзелде һәм басылып чыкты; төрле тәрҗемәләре мәйданга килде, автор хакында төп мәгълүматлар ачыкланды — кыскасы, 1983/84 елгы юбилейга ныклы нигезләмә булдырылды һәм шул уңайдан дистәләрчә мәкалә, җыентык, публикацияләр дөнья күрде. Күп кешеләр катнашында барган бу зур эшләрдә тулаем хаклы, төгәл фикерләр белән бергә кайбер төгәлсезлек, кимчелек, мавыгу һәм төрлелекләр очравы гаҗәп түгел. Киләчәктә алар төзәтелер дип уйларга кирәк.

Иң мөһиме шул: Кол Гали һәм аның үлемсез әсәре «Кыйссаи Йосыф» бәйле мәсьәләләр даирәсе бөтен киңлеге-тирәнлеге белән җәмәгатьчелек күзенә ачылды. Кол Гали — ул Гомер, Фирдәүси, Низами, Руставели, Җәлялетдин Руми, Җәми, Данте, Шекспир, Гете, Пушкиннар кебек үк, бөтен дөнья әдәбиятының бөек затлары сафында тора. Кол Галигә 800 ел тулуның ЮНЕСКО карары белән киң төстә бәйрәм ителүе әнә шуны тану һәм тәкъдир итү иде.

Язма әдәби традициядә — «Кыйссаи Йосыф» дип, шәкертләр — «Йосыф кыйссасы» дип, халык үзе «Йосыф китабы» дип йөрткән бу дастанны, ягъни шигъри романны белмәгән, ишетмәгән кеше юктыр дисәк тә, ялгышмабыз кебек. Бигрәк тә Казан, Идел-Урал җирлегендә әсәрнең кульязмасын эзләп, кая гына барма, тулы нөсхәсе булмаса, аерым өзекләре йә басма китабы табыла, йә сөйләмә хикәятен әйтүче очрый — һәрхәлдә, ни дә булса табылмый һич калмый.

Әүвәлрәк «Кыйсса» белән хәбәрдарлык тулырак, тирәнрәк булган. Ул мәктәпләрдә уку китабы булып йөргән: болгар-татар баласы, хәреф тану белән үк, аны укып ятлаган, мәдрәсә шәкертләре исә хөсне хат (матур язу һәм стилистика) дәресләрен үзләштерү белән. Кыйссаны үзенә күчереп алу, бүтәннәргә исә күчереп бирүне күңел һәм савап эше дип хисаплаган; каләм көче булганнар «Йосыф китабы» үрнәгендә беренче бәетләрен чыгарган, беренче тезмәләрен язып, мәгъшукаларына хат итеп күндергәннәр.

Бу язма дастан башта ук фольклор белән тыгыз бәйләнештә яшәп килгәнгә охшый. Шигъри тезмәләренең күмәк укылышка исәпләнгән булуы, үзенә махсус көе белән яттан әйтелүе — бу фикерне бик нык куәтли. Ул традициянең соңгы эзләрен Р. Фәхретдинев, Г. Тукай, Г. Бәширов һ. б. әдипләр бик җанлы тасвир итәләр, җөмләдән берсе:

«Безнең өй еш кына үзенә күрә бер әдәбият кичәсенә әйләнеп китә иде... Бу вакыт нәселдә бердәнбер татарча укый-яза белүче Яһүдә абзый лампага иң якын урынны ала... Болар арасында, ни өчендер, иң күп укыла торган «Йосыф китабы» була иде... һәрвакыт мөнәҗәт кебек көйләп укыла... Абзыйның осталыгы чамалы булгандыр инде, ул кайбер сүзләрне әйтә алмыйча, тотлыгып кала иде. Мондый чакта әни мәрхүмә — үзе бөтенләй укый белмәгән көйгә — абзый әйтә алмый торган сүзләрне һәм бәетләрне тоткарлыксыз яттан әйтеп, аны кузгатып җибәрә торган иде» (Кудаш С. Хәтердә калган минутлар. Казан, 1959, 6-7 бб.).

Бөек Ватан сугышы чорында бу традиция яңадан көч алып, 1950 елларгача дәвам итте. Кичләрен эрләү-бәйләү, фронт өчен җылы кием әзерләү кебек кул эшләре белән күрше-күлән, туган-тумача бер өйгә җыела. Шунда ук укучы балалар дәрес әзерли, фронт хатлары укыла — җаваплар языла, аһ-зарлар түгелә. Боеккан күңелләргә шулчак иң хуш килгәне Йосыф маҗараларын уку була торган иде. Әкият, җыр-бәет никадәр кабатланса да, ялыктырмый — бу да шулай. Чөнки һәр гаиләдән йә атасы, ире-туганы, йә улы-кызы, йә сөйгән яры ерак фронтта, хезмәт армияләрендә; карты-яше булсын — һәркем сагыш чигә, кавышу бәхетен — Ягъкуб, Йосыф, Зөләйхалар кебек үк — өмет итә, сугыш бетүен көтә. Аларның сабырлыгы, ныклыгы һәркемне рухландыра, соклandыра, сафландыра... Аннары һәр уку мәҗ-

лесе үзенчә: элек дикъкать итмәгән төшләре, кинәт, бөтен җанлылыгы белән күз алдына килә, гыйбрәтле вакыйгалары, кинаяле сүзләре өр-яңадан ачылып, яктырып китә... Яшьрәк буынга бирәр олырагы юл уңаенда кыска-кыска аңлатма бирә. «Кыйсса» шулай итеп яшь күңелләрдә дә яңгыраш таба иде. Боларның без белгән берничә авыл-төбәк белән генә чикләнгән хәл булмавын, гомуми күренеш икәнен һәм шул чорда ил берлегенә, ныклыгына хезмәт иткәнен аңлау кыен түгел, билгеле.

Халкыбыз яши торган якларга 1920 еллардан ук күп һәм төрле фәнни экспедицияләр оештырылып килә. Тел-әдәбият, тарих һәм культура мирасын җыйнаутуплау һәм, тикшереп, киләчәк буыннар өчен басма китап хәлендә саклап калдыру бөтенхалык, җәмәгатьчелек эше булып әверелде. Шул рәвешчә, 1980 елга «Кыйссаи Йосыф»ның 161 кульязма нөсхәсе тупланып һәм 70 тән артык иске басмалары мәгълүм булып, алар тикшерелде, тасвирлама ясалды. Кайсы яклардан табылуына күз салсак, хәл түбәндәгечә:

Татарстан — 115 нөсхә
Пермь өлкәсе — 11
Башкортстан — 9
Горький өлкәсе — 6
Идел буендагы башка өлкәләр — 11
Свердловск өлкәсе — 3 нөсхә
Касыйм шәһәре — 2
Оренбург өлкәсе — 2
Төмән өлкәсе — 2

Барлыгы — 161 нөсхә

*Татарстаннан табылган нөсхәләр (районнар буенча):*

Казан шәһәре — 32
Актаныш р.— 19
Сарман р.— 8
Әлмәт р.— 5
Арча р.— 7
Мөслим р.— 5
Лениногорск р.— 4
Апас р.— 4
Әгерҗе р. — 3
Минзәлә р.— 3
Биектау р.— 3
Балтач р.— 2
Буа р.— 2
Башка районнар* — 18

Барлыгы — 115 нөсхә

* Әлки, Зәй, Кукмара, Түбән Кама, Чирмешән, Чүпрәле, районнарыннан — икешәр, Балык Бистәсе, Кама Тамагы, Куйбышев, Октябрь, Питрәч, Саба, Чистай районнарыннан — берәр нөсхә табылган.

Бу мәгълүмат чик түгел, әлбәттә. Чөнки кайбер районнарга әле экспедицияләр чыкмаган, булган җирләрдә дә һәр авыл тоташтан тикшерелмәгән.

Әсәрнең кульязма нөсхәләре, башлыча, тарихи Болгар-Казан җирлегендә табылуы, димәк, әүвәлдән үк шунда таралыш алган булуына бәхәссез факт. Әгәр хәзер чит илләрдә яки өлкәләрдә саклана торган нөсхәләрне җентекли башласак, аларның да шул ук Казан-Идел ягыннан чыкканлыгы раслана. Мәсәлән, Берлин һәм Дрезден нөсхәсе икесе дә Казаннан алынганын Көнчыгышны өйрәнүче мәшһүр галим Карл Броккельман 1917 елда ук ачыклаган. Бу нөсхәләрнең тышлык һәм буш битләрендә әүвәлге хуҗаларының — князь Дәүләтгилдиев, Казан бистәсе тылмачлары, Саратов-Кузнецкий өязе татарларының — автографлары, Казан каллиграфларының матур язу һәм бизәк төшерү үрнәкләре һәм башка билгеләр бар.

Ленинградтагы ун кульязмадан өчесе Әстерханнан алынган булса да, аларның хуҗалары Казан арты Мәңгәр авылыннан һәм башка яклардан күчеп килгән татар укымышлылары икәнлеге нөсхә битләренә теркәлгән төрле-төрле язмалар белән раслана. Калган җиде кульязманың чыганаклары: 1) Казан университетында укып галим-тюрколог булган Ярцов нөсхәсе; 2) берничә нөсхә мәшһүр археограф Сәед Вахиди коллекциясеннән; 3) Казанлы бай меценат Апанаевлар коллекциясеннән; 4) 1934 елда СССР Фәннәр академиясенең Татарстанда эшләгән Археографик экспедициясе алып кайткан берничә нөсхә.

Уфадагы алты нөсхә (хәзер инде артыграк булуы мөмкин) шулай ук, асылда, татар халкы яши торган авыллардан: Каенаул (Пермь өлкәсе, Барда р.), Каран-Бишенде (БАССР, Туймазы р.), Сеңрән (БАССР, Илеш р.) яки татар гаиләләреннән табып алынган.

Бакудагы бер нөсхәнең шулай ук Идел буеннан чыкканлыгы безнең тарафтан гөман ителгән иде. Соңрак Ш. Абилов бу кульязманың, чыннан да, Казан мулласы Исмәгыйль Рәхмәтуллин тарафыннан Кировобад мулласына бүләк ителгәнен ачыкладоы (Татар әдәбияты тарихы. Казан, 1984, 1 т., 120 б., искәрмә.) «Кыйссаи Йосыф»-

ның хәзергә мәгълүм булган, архив, китапханә, музей һәм шәхси коллекцияләрдә тупланган барлык нөсхәләренең саны 200 гә якынлаша. Хәлбуки XIX-XX гасыр башларында һәр татар авылында — берничә «Кыйссаи Йосыф» кулъязмасы, һәр өйдә диярлек «Йосыф китабы»ның басма нөсхәсе булган. Соңгылары Казан нашир-ләренең эшчәнлеге белән аңлатыла. Монда сәбәп-максат бәйләнешләре бик тирәнгә китә: «Йосыф китабы»н халык яратып укымаса, наширләр бишәр, унар, егерме бишәр мең тираж белән 70 тән артык басмада, кайбер елларда 2-3 тапкыр бастырып чыгармаслар иде. Әсәр үзенең асылы, рухи юнәлеше, формасы белән халыкчан булмаса, аның күңеленә, хисенә хуш килмәс һәм яратып укылмас иде. Ул җирле халыкның теле белән,— билгеле, аның моннан 7-8 гасыр элек булган гомум язма теле белән — иҗат ителмәсә һәм бу язма әдәби тел, гомум фольклор теленә, аеруча халык эпосы теленә якын булмаса, «Кыйссаи Йосыф» тексты, укыла-укыла, ятлана-ятлана, күчерелә-күчерелә, югалмыйча, өзелмичә, безнең заманнарга кадәр килмәс тә иде.

Әсәрнең яшәеш-таралыш киңлегеннән, текстның вариацияләнүеннән үк инде аның озын, катлаулы юл үткәнен һәм культурабызда гаять мөһим урын тотканын чамалап була. Ул халык рухына элек-электән үк шундый тирән үрелгән ки, аның үз авыз иҗаты кебек үк, «Сак-Сок»лары, җырлары кебек үк анонимлаша язган. Аның бик күп мотив һәм сюжет сызыклары җыр, такмак һәм бәетләргә, шәкертләр фольклорына — истәлекләргә, риваять һәм әкиятләргә кергән.

Әсәр тулаем тыгыз бербөтен булуына карамастан, фәнни анализ аны төзем өлешләренә аерып тикшерүне таләп итә. Шунсыз аның эчтәлеге һәм формасының тирән үзлекләрен танып-белү мөмкин булмас иде. Дастан өч төп кисәктән гыйбарәт: А. Кереш («мөкаддимә»), Б. Хикәяләү — сюжет өлеше (I—XVIII фасыллар), В. Йомгаклау өлеше («хатимә»).

Әсәр эчтәлегенең төп үзәген, әлбәттә, сюжет вакыйгаларын эченә алган хикәяләү өлеше тәшкил итә. Әмма традицион сюжетның нәкъ бу конкрет автордагыча сурәтләнешен, аңлатылышын ахырынача дөрес төшенү өчен, әлеге кереш һәм бигрәк тә хатимә бүлеге кирәк булган. Бу чагыштырмача кыска гына ике бүлек, гүяки, традицион сюжетны ике яктан автор билбавы белән урап алган кыршау кебек. Ул «автор кысасы» дип атала, анда сюжет-вакыйга бәян ителми, бәлки авторның үзенә һәм әсәрнең иҗат ителешенә бәйле булган гомуми караш һәм мәгълүматлар урын ала. Шәрык поэзиясендә мөкаддимә-хатимәләрнең кануни рәвештә урнашкан кагыйдәләре бар. Һәр әдип үзенә, үзенең карашларына, әсәрнең иҗат ителүенә багълы мәгълүматны әнә шул үрнәк калыпларга салырга тиеш булган.

Кереш бүлеге — Шәрык ислам поэзиясенең кануни башламы, һичбер автор моны читләтеп үтә алмаган. Тарихи яки легендар затларның дәрәҗәсенә карап, һәркайсына аерым-аерым, дистәләрчә тезмәдән гыйбарәт мәдхияләр язылган. Кол Гали исә бу мәҗбүриятне бик «кыска тотып», һәркайсына берәр генә тезмә (строфа) багышлаган. Икенчедән,— һәм бусы иң мөһиме — ул юллар шул заман һәм җирлекне, ил-дәүләт ситуациясен һәм идеологиясен тегә йә бу рәвешчә чагылдырмый кала алмаган. Аларны региональ-этник, дини-идеологик, тарихи-хронологик һәм башка яклардан җентекләп тикшергәндә, автор һәм әсәрнең атрибуциясе өчен мөһим мәгълүматлар табыла: авторның ортодоксаль сөнни региюннан булуы, аның да Әбү-Хәнифә мәзһәбендәге ил-халык арасыннан икәнлеге ачыклана, ә бу исә шигый, шафигый, хәнбәли h. б. мәзһәб таралган бик күп ил һәм өлкәләр автор яшәгән һәм аның әсәре иҗат ителгән җирлектән читтә булган дигән сүз. Әлбәттә, Кыйссаның җирлеген билгеләү өчен, бу мәгълүмат кына җитми: кулъязмаларның борынгы һәм хәзерге таралыш даирәсе h. б. өстәмә чыганаклар комплексы да исәпкә алына.

«Илһам теләү» бүлемендә автор, бөтен дөнья поэзиясендә кабул ителгән гадәт буенча, илһам алиһәсенә фикер ачыклыгы, тел күрке сорап мөрәҗәгать итә.

Шуннан соң автор әсәрнең планын, өлешләрен билгели. Йосыфның ата-бабаларын, ягъни кыскача шәҗәрәсен санап чыга. Тыңларга татлы, күңелле, күркәм булган бу хикәятнең Коръәндә дә теркәлүен искәртеп, дини фанатиклар һөҗүменә каршы тору өчен, бусы да бик кирәк булгай ахры, үзенең максатын болай дип белдерә:

*Моннан соңра хикмәт таба күчәрмен дим,*
*гөл вә рәйхан, энҗе-мәрҗан сачәрмен дим,*
*газиз Йосыф әхвәлләрен ачармын дим —*
*мөэминнәргә гыйбрәте күп, аңла инде.*

Бу максатлар хикәяләү бүлегендә үтәлә. Һәм «Кереш» бүлегендә чагылган күп кенә мотивлар «Йомгаклау» бүлегендә дә нәтиҗә буларак искә алына, ягъни кереш,

хикәяләү һәм йомгаклау бүлекләре бер-берсенә гаҗәеп ярашкан һәм аваздаш яңгырыйлар.

Автор бу күләмле, катлаулы әсәрне иҗат иткәндә, билгеле, бер генә чыганак белән чикләнә алмаган, һәм үзе үк:

> *Йосыф нәби кыйссасын хикәят кылдык,*
> *гарәп-фарси теленнән аңлатып яздык*

дию белән гарәп һәм фарсы үрнәкләренә ишарә итә. Әмма урта гасырдагы иҗат эшендә чыганакларга мөрәҗәгать итү, алардан өлешчә файдалану ул әле тәрҗемә дигән сүз түгел. Әлеге контексттан андый мәгънә чыгарырга омтылу, янсә традицион сюжетта ук булган мотив һәм эпизодларны Фирдәүси ~ Кол Гали параллеле белән генә, яки бүтән бер чыганак белән генә чикләргә тырышу үзен акламый һәм расланмый.

«Йосыф» сюжетын Кол Галигә кадәр төркичә әдәби эшкәрткән әсәрне тарих белми. Әмма авторның стиленә хас читләтеп әйтүләрне искә алсак:

> *Әй дәригә, дикмә кемсә дөзүмәде,*
> *фәһме иксүк кемсәләр язумады.*
> *(Әй үкенеч, теләсә кем төзә алмады,*
> *гыйльме, фикере ким кемсәләр яза алмады)*

дигән юллар, күрәсең, аңа кадәрге кайбер тәҗрибәләрнең уңышсыз чыгуын чамаларга нигез бирә.

«Кыйссаи Йосыф»ның янә бер мөһим үзенчәлеге — халык җырларына хас «бармак үлчәме» — иҗек исәбе белән язылуында.

«Кыйссаи Йосыф» строфасының рифмалашуында да үзенә генә хас яклары бар. Мәсәлән, һәр тезмәдә баштагы өч юл уртак рифма белән бер-берсенә үрелеп килә дә, дүртенче юл әлеге рифмага буйсынмаган *имди* рәдифе белән тәмамлана. Шунысы да игътибарга лаек, бу *имди — инде* сүзенең ачык беленеп торган лексик мәгънәсе юк, ул кисәкчә буларак сөйләмдә һәм язмада өстәмә сүз җилеме булып йөри, тойгылы акцент, тыныш функцияләрен үти, «Кыйсса»да, рәдиф буларак, бөтен строфаларны бер-берсенә бәйләү, бер җепкә тезү йомышын да башкара.

*Имди (инде)* кисәкчәсенең «Кыйссаи Йосыф»тагыча рәдиф булып кулланылуы моңарчы, борынгы татар әдәбиятыннан башка төрки әдәбиятларда күренгәне юк (Татар әдәбияты тарихы, 1 т., 118—120 бб.). Бездә ул «Кыйссаи Йосыф»тан соң, әледән-әле кулланылып килә, хәтта XX гасыр башында һәм революциядән соң да очраштыра. Моның «Кыйссаи Йосыф» традициясе белән бәйле булуында шик юк. Икенчедән, *имди (инде)* кисәкчәсенең төрле төсмер һәм функция белән сүз җилеме буларак киң кулланылышы шулай ук татар телендә генә, башка төрки телләрдә ул үзенең әүвәлге төп мәгънәсен, «хәзер, хәзерге» мәгънәсен, әле һаман да саклап килә. «Кыйссаи Йосыф»та исә аның «хәзер, хәзерге» мәгънәсендә кулланылуы очрамый. Бу — «Кыйссаи Йосыф» авторы һәм әсәренең Идел буе төркисе белән, иске татар әдәби теле һәм поэзиясе белән тамырдан бәйләнгәнен, татар поэтик традициясенең чишмә башы булуын тагын бер кат раслый.

Кол Гали шигыренең янә дә бер поэтик үзенчәлеге шунда ки, һәр тезмәнең эчке җегәрен өчәрле кабатлану — градация тәшкил итә: ягъни әүвәлге өч юл бер-бер артлы мәгънәви-хисси, яки мәгънәви-логик яктан көчәеп килә-килә дә, өченче юлда иң югары дәрәҗәсенә җитеп, көчле тойгылы басым ясала, һәм соңгы юл нәтиҗә рәвешендә әкренләп салмак аһәңгә күчеп *инде (имди)* тынышы белән төгәлләнә. Музыкаль башкарганда исә, бу зур пауза-аккорд белән тәгъбир ителә.

Шуның белән бергә «Кыйсса» тезмәләрендә алгы рифма, эчке рифма, тирән рифма һәм аллитерацияләр бик күп очрый. Бу тәрҗемәчедән гаять түзем эш итүне, бер тезмәдә чагылдыруы мөмкин булмаган аһәң рифмаларын, икенче уңай тезмәләрдә тутыруны таләп итә. Шул рәвешчә тышкы аһәң поэтикасы белән, эчке семантик, хисси-психологик поэтика аерып алмаслык берберөтен хасил итә һәм моның укучы хәтере-акылына, хисе-тойгыларына тәэсире бермә-бер көчәя. Ул гына да түгел, *өчәрле* кабатлану эпизодларның сәбәп-мотивларында да чагыла. Мәсәлән, иң элек, Ягъкуб кинаяле төш — Йосыфны бүре алганын күрә, икенче кат — кызы Динәнең төше.

Өченче кат — чын бүредән сорау алу. Хәлбуки, бүре кинаяи генә, чынбарлыкта ике аяклы бүреләр булуы укучыга ачык. Шул ук рәвешчә Йосыф *өч көн* коеда кала, Зөләйха өч тапкыр төш күрә, Йосыфның агалары Мисырга өч мәртәбә икмәк алырга киләләр һ. б. ш. кебек өчәрле кабатлану саннар гармониясе бөтен

әсәр тукымасына салынган! Бу хәл, күрәсең, шундый зур күләмле дастанны ятлау һәм башкару өчен дә кулай булгандыр. Һәрхәлдә, мондый кабатланыш — халык иҗатыннан ук килә торган сыйфат.

Әсәрнең идея эчтәлеге, сюжет-фабула колачы, хикәяләү һәм композиция үзенчәлекләре, шигырь төзелеше, теле һәм стиле — болар бөтенесе дә аның жанрын тулаем *дастан (эпос)* дип билгеләү мөмкинлеген бирә. Әсәрнең төп юналеше — традицион мифологик сюжет кысасы мөмкинлек биргән кадәр — реаль кеше, ил, җәмгыять тормышын сурәтләүдән гыйбарәт, кеше гомерендә очрый торган табигый үсеш-яшәеш этапларын, каршылык һәм кыенлыкларны, котылгысыз мәсьәләләр һәм конфликтларны, хис-өмет, кичереш һәм омтылышларны, ниһаять, аларның төрле баскычта, төрле очракта төрле рәвешләрдә тормышка ашуын күрсәтүдән гыйбарәт.

Әмма дастан дип әйтү белән генә әсәрнең жанр хосусиятләре һәм жанрга бәйле үзгәлекләре тулы ачылып җитми әле. Беренчедән, «дастан» термины бик гомуми, ул бик күп төрләрне үз эченә ала. Икенчедән, «Кыйсса»ның эчтәлек һәм форма тукымасында героик-эпик, тарихи-реалистик, лиро-эпик, романтик, хисси-лирик, лирик-психологик; җиңелчә скепсис, тәнкыйть һәм юмор башлангычлары да тегеге я бу өлешчә урын алган. Әсәрдәге ул үзенчәлекләрнең һәркайсын бәйнә-бәйнә сыйфатлап язарлык нигезләр бар. Әгәр берәү үзенең тикшерү объектына, нинди дер сәбәпләр белән, субъектив һәм берьяклырак килсә, ул әлеге башлангычларның тегесә кайсына аеруча басым ясарга мөмкин. Чыннан да: берәүләр аны дини поэзия жанры («пәйгамбәрләр кыйссасы») дип карауны алга сөрә; кайбер тикшерүчеләр исә мәхәббәт романтикасын гына күреп һәм әсәр исемен дә «Йосыф-Зөләйха»га алмаштырып, «дөньяви гыйшык» сызыгын, эчке хис-кичереш маҗараларын, рухи иркенлек мотивларын һ. б. купайтып күрсәтәләр, гүяки атеистик һәм «иреклe тәрбия» максатыннан беренчеләргә каршы чыгалар; өченчеләр исә XII-XIII гасыр авторына хас була алмаган критерий куялар.

Хәлбуки, «Кыйсса»ның диапазоны киң, күптөрле һәм күптөсле: контекстка нигезләнеп тикшерә башлау белән идея-мәгънәви эчтәлегендә берничә планлылык (туры һәм күчерелмә мәгънәләр, киная-ишарәләр, мәгънәви акцент һәм кабатлаулар), тарихи-генетик тикшерә башлау белән — төрле җирлек һәм дәверләрнең катламнары аерымлана башлый.

Без исә Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ын *шигъри роман* дип тә билгели алыр идек, чөнки монда дини-мифологик элементлар белән бергә мәхәббәт романтикасы шактый урын алса да, әсәрнең төп идея эчтәлеге һәм проблематикасы үзәгендә иҗтимагый-тарихи, социаль-этик, гуманистик мәсьәләләр ята һәм сюжет панорамасында аларның күпчелеге тормыш-көнкүреш реализмы яссылыгында сурәтләнгән, ә кешелек өчен мәңгелек проблема булып торган социаль гаделлек һәм рациональ хуҗалык итү һәм идарә мәсьәләләре соңгы исәптә социаль утопия юнәлешендә хәл ителгән (һәм ул дәвердә башкача бирелүе мөмкин дә булмаган).

Кол Гали әсәрен *эпопея* дип атау өчен дә мөмкинлекләр җитәрлек... Без бу атамаларны әлегә фараз-тәкъдим рәвешендәрәк җәмәгатьчелек алдына куярга уйладык. Чөнки моңа кадәр кулланылышта йөргән поэма, дастан яисә романтик поэма дигән якынча билгеләмәләр безне инде канәгатьләндерә алмый, чөнки алар Кол Гали әсәренең хосусиятен тарайтып күрсәтергә яки үзгәртеп аңлатырга юл куялар.

Әйтик, моңарчы күбрәк «романтик поэма» дип билгеләү очраса да, ул гомумән төгәл атама түгел. Әгәр романтизм юнәлешендәге әсәр дип аңласак, «Кыйссаи Йосыф»ның бу әдәби юнәлеш белән бәйләнеше юк; хыялый, хисси, эмоциональ дип аңласак, бу да аның төп атрибуты түгел, бер ягы гына; романтик (=романик) «мәхәббәткә бәйле» мәгънәсендә дә кулланыла: романтик поэма — мәхәббәт поэмасы. Тик әсәр мәхәббәт, гаилә темасына гына кайтып калмый, автор да аны «Йосыф-Зөләйха» дип атамаган бит.

Кыйссаның авторы Гали (яки Кол Гали) турында тарихта мәгълүмат бик аз сакланган. Төп чыганак — әсәр үзе, аның йомгак бүлеге.

Гали — Идел буе, Болгар иле төбәкләренең берсендә 1183 еллар тирәсендә (башка чыганак һәм исәпләүләр буенча 1163-1168 елларда) туып, җирле мәктәп-мәдрәсәләрдә укыган булса кирәк. Аннан соң, урнашкан гадәт буенча белем эстәп читкә киткән. Кәрван юллары аны иң элек Харәземгә алып килә, ә анда Әхмәт Ясәви һәм аның шәкерте Сөләйман Бакырганн мәктәбенең чәчәк аткан чоры. Безнең автор, һәрхәлдә, күпмедер вакыт биредә укыган булырга охшый. Аннан соң үзенә яңа остазлар эзләп, Нишапур, Сүрия, Кодес һәм Мәккә якларына сәяхәт иткән, мәшһүр шагыйрь һәм галимнәр белән аралашкан, хәким шәехләрнең лекцияләрен тыңлаган. Күп еллардан соң, туган иленә кайтып, үзе дә мөдәррислек һәм иҗат белән шөгыльләнгән.

Авторның үзе хакында бик аз мәгълүмат калдыруы бүгенге кешегә сәер тоела. Ләкин бу хәл борынгы әдәбиятның торышы — статусына бәйле: ул чакта әле авторлык хисе, хокукы хәзергечә булмый. Авторлар күбесенчә гомуми традицион сюжетларга язалар. Шуңа күрә язма әдәбият фольклордан (ягъни кәгазьгә теркәлгән халык дастаннарыннан) бик нык аерылмый, иҗатчы автор белән башкаручы-импровизатор арасындагы чикләр дә томанлы. Кол Галинең вакыт-вакыт үзен дастан әйтүче-башкаручы кебегрәк хис итеп язуы шул күренешнең бер чагылышы булса кирәк. Кол Галинең яшьтән үк көй-шигырьгә сәләтле, яхшы хәтерле булуы, болгар риваятьләрен белгән, угыз-кыпчак дастаннары белән сугарылган булуы хакында ышанычлы итеп әйтергә мөмкин, чөнки бу аның әсәр тукымасында көчле чагылыш алган.

Ул гына да түгел: автор үзен гади халыктан аермый, алар җырын җырлый, алар көен көйли, шуңа да ул сарай шагыйрьләренчә өстен катлауларны мактап багышлама язмаган, әсәрен хан-әмирләргә тәкъдим итмәгән, ул, киресенчә, «Кыйсса»ның азагын: «Сезгә, безгә ул (кыйсса) файдалы булсын инде!» — дип киләчәк укучыларына, әсәрнең язмышына зур өмет һәм ышаныч белән тәмамлаган. Бу — аның позициясе ныклы булуын, әсәр тукымасына сибелгән дөньяви-реалистик, халыкчанлык, гаделлек, әдәп-әхлак һәм тәрбия карашларының бер-берсе белән тыгыз бөтен булып үрелгәнен раслый.

Инде сорау туа: бу сыйфатлар авторга хас саф индивидуаль күренешме, әллә алар конкрет тарихи шарт белән, заман рухы белән дә сәбәпләнгәнме? 1212—1233 еллар арасындагы Болгар иленең хәрби-политик хәләтенә күз салыйк. Монголларның беренче һөҗүмен уңышлы кире кагу гына ил иминлеген тәмам тәэмин итмәгәнлеге аңлашыла. Болгар чикләрен монголлар һаман тынгысызлап торалар. Түбән Идел, Җаектан, Саксин һәм кыпчак сахрасыннан агылып килгән качаклар да ил өстенә ябырылуы мөмкин афәтне искәртә. Бу хәл, әлбәттә, җәмәгатьчелек фикерендә төрле караш һәм позиция тудырмый калмаган. Ил, дәүләт, бөтен халык язмышы алгы планга чыгып, ватанчылык хисләре көчәйгән чакта, алдынгы карашлы акыл ияләренең халыкка мөрәҗәгать итүләре, Кол Гали кебек мәшһүр шагыйрь һәм мөдәрриснең дә шулар арасында булуы, һичшиксез, аның идеалларына туры килә.

Бу шартларда гомумхалык эпосы булып әверелгән «Кыйссаи Йосыф»ның ролехезмәте янә дә күтәрелеп, актуальләшеп китүе соңгы аналогияләр белән дә раслана.

Бу чорда, ягъни 1212—1233 еллар аралыгында «Кыйссаи Йосыф» кебек әсәр язылырдай бүтән төрки дәүләт, регион, җәмгыять булмавын Җ. Алмаз, Г. Таһирҗанов һ. б. бик хаклы, ышанычлы һәм тәфсилләп исбат иткәннәр иде. «Кыйссаи Йосыф» кульъязмаларының башлыча, Урта Идел буенда таралуы һәм табылуы да шул ук нәтиҗәләргә китерә: димәк, әсәр Болгар-Казан җирлегендә иҗат ителгән, Идел буена монголлар килгәнче үк тәмамланган дигән сүз.

«Кыйссаи Йосыф»та монгол элементларының бөтенләй очрамавы, 1236-40 ел фаҗигаләренең әсәрдә чагылмавы (дөресе — чагылыш алырга өлгермәве) әле ул чакта, 1212-32 елларда, Болгарның тыныч тормышта мөстәкыйль яшәгәнен, поэманың монгол яуларынача иҗат ителгән булуын раслый. Әгәр Кол Гали шул һәлакәтне кичергәннән соңрак яшәгән булса, бу хәлләргә үзенең мөнәсәбәтен белдерми калмаган булыр иде...

Монгол яуларыннан соң Идел-Кама болгарларының шактый өлеше төньякка — Казан артына, төньяк-көнбатышка — Тау ягына, төньяк-көнчыгышка — Кама-Чулман, Нократ Иделе, Зәй-Иж-Ык һәм Агыйдел тамагына күчеп утыра. Кама аръягындагы элекке Болгар, Биләр, Суар җирләре ярым буш дала булып, монгол (соңра — нугай) урдаларының көтүлекләренә әйләнә. Шул сәбәпле булса кирәк, хәзергәчә «Кыйссаи Йосыф»ның күпчелек кульъязмалары нәкъ менә шул болгар бабалар, аннан соңра казан татарлары (XVI—XIX) күчеп утырган төбәкләрдән табыла.

Кол Галинең ул заманда иҗат белән генә яши алмавы, бәлки укымышлылыгына, дәрәҗәсе, талантына тиң булган рәсми вазифа башкарган булуы аңлашыла. Кол Галинең шул заман гыйлемнәр даирәсеннән киң хәбәрдарлыгы: ислам теологиясе, фәлсәфә һәм тарихы, телләр белүе, филология, гаруз һәм хокук гыйлеме, анатомия һәм табиблык (!) белән дә бик яхшы танышлыгы әсәр тукымасындагы күпләгән детальләрдән сиземләнә. Бу аның күп җирләрдә сәяхәт итүе, төрле халык, тел, дин, культуралар белән якыннан аралашуы, алдынгы карашларны, көнчыгыш ренессансы — яңарыш рухын үзләштерүе белән аңлатыла.

1210—1212 елларда «Кыйсса»ның башлангыч редакциясен тәмамлаганда, автор урта яшьләрдә генә (45-55) булгандыр ахры. Әмма соңгы редакциясен эшкәрткәндә (1232-33), ягъни 20-21 елдан соң) аның олы яшьтә икәнлеге ачык күренә. Ә 1236—1240 еллардагы сугышлар вакытында аның һәлак булуы да ихтимал...

Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы — Идел буе язма әдәби традициясендә безгә билгеле булган борынгы әдәби ядкарьләрнең иң беренчесе һәм иң күренеклесе. XIII гасыр башларында (1212—1233) язылган бу тезмә әсәр татар халкының һәм язма әдәби, һәм авыз иҗаты мирасында ныклы урын алып, менә сигез йөз елга якын инде халкыбызның рухи дөньясын тәрбия итеп килә.

Болгар-Казан, борынгы һәм яңа татар әдәбиятының тарихи барышында ул бик күп әдәби талантларны илһамландырган, күп миллионнарча укучы һәм тыңлаучыга рухи азык биргән, гасырдан-гасырга күчә һәм күчерелә килеп, халык тормышы һәм культурасының аерылгысыз өлеше булып яшәгән, хәрәкәт иткән һәм әдәби-эстетик һәм тәрбияви функция башкарган. Ул бүген дә яши, һаман хәрәкәттә.

«Кыйссаи Йосыф»ка карата, күп кенә борынгы язма ядкарьләрдән үзгә буларак, «яңа табылган, әле ачылган» дип билгеләү туры килми. Чөнки аның кайчандыр югалып, традициясе өзелеп, онытылып торганын яки кем дә булса табып, әдәби әйләнешкә кертеп җибәргәнен тарих белми. Идел буеның катлаулы тарихына карамастан, «Йосыф китабы»ның ике йөздән артык кулъязмасы табылган булуы үзе генә дә күпне сөйли, күпне исбат итә! Бу күзлектән борынгы әдәби әсәрләрнең бик сирәкләре генә аның белән ярыша алыр. Шуңа күрә бөек Тукайның: «Әмма менә бу кыйммәтле мирас дидекемез халык шигырьләрен туплар да ватмады, уклар да кадамады. Алар һаман да халык күңелендә...» — дигән сүзләре «Кыйссаи Йосыф» кебек әдәби ядкарьләргә карата бигрәк тә хаклы.

Бөек шагыйрь, бөек әсәр үз җирлегендә генә калмый, ул күрше халыкларга да — әдәби, мәдәни, демографик бәйләнешләр аша — таралып мәгълүм була, торабара халыкара дан казана, бөтен кешелек өчен кыйммәтле, кадерле, актуаль мирас булып әверелә. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы белән дә нәкъ шундый ук хәл: аны күрше башкортлар татар әдәбиятының башка әсәрләре белән бергәттән укып килгән, казахлар, комыклар аны үз телләренә тәрҗемә иткәннәр. Кырымда һәм Кече Азиядә дә Кол Галинең кайбер әзләре табыла. Төрки телдәге беренче лирик-эпик поэма буларак, *ул һәр төрки тел һәм әдәбият филологиясе өчен чагыштырма чыганак булып* хезмәт итә ала. Шул ук вакытта бу — «Кыйссаи Йосыф» гомумтөрки әсәр, яки гомумтөрки әдәби тел ядкаре дигән сүз түгел, чөнки XIII гасырда гомумтөрки дәүләт юк, ул региональ төрки дәүләттә — Болгардагы язма традицияләр җирлегендә иҗат ителгән һәм шунда гасырларча яшәп килгән.

Журнал укучыларга «Кыйссаи Йосыф»ның безнең тарафтан хәзерге әдәби телгә салынган яңа варианты тәкъдим ителде. Һәр тәрҗемә — ул борынгы әсәрне аңлау, аңлатуда бер яңа этап дигән сүз. Кол Гали иҗаты һәм әсәренең тирән мәгънәләре-серләре әле ахырынача ачыкланудан ерак. Шуңа күрә аның яңадан-яңа тәрҗемәләре һәм төрле яклап тирән фәнни тикшеренүләре киләчәктә дә булыр дип ышанабыз.

**Фазыл ФӘСИЕВ,**
филология фәннәре кандидаты.

## ӘДӘБИЯТ

Алмаз Җәвад. Кол Галинең «Кыйсса-и Йосыф» дастаны.— Совет әдәбияты, 1960, 2 сан, 92—114 бб. Алмаз Джавад. «Кисса и Юсуф» Али — булгаро-татарский памятник. М., 1960.

Борынгы татар әдәбияты. Казан, 1963. 67—96 бб.

Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. Казан, 1983.

Кол Галинең 800 еллыгына багышланган материаллар.— «Казан утлары», 1983, 9 сан; 1985, 2 сан.

Кул Гали. Сказание о Йусуфе. Казань, 1985.

Поэт-гуманист Кул Гали (сб. материалов). Казань, 1987.

Татар поэзиясе антологиясе. Казан. 1956.

Татар әдәбияты тарихы. 1 том. Казан, 1984. 115—157 бб.

Таһирҗанов Г. Тарихтан — әдәбиятка. Казан, 1979. 79—94 бб.

Тагирджанов А. Влияние поэмы Фирдоуси «Юсуф и Зулейха» на «Кисса-и Йусуф» Али.— К-та: Палестинский сборник. Вып. 21(84). Л., 1970. 46—61 бб.

Фәсиев Ф. С. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы. Сюжет, композиция, идея эчталеге. Татар теле һәм әдәбияты. Т. V. Казан. 1976. 154—173 бб.

Хисамов Н. Ш. Поэма «Кисса-и Йусуф» Кул Али. М., 1979.

Хисамов Н. Ш. Бөек язмышлы әсәр. Казан, 1984.

# ПРОЗА

## Якуб Зәнкиев

# ИРТЕШ ТАҢНАРЫ

РОМАН



Йә, бу нәрсә?.. Шамил Сәрвәрнең исемен әйтмәкче була, сулыш җитми, тыны кысыла, йөрәге әллә кайчан таудан тәгәрәгән таш сыман, гел хәрәкәттә, туктаусыз тибә, атылып чыгарга дип күкрәк читлеген кага, уйлар, сораулар, җавапсыз сораулар ми тартмасына тыгызланып тулганнар да башны ярырдай булып кысалар, чигәләр сулкылдый...

— Сәрвәр? Сәрвәрне нишләттегез?!

Шушы ике сүзне Шамил бик озаклап, туктый-туктый әйтте, ул яңадан тотлыга башлаган иде...

Хафиз әкә атын капка төбенә куеп йортка кереп килгәндә Шамил Сәрвәрне кулларына күтәреп алган да нишләргә белми шаккатып тора иде. Ачык капкадан кереп тулган бала-чага да шым булган. Өннә апа капка келәсен кулына тоткан килеш онытылып басып тора, Шәмсеруй, кызының аяк очына басып, яшь коя иде.

Олырак бер малай өйалдыннан чүмеч белән су күтәреп чыкты, Сәрвәрнең иреннәренә су койды, ләкин бичара кызның су йотарлык хәле дә калмаган иде. Шамил кызны кадерләп күкрәгенә кысып алды һәм капкага атлады. Әллә каян гына чыккан җил Сәрвәрнең толымын җилфердәтеп егетнең коңгырт чәчләренә китереп чорнады, җил аңа чак кына хәл кертте. Ике көн буена бу фаҗигадан алҗыган, һушы китеп рухы сынган Шәмсеруй апа ни дип тә әйтә алмый иде. Вакытны әрәм итмичә авыруны хәзер үк больницага алып китәргә кирәклеге көн кебек ачык. Тик менә ничек алып китәргә? Эшкә яраклы ирләр, авыл яшьләре берсе дә өйдә юк. Тапканнар бит кызны мәсхәрәләргә иң җайлы чакны! Яшьләр менә ничә көн инде Кобланды батыр җирендә куна-төнә печән чабалар. Атларның да җигәрлеге, рәтлесе шунда, Иртеш аръягында. Картаеп, аяклары көянтәдәй кәкрәйгән Хәбир җирәне дә арык кола бия генә кардада калганнар.

— Ат кирәк, Хафиз әкә!— диде Шамил, тотлыга-тотлыга.

Торадан кайтышлый тәмам алҗыган атына карап Хафиз әкә чырт итеп җиргә төкереп куйды. Ул арада Иртеш ягыннан дыңгырдаган дүрт-биш арба, чабышып килгән ат тояклары тавышы ишетелде. Атлар Сәрвәрләр капкасы янына килеп җитеп, бөялешеп тукталдылар, ашыгудан күчәр башлары бер-берсенә эләкте. Алдагы арбадан дилбегәсен ике куллап кысып тоткан Маннур сикереп төште. Аңа хәбәрне Сәлимә җиткергән булган, ул барып әйткән. Шамил кулындагы Сәрвәрне күргәч, Маннур:

— Хәле ничек?— дип сорады.

---

Ахыры. Башы 1, 2 нче саннарда.

— Яман,— диде тотлыга-тотлыга Шамил.— Аны хәзер үк больницага алып барасы иде...

— Әнкәсе дә барсын,— диде Хафиз әкә.— Дөнья хәлен белеп булмый, кызның хәле авыр күренә.

Ул арада пар ат җигеп председатель Дәүләтша әкә дә килеп җитте, ул да аргы болында булган да, яман хәлне ишеткәч, монда чапкан. Сәрвәрне йомшак рессорлы тарантаска салырга кушты да әйтте:

— Хәзер үк торып чабыгыз! Атлар болында ял иткән, тиз йөрегез!

Шамил буынсыз калган Сәрвәрне ике беләгенә салып тарантасның түренә менеп утырды, алар янына битеннән каны качкан Шәмсеруй апа килеп сыенды, сыенды да Шамилнең беләгенә асылынып үкереп җылап җибәрде.

— Нигә иртәрәк кайтмадың? Ичмасам бер көн генә иртәрәк кайткан булсаң да бу хәлләрне күрми идек бит!— дип кабатлады.

Шәһәр юлын җилдереп кенә үттеләр, печән өстендә көрәйгән юртаклар, дилбегә какканны да көтмәделәр, юырттылар да юырттылар. Шамил Сәрвәренә наз сүзләрен әйтергә дип авызын ача да тотлыгып тыелып кала, читенсенә... Алар кичке караңгыда гына больницага барып җиттеләр. Сәрвәр исенә килмәде, вакыт-вакыт авыр сулап, ыңгырашып кына куйгалады. Ләм-мим дәшмәде.

Авыруны кабул итеп алган врач:

— Көтелмәгән авыр кичерешләрдән була торган нервный шок, бетеренмәгез, абыстай, кызыгыз терелер,— диде дә Шамилгә күтәрелеп карады.— Ә сез аның кеме буласыз?

— Дусты, дусты!— диде ашыгып-ашыгып Шәмсеруй апа.

Аларга чыгып торырга куштылар, больницаның икенче катыннан җирән чәчләрен ак башлыгы астына өеп тутырган тагын бер врач килеп төште, Сәрвәр тирәсенә шәфкать туташлары җыйналды. Бераздан җирәнчәч Шәмсеруй апа белән Шамил янына чыкты:

— Кыз кайдадыр бик нык егылган, ахры. Чак кына мие селкенгән булуга да охшый. Әмма артык борчылырлык нәрсә юк шикелле, тынычланыгыз, тырышырбыз, дәваларбыз.

Больницадан чыккач, икесе дә ни эшләргә белми аптырашып калдылар: нишләргә хәзер? Кая барырга?

Кайтып китәр иде, әле Сәрвәрнең хәле бөтенләй ачыкланмаган, монда калыр иде, капка төбендә багана кимереп пар ат көтеп тора, күпме юл үтеп килгән бахбайлар, аларны ашатып, сугарып ял иттерергә кирәк.

— Минем әти монда ич!— диде кинәт Шамил.— Мин аның кемдә тукталуын беләм. Зиннур әкәләрдә, шуларга төшик, Шәмсеруй апа.

— Юк, энем... Шайтан күзенә күренергә әзер, иллә мәгәр бу шәптә миңа Мөхәммәт Уразаев күзенә чалынырга ярамый.

— Нигә алай?— диде Шамил аптырап.

Аның тотлыгуы кимеми, һаман арта гына тора кебек иде, шуңа күрә ул кыска-кыска җөмләләр белән генә сораша башлады...— Әти сезне ярата.

— Яратадыр да,— дип тагын җылап җибәрде бичара ана. Күз яшьләре бетмәгән икән әле Шәмсеруйның, бала өчен ананың күз яше бер чакта да бетми, диләр, хак икән. Ул Шамилне сак кына кочаклап алып, аның иңенә башын куйды һәм озак кына елады.— Иң яхшысы мин монда калам, сезгә дә мәшәкать ясап йөрисем килми. Сәрвәр янында берәр урын табып бирерләр әле. Ә Мөхәммәт абый янына барасым да, күрәсем дә юк. Бар, бар, Шамил балам. Инде син миңа үпкәләмә, карт җүләр, дип сүкмә, үзем кыйналган да бик җиткән...

Тотлыккан тел белән озын-озак аңлашып торырга уңайсызланган Шамил тарантаска менеп утырды һәм атларны әкертен генә атлатып әтисе төшә торган фатирга, Зиннур Бекшеновлар йортына таба юл алды.

Төн иде инде, шәһәр урамнары тын, анда-санда гына тонык фонарьлар яна. Шамил алдына-артына карап алды да:

— Сәрвәр, мин сине яратам! Барыбер яратам!— дип кычкырып карады. Һаман тотлыга икән...

Капка алдына пар ат килеп туктауга йортта ут кабыздылар, өй эчендә ыгы-зыгы сизелде, бераздан шакылдап ишек, аннары шыгырдап капка ачылды, хужа белән бергә чыккан Мөхәммәт ак күлмәкчән генә болдыр баскычында басып тора иде, ул башта атларны, аннан тарантастагы Шамилне таныды.

— Улым, ни булды?— дип түбәнгә каударланып төште.

— Сине алырга килдем.

— Мине? Үзем дә кайткан булыр идем әле. Нигә юлдан ял итмәдең? Сания әниең җибәрдеме әллә?

Шамил эндәшмәде, Зиннур абыйсына кулын бирде дә, атларны лапас алдында туктатып, тугарырга да кереште. Өчәүләшеп тиз-тиз тугарып, сбруйларны җыештырып та алдылар. Зиннур атлар алдына коры печән китереп салды.

— Әлегә корысын ашый торсыннар, аннан сугарып яшел үлән дә бирербез. Сыерга дип чабып кайткан бик яхшы печәнебез бар!

Өйгә керделәр. Зиннур, хатынын уятып тормыйча гына, самавыр яңартырга кереште, тегеннән-моннан ризык чыгарып табын хәстәрләргә тотынды.

— Улым,— диде Мөхәммәт улының суырылып калган яңакларын, таушалган кием-салымнарын абайлап,— син мине алырга гына килмәгән. Сөйлә.

— Эх, эти...— дигәч, иреннәрен тешләп туктап калды.— Эх, эти! Күрмисеңмени? Миңа гына түгел, авылга бәла килде. Минем бик якын кешемә.

— Сәрвәргәме?

— Әйе. Без Шәмсеруй апа белән аны больницага китереп салдык. Хәле бик авыр.

— Нәрсә булган?

— Берәр каты җиргә егылганмы әллә, ди доктор... Җен суккан, шайтан кагылган, дип уйнатканнар аны!

— Кем? Һаман шул булыр-булмас шаман Чырыкмы?

— Тагын кем булсын?

Артык дулкынлануданмы, Шамилнең тотлыгуы бер көчәеп ала, сөйләшүе бер көйләнеп китә. Ипи кисеп маташкан Зиннур да тавыш бирде:

— Әле каһәр суккан Чырык һаман исәнмени?.. Саз ягы авылларына чыгып та шаманлык итә икән хәзер, дип ике-өч ел элек ишеттергәннәр иде. Манси чатырларына тикле барып җитә икән.

— Монысын белмәгән идем,— диде Мөхәммәт.

— Без белмәгән бик күп нәрсәләр бардыр әле шул нәни генә авылда!.. Эх, эти!

— Халыкта наданлык көчле, артталык. Мәктәп күрмәгәннәр, газета-журналларның ни икәнен дә белмиләр. Әле врачка барып күренергә теләмәгәннәр дә очрый. Һаман очрый! Менә син, улым, югары белемле беренче укытучы булып авылга кайтасың. Озакламый, Йосыф белән Мәүлия кайтып төшәрләр...

— Эх, эти!— диде тагын тирән үкенеч белән Шамил.

— Әйтеп бетер, улым.

— Күрмисеңмени, тагын тотлыга башладым. Инде бетте, онытылды дип йөрдем, сөенечемнең чиге юк иде...

— Хәзер дә узар, улым, борчылма.

— Тотлыга торган нинди укытучы була ди? Андый укытучы булмый. Үзеңнең беренче дәресеңне хәтерлисеңме?

Бу төн ифрат авыр, борчулы яңа хәбәрләр китерсә дә, үзенең беренче адымнарын, беренче дәресләрен хәтерләгәч Мөхәммәт Уразаев

елмаймыйча түзә алмады. Рәхәтләнеп дөнья капиталын сүккән иде бит ул чагында! Буржуйларның тетмәсен теткән иде! Ә балалар зирәк булып чыктылар, аның күперенке сүзләрен сабыр гына тыңладылар да кайсы йокыга талды, ә берәүсе: «Абый, ә сез әкият сөйли беләсезме?»— дип сорады.

— Мин дә ул чакта педагогикадан шыр надан булганмын. Әзерлек бик бәләкәй иде... Ә син педтехникум үткән, институт тәмамлаган бел- геч...

Ул арада өстәлгә самавыр килде, Зиннур абый күкәй тәбәсе куырган икән, каяндыр тозлы балык, салкын ит кисәкләре килеп утырды, хуҗа Шамил алдына каймаклы сөт куйды.

— Хуш килдегез, кадерле кунаклар.

— Ә Шәмсеруй кайда?— дип сорады кинәт Уразаев.

— Больницада калды.

— Нигә алып килмәдең аны?

— Кыенсындымы, киләсе итмәде, кызы янында калды.

Зиннур Бекшенов кайчандыр үзе дә Шамил тәмамлаган институтта укып, шунда диплом алган, хәзерендә бер Тоболда гына түгел, тирә-юньгә атаклы, тәҗрибәле укытучы иде. Мөхәммәт Уразаевның бүген куна калуының төп сәбәбе шул булып, ул күпне күргән, күпне кичергән укытучының үз улына, яңа эшли башлаган яшь һәм кайнар педагогка аз-маз күз-колак булуын үтенергә исәпләгән иде. Бу үтенечен белдергәч, Зиннур бераз гаҗәпсенеп тә куйды:

— Ә үзең? Син дә ничә еллар укыткан, тәҗрибә туплаган укытучы лабаса?!

Уразаев чак кына да уйланып тормады, кайнарланып сөйләнеп китте:

— Аңла, барыннан бигрәк ул минем балам! Улым! Мин ата кеше, аның кайбер йомшак якларын да кичерә алам, хаталарын күрми калуым да ихтимал. Ата кеше үз баласына бүтәнчә карый, башка күз белән. Минем ялгышуым ихтимал. Ул ялгышларның Шамилгә соңыннан бик кыйбатка төшүе бар. Ул минем бердәнбер улым, аңла, Зиннур кордаш, бердәнберем!

Алар кичке чәй янында шулай кызып-кызып сөйләшкәннәр иде, хәзер сүзләр юк дәрәҗәсендә. Зиннур, теле кычытса да, институт, андагы хәлләр хакында берни дә сорашмады диярлек. Шамилнең нинди хәлдә булуын аңлады, аны бу йортка нинди хәсрәт китергәнен төшенде. Әйе, тәне-гәүдәсе белән ул монда, ә җаны тегендә калган, больница бусагасы артында. Анда яшь кыз, аның сөйгәне, әҗәл белән тартышканда, нинди сораулар булуы мөмкин?

Зиннур чәйдән соң Шамилгә урын җәя башлаган иде, ул аны кул хәрәкәте белән туктатты:

— Зиннур абый, атлар янына печәнлеккә генә чыгыйм әле. Ат исе сагындырган, коры печән исе.

— Рәхим ит, туган. Черки бимазалый димәсәң, әйдә, анда да урын җитәрлек.

Атларны сугарып, мул гына яшел үлән салгач, Шамил аларны муеныннан сөйде дә печәнлеккә менеп ятты. Озак та үтмәде, аның янына әтисе менде.

— Улым, мин әле бу. Йокламыйсыңмы?

— Кая ди йоклау...

— Көяләнмә, улым, терелер...

— Терелер, ышанам... Ә мин? Үзем... Класска барып кереп авыз ачуга укучылар көлә башламасмы? Ничек мин аларга Пушкин шигырьләрен укып күрсәтим, Лермонтовны яратырга өйрәтим! Безнең Ялан кешеләре дә рус телен үз телләре кебек үк белергә тиешләрдер бит? Шуны уйлап кайткан идем бит мин. Гомерем буе шуңа әзерләнгән идем.

Шамил моны озаклап, тотлыга-тотлыга, туктап, бер кайнарланып,

бер сүрелеп, ярсып сөйләде. «Пушкин» дигәндә, «Пуш-Пуш-Пуш!»— дип кабатлап торырга мәҗбүр булды, таки әйтеп бетерә алмады, әтисе:

— Пушкин,— дип төзәтеп куйгач кына, сүзен алга таба ялгады.

Атлар керт-керт китереп бик озак печән ашадылар, ара-тирә пошкырып куеп Шамилне сискәндерделәр, колак төбендә генә әрсез черкиләр безләп торды, шәһәрнең аргы башыннан да, бирге ягыннан да әтәчләр кычкыра башладылар. Алар, аталы-уллы, бер мендәргә башларын куеп, чак кына черем итеп алдылар...

Әтисен больницага алып барасы килмәгән иде Шамилнең. Шәмсеруй апаның Уразаевны күрәсе килмәвен ул кичә бик ачык аңлады, авыр сынау кичергән бичара хатынның нигә күңелен тагын авыртырга? Кыен вакытында кемгәдер күренәсең килми икән, бу табигый бер хәл түгелмени? Ләкин ата кешегә «барма!» дип ничек әйтәсең, Сәрвәр аның укучысы, укучысы гына түгел, укытучысы да, аның өмете, мәктәпнең киләчәге... Өмете! Сәрвәр — аның фикердәше, көрәштәше Әсәт Фәтхуллинның кызы. Ятимә кыз. Мөхәммәт Уразаев кызның язмышы өчен вакытсыз корбан булган көрәштәш дусты алдында да җаваплы! Әгәр кызга бәла килгән икән, аның өчен ул да гаепле, димәк, нәрсәнедер күреп бетермәгән, нәрсәнедер уйлап куймаган, әзерләнмәгән. Белә иде бит, Сәрвәр тирәсендә Ташкәй чуалуын да белә иде, Үлмәснең дә анда күңеле барлыгын җиткергәннәр иде. Улы Шамилнең дә бары тик Сәрвәргә генә тартылуын сөенеп күзәтә, аларның кавышу сәгатен җиткерә алмыйча яши иде. Иң зур өмете иде ич ул аның!

Хәзер, әлбәттә, больницага барырга кирәк. Кичтән үк барырга теләсә дә, вакытның соң икәнен чамалап, бармады, түзде. Барырга ашкынуын улына сиздермәскә тырышты, ул да борчылуның соң дәрәҗәсенә җиткән, каны кайнаган, мие уйлар белән туп-тулы, шулай булмаса, янәдән тотлыга башлар идемени бала? Әйе, аңа хәзер бер дә җиңел түгел! Укытучы булып, диплом алып кайтып кер дә, беренче адымыңнан ук тотлыга башла! «Пушкин» дигәндә класста «Пуш... Пуш... Пуш»— дип кабатлап тора башласаң, иң әлек арттагы рәтләрдән пырхылдап «Пушка!»— дип кычкырачаклар, аннары күзләрен аска төшергән алдагы рәтләр дә аңа кушылып шаркылдарга керешәчәк... Әле кыска гына Пушкин исемендә төртелеп торганда, Лермонтов, Белинский исемнәрен ул ничек әйтә алыр? Ә Пушкинсыз, Лермонтовсыз рус телен укытып буламыни? Тукайсыз, Такташсыз татар телен өйрәтә алмаган кебек, Пушкинсыз да рус теле юк, тел һәрвакыт бөек шәхесләргә, аларның якты иҗатына таяна...

Таңга кадәр шуны уйлады Мөхәммәт Уразаев...

Уйлары Чырыкка да кайтып калды, аңа да кагылып чыкты. Тик аңа кагылышлы уйларның аныклыгы юк иде әлегә. «Җитте аңа!— диде ул йодрыкларын кысып,— түземлекнең дә бер чиге була!»

Ике катлы таш больница янындагы нәни генә бакча эскәмиясендә бөрешеп кенә, «Инде кеше күзенә чалынмасам ярар иде!»— дип утырган Шәмсеруйны күргәч, аталы-уллы Уразаевлар бер-берсенә караштылар.

— Әллә бакчада утырып төн чыккан инде бу бичара?— диде хафаланып Мөхәммәт.

— Алып кайтасы гына калган!— дип үкенде Шамил.

Мөхәммәт тик кенә карап утырган Шәмсеруйның ике кулын да үз учларына алды:

— Хәлләр җайсызланыбрак киткән икән бит, Шәмсеруй,— диде.

Бичара ана бүген җыламады, кулларын да тартып алмады, бер ноктага, ак пәрдәләр җилфердәгән больница тәрәзәләренә карап торды да, тирән итеп бер көрсенде.

— И, Мөхәммәт, Мөхәммәт! Син минем иремнең ахирәте идең... Хөрмәтләп, олылап аны син җирләдең. Иремнең исемен халык күңелендә саклап килдең. Аның намына мәктәп янында бакча утырттың. Аның кызын кадерләп, карап үстердең, «Әнкәңә тормыш итүе авыр, курсларда

гына укы да, эшкә тотын, аннан хәлләнгәч бераз, иплап кенә заочно укырсың»,— дип акыл бирдең. Чит кеше баласы дип тормадың, күз өстендә каш иттең... Гомерем буе сиңа рәхмәтле булып яшәдем. Инде, көне-сәгате житеп теге дөньяга баргач, Эссәт белән очраша калсак, анда да беренче сүземне сиңа рәхмәттән башлармын...

Уразаевлар икесе ике яктан бичара ана янына килеп утырдылар, Мөхәммәт Шәмсеруйның боз кебек суык кулларын ычкындырды.

— Ирем алдында бер гаеплемен — кызын күз карасыдай саклый алмадым. Аягым да тартмады, нигә дип кенә бардым икән кунакка? Күрәчәгең булса күркә талап үтерер, диләр, шул буладыр инде, мөгаен... Күрәчәгемә каршы чыгып киткәнмендер шул. Күңелемдә шом да бар иде, шул таралмасмы дип чыгып киттем бит! Бәхетсезгә вакытсыз, диләр, шулай булды да куйды бит... Синең алда тагын да гаеплерәкмен, Мөхәммәт, Эссәт аңлар, бәлки рәнжемәс тә; син кичер. Кичерә алсаң кичер мин тиле башны!.. Өннә дә шул сүзне куәтләгәч, үзем дә Сәрвәрне шул хәлендә күргәч, буш өйдә җен суккандыр дип ышандым... Күз алларым томаланды да китте, акылым калмады, үзем йөрим җен суккан тиле сыман буталып... Шунда сезгә барып егыласы гына да бит, юк, уйланылмаган... Гомер-гомердән килгән гадәт буенча, шул карачкыга ышанылган... Чырыкка барып ялындым бит, «Коткар!»— дип тез чүктем. Ул явызы да «Кулымнан килми, больницага гына алып бар!»— димәде шул, үзе сыман җыен юньсезне җыеп килеп, ике көн, ике төн эчеп яттылар... Кызымны, багалмамны, шул явызларга тапшырып харап иттем бит... Мөхәммәт абый, кичерә алсаң син кичер мине! Шамил улым, сиңа әйтер сүзем күп тә, әйтә алмыйм. Кыймыйм! Синең алда да гаеплемендер мин, нишлисең, кызымны саклый алмадым... Харап иткәннәр аны! Җен дә сукмаган, шайтан да кагылмаган, явызлар әрәм иткән аны.

Шамил каты тотлыгып урыныннан күтәрелде, үзе белән җаны да күтәрелеп бугазына килеп тыгылды.

— Кем? Ке-е-ем?!

— Үлмәс явыз. Чырык аларга көчләп никах укыган. Ике көн буена алар кызны бикләп тотканнар... Үлмәс исемле җен кагылган аңа, Чырык дигән шайтан суккан аны!

Шәмсеруй тезләре өстенә капланып төште һәм тавышсыз гына үксергә тотынды, бераздан калкынды, күз төпләре коп-коры иде. Аның да күз яшьләре бетсә бетә икән...

Больницага өчәү бергә керделәр, төнлә дежур торган җирән врачны күреп сөйләштеләр.

— Хәле арулана, аңына килде. Сөйләшүен сөйләшмәде, әмма бик яхшы ишетә, башын селкеп «юк» ди...

— «Бар» димиме?— Шәмсеруй апа врачның авызына керердәй булып йотылып тыңлап торган җиреннән шулай дип сорап куйды.

— Без әлегә аны борчымаска тырышабыз. Сез шулай да милициягә хәбәр итеп куегыз, белеп торсыннар. Кемдер кызны бик нык җәберләгән булса кирәк.— Врач шулай диде дә кызганып кына Шамилгә карап алды. Бу карашның мәгънәсен аңлаган Шамилнең тәне эсселе-суыклы булып китте.

— Керәбез, әлбәттә, милицияне дә күрербез. Ә хәзер безгә аның янына керергә ярыймы?

— Сезгәме?— Врачның киң маңгаена буразна булып авыр сыр ятты.— Юк, ярамый. Борчымагыз аны. Хәер, менә бу яшь егеткә күренеп чыкса ярый. Белүемчә, сез аның яшьлек дусты бугай?

— Шулай, шулай,— диде ашыгып-ашыгып Шәмсеруй апа.

Гомер-гомергә ир-ат янында күп сөйләшергә яратмаган, ир-ат бар җирдә тавышын күтәрмәгән, бәхәсләрдә катнашмаган тол хатынның бүген шундый акыллы сүзләр сөйләвенә Мөхәммәт Уразаев гаҗәпләнеп тә калды, аның кыюлыгына исе китте, врач белән дә рәттән торып

сөйләшә, Шамилгә дә килештереп сүзен әйтә ала, Мөхәммәтнең дә күңеленә юл саба...

Ак стеналарда кояш нуры уйный, тәрәзәдәге ак пәрдә бер тына да, бер кузгалып кемгәдер кул болгый, изи, чакыра, дәшә, дәртләнә. Ак мендәргә Сәрвәрнең кара толымнары таралып яткан. Ак мендәрдә аның ак битләре, ап-ак җәймә өстендә ап-ак куллары. Баш очындагы тумбочкада да өч бөртек ап-ак ромашкалар тора, кыр чәчкәләре. Кем кертеп куйды икән аларны монда? Врачмы, шәфкать туташлармы?.. Ә Шамил буш кул белән килде, әле юлдан кайтып аның бит юарга дә өлгергәне юк, гел ашыгып, гел чабып шашып кына йөри. Ул йомшак тавыш белән, ашыкмыйча гына, тотлыкмаска тырышып эндәште:

— Сәрвәр. Сәр-вәр! Бу мин.

Кыз эндәшмәде, сул кулының чәнчә бармагы калтырап куйды, бары тик шул гына, алай да Шамил куанды: «Исән! Ул ишетә! Ул минем монда икәнне аңлый!»

Тәрәзә пәрдәсе җилфердәп Шамилне кыюрак булырга чакыра, өнди, ашыктыра: «Әйтеп кал әйтәсе сүзләреңне! Кадерле сүзләреңне җәлләмә! Аңа бүген дару гына түгел, йомшак сүз дә кирәк!»— дип әйтә кебек.

Ул ярты адым гына алгарак килде, кызның нәзек, матур муенында типкән кан тамырына карап торды... Минем янәшәдә икәнлегемне хәбәр итәме икән синең кайнар каның?!

— Сәрвәр, Сәрвәр!..

Кызның керфекләре тагын йомшак кына тирбәлеп алдылар, бит очларына шәфәкъ алсулыгы йөгерде. Ул кемнеңдер үз исемен атап эндәшкәнне ишетте, аңлады, һәм өне төшкә ялганып китте.

Сәрвәр, Сәрвәр... Кем аның исемен шулай моңлы җырга кушып җырлый? Дөньяда бер генә кешенең аның матур исемен җырга кушырга хакы бар бит! Шамилнең генә, Шамилнең генә! Ләкин аның Шамиле моннан бик еракта шул, бик, бик еракта! Төмән дигән зур шәһәрдә ул... Туктагыз инде, зинһар, гармуннар, уйнамагыз, кем сезгә Кызлар Убасына килергә рөхсәт иткән дә, кем Сәрвәрнең исемен кушып җырларга кушкан?.. Хушыгыз, кошкайларым, сары былбылларым... Мин Иртеш бозлары белән бергә агам инде... Миңа салкын, суык, туңам мин, үләм...

Үзенә ул кычкырып сөйләшә кебек тоела, Шамил дә Сәрвәрнең иреннәре кыймылдаганны күрә, күз кабаклары да дерт-дерт итеп куялар, ләкин кызның сүзе-өне юк, ул саташа, төш күрә...

— Мин кайттым, Сәрвәр,— диде Шамил.— Бөтенләйгә кайттым, Сәрвәр. Синең яныңа кайттым, Сәрвәр... Мин сине бик нык яратам, Сәрвәр! Моннан болай мин сине бер минутка да ялгызыңны калдырмам, Сәрвәр...

Үз исеменең шундый ягымлы итеп, иркә-назга төрелеп яңгыравы тәэсир иттеме, кыз кинәт күзләрен ачты, кинәт кенә торып утырды, Шамилнең күзләренә карады, исе китмичә генә:

— Ә, Шамил, бу син икәнсең... Син бүгенгә минем яныма килә күрмә, мин бүген бик ямьсез, чәчем дә таралмаган, аякларым да авырта,— диде.

Ап-ачык итеп әйтте, тавышында гына ниндидер ят, чит аһәңнәр бар иде. Әйтте дә янадан сузылып ятты, Шамилдән читкә борылды һәм күзләрен йомды. Йокыга киттеме, һушы таралдымы — Шамил тагын, тагын эндәшеп караса да кыздан җавап ала алмады. Ишек шакыдылар, яшь кенә шәфкать туташы аны кул изәп чакырып чыгарды.

— Җитәр, йокласын. Хәзер аңа иң яхшы дәва йокы...

— Мин тик кенә утырам, дәшмим дә, сөйләшмим дә,— дип ялынды Шамил.

— Ярамый,— диде туташ нык итеп һәм ишекне тыгызлабрак япты.

Мөхәммәт белән Шәмсеруй апа егетне дүрт күз белән көтеп торалар иде, икесе беравыздан:

— Ничек?— дип сорадылар.

— Таныды,— диде Шамил.— Бер-ике сүз дә алыштык. Арулана башлаган...

«Ә син аны танылыңмы соң, дип ник сорамыйсыз?»— дип сыкрады Шамилнең күңеле... Әгәр палатада Сәрвәр ята дип әйтмәсәләр, ул аны, мөгаен, таный да алмас иде, кыз шулкадәр нык үзгәргән иде. «Кеше төс үзгәрткәч, икенче кешегә әверелә, характеры, гадәтләре икенчеләнә»,— дип кайдадыр укыганы бар идеме, ишеттеме, ул Сәрвәр янынннан чыккан чакта гел шуны уйлады: кем булды икән ул хәзер? Аның хәзерге дөньясына Шамил сыярмы, юкмы? Сыйса да кем хәлендә сыяр ул аның тапталган күңел бакчасына?!

## 41

Кайгы-хәсрәтләр, күңелсезлекләр ямьсезләсә дә, тормыш тукталмый, ул һаман ага, бу җәһәттән ул мәңгелек Иртеш елгасына охшаган. «Иртеш»— борынгы төркиләр сүзе, ярларын җимереп каты ага торган елгага шул якларда яшәгән борынгы төркиләр «Җир тишүче» атамасы биргәннәр, себерчә «җир» «ер» яки «йир» дип әйтелә, «җир-тиш» шуннан киткән... Бер давылланып ала Иртеш, бер тына, әле калын боз астына кереп поса, кача, йоклый, аннан кинәт юрганын ачып ташлый да боз кантарларын җимереп ыргытып, бар көч-куәтенә ярларны кысрыклый, ишә, җимерә, болын күкрәкләренә суын җәя, тына, ипле генә, моңлы гына ага башлый... Тормыш та шулай түгелмени? Яңа буын килә, яңа эшләр башкара, яңа сүз әйтә һәм үзен соңгы юлга озатырга яңа буын әзерли.

Уразай Мөхәммәте укыта башлаганда өстәл астыннан яңа чыккан буын — бүген авылда төп терәк, колхозның иң авыр, иң җаваплы эшләре алар кулында. Маннур бригадир, Дәүләтша әкә аның азрак калкынганын, ирлеге өлгереп житкәнне генә көтә, көне-сәгате белән колхоз дилбегәсен аңа тоттырмакчы... Шамил укып кайтты, тиздән Сәгъдетдин улы, Һади бабайның кадерле оныгы Йосыф та белем алып, шәһәр урамнарында ныгып авылына кайтыр...

Авылда эш өсте: печән чабалар. Печән бердәмлекне һәм кинәтлекне ярата торган уртак эш, олысы-кечесе печән өстендә читтә кала алмый, колхоз терлекләреннән тыш һәркемнең мал-туары бар, ә печән — сезонлы эш, атна-ун көн көйдереп ала да, аннан чабылмаган болын, урман аланы табып кара син! Яланлылар печәнне күп чабалар, мал-туарны иркен асрыйлар, икешәр сыер тотучылар да бар, ишле семьяларда өчәре дә бергә күши. Сөт-катык житәрлек, кашыклары майда, авызлары симез иттә...

Авылның төп болыннары Иртешнең аръягында, атларны, кирәк-яракны көймә белән берәм-берәм теге як ярга күчерәләр дә, аннан хатын-кыз, бала-чага шау-гөр килеп елга кичәләр. Бу үзе зур бер тантана була. Атлар да бу көнне сагынып көтеп алалар, текә ярдан Иртеш буена карышусыз гына төшәләр, көймәгә дә иплән кенә, жайлап кына кереп басалар.

Карт-коры да читтә калмый, аларга төп эш тапшырылган: чалгы сабы рәтли алар, тырма тешләрен алыштыралар, кибән куярга өч җәпле шома сәнәкләрне барлыйлар. Хатын-кыз арасыннан чалгы тотучылар аз түгел, гомере буе ялкаулыгы белән дан алган, «мунчага кергәч аркасын юарга да иренә» дип ялкаулыгы көнгә чыккан Гобәйбә буйдак та чалгыга тотына, күлмәген күтәреп ыштан бөрмәсенә тыгызлап тутыра, кулларын төкрекли, аякларын киң итеп ерып баса һәм әрәмәдәге талларның башын кыярга жыенгандай киң селтәнеп чабып китә. Бөтен ирләр дә аның белән бер шәпкә бара алмыйлар, гыжлап, тыннары бетеп арттa калалар. Көндезге әбәт вакытында кирәген бирә инде Гобәйбә буйдак! Ялгыз яшәп, казан асып кайнар аш пешерергә иренгән, жәен-

кышын коры-сары капкалап, кайда кешедә тамак уздырып, кайда күршедә чәй эчеп күнеккән җан, печән өсте өчен дип симертелгән яшь танатиннән пешкән мул өреле, кайнар токмачлы ашны унар тәлинкә ашый, итне комарланып ике кулы белән умырып тота, юан-юан җелекле сөякләр аның таза уртлары арасына кысылып шытыр-шытыр киләләр...

Бүген бөтен кеше кырылып эштә, көн әйбәт, кояшлы, аз гына җиле дә бар, Дәүләтша әкә чабылган гектарларны санай, бүген кичкә районга хәбәр итәргә кирәк, халык бердәм, күндәм, эшли дә эшли...

Хатын-кызлар арасыннан ул күзе белән берничә кешене эзләде. Әһә, Шәмсеруй мондамы? Монда, чыккан, йөрәк маем. Эше белән юансын, кызы әнә терелә башлаган, диләр... Гобәйбә буйдак та монда, киерелеп-киерелеп чаба... Өннә дә Шәмсеруй тирәсендә юргалый. Бер читтә Хафиз әкә чалгы чүки... Монда яшьләр, кызлар. Кайсыларының исемен дә аңык кына белеп бетерми инде Дәүләтша. Бөтенесе чуен кебек каралып-янып беткәннәр, бераз эшлиләр дә, чыраулашып Иртешкә төшеп китәләр, китә куышу, китә су чәчрәтеп уйнаулар, карт-корының күзеннән яшьләр килә: «И-и, безнең дә шундый чаклар бар идеме икән?»

Тукта, Йомабикә абыстай юк... Ул булырга тиеш иде. Улы Ташкәй дә чалгычылар арасында шәйләнмәде, гәрчә ул әртилдә эшләсә дә авылның язылмаган законы буенча печән өстендә уртада булырга тиеш. Үзенә печәнгә дип пай сорап киләчәкме, киләчәк!

Уразай монда, гаиләсе белән чыккан, хатыны, улы, кызы Фаягөлгә дә тырма тоттырганнар, эшкә өйрәтәләр янәсе, кара син, бөтерчек кебек кенә кыз, тырмапмы-тырмап маташа.

Ә Йомабикә юк, Ташкәй дә күренми. Юклар...

Тиккә эзли колхоз рәисе Дәүләтша әкә: Йомабикә абыстай бүген йорт арасында, өйдә калды. Гыйззәтбану түти эшкә әйтергә кергәч, аңа авыз да ачтырмады:

— Беләм, Гыйззәтбану, уттай эш өсте икәнен бик яхшы аңлыйм. Мәгәр син бүгенгә мине калдырып тор инде, яме, үпкәләмә. Киресенчә, җәллә син мине. Кызган.

— Ни булды, Йомабикә апа?

— Үземә бер хәл дә булмады. Хатын-кызның җаны бакырдан койган булса да түзә. Ташкәемә нидер булды. Менә өч көн рәттән эшейә бармады, төннәрен йокламый, тамагына юньләп ашамый, чыгып китә дә эчеп кайта. Бер-бер хәл булмасын дип куркам... Шәмсеруйның кызын яраткандыр шул, бүтән сәбәп күрмим дә, белмим дә. Менә бүген көтү куганда ук чыгып югалды, кайда йөри дип беләсең аны? Печәндә булмаган, эшенә бармаган, кичә сорашып белештем. Өннә апа бер күргән, Шәмсеруйларның ындыр киртәсенә ике кулы белән ябышкан да тик тора, ди...

Гыйззәтбану бригадир, хәзер һәр җирдә сак булырга кирәклеген белә, аңлый, әнә ич, саксызлык белән авылның сылу бер кызын харап итеп ташлый яздылар, ярый ла терелсә, терелеп рәткә керсә, тәндәге бәләкәй генә кутыр эзе дә җөй булып кала, гомергә бетереп булмый, ә җандагы җөй бетәрмени? Әрлисе урында ул Йомабикәне тынычландырырга тырышты, эшкә бармаска, чыгып йөрмәскә, улын күздән ычкындырмаска кушты.

— Дәүләтша әкәгә җайлап кына әйтермен, ул да орышмас, аңлар. Ялан авылына бер бәхетсезлек тә бик җиткән, икенчесе килмәсен берүк,— дип Гыйззәтбану артына карый-карый, чираттагы йорт кешеләренә эшкә әйтергә кереп китте.

Кайда йөрер бу Ташкәй?

Йомабикә аннан чалып, моннан егып кына йорт эшләрен барлады, күңеле белән улы кайда булырга мөмкин урыннарны санап чыкты, әмма аның хәзерге мәлдә кайда булуын төгәен генә белә дә, ачыклый да алмады.

Ташкәй кайдамы, әнә-ә генә ул, Иртеш ярында утыра. Берүзе.

Күлмәге каеш астыннан бүселеп чыккан, яланбаш, яланаяк, кулында сандалилары. Шул урында утыра. Сәрвәр белән соңгы кабат очрашкан урында... Хәзер һәммәсе аның күз алдына матур бер хатирә булып килә. Менә ат аның көянтәсенә басты, менә аның чиләге тәгәрәп китте, ул ярым елмаеп аны «Таштимер» дип атады. Аның мулла кушкан чын исеме Таштимер ләбаса, бала чакта «Ташкәй дә Ташкәй!» дип гадәтләнгәннәр инде, ә аның үз исемен тулы итеп «Таштимер» дип әйттерәсе килә. Таштимер дип аңа беренче тапкыр Мәүлия әйткән иде. Ничек матур яңгыраган иде ул чакта аның үз исеме! Ә монда Сәрвәр шулай диде...

Менә кыз авыр чиләкләрен көянтәсенә элеп бөгелә-сыгыла менеп китте. Шул чакта чиләкләрен тартып алып өенә хәтле итеп бирәсе калган, атын ычкындырырга куркып, шуның авызлыгын тартып яр астында исәр сыман карап калды бит!.. Юк шул андый нечкәлеге Таштимернең, юк! Булса Сәрвәр бүтәннәргә түгел, аңа карар иде. Төскә ямьсезме — түгел! Буйга бәләкәйме — түгел! Көче-егәре, һөнәре юкмы?.. Теге чакта пычак кайрый алмаган иде, хәзер килеп карасыннар иде кызлар, калын йөзле калуннан да Гали пәкесе ясап бирә Ташкәй! Эшкә остарды, өе иркен, хуҗалыгы нык, белә, әнкәсендә әткәсеннән калган байтак алтын акчалар да саклана әле. Кемгә булсын алар? Мәүлия кыз кеше, ул китеп барачак...

Ташкәй алдагы тормышын гел Сәрвәр белән уртак итеп күреп гадәтләнгән иде. Ә хәзер Сәрвәр юк. Юк Сәрвәр... Сәрвәр җүләрләнде. Аны харап итеп ташладылар. Кем харап итте диген әле — сасы көзән Үлмәс...

Ташкәй авыл ягына карады, анда елга ярытирәсендә йөргән бозаулардан башка бер җан иясе күренмәде, Ялан авылы мәет чыккан йорт кебек тып-тын, ятим һәм күңелсез. Ул томанланып торган аръякка, әрәмәләргә, әрәмә артындагы күгелҗем болыннарга карады. Беркем күренмәсә дә Ташкәй анда тормышның кайнап торганын белә, чамалый, күз алдына китерә ала. Әгәр Сәрвәр анда булса, ул Иртешкә ташланып колачлап-колачлап йөзәр иде, бер минут монда тормас иде. Күңелсез... Кая барырга? Нишләргә?

Ул үз-үзе белән киңәшеп байтак утырды, кояш күтәрелде, ләкин егет анык кына бер сүзгә килә алмады, нидер эшләргә кирәген генә белә иде. Чыннан да, нидер эшләргә, нидер чарасын күрергә, элеккеге җан тынычлыгын табарга, ниһаять, үч алырга кирәк!.. Үлмәснең телетеше юк, мулла мәчесе сыман мыраулап тик йөри, тик Сәрвәрне урлашкан Акъяр юньсезләре Ташкәйгә серне чиштеләр, «Синнән булмаган иде, әнә Үлмәс, сылуның күкрәкләре өстендә йөзде!» — дип мыскылладылар житмәсә. Акъяр тинтәкләрен ул бер якка гына чөеп ыргытыр иде, ачу килгәндә ир — яралы арыслан белән бер, тау-ташны җимереп ыргыта ул, кыяларны әллә кая чөя.

Югалткач кына әйбернең чын бәясен беләсең, диләр. Юк, сатып алу бәясен түгел, анысы мәгълүм, әйбернең синңа кирәклек дәрәҗәсе ачыклана. Сәрвәрне шулай яратканын аны югалткач кына аңлады. Үзенең андый мәхәббәткә сәләтле икәнен менә ул җүләрләнгәч кенә төшенде. Әгәр мондый тирән хисләрне элегрәк татыса, үзенең сөю сәләтен элегрәк белсә, ул әллә кайчан Сәрвәргә йөрәген ачып күрсәткән булыр иде...

Хәзер, иң әүвәл өйгә кайтырга да, бераз кәгеп, тагын уйларга кирәк. Бауның очы булмый калмый, һәр уйның да чиге булырга тиеш ләбаса, ул — ярсыз диңгез түгел...

Ташкәй өенә кайтып китте. Бара, атлавы атлау түгел, гәүдәсе начар бәйләнгән арыш көлтәсе кебек тарау, чәчләрен җил тузгыта, уйларында давыл, күз нуры сүнгән, колагы берни ишетми. Тургайлар сайрый ич — ишетми! Иртеш дулкыннарын ярга кага ич — ишетми! Бара да бара, уйдан качып уйга бара!

Ә өйдә...
Ә аңа кадәр...
Истә-оста югында өйгә Чырык Абдрахман килеп керде. Аны да бу йортка уй китерде, ул сасы көзән дә, уйларына җавап эзли, ахмак тормышының мәгънәсен табарга тырыша. Җүләр түгел, әле давыл башланмаган, әле Кызлар Убасы өстендә җиңел ак болытлар гына йөзә, болай тормас, һава үзгәрер, ак болытлар тулып бу якка карап агарлар һәм, мә сиңа, китәр яңгыр! Теге көнне, никах укырга барган көнне, шулай булган иде бит. Ул көнне җилле яңгырга куанган Чырык бу юлы давылның, әгәр ул күтәрелсә, үзен ялмап-ялап алып китәсен белә. Сәрвәрнең ни хәлдә икәнен ул күрше-күлән аркылы бөртекләп белешеп, сорашып торды. Авыр хәбәрләр килгән саен баш очында кылычларның ыграк чыңлаганын, ыграк ялтыравын тойды. Ниһаять, кылган гамәлләре өчен түләр сәгать сукты бугай, яшәде, яшәде, койрык болгап күп бәлаләрдән котылып калды, әмма бу юлы килеп капты. Элекке заманалар түгел, иске кешеләр юк, Шәмсеруй тиле баш, исәрләнеп китеп кызын имчеләргә тапшырса да бүтәннәр алай уйламаячак. Уразай да тешен кайрый торгандыр, Шамил дә, бүтәннәр дә... Яхшы чакта китеп котылырга, яхшы чакта Яланнан чыгып ычкынырга кирәк. Мансилар арасында таныш шаманнар җитәрлек, байлыгы да бар Чырыкның. Элек нәсел-нәсәбе белән мал артыннан кумасалар да, соңгы елларда Чырыкка акыл керде, ул бер заман «кара көн» киләсен чамалап куйды. Шул кара көне килеп җитте һәм ул ипләп кенә, карчыгына аны-моны сиздермичә, Ырсытдин кордашының хатыны Йомабикә катына килде.
Керде, тәкъвә генә кыланып сәлам бирде, суфиланып дога укыды, хәл-әхвәл сорашты, улының кайдалыгын белеште.
— Печәнгә киттеме икән, әллә үз эшендә балыктамы, өзеп кенә әйтә алмыйм, Абдрахман әкә,— диде Йомабикә абыстай, сөйләшергә кеше табылуына куанып.— Мәгәр Ташкаемнең хәле авыррак әле.
— Ни булган аңа?— Сүз юкта сүз булсын дип кенә әйтте, Чырык бу соравын. Аңа Ташкәйнең өйдә булмавы кирәк иде бүген!
— Яшьләрнекен кем белсен инде!— Йомабикә абыстай да бик алай ачылып китмәде.
Чырык турыдан барырга булды, өй аулак чакта, авыл буш, мондый вакытны сатып та ала алмассың!
— Мин сиңа бик зур бер йомыш белән килдем әле, Йомабикә абыстай... Киңәш дип әйтимме мин аны, йомыш диммe, мәгәр сүзем бик зур, колагыңны арчып тыңласаң иде. Ошамаса, күтәрелеп бәрелмә, кызма, бергәләп уйлаша торган замана...
Чырыкның юкка йөрмәвен сизенә Йомабикә, ләкин һичничек аның төтене кая таба борылганны аңлый алмый, әрсезлеген, оятсызлыгын белә, әйтер сүзенең юньсезлек буласын да чамалый, ләкин һич аңыша гына алмый.
— Абдрахман әкә, әйдә, әйт, ни сүзең бар?
— Минем хәлне беләсең, яман якка борылды гуй. Электән үчле адәмнәр күп, бөз бер кузгалса, бөтен елганы алып китә. Шуның сыман, болай дим мин, Йомабикә... Моннан китәргә булдым мин. Аяк асты коры чакта аякка киеним дим...
— Миннән сиңа ни кирәк алайса?
— Син дә минем белән кит!
— Мин?— Йомабикә абыстай бер дә мондый сүз көтмәгән иде Чырыктан, көләргә дә, еларга да белмәде.— Нишләп китим ди мин.
— Хатыным булып яшәрсең. Мин, Йомабикә, гомерем буе сиңа кызыгып яшәдем. Ырсытдин белән ир рәхәте татымадың, беләм. Кагылып-сугылып үтте гомерең, ә мин сине балда-майда йөздерермен, уйлама, безнең нәсел мал җыймады, мәгәр минем маям бар, икебезгә генә җитәр. Әле тәндә көч барында дим... Йә әйт, ризамы?
Уклау белән бәрсәң күзе чыгар, табагач белән орсаң башы тише-

лер, ни әйтергә соң бу дәҗҗалга?! Койрыгы утта көйгәч, аяк астында җир убыла башлагач качарга иптәш кирәкме сиңа?! Ырсытдинның байлыгына кызыктыңмы? Йомабикәнең гөбе-гөбе ботларына күзеңне яндырдыңмы, карт мәче?

Боларын әйтмәде Йомабикә, чал сакалын аяды, көлде генә:

— Эх, Абдрахман әкә, Абдрахман әкә! Синнән бер юньле сүз чыгармы дип көтсәм, һаман шул җилгә җибәреп йөрисең икән.

Чырык калкынды, нәзек тавышы белән тагын нидер әйтергә җыенды, шул чак, Йомабикәнең бәхете, ишегалдында авыр гына атлап кайтып керүче Ташкәй күренде. Шапылдатып өйалды ишеге ябылды, дөп-дөп аяк тавышлары ишетелде, Ташкәй өйгә керде, мич арасындагы ачы бал мичкәсенә атлыйм дигәндә күзе кәҗә сакаллы Чырыкка төште.

— Нишләп йөри бу хәшәрәт?— дип сорады ул әнисеннән.

— Мена килгән. Үзе белән качарга димли.

Дөресен әйтеп, Йомабикә Чырыктан үч алырга уйлады, дөресен белсә Ташкәйнең котырасын ап-ачык күз алдына китерде. Өркетсен әле шушы кәҗә тәкәсен бер.

— Ә, исәнме, Ташкәй улым, сау гына йөрисеңме?— дип Чырык, берни ишетмәгәндәй ике кулын аңа сузып, кәвешләрен лыштырдатып егеткә каршы китте.

Ташкәй эндәшмәде, чирегә белән бал тартып чыгарып, зур чүмечкә койды, голт-голт итеп эчте, калганын идәнгә, Чырыкның кәвешләре янына сибеп җибәрде, сүз көтеп торган әнкәсенә борылып:

— Әни, су җылыт!— дип боерды.

— Нишләргә уйлыйсың, улым?

— Кырынам,— диде Ташкәй кыска гына.

Улының иртән генә кырынып чыгып киткәнен күргән Йомабикә су җылытырга керешге. Чырык кыбырсып утырды, утырды да:

— Кайтыйм булмаса мин, эшләрем дә бар!— дип урыныннан торды.

— Утыр!— дип боерды аңа Ташкәй.— Кузгаласы булма! Син кирәк миңа. Син!— диде дә, беләүдә бритвасын ышкып алды, битендә йөртеп аның үткерлеген тикшерде һәм Чырыкны кулыннан тартып яктыга китерде.

— Утыр! Кымшанма! Хәзер мин сине кырам.

— Улым, улым! Нишләтәсең син мине? Нишләтәсең? Адәм көлкесенә калдырасыңмы? Миңа сакалсыз ярамый! Ай, нишлисең!

Ул арада Йомабикә табак белән кайнар су, сабын китереп бирде. Ташкәй бер кулы белән картның ябык, йонлач муенын эләктереп алды, икенче кулы белән битен сабынлады һәм бритвасын уңга-сулга йөртә башлады.

— Ай-ай,— дип чәрелдәде Чырык.

— Тик утыр диләрме сиңа, хайван? Үләсең киләме?

Бер тотынгач Ташкәй туктамады, башта Чырыкның кәҗә сакалын кырып бетерде, аннан башын кырып алды, иң соңыннан үткер бритвасы белән картның кашларын кыеп төшерде. Колак тишегеннән тырпаеп торган эре-эре шыргый төкләргә кадәр калдырмады. Чырык аһылдады, ыңгырашты, теш арасыннан гына нидер әйтеп карганды, кыймылдарга курыкты. Ташкәй кулындагы үткен бритва аның бөтен әгъзаларына хуҗа булып йөреп торды, ара-тирә бугаз тирәсен дә ышкып китте, андый чакта Чырыкның коты ботына төшеп, җаны бугазына килде.

Йомабикә башта улының ни теләгәнен аңламаган иде. Чырыкның якты кавын кебек очлы шәрә башын, кашсыз, сакалсыз битен күргәч, чыдый алмыйча бот чабып көләргә тотынды.

— Мена, күп кияүләп йөрмәссең, карт алаша! Төсеңә күрә таман!

Кырып бетергәч, Ташкәй Чырыкның якасыннан алып стенадагы көзгегә китереп терәде:

— Ач күзеңне, кара! Җенме, шайтанмы?

Абдрахман көзгегә карады да башын ике кулы белән тотып бүре булып уларга тотынды. Шул көнне үк ул авылдан чыгып качты һәм яңадан Яланда тиз генә күренмәде...

Ташкәй тагын бер тустаган ачы балны каплады да, әнисенең үтенечле-сораулы карашын күрмәгән дә шикелле, кайткандагы кебек үк авыр атлап чыгып китте.

Тагын Иртеш буена төште, нәкъ баягы эздән барды, тик бу юлы ашыга башлады, яр буена бәйләп куелган җиңел көймәләрнең берсен алды, сикереп менеп, аягүрә генә ишә башлады. Көчле агым аны кыеклап бик тиз теге як ярга алып чыкты. Көймәсен өскәрәк тартып тал агачына бәйләде дә тиз-тиз атлап печәнчеләр эшләгән якка, башта Маннур бригадасына, Кызылбай төпкә китте. Ул барганда бригада халкы тир түгеп, мәж килеп эшләп ята иде, чабалар, әйләндерәләр, чүмәлә куялар, атлар белән ташып кибәнгә өяләр. Бу печән Иртеш боз белән каплангач, юл төшкәч кенә авылга кайтачак.

Маннур үзе кибән куюда иде, яланөс, бөтен җиреннән тир ага, җилкәсенә, күкрәгенә тир белән печән оны, үлән сабаклары ябышкан, ул Ташкәйнең якынлашуын күреп, сәнәгенә таянып аны көтеп алды, сүзсез генә кул биреп күрештеләр.

— Булышырга килдеңме?— диде Маннур, кул аркасы белән маңгай тирен сөртеп.

— Эш кайгысымы әле монда,— диде төксе генә Ташкәй.

— Аңлыйм,— дип сузды Маннур.

— Һәммәсен дә аңлыйсыңмы син?

— Һәммәсен дә дип әйтә алмыйм...

— Аңласаң, син миңа менә нәрсәне әйт... Аңлыйсың икән ярдәм ит, Маннур! Минем урында булсаң ни эшләр идең?

Ташкәйдән мондый сүзләрне көтмәгән Маннур, аның моңарчы булган дуамаллыгына ияләнгән Маннур, гаҗәпсенеп Ташкәйгә карады.

— Юк, аңлат син миңа! Минем хәзер баш эшләми! Әйт, акыллы сүз әйтсәң, гомерем буе рәхмәт кенә укырмын... Кил әле монда читкәрәк!

— Мин болай гына, ирмәк ясап кына Сәрвәр артыннан йөрде дип беләсез инде сез. Мине бер юк кешегә чыгарасыз...

— Юк, Таштимер,— диде Маннур.— Бер дә алай уйламыйбыз. Синең хәлең авыр. Хәер, бер синеке генәме? Сәрвәр безнең дә якын дустыбыз иде.

— Якын дустыгыз булгач әйт син миңа: миңа хәзер нишләргә?

— Сәрвәр терелеп чыксын инде, Таштимер!

Бүген Маннур аны олылап ике тапкыр Таштимер дип атады, сүзен бүлдермәде, җикеренмәде, ул аңлады... Әллә аңламадымы? Нишләргә кирәклеген әйтмәде:

— Дуамалланып киртә җимереп ташлама тагын син. Мондый чакта сабыр була белергә дә кирәк.

— Бар киңәшең шулмы?— Ташкәйнең иреннәре чалшайды.

— Әлегә җитмимени? Чырык белән Үлмәсне судка бирәчәкләр. Буш калдырмаслар дип уйлыйм. Гаепләре җитәрлек...

— Суд, суд!— дип инәлде Ташкәй.— Аннан миңа җиңеллек килерме? Моннан ары мин тыныч кына яши алырмынмы?.. Эх, Маннур! Киңәш бирерлек кеше булсын иде бер!

— Мөхәммәт абый янына кагылып кара...

— Шамил андамы?— дип сорады Ташкәй кинәт.

— Анда дип беләм. Бүген күрешкән юк, эш бик тыгыз. Көн эссе, печән тиз кибә, җыеп алырга иде.

Ташкәй эре-эре атлап китә башлады, аның куна кебек киң, таза җилкәсенә карап Маннур кычкырып калды:

— Ташкәй, кая киттең тагын?

Әгәр «Таштимер!» дип эндәшсәләр Ташкәй борыла иде, Маннур

алай димәде, иң кирәкле сүзне белмәде, егетне туктата алмады, ул туп-туры мәктәп печәнчеләрен эзләп китте. Юлда очраганнардан сорашты. «Кобланды батыр болынында аларның жире»,— диделәр очраганнар.

Иң элек аңа мәктәп завхозы Чәләкә әкә очрады.

— Мөхәммәт абый андамы?

— Кая булсын ди?

— Шамиле дә шундамы?

— Шунда булмый димени?

— Барчы, Мөхәммәт абыйны дәшеп китер әле.

— Үзең бар, вәт әкәмәт.

— Чакыр диләр сиңа!

Чәләкә әкә Ташкәйгә карышуның файдасыз икәнен белә иде, барып, җәһәт кенә өлкән Уразаевны алып килде. Бу арада күрешкәннәре юк иде, Мөхәммәт абыйсы олыланган, йончыган һәм бик күңелсез кебек тоелды. Әллә бөтен кеше аның күзенә шундый булып күренә башладымы? Ташкәй гаҗәпсенеп шулай дип тә уйлады.

— Ә, Ташкәй,— диде Уразаев агач күләгәсенәрәк, җиләс җиргә үтеп.— Син йөрисең икән әле. «Чакыралар» дигәч, аптырап киттем.

— Аптырапмы, куркыпмы, Мөхәммәт абый? — Үз соравына үзе гаҗәпсенде егет, каян теленә шундый сүзләр, башына шундый уйлар килә аның бүген.

Уразаев җавап бирмәде, сорашырга да ашыкмады, ул халык кырылып эштә йөргәндә Ташкәйнең юкка гына килеп йөрмәвен, аны читкә чакырып алуының да сәбәпсез түгеллеген бик яхшы аңлый иде. Алай да, кинәт соравы сәерсендерде: һаман яман хәбәрләр тараталармы әллә? Сәрвәрнең бәхетсезлеген дә аңа кайтарып калдырмакчылармы? Ташкәй шуны ишетеп аяп алырга дип килгәнме? Егетнең Сәрвәр мәсьәләсендә йөрүендә аның һичбер шиге юк иде.

— Мин йөрим шул, Мөхәммәт абый. Мин йөрим! — Ташкәй теше сызлагандай йөзен чытып, күзен түбәнгә төшерде.— Йөрмәс идем дә, йөрим!

Икесе дә агач күләгәсендә җиргә чүгәләделәр.

Мөхәммәт Уразаев егетне ашыктырмады, эше никадәр тәжел булса да сабыр гына көтте, сүзгә җилем кушарга теләп:

— Ни хәлләрең бар? — дип сорады.

— Хәлләр матур булса, эш калдырып, болынга килеп сезне бимазалап йөрмәс тә идем, Мөхәммәт абый, хәлләр шәптән түгел, яман хәлләр, бик яман!

— Аңлыйм,— диде Уразаев, нәкъ менә Маннурча иттереп. Шушы кыска сүз, Ташкәйнең халәтен бер караудa аңлаган булып күренү егетне котыртып җибәрде, нелеп торганнан аның юантык муены кура җиләгедәй кызарды, ул кулындагы үлән учмасын күккә чөеп җибәрде.

— Аңласагыз, киңәш бирегез: нишләргә миңа? Нишләргә тиеш мин?

— Ни мәгънәдә сорыйсың, Ташкәй? — Мөхәммәт абыйның тавышы үзгәрде, җылынды.

— Аңлагач, ни мәгънәдә соравымны да белегез инде!.. Минем хәлне күреп торасыз ич! Юк, мин исерек түгел. Исереп, мәс булып, дуңгызга әйләнеп Иртеш төбендә ятыр идем, юк, исерә алмыйм, айныта, уйлата, ә уйларның азагы юк. Кая барырга? Нишләргә?! Сез менә эшләп юанасыз, ә мин эшли дә алмыйм. Дөнья караңгы миңа...

— Ташкәй! — диде Мөхәммәт аңа ягымлы карап.— Аңлыйм дигәндә мин синең бүгенге хәлеңне аңлавымны әйттем. Иртәгә ни булыр, анысын белеп булмый. Мин НКВД начальнигы Данилов янына кереп сөйләштем, алар Чырык Абдрахман белән Үлмәскә «Дело» ачалар. Бары тик Сәрвәрнең аз-маз хәл алганын гына көтәбез. Аның рәтләнә башлаганын, тынычланганын, әнкәсе белән сабыр гына сөйләшә дә башлаганын ишеткәнсеңдер.

— Ишеттем,— диде егет саңгырау гына.

— Абдрахман да, Үлмәс тә бу юлы җәзасыз кала алмаслар! Аларның кыргыйлыгы һаман-һаман шуларга ышанып килгән томана бәндәләргә дә ачы сабак булыр. Дөрес, бу сабак өчен без артык зур бәя түләдек.

Тагын икесе дә беразга тын калдылар. Ләкин бу баягы сүзсез тынлык түгел иде инде, хәзер Ташкәйнең күңеле ут өстенә куйган сулы казан кебек кайный, ташый, ыргыла, күмерләргә төшеп чәчри! Юк, акыллы укытучысы да бу юлы аңа әйбәт киңәш бирә алмады... Чырык белән Үлмәс тәрене судта хөкем итәчәкләр имеш... Аннан ни була? Бер ел бирерләр, ике ел, кайтып та килерләр. Үч алу шул булдымы? Менә Чырыктан үчне ала белде ул ичмасам! Шәп-шәрә башы, кашсыз бите белән берәрсенә күренеп карасын, шаман!

Ташкәй кинәт үзендә бер рәхәтлек, җиңеллек сизде, сизде дә гаҗәпләнде: каян килде аңа мондый җиңеллек? Каян туды мондый рәхәтлек? «Ә-ә!»— дип сөенде күңеле, бу җиңеллекне Чырыктан үч алу тойгысы китерде бит! Рәхәтлек хисе дә шуннан калды! Үч алды. Суд Ташкәй үче түгел. Түгел! Ташкәй үз сүзен әйтергә, үзенчә үч алырга тиеш! «Чырык шыр җибәргәндер бугазына бритва килеп кагылгач! Гомере буе кеше хөкем итеп йөрде, ә каты хөкемне аңа Ташкәй чыгарды! Ыштанын күтәрә-күтәрә ындыр артлатып чапкандыр!»

Мөхәммәт абыйсы йомшак, сабыр тавышы белән тагынниләрдер сөйләде, мәгәр боларын инде Ташкәй ишетмәде, ул үз уйлары белән еракка агып киткән иде, тиле кеше сыман, елмаеп тик аска карап, чүгәләп утыра бирде. Торды, Уразаевка кулын бирде:

— Сау булыгыз, Мөхәммәт абый!

— Кая барырга җыенасың болай, Ташкәй?

— Кая да булса барырга кирәктер ич? Болай яшәп булмый бит инде!

Соңгы сүзләре белән сәерсендереп, Ташкәй тиз-тиз китеп барды. Әтисе борылып килгәч, Шамил:

— Нигә килгән ул? — дип сорады.

— Кайгы йөртә егетне, кайгы! — диде Уразаев бер сүз белән.

Шамил артыгын сорашып тормады, аның үз хәле хәл, Ташкәйнең Сәрвәргә булган мәхәббәте шулай тирәндер дип ул да, әтисе дә, Таштимер үзе дә уйламаган да, белмәгән дә иде...

* * *

Ничә көн Ташкәйнең әртилдә күренгәне юк. Инде ничәнче көнен Үлмәс авылга кайтмый. Кичә кичләтеп кенә, эштән соң, алар туктаган күл ярына әткәсе килеп китте. Тизгә генә килгән, ипи-тоз тутырган бишҭәрле капчыгын улына сузды да, шыпырт кына:

— Сүзләр күп йөри, кеше күзенә күренмә, алай-болайга әйләнсә, ым шыңшырмын, ераграк авылларның берәрсенә китеп торырсың, бригадирың белән сөйләшә тор, көйләп куй, и бала-бала, башка килмәгәннәрне күрсәттең син! — дип пышылдады. Пышылдады да китеп барды, күргән күрде, күрмәгән колагын шәңкәйтеп калды. Тозлары беткән иде, тозсыз балык ашап, эче йомшаган Үлмәс калын ипи телемен каерып кисте дә учы белән тоз сибеп җибәрде һәм ач бүре сыман чәйнәминитмичә генә йота башлады. Бүген иртән «Эч йомшады әле тозсыз балык ашап!»— дигәч, иптәшләреннән берсе: «Курыкканга йомшый ул эч, берәр нәрсәдән шүрлисеңдер!»— дип ачуын чыгарган иде. «Ух,— дип уйлады Үлмәс,— бүтән чак булса синдәй мукле муенның җилкәсен кашыган булыр идем, әлегә ярамый, әлегә шыпырт яшәргә туры килә!»

Юк, үкенмәде Үлмәс, үкенә белми иде ул, Сәрвәрне җәлләмәде дә, барыбер кемдер аның матурлыгына хуҗа булырга, яшьлеген алырга тиеш иде бит! Үлмәс түгел икән, Ташкәй ашар иде аның башын,

аларның икесенә тәтемәсә. Уразай малае Шамил тотар иде кызның нәзкәй биленнән, ә болай Үлмәс алардан кимме? Кай җире китек? Эшли — егәре бар, умырып ашый — тазалыгы җитәрлек... Гел-гел аста калдырып яшәрләр иде Үлмәсне, булмый торсын әле! Буласы булган, никах укылган, юк, Үлмәс андый сантый түгел, никахсыз кызга кулын да сузмас иде ул! Сәрвәр аның законлы хатыны иде. Ике көнлек... Киткән икән, бигайбә, аңа Үлмәс гаепле түгел. Зөфаф кичәсеннән кайтып киткән киленчәкләр була... Чирләгән икән, анысын инде дуктырлар карасын, алар шуның өчен акча ала, зарплата дип атала ул, зарплатаның ни икәнен Үлмәс тә бик шәп белә хәзер, үзе дә ала, кеше рәтеннән калганы юк, калмас та. Кайбер чакларда атаклы кешеләрдән алгарак та уза ала, мисалы күз алдында, Ташкәй мыгырдап йөреп калды, Үлмәс сугып алды...

Тозлы ипи дә ярдәм итмәде, эчне тагын борып алды, ул читкәрәк китеп әрәмә куаклары арасына кереп утырды. Җиңеләйде. Чалбарын төймәли-төймәли кул буена килсә, баягы иптәшләреннән берәү дә калмаган, сүнәр-сүнмәс янган учак янында Ташкәй басып тора. Туктап калды Үлмәс, ашыгып төймәләрен каптырып бетерде, сагаеп иптәшенең чыраена карады. Ләкин бүген Ташкәйнең чырае таштай каты һәм җансыз иде. Батып барган кояшның сүрән нурлары аның җыерылган кашларын киерелгән җәя итеп күрсәтәләр, карга канаты кебек чем-кара чәчләре бер якка усалланып таралып төшкән, ул нигәдер янган утка карап каткан, эндәшми дә, дәшкәнне дә көтми кебек.

— Нихәл, парин...— дип Үлмәс аңа ике кулын сузды.

Ташкәй сузылган кулны алмады, алмады гына түгел, киресенчә, ачу белән бер якка сугып җибәрде.

«Сугышырга килгән!»— дип уйлап алды Үлмәс. Аңа сугышырга ярамый иде, чүп өстенә чүмәлә өюдән мәгънә юк, этисе дә кисәтеп китте, аннары нигә Ташкәй белән сугышып ятарга? Кыз барыбер аңа буласы түгел иде ич, әнә, күзен тондырып Шамиле кайтып җиткән. Уразайлар да төшеп калган токымнан түгел, тешләгән җирләреннән өзә торган халык. Шамил торада чарланган булырга тиеш, элек тә алай бик баш бирә торганнардан түгел иде бит. Ташкәй, киресенчә, Үлмәсне мактарга гына тиеш! «Сиңа да юк иде, миңа да буласы түгел иде Сәрвәр, ичмасам Шамилнең танавына тизәк сөрттең!»— дип яртыны куярга тиеш иде...

Ярты дигәч Үлмәснең исенә төште, кеше күзеннән яшереп тоткан бер яртысы бар ич әле аның! Менә хәзер ул уртага чыгарга тиеш, бик вакытлы килдең, Ташкәй, аракыны тозлап йотсаң, эчкә файдасы бар диләр, бу бер, икенчедән аракының араларны ныгыта торган шәп сыйфаты да бар әле аның!

— Бер яртым бар! — Үлмәс күңелләнде.

— Ауларны кайчан салдыгыз? — диде аны тыңламыйча Ташкәй.

— Әлерәк кенә салып бетердек.

— Әйдә минем белән!

— Кая?

— Ау карарга!

— Әлерәк кенә салдык дим ич, таң белән карарбыз, диде Кузьма Матвеевич.

— Ә мин хәзер карыйк дим!

Егетләр кискен-кискен эреләшә башладылар, Үлмәс карыша, Ташкәй әкрен-әкрен аны кул ярына таба кысрыклый иде.

— Утыр көймәгә!

Үлмәс көймәгә сикереп керде, ул Ташкәйне ярда калдырып, йөзеп китәргә чамалады, әмма Ташкәйнең усал тавышы аны туктарга мәҗбүр итте.

— Мин сине күлнең җиде кат төбеннән дә табам ич теләсәм! Мин сине җиде кат стена артыннан да алып чыга алам! Теләсәм

бакыр итеп изәм, теләсәм тимер итеп сытам. Син мине белмисең әле, Үлмәс!

Әнә шул Үлмәс дигән исем ярсытты да инде Ташкәйне! «Үлмәс?» Шушы йолкышка кемдер Үлмәс дигән исем кушкан, аңа озын гомер теләгән, кеше канын эчеп яшәячәк шушы черкигә, мәгънәсез шушы тар маңгайга, шушы авызыннан эт исе килеп торган җебегәнгә... Үлмәс дигән исем кушканнар икән, ул үләргә тиеш! Үләргә!..

Үлмәс басып торган көймәгә ул каракош кебек очып кунды, көймә чайкалырга да өлгермәде, йөзеп китте, күл буе камышлары тирбәлеп кенә калдылар.

— Кая барасың?

— Үзең ау карыйбыз диден ич.— Үлмәс ишкәкләргә тотынган иде инде.

— Уңга борыл.

— Анда аулар юк.

— Кем сиңа анда аулар бар ди? Уңга борыл, и бетте-китте.

Көймә уңга каерылып, көзге кебек күл өстеннән тавышсыз гына бара башлады, кечке тынлыкны ишкәк тимерләренең чыгырдап куюы гына боза иде. Үлмәс тирән нәфрәт белән Ташкәйгә һәм буш өмет белән яр буена карады, юк, иптәшләре таңга кадәр таралганнар, һәркемнең өендә эше бар, эш вакыты, печән өсте, өйдә дә кыймылдый торган чак, балык белән, акча белән генә гомер итеп булмый, сыер малына печән житкерер хәл юк, кышның көне бик озын, таралганнар, ник ичмасам берсе күренсен! Теге мүкле муен, пычак тел дә күренми ичмасам! Әгәр килеп чыгып шушы хәшәрәттән коткарса, яртысын жәлләмәс иде Үлмәс... Тукта, нигә буйсынды ул Ташкәйгә, нигә карышмады? Ишкәкне тартып чыгарырга да, юк, башына түгел, башына ярамас, иңбашына берне кундырырга, уң кулы салынып төшсә, Үлмәс әкәсе алдында тезләнеп ялыначак...

Үлмәс акрынрак ишә башлады, көйләгән булып уң ишкәген чокырыннан чак кына калкыта төште, ике күзе белән дә аны бораулап барган Ташкәй теш арасыннан гына:

— Иш, иш, нәрсә тукталдың? — дигән сүзләрне сытып чыгарды.

— Ишәм ич!

— Ишмисең, хәйләләргә маташасың! Ишкәк калагы белән кулына берне тондырсам дип уйлыйсың...


Үлмәс таң калды, каян белгән бу нәләт? Каян сизенгән?.. Һәм аның күңеленә чынлап торып курку иңде, эче туктаусыз быгырдады, жил жибәрәсе килде. Ул Ташкәйгә ялына башлады.

— Йә инде, Ташкәй, юкка торып мине жәберләмә. Бердәнбер гаебем, сиңа алдан әйтеп куя алмаганмын...

— Әйткән булсаң нишләр идең? Әллә Сәрвәргә кагыла алыр идеңме? Мин гаепле монда, мин! Синең куркак жаныңның шундый этлеккә баруына ышанмадым, уйламадым! Белгән булсам, муеныңны борып ыргыта идем бит! Багалмамны синдәй тинтәктән таптатмый идем! Йә, тагын ни сүзләрең бар? Әйтеп кал!

Ташкәйдән мәрхәмәт, шәфкать көтәргә ярамаганын, көтәр чама калмавын Үлмәс шунда гына аңлады, егетнең күзләре ут булып яна, киерелгән борын тишекләреннән сулыш түгел, ут, ялкын бөркелеп чыга, калкандай тез өсләренә яткан тимер йодрыклары бер языла, бер жыела... Хәзер алар укмашып Үлмәснең башына куначаклар! Сәрвәр мәсьәләсендә Ташкәйне артта калдырган Үлмәс нигә әле бу юлы бирешеп торырга тиеш? Сабакны ул түгел, әйдә, Ташкәй алсын! Көч ягына килгәндә алар тигездер әле, мөгаен, ә хәйлә ягына килсәк, Ташкәй үзе аңгыра, укыганда да гел артта кала иде, хәзер, хәзер...

Үлмәс, кулының калтыравын сиздермәскә тырышып, тизрәк ишә башлады, көймә ярдан шактый читкә китте, вак дулкыннар ясап балык сикерде, кечке жил исте. Ул уң ишкәген суырып чыгарам дигәндә



*А. Тимергалина рәсме*

генә Ташкәйнең йодырыгы аның баш түбәсенә очып кунды. Сәрвәр чәч йолкыган урыннан чәчрәп кан чыкты, кан икесен дә котыртты. Үлмәс алагаемга ике кулын алга сузып көндәшенә ташланды. Ташкәй көймәне бер якка янтайтты, аны-моны абайламаган Үлмәс аркасы белән суга барып төште, калкынды, ул арада Ташкәй аның чәченнән умырып тотты.

— Ташкәй, уйнама, җибәр.

— Үч алуның тәмен мин Чырыкны өтелгән дуңгыз шикелле шәрә калдыргач күрдем... Юк, Маннур да, бүтәннәр дә, Мөхәммәт абый да миңа киңәшнең кирәклесен таба алмадылар! Менә ул, миңа кирәк нәрсә — үч! Үч! Үч!

Үлмәснең чәчен нык тоткан иде, «үч!» дигән саен аны җылымса күл суына батырып алды. Үлмәс судан калка да, хырылдап, ике куллап көймә читенә ябышырга тели, әмма Ташкәйнең сул кулы буш, ябышкан бармакларны ул бер сугуда ычкындыра...

— Өтелгән дуңгыз шикелле Чырыкка күрсәтәсе иде менә хәзер сине! Күрсеннәр иде Сәрвәрне изгән батырны! Үч! Үч! Үч!..

Тагын ничә мәртәбә бу ярсулы кыска сүзне кабатлагандыр Ташкәй, соңга таба Үлмәс судан калкынмый башлады. Ташкәй аны тартып чыгарды, тагын батырды, инде куллар да көймә читенә ябышмый башладылар, әмма аны туктатыр хәл юк иде, «үч!» — дип кычкыра да көндәшен суга мана...

Ниһаять, гәүдә авырайды. Ташкәйнең үзен аска сөйри башлады, ул иелеп Үлмәснең ике култык астыннан эләктереп аны көймәгә сөйрәп менгерде. Үлмәс гадәттән тыш авыр иде, көймә янтайгач, чырылдап су керде. Ул Үлмәсне көймә төбенә җаеп салды, ишкәкләрнең берсе суга төшеп киткән иде, ул сыңар ишкәк белән ишә-ишә ярга, сүнгән учак янына ашыкты.

Көймәне ярга, корыга сөйрәп чыгарды, Үлмәснең өстенә киемнәрен япты да тиз-тиз атлап, артына борылып карамыйча гына, авылга кайтып китте.

Ачык тәрәзәдән шатлыклы авазлар ишетен, ул чак кына тыелып торды, башы гүли, авыз эче кипкән, теле әйләнмәслек хәлгә җиткән иде.

«Кем көлә ала мондый чакта? Сәрвәр чирләп үләргә ятканда, мәсхәрәләнгәндә кем шулай сөенә ала?»

Ул арада өстә, болдыр баскычында, яңа күлмәген киеп алган, иңенә кыйммәтле шәлен салган әнкәсе күренде.

— Кайда йөрисең син, улым? — диде ул шатлыклы әрләп.— Мәүлия белән Йосыф кайттылар бит!

— Мәүлия? Йосыф? Алар исәнмени? — Соравының йогышсыз икәнен аңлап, хәле бетеп баскыч тактасына килеп утырды һәм нидер сизенеп, куркынып көтеп торган әнкәсенә:

— Бар әле, Йосыф монда чыксын! — дип боерды.

Йосыф көттермәде, тик ул ялгызы түгел иде, аңа Мәүлия дә ияргән. Торып аларга сүрән генә кулын биргәч, ул Мәүлиягә карап:

— Бар, сеңел, кирә тор, әз-мәз ашарга әзерлә, минем Йосыф белән сөйләшәсем бар.

Мәүлия кереп киткәч Ташкәй торды, өйалды ишеген тыгызлап япты һәм төшенке, үлек тавыш белән:

— Анда... без балык тота торган Чөгә күле ярында... көймәдә Үлмәснең мәете ята... Барып алыгыз,— диде.

## 42

Шамил бүген Сәрвәр белән күрешергә тиеш, сельпо атын товарга җибәрәләр, ул шуңа утырып бара. Хәзер торага йөрү өчен ат табу бик читен, атлар санаулы, бөтенесе печәндә. Дәүләтша әкәне көн

туды исә телефонга чакырып алалар: «План! План! Әнә фәлән колхоз үтәгән инде! Төгән район алга чыккан! Без артта сөйрәләбез! План! План!»

Болай да көйле барган эш тагын да кызып китә, әмма егетнең ат соравына кире җавап бирә председатель.

— Беләм, барырга кирәк икәнен дә беләм, әмма ләкин ат юк, үзең күреп торасың. Кобланды батыр болынын өч-дүрт көндә бетерергә кирәк, яңгырлар башланса, аннан курмыны алам димә...

Мөхәммәт абыйның бик яхшы велосипеды бар, «Пенза» маркалы, әмма үч иткәндәй бер камерасы тишек, ямап-ямап та карадылар, ишегалдында йөри, урамга чыктың исә, пыш итә дә бушап кала... Сельпо атын да печәнгә алдылар, бүген, кичкырын гына бушаталар, кичке ярауда торага бара да, иртәннән товар алып ат печәнгә кайтып та житәргә тиеш. Дәүләтша әкәнең боерыгы шулай. Шамил, барган-барган, складлардан үзенә кирәк камераны да эзләп карарга тиеш. Ат ял иткәндә, төнен, ул Сәрвәр янында утырачак. Шәмсеруй апа пешереп китергән бәрәңге шаңгәләрен дә Шамил алып барачак.

Кояш инде түбәнгә тәгәри...

Ташкәй килеп киткәннән соң Мөхәммәтнең йөзе бераз кырысланды, уйга калды, Ташкәйнең үз-үзен сәер тотышы, сәер сүзләре аның эчен пошырдылар.

— Җәһәтрәк кенә эшлик тә, мин синең белән кайтырмын, ахры-сы,— диде ул Шамилгә.

Кибән куялар иде. Сания, тагын берничә хатын-кыз, мактап җыеш-тыручылар тырма-сәнәкләр белән печәнне күбәгә куялар, завхоз Чаләкә әкә, Мөхәммәт, Шамил, тагын Дәүләтша әкә биргән ике булышчы ир коры урынны сайлап кибән куялар... Эш белән мавыгып, алар бер читтәрәк чикерткә куып йөргән Фаягөлне онытып та җибәрделәр...

Печән өстенең рәхәт икәнен үсмер кыз булып килүче Фаягөл әллә кайчан аңлады инде. Печән өстендә и күңелле була, учак янында тәмле ризыклар әлгә, төтен исе килеп торган җиләк чәе дә бик тәмле, әтисе дә, әнисе дә аны тагын да ныграк иркәлиләр, бераз эшләп алгач, «Бар, кызым, күләгәдә утырып тор, башыңа кояш капмасын тагын, бик нык көйдерә!»— дип уйнарга да ирек куялар.

Кипкән печән өстендә сикергәләп йөргән яшькелт, коңгырт эре-эре чикерткәләр барында Фаягөл күләгәдә тын гына утыра аламы соң? Алай да бүген сак булырга, аяк астына карабрак йөрергә кирәк, кичә Шамил абыйсы тимер сәнәге белән печән күбәсен күтәреп алган иде, печән арасыннан кап-кара җылан килеп төште... Әле ярый Шамил абыйсы батыр, каушап калмады, җыланны сәнәк очы белән әрәмә арасына ук чөйде. «Шунда йөрсен, өе шунда аның!»— диде. Димәк, әрәмәгә якын барырга ярамый, анда җылан өе, алар анда уйныйлар, яшиләр, бала чыгаралар... Әй, ахмак чикерткәләр, кая сикерәсез сез, туп-туры җылан өенә барып керәсез ич!

— Фаягөл!

Рәхмәт, әнисе кызының шактый ук еракка китәнен абайлады... Ерак дип, ара ерак та түгел инде, ана өчен ерак. Сания тагын бер тапкыр кычкырды:

— Кызым!

— Хәзер, әни, менә бу зур башлы яшел чикерткәне генә тотам да сезнең янга алып кайтам, югыйсә ул җылан өенә кереп бара.

Һәйт, тагын бер сикерде яшел чикерткә, ике, өч...

Шамил абыйсының кулында тимер сәнәк, ә Чаләкә әкә белән әтисе кулында агач сәнәк, кочак-кочак печәнне чөяләр генә өскә!

Мөхәммәтнең Шамилдән бер дә калышмыйча эшләвен күреп Сания дә сокланды. Соңгы вакытларда «билем авырта, сырт сөягем кузгалды» дип зарлангалый, ул язын әле аркасын җылытып йөрде, сылап та

карадылар, хәзер, баксаң, сөбханалла, егетләргә бер дә биргесез, күлмәк итәге җилфердәп тора, куллары туктаусыз хәрәкәттә, буе төзек, басып торган аяклары нык.

Хәзер нәкъ Фаягөл каршысына урманнан дәү, йөнтәс аю килеп чыкканны кем иң беренче булып күргәндер, берсе дә әйтә алмый, әллә кызның «чыр-р» итеп кычкыруына барысы берьюлы борылып карадымы? Борылып та карадылар, салкын су койган төсле һәммәсе өшеп, катып та калдылар — сары тешләрен ыржайтып, арт аякларына басып нәни кызчыкка таба урман хуҗасы килә... Ялан урманнарында аюлар еш очрыйлар, элек махсус аючылар булып, хәзер ау белән генә шөгыльләнгән кеше юк диярлек, ара-тирә, көзен, чикләвектә симергән аю атып алып кайткалыйлар, Мөхәммәтнең авыртып торган җилкәсен нәкъ әнә шул йөнтәснең мае белән сылаганнар иде инде.

Ачуы килсә тайга аюы бик куркыныч, бу тирәләр, мөгаен, аның хуҗалыгы булгандыр, әрәмәдә кура җиләге күп, шуның белән сыйланырга дип бу якка килеп чыккандыр, кешеләрнең, атларның күп булуы аның ачуын чыгаргандыр...

Әлбәттә, әтисе дә, әнисе дә, тимер сәнәк тоткан абыйсы да бу хакта уйлый алмадылар, алар, гомумән, бу мизгелдә бер нәрсә дә уйларга сәләтле түгелләр иде, кинәт килеп чыккан хәл аларның һушын алган, каушаткан һәм куркыткан иде. Курыккан кешедән уй кача, ди татар, дөрес әй, уй качты болындагылардан.

Фаягөл бер чырылдады да тынды, бала бит, аны-моны уйламый, каршысына килгән аюга карап елмайгандай итә, әллә уйнарга ук тели инде. Беренче булып исенә Шамил килде, ул сәнәген ике куллап тотып бер атлады, ике... Өч атлагач, адымнарын вагайтып, ботинка табанын ышкып кына бара башлады, аның ашыкканын күрде исә, аю да ашыга башлар һәм һөҗүмен тизләтер, дип уйлап өлгерде Шамил.

Чәләкә әкә кибән артына кереп посты, җыештыручы хатыннар — алар аюга күренми торган якта печән күбәлиләр иде — аның янына чумдылар.

— Барыбыз бергә кычкырып карыйбызмы әллә? — дип пышылдады Сания.

— Тукта, ашыкмыйк...— Мөхәммәт тә агарынып калган иде. Хәзер ике баласының да язмышы кыл өстендә иң, кызы гына түгел, Шамил дә афәт алдында басып тора.

Шамилне күреп, аю тукталды, дәү башын югары чөеп, борынын алгарак сузды, шул мизгел Шамилгә җитте: ул ике-өч сикереп Фаягөл янына барып басты һәм аны үзенең артында яшерде. Башта: «Әти янына йөгер!» — дип кычкырырга уйлаган иде, аюга кире тәэсир итәр дип дәшмәде, өч җәпле тимер сәнәген аюга төбәгән килеш әкренәкрен артка чигә башлады, аның белән бергә кыз да аюдан ераклаша бара иде. Туктаган аю яңадан кузгалмады, тагын бер-ике тапкыр башын югары чөеп борыны белән һаваны сөзде дә дүрт аякланды һәм, кире борылып, бик олы эш башкарган сыман эре атлап, арт санын уйнатауйната әрәмә арасына кереп китте, коры ботаклар шартлап сынды, бераздан алар да тынды, мәктәп кибәне янындагылар тирән итеп көрсенеп куйдылар, Сания чабып барып Фаягөлен кочагына алды, кычкырып җылый башлады. Мөхәммәт маңгае гына түгел, бөтен тәне шыбыр тир булган Шамилнең кулын кысарга дип үрелә, кыса алмый, Шамилнең бармаклары сәнәк сабына ябышып кәкерәеп катканнар иде. Ул әле байтактан соң гына сәнәк сабын ычкындырды...

— Әни, аю бабай минем белән уйнарга килә идеме ул? — дип сораша һаман Фаягөл.— Башта мин курыктым, аннары инде тамчы да курыкмадым.

— Әйе, кызым, уйнарга килә иде... Әйе, балам, син бер дә курыкмадың. Мин дә курыкмадым, әтиең дә, Шамил абыең да курыкмады, ул аюга: «Син нишләп безнең янда йөрисең, үз өеңә кайт!» — диде.

— Әйтмәде лә! — дип карулашты кызчык.

— Башта «Үтерәм!» дип уйладым, барам да, мин әйтәм, сәнәк белән кадыйм... Аннары шуны уйлыйм, ә бер кадауда үтерә алмасаң? Яралап кына калдырсаң? Бер сикерүдә кызны харап итәчәк, бүтәннәргә дә ташланачак. Әле ярый, әйбәт холыклы аю булды, тамагы тук чак булгандыр, сәлам бирде дә китте...

Шамил сөйли, ә Мөхәммәтнең ике күзеннән дә елгадай яшь ага, ул бертуктаусыз улының аркасын кага башлады. Шамил әле үзе берни сизми, сөенеченнән аю белән күрешүен, уена нинди кискен фикерләр килүен сөйли дә сөйли, рәхәтләнеп кат-кат сөйли. Мөхәммәт аның аркасын кага да кага, әле Сания дә берни сизми. Чәләкә әкә дә батыраеп кибән артыннан чыккан, агач сәнәген болгап: «Мин дә барып җитәм дип торганда гына кире борылды!»— дип, күкрәк кага. Ниһаять, Мөхәммәт Уразаев улын бүлдерә:

— Улым, улым, тотлыкмыйсың бит, үзды!— дип кочаклап алды.

— Әйтәм җирле сөйләшүе җиңел, рәхәт! Шуңа сөйлим дә сөйлим икән әле!

Аталы-уллы кочаклаштылар. Фаягөлне җитәкләгән Сания дә бу кочакка кереп сыйды, бераздан алар җыйнаулашып кайтырга булдылар.

— Юк-юк, монда кунарга калабызмы соң?— диде Сания.

— Калыйк,— дип ялынды бәләкәч Фаягөл,— минем аю бабай белән уйныйсым килә.

Көлештеләр...

Шамил сөйләшеп туймый иде, ул бертуктаусыз көлдереп, үен сүзләр әйтеп кайтты, үзенең хәзер үк, авылга кайту белән Сәрвәр янына китәсен онытжандай булды, ул да терелер, менә бәхет, һич уйламаганда Шамилнең тотлыгуы бетеп куйды, кычкырып русча Пушкин шигырьләрен укып җибәрде, «Пушкин, бөек Пушкин, великий Пушкин!»— дип кычкырып, кичке салкында тавышны иркен тирбәтә торган болын, әрәмә буйларын яңгыратты. Кичке кошлар сайрашып аңа җавап бирделәр. Сания дә куанып кайтты, мөгаен аның күңел күтәренкелеге Сәрвәргә дә йогар, бергәләшеп куанырлар. Шамил кыз янына кайгы төяп түгел, шатлык тутырып алып бара. Фаягөлгә аю ташланган булса, нинди олы кайгы булачак иде бит...

Аю Фаягөлгә карап туктап калганда Мөхәммәт ни өчендер бүре Рәхмәтулланы, аның эре-эре җөй эзләре калган битен, ыржаеп калган питек иренле авызын, аннан күренеп торган тешләрен хәтерләде. Хәзер генә уйлады, мөгаен, аю ботарлаган дыр аны, аю ботарлаган аучыларны аның моңарчы да күргәләгәне бар иде. Хәзер ул куркынып, өшеп китте, әгәр аю Фаягөлгә кулын сузган булса...

Шамил сөйли дә сөйли, Иртеш буена кайтып җиттеләр.

И тормыш, нинди көтелмәгән хәлләр китереп куясың син алга! Сөенеп ачылган авыз җыелып та өлгерми, син адәм балаларына күпме авыр сынаулар әзерләп куясың.

Иртеш буена әле генә Үлмәснең мәетен алып кайтып җиткерганнәр икән...

Ни булган? Кем эше? Ничек? Кайчан? Беркем берни белми.

— Суга батып үлгән булса кирәк,— диделәр Мөхәммәткә.

Арада Йосыфны да күреп, ул куанырга да, куанмаска да белмәде, кул бирергә онытып, аңа карап тукталды. Кайткан! Мәүлия дә кайтканмы?

— Кайттык, икебез дә кайттык, Мөхәммәт абый... Тик сезгә бик зур күңелсезлекне хәбәр итәргә туры килә. Очрашу шатлыгын ямьсезләү булса да әйтәм, Үлмәсне Ташкәй үтергән. Ул үзе милициягә хәбәр итәргә китте, безне монда җибәрде. «Сәрвәрне җәберләгән өчен алдым мин аның җанын!»— диде.

Мөхәммәт эсселе-суыклы булып китте. Менә ни өчен килгән булган икән Ташкәй! Менә ни өчен читләтеп, кинаяләр белән генә сөйләгән икән! Ник ачмадың син шул чакта җаныңны, егет! Үзеңнең өлкән укы-

тучыңа тагын кайгы-хәсрәт өеп киттең ләбаса! Аның тормышына тагын үз язмышыңның хатасын да калдырдың, эх, егет, егет!

## 43

Юлга дүртәү җыендылар.

— Һәр кешегә аерым-аерым ат йөртеп булмый,— диде кистереп Дәүләтша әкә.— Ташкәйне дә алып барасыз!

Сельпо атына йөкче үзе (ул товар алып кайтырга тиеш), Шамил (ул Сәрвәр янына бара), Ташкәй белән Загвалова авылыннан килгән участковый милиционер: ак мыеклы, ак кашлы, юаш кына дядя Захар утырдылар. Дядя Захар — русча да, татарча да бик шома гына сөйләшә торган кеше — Ташкәйне төрмәгә алып бара.

Олау янына байтак кеше җыелды. Печән өсте дисәң дә авылда кеше шактый табыла икән инде. Туктаусыз елаудан шешенеп беткән Йомабикә абыстай Мәүлиясенең иңенә таянып кына тора. Йосыфны каршыларга дип кырдан Гыйззәтбану түти белән Сәгъдетдин дә кайтканнар. Алар бер читтә житәкләшеп диярлек басып торалар. Гыйззәтбану күләгәсеннән Сәгъдетдин күренми дә дип әйтерлек. Сәлимәсе белән Маннур да монда, алар Шамилне озаткач ук кырга китәргә тиешләр. Шәмсеруй җиңги, тагын да кечерәеп, сүзсезләнеп арба тирәсен бер әйләнә, ике әйләнә, печән астына кыстырган төенчеген бер барлый, ике капшап карый, аннан Шамилнең күз карашы белән очрашкач, капылт кына авыз читен яулыгы белән каплый, башын аска ия...

«Бу балаларнең башы минем кунакка китүем булды ласа!»— дип үкенә бичара ана.

«Бу бала-казаларның башы миндә, ныграк торсам, улым белән ачыграк сөйләшсәм, эш болай ук ямьсезләнми иде бит!»— дип үкенә Йомабикә абыстай.

«Әгәр без иртәрәк кайтып житсәк, боларны булдырмаска да мөмкин иде бит!»— дип уфылдыйлар Йосыф белән Мәүлия.

«Акыл житеп бетмәде, шунда Ташкәйне тыеп, кибән куйганчы гына ярдәмләшергә кыстасаң, мөгаен, егетнең зиһене дә ачылып китәр иде!»— дип үз-үзен кыйный Мөхәммәт.

«Әгәр без Сәрвәр белән юк-бар өчен ачылы булып, күпме вакыт хат алышмыйча тормасак, мөгаен, мин өйләнгән дә булыр идем, өйләнмәгән тәкъдирдә дә, Үлмәс безнең ара ныклыгын белеп, буталып, кысылып йөрмәс иде!»— дип уйлый Шамил.

Әйтегез, гаепләме алар? Кем белсен! «Бу дөньяның эшләре, шыкшык итә тешләре»,— ди халык... Дөрес әйтә, һәркем җирдәге һәр эш өчен җаваплы булган кебек, җирдәге хаксызлыклар, бәхетсезлекләр, вакытсыз үлем-житемнәр өчен шулай ук һәркем өлешчә гаепле.

Дөрес яшәмәве, пычрак эшләре өчен Үлмәс тә гаепле.

Дөрес хөкемнәр чыгармаганы өчен Ташкәй дә гаепле, ул үз өстенә артык авыр йөк алды.

Үлмәс вафат, бу дөньядан киткән инде, иртәгә торадан врач килеп үзенең нәтиҗәсен ясарга тиеш. Ташкәй хөкем каршысына басарга җыена...

Ә тереләр? Монда калганнар?

Үлмәснең әти-әнисе... Гәрчә алар олау янында күренмиләр, мәгәр монда ич алар, өйдә. Улларының мәете өстенә карап алар ни уйлый икән? Үкенәләрме, кыйналалармы, әллә Ташкәй токымын кырып бетерергә дип пычак кайрыйлармы? Сәрвәрне мәсхәрә иткәндә алар икесе дә өйдә иделәр ич, улларын явызлыкка үзләре этәрде, үзләре фатыйха бирделәр, асылда үзләре котырттылар да: «Син булмасаң башка бирәү алачак аны!»

Ә Шәмсеруй апа! Туйларда такмак чыгарып, чичән булып йөри торган, вакытсыз үлеп калган Эссәт Фәтхуллинның сердәше, тормыш

иптәше, көрәштәше нигә бүген тып-тын? Бу кыргыйлыкка юл куйганда аның өлеше юкмыни? Чырык белән ул барып сөйләшмәдеме, Гобәйбә буйдактан агулы көмешкәне ул алып кайтмадымы?

Кабык арбага җигелгән алашаның гына гаебе юк, ул эченнән генә зарлана, эче урт-урт итеп куя. «Көне буе печән ташыдым, тагын кая куасыз инде сез мине, кешеләр!»— дип зарлана ул.

Арба майланган, ни дисәң дә сельпо арбасы, анда акмаса да тама, мае-дегете дә җитәрлек, тәгәрмәчләр дә кыршаулы, яңа тәгәрмәчләр, арбага дүртәү утырсалар да алаша җиңел генә юырта, юл коры, юл туры, таныш юл, юл торага — Тоболга илтә...

Күп йортлары кайгы-хәсрәткә чумган Ялан артта калды. Үнда авылның күпме сөенеч-шатлыгын иңенә салган Кызлар Убасы. Тауга менеп карасаң, хәзер Иртеш аръягындагы болыннар, болында янган учаклар, учак тирәли утырган уйчан кешеләр ап-ачык күренәдер. Үлмәснең вафаты турындагы хәбәр инде иң ерак болыннарга да барып ишетелгәндер, авыл бер гаилә ич, кайда да мәрхүмнең туганнары бар, якыннары, хәтта аңа күзе төшеп йөргән кызлар да бар. Үлмәс тә төшеп калган токымнан түгел, егет буларак та күркәм кеше иде бит.

Ат бара да бара, Захар дәдәй, фуражкасын салып тезенә кага да һаман бер үк сүзләрне кабатлый:

— Да, парин, ясадың син безгә мәшәкать! Ну, үзенә дә катылык булыр! Да, булыр!.. Анаң жалкы, сеңлең. Хәзер ничек яшиләр инде алар?

Ташкәй эндәшми. Шамилнең тел сынар өчен бик сөйләшәсе килә, ул да тыныч, уңайсызлана, олаучы гына берни дә булмаган кебек һаман шул ук озын бер җырны суза:

Карадагынай урман, караңгы төн...

Олаучы — Казан татары, Яланга аның әти-әниләре килеп урнашкан, алар әле тәмам «себерчә» сөйләшмиләр дә, гомерләре буе нужа чиккән шул Казан тирәләрен сагыналар, җәйге кичләрдә, ачык тәрәзәдән алардан гел патефон тавышы килә, Гөлсем апаны җырлаталар алар, үзләре дә кушылып җырлыйлар.

Юл озын, эңгер-меңгер, нәкъ алар каршысында гына күктә беренче эре йолдыз балкый башлады, ат пошкырып ала да, тауҹыкларда әкренәя, менеп җиткәч, каулаганны да көтеп тормыйча иңен уйнатып юыртып китә, тизрәк барып җитеп ял итәргә ашыга булса кирәк. Юл озын, эчпошыргыч дәрәҗәдә бер төрле, кырлар, болыннар, урманнар алмаштилмәш кишәрлек булып, ялгыз атны үткәреп җибәрәләр, кичкә карап беркем дә юлга чыкмаган, бу арада авыллар сирәк, кырлар иркен, җирләр күп, урманнар аннан да күбрәк.

Захар дәдәй фуражкасын тагын тезенә бәрде, тагын:

— Да, парин, эш таптың син безгә! Печән өсте, минем дә сыер бар, унбиш баш сарык! Алар да печән сорый! Ә мин юк эш артыннан йөрим!

Шамил чыдамады:

— Дядя Захар, сез барасыз-барасыз да картузыгызны кагып куясыз. Ни өчен?— дип сорады.

Дядя Захар көлеп куйды:

— Башта уйлар күп. Уйлар фуражкага да йога, фуражка авырая, баш аны күтәреп тора алмый башлый, кагам да уйларны коеп калдырам...

Алар Тоболга барып җиткәндә кап-караңгы иде инде, соң, сирәк йортларда гына утлар яна, алай да больница ишеге төбендә үк, баскыч өстендә нәни генә лампочка җемелди. НКВДга юл больница кырыннан үтә, иң элек Шамилне төшереп калдырдылар. Ул саубуллашырга дип Ташкәйгә кулын сузды.

— Исән йөреп кайт, Таштимер.

— Дядя Захар,— диде ялынып кинәт Ташкәй.— Мин Сәрвәр белән саубуллашып чыгыйм инде. Иртәгә мине монда чыгармаслар бит?

— Знамо, чыгармыйлар. Да парин, син үз акылыңдамы? Кем сине бу вакытта больницага кертсен ди? Житмәсә, каты авырган кыз янына.

— Минем сүзем бар.

— Әйт Шамилгә, ул тапшырыр.

— Юк, ул минем үз авызымнан ишетергә тиеш аны.

Захар аптырауда, Шамил да югалып калган иде. «Кермә, йөрмә!»— дияр иде, Ташкәй үтенеченең нигезе дә бар: ул соңгы кичен иректә ләбаса, алда әле ни булыр, бәлки бик каты җәза бирерләр, мөгаен, туган якларына тиз генә кайта алмас, кем бар да кем юк бу дөньяда дигәндәй...

— Дядя Захар, әгәр сез кереп дежурный врачтан үтенеп сорасагыз, аларны күрештерерләр,— диде Шамил.

— Син дә шулай дисеңме?

— Хөкем иткәндә «соңгы үтенечең бармы?» дип сорыйлар, анда мин дәшмәм, дядя Захар, соңгы үтенечем шул булыр,— диде Ташкәй.

— Күреп китсен инде!— дип кабатлады Шамил.

— Рәхмәт, Шамил...

Олаучы тыкырдата башлады:

— Җәмәгать, атны ял иттереп аласы да бар, күрәсез, таң атарга күп калмады. Бүген иң кыска төн.

Дядя Захар картузын какты да больницага кереп китте, ул анда ничек итеп, кемнәр белән сөйләшкәндер, чирек сәгатьтән әйләнеп чыкты һәм Шамил белән Ташкәйне эчкә чакырды.

— Бер минутка рөхсәт бирделәр, Сәрвәр исемле кыз уяу икән,— диде. «Нигә йокламый ул?»— дип пошынды Шамил, үзеннән алга чыккан Ташкәйгә:

— Син аңа ни өчен торага килүеңне чәчеп ташлама тагын,— диде.

— Мине бөтенләй үк җүләр дип беләсеңме әллә, Шамил?— диде Ташкәй ачу белән.

Керделәр. Шамилгә шушы баскыч, коридор, икенче кат, коридордагы ис тә таныш...

Сәрвәр ак мендәргә аркасын терәп аларга текәлеп калды. Ташкәйнең дә монда булуы аны бик нык гаҗәпләндерде булса кирәк, кашлары югары күтәрелде.

— Сәрвәр!— диде Ташкәй бераз кычкырыбрак.— Мин синең алда булган егетлек бурычымны үтәдем... Кичерә алсаң, һәммәсе өчен дә кичер мине. Сау бул!

Бер минут та үтмәгәндер, Ташкәй палатадан чыгып китте, буш, йокымсыраган коридорда аның аяк тавышлары яңгырап калды. Шамил Сәрвәрнең кулларын килеп тотты.

— Сәрвәр!

Ике егет авызыннан үзенең исемен ишетте Сәрвәр, икесе дә аның исемен наз белән атадылар, икесе дә нидер аңлатырга тырыштылар... Нигә Ташкәй «сау бул!» дигәнне дә көтеп тормады, нигә болай таң алдыннан килеп керделәр алар? Нигә Шамил аның кулларын ычкындырмый? Аның кулларыннан җирәнмиме ул?

— Сәрвәр!— дип кабатлады Шамил һәм аның янына килеп тезләнде.— Нигә йокламый идең син? Йоклый алмыйсыңмы?

Сәрвәр элекке шат, уенчак, ваемсыз кыз түгел, күзгә күренеп ябыккан, күз төпләренә күгелҗем төтен яткан, житди, олы кеше...

— Мин бик озак йоклadым, Шамил... Бүген ничәсе инде?

— Егерме икенче июнь, якшәмбе көн. Кырык беренченең егерме икенче июне...

— Уяныргa бик вакыт. Әнә таң ата... Күрәсеңме?

— Күрәм, Сәрвәр. Әти белән Сания әни сиңа бик күп сәлам әйтеп калдылар. Без кичә печәндә булдык. Фаягөл янына аю килеп чыкты.

— Аю?

Шамил: «Артыгын ычкындырып ташламадыммы?»— дип аның күзләренә күтәрелеп карады, юк, Сәрвәр тыныч дип әйтерлек, ул ике күзен тутырып егеткә йотылып карый.

— Әрәмәдән килеп чыкты да тиз генә китеп тә барды.

— Бәхете...

— Барыбызның да бәхет инде. Башта куркыштык, аннан көлешәбез.

— Ә, Шамил!

— Нәрсә бар, җаным.

— Җаным димә миңа.

— Әйтсәм?

— Тагын үпкәләшәбезме?

— Безгә бер дә үпкәләшергә ярамый. Без бер-беребезне эзләп тапкан җаннар. Табигать безне бер-беребезгә бәхет итеп яраткан. Теге чакта саксыз сүз әйткәнем өчен дә үкенеп бетә алмыйм. Әгәр үкенеч акылга китерә икән, ул — файдалы. Минем үкенечем мине акылга утыртты. Ваклыкларына кереп тормыйм, мин ул хакта уйламаска тырышам, ләкин уйламыйча да булмый, килешеп куйыйк, син мине бер чакта да рәнҗетмисең. Мин сине бер чакта да рәнҗетмәвемә ышанам!

Һич көтмәгәндә, кызык бер дә юкта, Шамил калтырана-калтырана җанын ачып маташканда, Сәрвәр көлеп җибәрде. Кызның көлүен сәламәтләнү дип уйлар идең, бигрәк вакытсыз, урынсыз көлә. Шамил шып тукталып аңа текәлеп карады.

— Нигә көләсең?

— Тотлыгуың беткән бит!

Ул кызны кочаклап алды, беренче мәртәбә Сәрвәр аннан тайчынмады, кочагына сыйды да бетте.

— Син миннән җирәнмисеңме?— дип сорады ул күзләрен йомып.

— Юк!— дип җавап бирде Шамил чын күңеленнән.

Шамил Сәрвәр янында төшкә кадәр юанды... Төшке аш җитәрәк ишек, ничектер, шикләндереп бик кинәт ачылды да, аннан дежурда торучы шәфкать туташы килеп керде. Ул керә-керешли сөйли дә башлады:

— Немецлар безгә каршы сугыш башлаган! Әле генә радиодан үзем ишеттем. Фашистлар безнең шәһәрләрне бомбага тоталар.

Шамил Сәрвәрне кочагыннан чыгармады, сүз дә әйтә алмады. Институтта укып ул армия хезмәтенә бармый калды, әмма хәрби кафедрада дәресләр, күнегүләр үтеп, җәйге өйрәнүләргә чыгып лейтенант званиесе алган иде. Аның хәрби билетында «Сугыш чыгу очрагында, хәбәр алыну белән, хәрби комиссариатка килеп җитәргә»,— диелгән.

Соңгы вакытта борчулар күргән Сәрвәр бу хәбәрне Шамил көткәнгә караганда тынычрак кабул итте, йөзенең җитдилеге генә артты.

— Ә мин нишләрмен?— дип сорады ул.

— Без дошманны тар-мар итеп бик тиз әйләнеп кайтырбыз, Сәрвәр. Син мине сабыр гына көтәрсең. Көтәрсең бит?

— Ел булса да көтәм, ике ел да! Аннан ары да!

— Алай ук озакка куйма, без бик тиз әйләнеп кайтырбыз...

Авылына кайтып, әти-әнисе белән саубуллашып килү өчен Шамилгә өч сәгать вакыт бирделәр. «Азрак!»— дигән иде, үз сүзеннән кире кайтып: «Өлгерермен!»— дип өстәде.

Менә пар ат таныш юллар буйлап Ялан авылына чаба.

Арба буп-буш, товар кайгысы онытылды. Велосипед камерасы табылса, Сәрвәр янына ешрак килеп йөрер идем, дигән хыяллар онытылды. Тормыш кинәт икегә бүленде: бер ягында сугышка кадәрге гомер, икенче ягында бөтенләй билгесез, татылмаган, куркыныч һәм хәвефле сугыш көннәре. Артта бәхет тә, кайгылар да — бар да бар, сөенеч белән көенечләр алмашлап килгән, ә алда ни буласын беркем дә белми. Шамил Уразаевның, дары төтене иснәп карамаган лейтенант-

ның, үз исәбендә өч сәгатьлек гомере бар, аннан бөтенесе дә үзгәрәчәк, озаккамы — әлегә анысын әйтү кыен. Аның җанын Сәрвәр генә борчый. Әгәр ул сәламәт булса, Шамил сугыш кырларына җырлый-җырлый чыгып китәр иде... Ул кала. Сынык күңел, боек җан белән ялгызы кала. Имгәтелгән намусы, тапталган тәне кала. Кем юатыр аны? Ерактан торып аңа яшәү көче бирергә, аның күңелен үстерергә Шамилнең көче, белеме, тәҗрибәсе җитәрме? Юл буе ул шуны уйлап кайтты.

## 44

Сәгъдетдин белән Гыйззәтбану чоланда йоклыйлар. Өйләре тәбәнәк, кысан, эссе көннәрдә өй эче ут булып кыза, тәмам керерлек түгел. Чолан идәнендә рәхәт, салкынча, урын җәяр алдыннан Гыйззәтбану чолан идәнен сап-салкын кое суы белән юып, тузанын сөртеп чыгара. Чоланның песи учы хәтле генә тәрәзәсе төньякка караган, аннан җанны рәхәтләндереп салкынча җил генә кереп тора. Ләкин, ни арган булсалар да, алар йоклый алмыйлар. Бүгенге вакыйгаларның сөенечлесе дә, кайгы-хәсрәт китергәне дә аларның йокысын мәңгегә качырган кебек.

Йосыф өйдә юк. Ул кичке уенда. Уенда дип, бүген Ялан аланында гадәти уеннар юк, Кызлар Убасы тып-тын, Иртеш буе үлгән, елга гына үз гадәтенә хыянәт итмичә төнге тынлыкны аяп кына рәхәт чупырдый, ара-тирә яр тирәсендә ауга чыккан ерткыч чуртаннар гына шопыр-шопыр килеп ала...

Авыл очындагы чалыш йортка бүген куаныч керде — Йосыф кайтты, кадерле уллары, өметләре... «Синең этиең карак, синең этиең төрмәдә!»— дип аны институттан чыгарырга да маташтылар, Мөхәммәт Уразаев ярдәм итте, институт җитәкчеләре янына барды, өлкә комитетына керде, бүтән кешеләрне күреп үзе сөйләште, үзе йөрде. Комсомолда да калдырдылар егетне, институттан да чыгармадылар. Авылда алар бу турыда моңарчы сүз чыгармадылар. «Дошманнары бар, тагын Уразайга сүзе килер»,— дип рәхмәтне эчтән генә укып йөрделәр. Инде җаннары тыныч, уллары хәвеф-хәтәрсез генә укып бетереп кайтты, кеше булды... «Кызганыч, бу көннәрне Һади бабасы күрә алмады!»— дип уфтана Гыйззәтбану. «Ничава,— дип шаярта андый чакта Сәгъдетдин,— ходай белән арасы якын иде, берәр фәрештәсе аша хәбәр иттерер әле!..»

Ялан авылыннан барып институтларда кеше исәбеннән укып йөр әле! И ходаем, бу Уразайга ниндиен яхшылыклар итик икән...

Йосыф кайтканны алар дүрт күз белән көтеп тордылар. Актырнак та аны көтте, кич җитте исә тынычсызлана башлый, Йосыф киткән юлга чыгып, әллә кайлардан урап, әйләнеп килә...

Малай кайтты, олы куаныч...

Әле куаныч аның белән генә бетмәде бит! Соңгы хатларының берсендә ул Мәүлия белән аралары бик якынаюын язган һәм хат ахырына болай дип өстәгән иде:

«Инде эшләр без уйлаганча көйле генә барса, быелгы көздән дә калмабыз, өйләнешербез. Әгәр сезнең ризалыгыгыз булса!»

Риза булмыйлармы соң... Бик риза, мең риза!

Гыйззәтбану түти артыгы белән риза, Мәүлиядән д. ипле киленне ул күз алдына да китерә алмый, чибәрлеге дә бар, җитмәсә укыган... Казан ягы кызы буларак, Гыйззәтбану түти гыйлем булуны бик өстен куя иде. «Их, азрак кына укыган булсаммы?! Чүт кенә, базар урыслары белән аяк терәп сөйләшерлек кенә урысча белсәмме, мин әллә кайларда әллә кем булып утырыр идем!»— дип җибәргәли.

Сәгъдетдин дә риза, тик аның бу җәһәттән үз уе да бар.

Нишлисең, күз йомып булмый: Мәүлия авылның кире, куылган бер бәндәсе Ырсытдин кызы... Бүген аны онытсалар да иртәгә кемнеңдер хәтеренә төшеп куяр. «Ә-ә,— диярләр,— атаң кем иде әле синең?» Канал казыганда төрле сүзләр ишетеп, төрледән-төрле хәлләргә шаһит булган

иренең сүзләрендә бер гыйбрәт барын сизә Гыйззәтбану түти, мәгәр Мәүлия кебек киленнән һич тә баш тартасы килми. «Булса ни, бай иде, дөрес, Уразаев мөгаллим яшь чагында аларда ялчылыкта йөргән, малтуар караган. Йомабикә абыстай бай кызымыни? Таза тормышлы булганнар, мәгәр үз куллары белән көн күргәннәр. Ырсытдин дөнья куйган инде, әллә кайчан гүр иясе адәм белән булашып маташмаслар. Хәзер ул йортта Ташкәй хуҗа. Ташкәйне сөргән кеше юк, әнә әртилгә кергән, уч тутырып акчасын ала икән. Ул яктан да эшләр көйләнеп бара».

Бу аларның көндәлек сүзләре.

Йосыф кайтыр көн якынлашкан саен шушы ук сүзләр, төрле аһәңнәргә манчылып, әле бәхетле авазлар белән, әле шөбһәләргә уралып шушы җиргә чүккән йортта ешрак яңгырый, әллә бу сүзләрнең мәгънәсен аңлый инде, Актырнак Йосыф киткән олы юлга көненә өчәр тапкыр барып кайта. Бара да Йосыфны озатканда үзе «тамга» салган телефон баганасы төбенә тагын бер тапкыр билге куя: Түбән оч этләре, монда уралып йөрмәгез, монда Йосыф дигән укымышлы егетнең Актырнагы хуҗа...

Уйлар татлы, хыяллар якты, көннәр матур...

Йосыф кайтты...

Инде хыялларны чынга ашырырга вакыт җитә, көзгә туй ясап җибәрәләр дә яңа өй хакында кайгырта башлыйлар. Йомабикә абыстайны буш кул белән кайтмаган диләр, кешелеге килеп, аның да янчыгын чиштереп булса, язын бураны күтәреп яшьләрне башка да чыгарырлар. Аннан күз күрер, ел килешләре әйбәтләнеп, колхоз да бераз елмайса, үзләренә дә нәни генә яңа өй кәмәше оештырып куярлар. Әле алай ук картлар түгел, Дәүләтша әкә дә яшәп ята, Чәләкә карт та теркелди, Атыш әкә сиксәнне узса да рәхәтләнеп челемен пышкыта. Сәгъдетдингә әле, яшисе дә яшисе...

Иртә шулай башланды, көн якты нурларга уралып үтте, кич исә авылны, берочтан Сәгъдетдин йортын да кара пәрдәгә төрде: «Ташкәй Үлмәсне суга батырып үтергән!»

Ташкәй дә кызганыч, ахыр чиктә Үлмәс тә алай ук зыянлы егет түгел иде лә, яши-яши ул да акылга бер утырыр иде әле, ә Сәгъдетдиннәрнең үз хәлләре яманрак. Мәүлия — Ташкәйнең сеңлесе... Менә нәрсәдә хикмәт! Хәзер бөтен нәрсә үзгәрәчәк. Мәүлия авылдан куылган бай кызы гына түгел, кеше үтерүче Таштимернең бертуган сеңлесе дә... Үтерелгән егет — Ялан авылыныкы. Кан кардәшләре күп, туган-тумачалары егәрле-хәлле, сүзләре үтә. Үлмәснең әнисенең туган энесе Омскида бик зур начальник булып утыра икән, гомергә телгә алганнары юк икән, имеш-мимешләргә уралып аның исеме дә калкып чыкты. Омскиның кап уртасында зур бер йортта, бик зур булмәдә начальник булып утыра икән, ашарга да машина белән генә йөртәләр икән үзен, җәйгә печән чабарга кайтмый икән, ялга Кара диңгез дигән олы диңгез буена бара ди, имеш. Хәзер шуңа «кайт!» дип телеграмма суктырганнар, ул кайтмыйча күммәскә дә исәпләп торалар икән...

Мәет козгыны Чырык килеп җитмәгәнгә аптырап аның өенә барсалар, карчыгы арык янагына сөякле йодырыгын терәп өстәл янында жылап утыра. «Юк, Абдрахман әкәгез, дукаментларын алды, акчаларны алды, кием-салымын алды да «Ялан авылы миннән башка яшәп карасын әйдә!» — дип чыгып китте...»

Юк менә Чырык, мәет куйганда ярап тора иде әле, әмәлен белә иде, оештыра ала иде, хәзер инде нишләргә дә белмиләр: кеше кулыннан киткән җанны зиратның кайсы төшенә куярга?

Аларның үз кайгысы, Сәгъдетдин белән Гыйззәтбануның үз хәсрәте...

Йосыф белән Мәүлия Йомабикә янында. Ташкәйне районга озаткannan соң шуларга кайтканнар иде, шуннан бирле аерылып тарала алмыйлар. Балаларны шулай ук онытылып, зур өметләр белән көткән

Йомабикә абыстай бүген кара хәсрәттә. Ул бар эштә дә үзен генә гаепләде.

— Үзем гаепле, үзем тиле баш булдым. Обдорскидан кайтмаган гына булсакчы! Үзем котырттым баламны «кайтыйк» дип, чит җирләрдә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул, дидем. Үзеңнең илеңдә дә солтан булыр җаең бар дип өметләндердем. Авылның иң сылу кызына хуҗа булырсың, дип ярсыттым... Кайтмаган гына булсакчы!

Ни әйтсеннәр Йосыф белән Мәүлия, алар, бичаралар, бер-берсенә битараф кына карашып алалар да, тыналар. Самавыр яңартып тормадылар, суык коймак белән салкын чәй эчтеләр. Тамакларыннан аш түгел, су да үтмәде...

— Атарлармы аны? Кеше җанын кыйган өчен атарлармы?— дип сорады ана, ниһаять.

Юридик мәсьәләләрдә бөтенләй тәҗрибәсез булган Йосыф бар булганы белән аны тынычландырырга тырышты.

— Атмаслар атуын, ул турыда уйларга да ярамый. Үлмәснең гаебе дә бик зур. Аның үзен атарга кирәк иде дөреслектә. Чырык Абдрахман да чыгып ычкынган! Менә аларны парлап атканда начар булмас иде.

— Чырык чукынып китсен!— дип чәбәләнде Йомабикә абыстай,— минем улымны, безнең бердәнберебезне нишләтерләр?

— Судка кадәр берни дә әйтеп булмый, монда Мөхәммәт абый белән дә киңәшеп куярга кирәк. Адвокат яларга кирәк булыр.

Йосыфның «юридик белеме» шуның белән такырайды, әмма ул әйткәннәр генә Ташкәйнең әнисен тынычландырырга җитмәде, тагын да борчылыбрак, куркыбрак калды Йомабикә абыстай. Билгесезлек һәркемне дә куркыта. Ә монда аның улы хәтәр эшкә дучар булган иде.

Аларның хәлен җиңеләйтергә кирәклеген белгән кебек, ишектән Мөхәммәт Уразаев килеп керде. Тыйнак кына сәлам бирде, ишек катыннан ерак та түгел ялгыз урындыкка утырып өйдәгеләргә карады. Өйдәгеләр кызыксынып һәм өмет белән аңа төбәлделәр. Ул ни әйтер? Бу хәлләрне ничек аңлатыр да, алардан, аларның күңелсез дәвамыннан котылу юлларын ничек эзләп табар?

Асылда Мөхәммәт үзе дә аптыраганнан килгән иде.

Йомабикә аңа карамаска, аның күз карашы белән очрашмаска тырыша. Йосыфтан читенсенәме? Кызы Мәүлиядәнме?

Мәүлия белән Йосыф янәшә утыралар иде, ул килеп кергәч тә шул урыннарында калдылар, тартынмадылар. Мәүлиянең кем кызы булуы хакында Йосыф та беләдер инде? Тик бу хактагы уй Мөхәммәтне артык озак биләп тормады, ул, Йосыфка карап, аннан гадел, юаш Һади бабай чалымнарын да, әткәсе Сәгъдетдингә охшаган билгеләр дә тапты. Сабыр акыллы кешеләр алар, Һади бабай да шундый иде, Сәгъдетдин дә акыллы алга күеп яши. Әгәр Мәүлия дә Сәрвәр хәленә төшсә... Юк, юк, бу турыда уйларга да куркыныч, болай, чагыштырып карау өчен генә күңелгә килде бу мисал. Мәүлиягә олы кайгы, бәхетсезлек килсә, Йосыф нишләр иде икән? Сабыр акыллы ата-бабадан туган бала, сабыр холыклы егет... Ләкин бар кеше дә Йосыф шикелле түгел, Ташкәйдә ярсу холыклы Ырсытдин каны ага! Ташкәйдә дәртле-кайнар Йомабикә каны... Сөйсә шашып сөя ала торган Йомабикә каны... Нигә бу хакта бер тапкыр да уйлап карамады икән Мөхәммәт?! Йомабикәнең кинәтлеккә дә, мәхәббәт хакына җүләрлеккә дә маһир икәнен аннан да шәбрәк Яланда тагын кем белә? Ташкәй аның улы иде ич, аның йөрәк ярчыгы, аның каны да! Нигә ул Ташкәйгә берчакта да Йомабикәнең улы итеп карамады икән? Үзенең якын кешесенең дәвамы итеп карамады?..

Хәзер моны аңлау да, аңлату да үтә кыен иде, бер генә нәрсә ап-ачык: укытучылык һөнәренең бик куркыныч яклары да бар, яши-яши, күрә-күрә, ел саен яңа класс кабул итеп, ел саен бер дулкынны мәктәптән озата-озата ул балаларны, кешеләрне гадәти үлчәү белән үлчәргә өйрәнеп китә, кешеләрне танып-белүдә стандарт өлгеләр куллана башлый.

һәр елны мәктәптән бер яки ике бик шук, өч-дүрт тыңлаусыз бала чыгып китә. Беренче класста шуларны хәтерләткән йә шук, йә тыңлаусыз балалар була икән, күңелгә: «Фәлән малайга алмаш килде инде!» — дип уйлап куймыйсыңмыни? Һәм шушы беренче бәя еллар буе теге бәхетсезгә тагылып йөрмиме әллә?

Хак, кайбер укучыларга еллар дәвамында мөнәсәбәт үзгәрәдер, теге бала үзен-үзе тотышы, өлгереше белән мөнәсәбәтне үзгәртергә мәҗбүр итәдер. Ә аның тотышында сизелерлек үзгәреш күренмәсә? Теге ярлык һаман ияреп йөри-йөри дә, ул бала мәктәптән чыгып китүгә, җилкел сулап куясың...

Тынлыкны Йомабикә бозды.

— Үлмәснекеләр: «Бездән куркып кына милициягә чапкан ул, юкса, ике ботын бер чалбар балагына тыга идек Ташкәйнең!» — дип сөйләнәләр икән, — дип куйды.

Мөхәммәтнең киң маңгаен нинди авыр уйлар сырлавын сиздеме әллә аның сизгер җаны? Юк, юк, Ташкәй үлмәснекеләр үч алыр дип курыкмаган булса кирәк, аны вөҗдан газабы тартып йөрткән, кыз каршында ул үзен гаепле санаган...

Йосыф белән Мәүлия аннан сүз көтәләр, ә сүз юк, сүз әле өлгермәгән, яшьләрнең дә Сания кебек әйтүләрен: «Кеше җанын кыючыны акларга җыенасыңмы әллә?» — дип нәтиҗә ясауларын теләми Мөхәммәт! Юк, ул Ташкәйнең мондый кыргыйлыгын гафу итми, гафу итәргә җыенмый, мәгәр шушы хәлләрдә үз урынын, үз өлешен, үз гаебен генә табып бетерми. Шуны ачыкламыйча торып Йосыф белән Мәүлиягә ни әйтәсең?

Сөйләшкәнгә караганда кайвакытта тынлык күп мәртәбә мәгънәлерәк, файдалырак була. Өйдәгеләр Мөхәммәт Уразаевның шулай соң йөрүенең тирән, чын мәгънәсен әнә шул сүзсезлектән аңладылар. Дөрес, Йомабикә абыстай моны үзенчәрәк, яшьләр үзләренчә кабул иттеләр, әмма асылда төп фикерләре бер иде: Уразаевның да җаны борчыла, аның күңеле тыныч түгел, ул авылга килгән уртак бәланең зурлыгын бөтен барлыгы белән тоя!

Килгән, килгән, гел төнтек булып кына утырып булмый. Мөхәммәт яшьләрдән ничек кайтып житүләре, Төмәндәге яңалыклар турында сораштырып алды, әмма яшьләр бу сорауларның әдәп өчен генә бирелүен, бүгенге очрашуның төп сәбәбе бөтенләй бүтән нәрсә икәнен бик яхшы аңладылар.

Йосыфка өенә кайтырга бик вакыт иде, әле аның әти-әнисе белән дә иркенләп сөйләшә алганы юк. Мөхәммәт абыйсы да килеп киткәч, аз-маз аңлашкач, инде кайтып китсә дә ярыйдыр, дип калкынуы булды. Мәүлия аны туктатты:

— Йосыф, син әни белән утыра тор, мин Мөхәммәт абыйны озатып керим.

— Озатып мәшәкатьләнмә, Мәүлия, — дип карышса да, кыз аны озата чыкты.

Җылы җәйге төн. Авыр эш көненнән соң ял өчен бирелгән иң кадерле вакыт! Байтак йортларда утлар яна. Нигә йокламыйлар? Капканы ачып урамга чыккач, Мәүлия йомшак тавыш белән укытучысына дәште.

— Мөхәммәт абый, сез әнинең ни әйткәнен аңлагансыздыр инде?

— Сизенәм.

— Ташкәйгә яныйлар дип, ул мине кисәтте!

Мөхәммәт кызның сизгерлегенә таң калды.

— Авылда калырга дип бик теләп, бик ярсып кайткан идек, Мөхәммәт абый, әмма мондый хәлдән соң мин Ялан мәктәбендә укыта алмам.

— Без урта мәктәп ачарга җыенабыз!

— Беләм... «Кеше үтерүченең сеңлесе!» дигән дан белән классларга кереп булмас. Болай да «Ырсытдин кызы!» дигән дан белән көрәшергә әзерләнеп кайткан идем. Аны гына җиңә идем лә мин! Тик бу очракта,

хәзер, барыбызга да тигез төшкән кара кайгыдан соң... Кыскасы, мин дүшәмбе көнне үк РОНОга барам. Мине башка мәктәпкә, ераккарак күчерсеннәр. Үтенеп сорыйм, каршы килә күрмәгез, киресенчә, миңа ярдәм итегез.

— Йосыф белән сөйләштеңме, Мәүлия?

— Калып торуын шуның өчен үтендем дә... Менә хәзер керәм дә, әни алдында сүземне әйтәм. «Мөхәммәт абый каршы килмәде, хуплады гына!» — дип әйтсәм, сез ризамы?

Уразаев бер минут кына уйлап алды.

— Шулай яхшырак булыр, Мәүлия. Риза.

— Онытмагыз, минем белән бергә Йосыф та китәчәк.

— Ул ризамы?

— Без бер-беребездән аерылмаска дип вәгъдәләр бирешкән идек инде...

— Сау бул, Мәүлия.

— Рәхмәт сезгә, Мөхәммәт абый.

Кыз аяк очларына басып Уразаевның яңагыннан үбеп алды. Урыс капка шапылдап ябылды, ишегалдында кунаклаган казлар каңгылдашып алдылар, абзар куначасыннан сузып кына карлыккан әтәч кычкырды.

Дөресен әйткәндә, Үлмәсләргә дә кереп чыгарга кирәк иде Мөхәммәткә, бик кирәк иде, әдәп, йола, гадәтләр шуны сорый. Йортта мәет, йортта кайгы, йортта зур бәхетсезлек... Уразаев бераз икеләнеп торды да, кермәскә булды, эре-эре адымнар белән, авыр уйларыннан качкан сыман, өенә кайтты. Кысып кына куйган лампа янында ярым бөкерәеп Сания китап укып утыра иде, иренең аяк тавышларын ишетеп уң кулының имән бармагын селкеде:

— Чү, әкрен.

— Нәрсә бар?

— Фаягөл әллә ничә мәртәбә саташып уянды инде...

— Төшенә һаман аю керә торгандыр.

— Шул!.. Юындырып, дару эчертеп йоклаттым.

— Җылы сөт эчертерләр.

— Эчерттем.

Мөхәммәт өстәл кырындагы стена янына килеп календарьдан бер битне ертып алды.

— Уһу, егерме икенче июнь җиткән бит, якшәмбе!

— Иртәгә иртә торасы бар, ятыйк,— диде Сания.

Мөхәммәт ишегалдына чыгып аягын, бит-кулларын юып кергәндә Сания киң агач караватка менеп яткан иде. Ул хатынын кочагына алды, иреннәрен, муенын, күкрәкләрен үпте.

— Әле ярый имтиханнарны иртәрәк биреп кайтканмын,— диде назланып Сания.— Бала-каза киләсен күңел сизгән кебек булган.

— Әле ярый син бар! Әле ярый бу дөньяда син бар!— дип пышылдады Мөхәммәт аның колагына...

Өйдә чакта шара-бара гына сөйләшеп утырганнар иде, урамга чыккач та Мәүлия сүзчәнләнеп китте.

— Йосыф, мин сине озата барам.

— Мин үзем дә озаям.

— Юк, минем сиңа сүзем бар.

— Сөйлә монда гына.

— Монда әни ишетә. Ә мин аның ишетеп, алдан ук хәсрәтләнеп торуын бер дә теләмим. Аның болай да кайгысы җитәрлек.

— Син мине дә кайгыга салмакчы буласыңмыни әле?— диде ярым житди итеп, ярым шукланып Йосыф һәм Мәүлиясен култыклап алды. Кыз карышмады.— Йә, тыңлыйм.

— Кайгырырсыңмы, юкмы, белмим, әмма сиңа сүзем бар, Йосыф. Юк, юк, алай читкә китәрлек үк түгел, кил якынрак! Әгәр син мин

яңалык әйткән саен кырыйга тайпыла башласаң, уһў, аңлашу кыен булыр бит!

— Ә син кыен ясама.

— Тырышам да бит, мин дигәнчә генә булмый! Йосыф!— Кызның тавышы кинәт үзгәрде.— Безгә Ялан мәктәбеннән китәргә туры киләчәк.

— Ничек? Нигә?

— Нигәме? Әле Үлмәсне җирләмәделәр... Әле Ташкәйгә суд булганы юк. Алай да күпме сүз йөри. Мәетне җирләрләр — илдә сүзе калыр. Ташкәйне ябып куярлар — илдә сүзе йөрер. Тамгалы укытучы булып йөримме? Беләсең килсә, мин моңарчы да тамгалы ич инде. Ырсытдин минем әтием түгел, минем атам Мөхәммәт абый Уразаев.

— Мин моны беләм,— диде кыенсынып кына Йосыф.

— Син беләсең, мин беләм — бик яхшы. Тагын кемнәрдер белә! Ләкин хәтер саклап, әдәп саклап моңарчы дәшми йөрделәр. Хәзер сүз буасы ерылачак. «Ә-ә,— диячәкләр,— Мәүлияме, теге кеше үтерүче Ташкәйнең бертуган сеңлесе!» Әгәр мин гади авыл кызы булып калсам, бер хәл иде, ә мин укытучы! Карты-яше аңа «апа» дип дәшә. Мөхәммәт абый янына киңәшкә күрше авыллардан киләләр. Минем карамның сиңа ягылуын теләмим, Йосыф... Онытма, синең әткәң дә төрмәдә утырып кайтты. Ни диячәкләр безнең гаилә хакында?

— Ә яңа урынга хәбәрләр барып ирешмәс дисеңме? Кара сакалың кая барсаң да артыңнан калмас!

— Мин ул турыда да уйладым. Син математика укытучысы, мин биологиядән укытырмын. Безгә еракkарак китәргә кирәк! Еракка! Безне белмәгән якларга, безнең Ялан авылын ишетмәгән төбәккә! Мин Мөхәммәт абый белән киңәштем, ул да шулай диде.

— Китегез диме?

— Әлегә күздән югалып, китеп торыгыз диде.

— Син минем белән киңәшкәнче үк барысын да уйлап куйгансың,— диде ярым үпкәләп Йосыф.

— Менә тагын, киңәшәбез ич!

— Әле бу киңәшүмени?

— Шулай булмыйча. Йә, ни дисең?

— Әтиләр белән сөйләшергә кирәк, Мәүлия.

— Минем дә әни белән сөйләшәсем бар. Иң әүвәл аны әзерләргә кирәк әле. Берүзе кала бит! Кара кайгыда! Кайчан гына ирен җирләде.— Нигәдер бу юлы Мәүлия Ырсытдинне «әти» дип атамады.— Хәзер Ташкәй... Инде мин дә ташлап китсәм...

— Ә минекеләр? Ә безнекеләр?

— Менә син кайтып та җиттең...

— Хәзер мин сине озатам.

— Юк, юк, кирәкми, Йосыф!

— Ялгызыңны җибәрәмме соң?.. Үзең мине саклыкка чакырасың, үзең дуамалланып ярты төн узгач ялгыз йөрмәкче буласың...

— Озат алайса...

Тагын, тагын Йосыф Мәүлияне озата бара да, аннан кыз аны озата китә, ниһаять, юлның кыл уртасында хушлаштылар. Йосыф кызны капкага кадәр күз белән озатып басып торды.

## 45

Шамил ат туктаганны да көтмәде, арбадан сикереп төшеп калды, төште дә икеләнеп тукталды: кая барырга? Башта өйгә кайтыргамы? Әллә туп-туры Шәмсеруй апаларга керергәме? Әйе, әүвәл сөенечне җиткерергә кирәк. Шәмсеруй апа өзелеп-өзелеп кызыннан хәбәр көтәдер!

Шәмсеруй апа, тол хатын, сугыш башлануын әле ул ишетмәгән дә иде. Шамил сынап карап торды: беләме, юкмы? Шәмсеруй апа «Сәр-

вәр арулана!»— дигәч, элекке кебек сыктап-җылап җибәрмәде, җиңеләеп, калкынып китте.

— Арулана дисеңме, балам?— дип кат-кат сорады.

— Минем белән бик әйбәт сөйләште, ашады.

— Шәңгеләрне әнкәң пешергән дип әйттеңме?

— Кат-кат әйттем.

— Яратып ашадымы? Суынып та беткәннәрдер инде алар. И ходаем, бүтән чакта ныгытып, ашъяулыкларга төреп җибәрермен инде. Тамагына каба башлагач, терелү юлына төшкән дигән сүз. И балам, күңелемнән авыр йөкне төшердең, төне буе нишләргә белмичә бәргәләнеп чыктым. Мин гаепле бит монда, үзем! Үз куллары белән баласын тәмугка илтеп тыккан ананы кем кичерсен дә, кем гафу итсен...

Сөйли Шәмсеруй апа, ә Шамил һаман көтеп тора: беләме сугыш башланганын, Шамилнең хәзер үк чыгып китәргә тиешлеген аңлыймы?

Шунда аның башына бер уй килде: нигә ичмасам бер көнгә генә булса да калдырып торуларын үтенмәгән? Әти-әнисе белән юньләп сөйләшмәгән, Шәмсеруй апаны юатмаган, бүген Үлмәсне җирли торган көн, зират юлыннан качып китсәң, авылдашлар ни уйлар? Ахыр чиктә ул яңадан Сәрвәре белән бер тапкыр да күрешеп-сөйләшә алмасмыни?.. Шулай бүгенге ашып-пошык аңлашу белән дә китеп барырмы? Кайчан кайтыр әле ул? Сәрвәрне юатып: «Без бик тиз әйләнеп кайтырбыз!»— дисә дә дөнья хәлләреннән хәбәрдар лейтенант Шамил Уразаев немец фашизмының нинди зур көч икәнен чамалый, Европаны таптап кына узган сугыш тәгәрмәчен ансат кына туктатып булмаслыгын юл буе уйлап кайтты түгелме? Әле кайта аласыңмы, сугыш корбансыз булмый, кем кала да, кем кайта, әле авылда кара кайгыга тарыган Мәүлия сеңлесе бар, яшьләгенең тугры дусты, кан кардәше, ул бар ич әле! Алар да дүрт күз белән аннан хәбәр көтәләрдер! «Тизлек белән килеп җит!»— дигәч, тыңлаучан Шамил Уразаев чыкты да очты...

Мәүлияләрне юатмыйча китәргә ярамый. Ярамый! Йосыфны да сугышка алалар, Маннур да китәргә тиеш... Уйлый башласаң, әле мондагы эшләр, мәшәкатьләр чамасыз күп җыела икән.

— Шәмсеруй апа, нишләп сугыш турында бер сүз дә әйтмисең?

Кинәт куелган бу сорау үз хәсрәте үзенә җиткән апаны сискәндереп җибәрде.

— Нинди сугыш турында әйтәсең, Шамил ускәнем? Әллә теге Чырык мәлгунь бер-бер яманлык кылганмы? Булыр ул эт җаннан!

— Юк, Шәмсеруй апа, герман фашистлары безнең җиргә бәреп кергәннәр. Ил чигендә бөтен фронтта каты сугышлар бара.

Һаман аңлашып ала алмады башы тинтерәгән хатын, тагын кулын селтәп җибәрде.

— Сугышырлар да, тынарлар да, барысы да булыр,— диде.

— Юк, миңа да сугышка чыгып китәргә кирәк.

— Бәй, ничек? Синең бүтән эшең беткәнмени?

— Авылның бөтен ир-атларын чакыралар, Шәмсеруй апа... Ярый, әле мин өйгә дә кереп тормадым, тагын кагылырмын. Китәсе икән, әзерләнергә кирәк.

Бусы Шәмсеруй апаның башына бөтенләй сыймый иде: ничек алай? Ә Сәрвәр? Терелеп килә торган бала кемгә кала? Аны кем карый? Кем саулыгын кайгырта? Әгәр Шамил дә китсә, аны кем яр итәр? Исеме таралган, яманаты чыккан кыз кемгә кирәк?.. Әле Шәмсеруй: «Менә Сәрвәр терелер... Бәлки, Шамил аннан баш тартмас, өйләнешерләр... Яши башлагач үткән кара эшләр онытылыр»,— дип юанып, алданырга тырышып йөри иде. Муены астына килгере герман, каян, шундый җайсыз вакытта башлаган диген сугышын!..

Димәк, хәзер үк, бүген үк Шамилне озатырга кирәк?

Шәмсеруй апа ашыгып-кабаланып камыр куярга кереште.

Мөхәммәт Уразаев бик кыенсынып кына иске танышы Даниловка шалтыратты:

— Үзем өчен сорамыйм, улымның китүен бер генә көнгә кичектерергә ярдәм итсәгез лә! Безнең авылдагы хәлләрне ишеткәнсездер, әйе, мәет тә бар... Юк, кардәшебез түгел, алай да улым белән бергә укыган егет вафат, үлеме дә шундыйрак инде, дүшәмбе көнне таң белән килеп житәр,— дип үтенде.

Данилов ярты сәгатьтән соң шалтыратырга кушты.

— Шамил Уразаев 23 ендә, иртәнге сигезгә военкоматка килеп житәргә тиеш,— диде ул. Уразаев трубкасын куймыйча чак кына уйланып торды.

— Нәрсә, риза түгелме әллә?— дип сорады Данилов.

— Юк, анысы өчен рәхмәт. Тагын бер четерекле мәсьәлә бар иде.

— Нәрсә тагын?— Даниловның тавышы кырысланды.— Мин аны сугышка китүдән алып кала алмыйм.

— Дөрес аңламадыгыз, иптәш Данилов. Шамил әгәр чакырмасалар, үзе теләп китә торган егет.

— Эш нәрсәдә соң?

— Анда төрмәдә Таштимер Йортлыбаев утыра...

— Беләм. Кәгазьләрен күрдем.

— Китүче егетләр аның янына саубуллашырга керсәләр ничегрәк булыр икән? Килешерме?

— Кеше үтерүчене кызганып керсеннәрме?

— Анысы дөрес, ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар бит әле...

— Ярар, карарбыз. Сез дә тагын бер кат уйлый торыгыз: кирәкме бусы әллә юкмы?!

Бу көтелмәгән үтенече Мөхәммәт Уразаев башына телефон трубкасына тотынгач кына килде. «Мәсьәләнең икенче ягы» дигәндә, ул әлеге дә баягы, Ташкәйнең үтә дә нык җаны кыйналуын, ялгыш адымнан аны берәүнең дә алып кала алмавын күз алдында тоткан иде. Данилов, табигый, ашыга иде, төпченеп тормады...

Шамилнең бер көнгә калып торуына аерата Фаягөл шатланды, ул абыйсының жилкәсенә атланып йөрде, «Болынга барыйк, тагын аюны күрик!»— дип аптыратып бетерде.

Районнан врач килеп, алар Сания белән бергәләп, Үлмәснең тын юлына су керүдән вафатын билгеләделәр һәм күмәргә рөхсәт бирделәр...

* * *

Кызлар Убасында бүген халык шактый. Егетләр, кызлар гына түгел, яңарак өйләнешкән ирләр, киленчәкләр дә шунда. Моңарчы кавышу, табышу, сөешү урыны булган изге тау бүген аерылышу, таралышу, сагыш урыны.

Төн. Күктә төн яме — ай. Айда Зөһрә кыз...

Төн. Төн гүзәле Кызлар Убасы. Карт кедрдан еракта түгел учак яна. Учак тирәсенә ярымалка булып баскан егетләрнең дә, кызларның да йөрәге яна. Бүген уеннар юк, әле аерым-аерым сөйләшеп йөрүләр дә, кыз куулар да юк, бүген һәммәсенең дә уйлары уртак, язмышлары бер. Аерылышалар. Егетләр китә, кызлар кала. Учак утына карап басканнар, ялкын шәүләләре егетләрнең күзендә уйный, кызлар күзендәге сагышны ап-ачык күрсәтә, ялкын шәүләсе кызларның толымнарын, алъяпкычларын, битләрен алга манган... Бүген монда аерылышу җырлары хуҗа. Егетләр башлап җибәрәләр дә кызлар җырны күтәреп ала, элек җырланган, күнегелгән җырларга яңа юллар өстәлә, яңа юлларны берәү дә бутап тормый, һәркем җырның мәгънә сөрелешен аңлап алып, җиңел генә кушылып китә. Җырлар үзгә, тавышлар бүтән, мөнәсәбәтләр яңача, аерылышалар. Озаккамы? Күпкәме? «Әллә гомерлеккәме?»

Яу кырына киткән чакта
Үттек Төмән каласын.
Әткәй, әнкәй, онытмагыз —
Кош та онытмый баласын.

Әле Төмән каласын үткәч күңелгә нинди җырлар иңмәс?

Без иләрдән киткән чакта
Юлга чәчәк җәйгәннәр!
Исән булсак бер кайтырбыз —
Сез көтегез, сөйгәннәр!

Моңарчы нигәдер тын торган гармун иплән кенә сыкрап ала, иңрәп куя, кыяр-кыймас кына җыр тавышына ияреп китә, җыр белән гармун кушылгач, йөрәкне сызып өзә торган бер моң туа. Бу моң тау битеннән төшеп йоклый алмый интеккән Ялан урамнарына, тыкрыкларга, Иртеш буйларына төшеп җитә. Төн булса да Иртеш буенда казлар каңгылдаша...

Аллар буласым калган,
Гөлләр буласым калган.
Былбыллар аерылмый диләр —
Былбыл буласым калган.

Тау өстеннән караганда авыл әллә кайчан йоклаган төсле... Юк, йокламый авыл, ул үзенең улларын озатырга әзерләнә. Кызлар Убасындагы уен тиз таралды, яшьләр җырлап-җырлап тордылар да икешәрләп-өчәрләп йортларга таралыштылар. Урамга кергәч җырламадылар, аларның тәшвишле аяк тавышлары гына шактый вакыт ишетелеп торды. Һәр йорт таңны үзенчә каршылады. Олылар үгет-нәсихәт иттеләр, Гражданнар сугышында катнашканнар яшь чакларын сагынып искә алып, үзләре катнашкан сугыш эпизодларын сөйләп утырдылар. Һәр йортта диярлек юлга чыгучылар хөрмәтенә йомычка таскак кертеп матчаларга кыстырдылар. Китүчеләр исән-сау әйләнеп кайтсалар, кузайтын чәен кайнатыр өчен шул йомычка белән ут тергезергә тиешләр... Өстәлләрдә китүчеләр тешләгән ризыкларны калдыралар. «Ризыгың бетмәсен, сау әйләнеп кайт!» — дип теләк теләделәр. Берәүләр мендәр өстенә ап-ак сөлге салып китүчеләрнең җылысын алып, сөлгене төреп куйдылар. «Җылың калсын!» Кайткач, шул сөлге белән ул бит-кулларын сөртәчәк...

Язмыш юллары кырт киселде, өметләр өзелде, матур итеп корылган планнар сүтелде...

Сәлимә төнен гел елап уздырды. Маннурның беләгенә ята-ята елады, әрем кебек ачы иде аның күз яше... Хатынының ярсуын туктатырлык көч, юатырлык сүз юклыгын белеп, аны күкрәгенә кысып, йомшак чәчләреннән сыйпап телсез каткан хәлдә утыра бирә Маннур. Аерылу алдыннан Сәлимәгә бик мөһим нәрсә әйтеп калдырасы бар иде кебек, ләкин аның башына хәзергә бер юньле фикер дә килми. Рәукыя апа бер чыга, бер керә. Бер кергәндә кулында йолкынмаган, канлы муенлы этәч булса, икенчесендә кар базыннан алган каймаклы сөт, әллә ничә мәртәбә казан асып, әллә ниләр пешереп бетерсә дә, ул һаман канәгать түгел, талкынган җанын эш белән тынычландырырга тели.

Алар бу якта ут кабызмаганнар, ашамаганнар, эчмәгәннәр. Бер мәл Сәлимә еракран килгән аваз тыңлагандай тынып калды, иренә сыланган көйдә назлап сүз башлады.

— Без сине икәүләп көтеп калабыз, әтисе. Бакчи, улың аваз бирә, ул да тынычсызлана,— дип Маннурның кулын эченә таба тартты, шул чагында әтисенең учына карындагы бала «тырт-тырт» итеп тибеп алды.— Безнең бәхеткә дошманны җиңеп исән-сау әйләнеп кайт, әтисе.

— Сугыш озакка бармас, Гитлерның чучка танавын үз җирендә җимереп кайтырбыз! — диде Маннур гайрәтләнеп.

Тыштан ишек шакыдылар, Шамил килгән икән. Аның маңгаена вак-

вак җыерчыклар кунган, йокысызлыктан күзе кызарган. Матур таза сыны авыр капчык йөкләгәндәй сыгылып төшкән.

— Нихәлләрегез бар?— дип сорады ул ишек катыннан гына.

— Уз, Шамил, уз!— диде ашыгып Сәлимә.

— Утырабыз менә!— диде Маннур.

— Сәлимә! Синең янына килдем. Зинһар, булдыра алган кадәр Сәрвәрнең хәлен белешеп тор инде. Бүген хәбәр килде, Сания әнине дә чакырдылар. Безнең белән бергә ул да китә!

— Әллә сугышка ук алалармы?— диде соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп Рәукыя апа. Ул ишегалдыннан кергән дә тыңлап тора икән.

— Алалар шул. Врачларны да алалар.

— Әле өлкәннәргә дә чират җитәр, ходай күрсәтмәсен,— дип Рәукыя апа кече якка кереп китте һәм йон туздырып әтәчен йолкырга тотынды.— Бусын, боерган булса, пешереп юлга тыгармын...

— Сания әни өйдә булса, больницадан кайткач, Сәрвәрне үзе аякка бастырган булыр иде, хәзер бөтен өмет синдә. Шәмсеруй апаның бер дә егәре юк. Үзем менә китеп барам.

— Кулдан килгәннең барын да эшләргә тырышырмын, Шамил, тыныч күңел белән кит!

Шамил авыз чите белән генә елмайды:

— Кая инде ул тыныч күңел белән китү! Бер якта эти ялгызы кала, кулында нәни кыз... Мөхлисә әбинең дә сәламәтлеге какшау. Мәүлия кала! Ташкәйгә ни булыр? Кеше үтергәнгә катылык диләр бит хәзер. Үзебез монда булсак, Үлмәснең этлеген судьяларга аңлата белер идек әле...

— Минем карчык булдырыр,— диде Маннур мактанып.— Өлгер ул! Сәрвәрне дә карар, Шәмсеруй апаны да онытмас, Мөхәммәт аганы күздән ычкындырмас...

— Мин иртәрәк кузгалам, Сәрвәр янына керәсем бар!— дип, Шамил саубуллашып чыгып китте. Сәлимә белән Рәукыя апа аны күз яше түгеп озатып калдылар. Маннур түзде, җыламады, уен-көлке әйткәләп, хәлне йомшартырга тырышып карады.

— Ничек дип җырлыйлар әле?— диде Сәлимә Шамилне озаткач.— «Былбыллар аерылмый диләр, былбыл буласым калган!»— диләрме?

— Ил өстенә дошман ябырылганда ир егетләр шомырт куагының ышыгында былбыл булып сайрап кына утыра алмый шул! Юк шул, Сәлимәкәй, алар яуга чыгарга тиеш...

Шушы урынга җиткәч әллә ни булды, Маннурның да күңеле тулды, моңарчы чыдап-чыдап килгән ир хатынын кочып елап җибәрде. Кала, Сәлимә кала! Яланда яшь түгеп Сәлимәләр кала. Быел кавышабыз дигән хыял белән яшәгән Шамилнең өмете өзелеп кала. Яшь күңелләрне һәрчак җилкеткән Кызлар Убасы, Иртеш буйлары, Кобланды батыр болыннары кала. Сау булыгыз, гармун моңнары өзелмәгән Иртеш буйлары! Сау булыгыз, гасырга ямь һәм туклык биреп килгән күксел кедр урманнары! Сау булыгыз, безне онытмагыз, туганнар, сөйгән ярлар...

Рәукыя апа тагын бер әтәчне суеп өлгергән, йолкый, йоннарын очырып йолкый:

— Бусын Йосыфка багышладым, алар фәкыйрьләр, шуңа бирермен.

Йосыфлар йортында үле тынлык. Алар да ут кабызмаган. Йосыф Кызлар Убасыннан Мәүлияне озатып кайтып керүгә Актырнагы сикергәләп өрә башлады.

— Сагындыңмы?— дип аның муенын сыйпады егет һәм тиз-тиз өйгә керде. Аның кайтуын көтеп торган Гыйззәтбану түти ут яндырды, лампаны өстәл кырына китереп куйды. Өстәлдә ризык әзерләнгән, самавыр кайнап утыра.

— Көне буе тамагыңа да ашамадың, улым...

— Ашыйсы килми, әни. Әти, мин таңнан зиратка барып килергә уйлыйм, әнкәй белән дә, бабай белән дә хушлашырга кирәк булыр.

— Бар, улым, бар!

— Таудан чәчәкләр дә җыеп төштем...

— Рәхмәт, улым, рәхмәт.

Табын янына утырыштылар, теләр-теләмәс кенә ризык капкалады-лар, аш үтмәде, капканы да тамак төбен тырнап авыр гына узды.

— Ни сөйлиләр соң, улым?— диде сәкегә салган зур мендәргә ярым ятып Сәгъдетдин.— Бу сугыш дигәннәре озакка барырмы икән?

— Кем белсен әле, әти. Сугыш уен түгел, шуны гына беләбез.

— Киткән кеше йөри инде шунда, калган кешегә читен,— диде Гыйззәтбану түти, иренә карап.

— Киткән кешегә дә бик кыен... Әмма, улым, әле шул юанычыбыз бар, син ил сакларга китәсең! Киту читен булса да, ил сакларга баруы хурлык түгел, зур мәртәбә. Исән-аман йөрергә язсын. Инде җиңеп, исән-сау кайтырга да насыйп булса, бөтенебез өчен дә уртак бәхет булыр... Бер үкенеч калды, өйләнә алмадың. Өйләнеп безгә бер малай да калдырган булсаң...

Сәгъдетдин мышык-мышык җылап җибәрде һәм үзе дә сизмәстән улының иң авырткан җиренә кагылды.

Әти-әнисе өчен борчылмады Йосыф, нигә ул кадәр көяргә, ил өстенә килгән уртак бәла, алар икесе бергә, бер-берсен хөрмәт итәләр, кадерлиләр, әле кулларыннан эш килә, йорт торгыза алмасалар да үз көннәрен үзләре күрерлек, тереклек итәрлек җай бар, авыл белән, киңәштабышка читкә чабасы түгел, дуслары Мөхәммәт Уразаев бар. Аның кызы Мәүлия бар...

Нигә моңарчы, язын ук, яки Мәүлия тәкъдим иткәнчә Яңа елда ук өйләнешмәделәр икән алар? Әйтте бит Мәүлия: «Әйдә, студент туе итеп, гади генә туй да ясарбыз, авылга өйләнеп кайтыйк!»— диде. «Юк,— диде шунда Йосыф килешенмичә,— әти-әнидән башка туй үткәрүне күз алдыма да китермим, яңа тормышыбызны ата-анадан ямьсез сүз ишетеп башламыйк!»— диде. Мәүлия шунда аның муеныннан кочып алды: «Акыллым син минем! Рәхмәт!»

Акыллысын акыллы, хәзер Мәүлия монда кала. Әгәр авылда гына кала торган булса, Йосыфның артык исе дә китмәс иде, бер ул гынамыни, сөйгән ярларыннан бик күпләр аерыла. Мәүлия авылдан китәчәк бит! Яланда булса, агай-эне күз алдында, нәсел-нәсәбе бар, йортында карчыгадай көчле Йомабикә апа бар... Ә читтә? Әле ул чит кайда булыр? Анда кемнәр булмас? Бөтен ирләрне дә армиягә алып бетермиләр ич! Көтәрме аның Мәүлиясе?! Көтәргә ирек бирерләрме? Берәр үткене кызны атып алса? Бигрәк чибәр шул аның багалмасы, үткән бер ир аңа борылып-борылып карый, кинога-мазарга барып, Йосыф билетка чиратка басса, шундук кызны урап алалар, сүз катарга ашыгалар, ачыктан-ачык тәкъдимнәр дә ясыйлар. Ләкин Йосыф моңарчы бер чакта да көнләшмәде, көнләшү дигән уй аның башына да кереп карамады, ул Мәүлиясенә үзенә ышанган кебек ышанды. Намусы саф, уйлары керсез, омтылышы чиста булгач, шуларның барысын да Мәүлиясе белеп яшәгәч, нигә, ни дип, кемнән көнләшсен?.. Очраклы дәшкән егетләрдән Йосыфның бер өстенлеге бар — саф, сыналган мәхәббәте.

Инде багалмасы пешеп-өлгереп җитте, инде өзәргә бик вакыт дип эчтән куанып, тыштан янып карап торганда гына сине алып китсеннәр әле. Ә алма агачында кала, алма матур, алма кызыл, алма пешкән... Бүтәннәр дә аны күрмәсмени? Бүтәннәрнең күзе сукырмы әллә? Күрерләр, кызыгырлар... Өзәргә тырышырлар... Һәр җимеш үз вакыты белән, алманы гына түгел, бәрәңгене дә көне җиткәч алалар...

Тыштан Йосыф бүген элеккеге егет иде. Елмайган чагы да булды, ара-тирә көлеп тә куйды, пошынды да, кайгырды да, бүтәннәрнең кайгысын да чын күңеленнән уртаклашты, әмма аның эчендә моңарчы барлыгы да беленмәгән көнчелек уты иде...

Көтәрме Мәүлиясе, юкмы?

Кая барып, кемнәр арасына юлыгыр?

Һәм егет, әтисе сүзеннән соң сикереп торды да, тиз-тиз аягын киенде.

— Тагын кая барасың?— диделәр ата белән ана бер авыздан.

— Барасы җир калган,— диде Йосыф ишек тоткасына ябышып.

— Улым, улым,— дип өзгәләнде Гыйззәтбану түти.— Олы юлга чыгасың бар, ял итәр идең, арган килеш юл газаплы булыр.

— Мин хәзер кайтам!

Йосыф бу юлы Актырнагын да ияртмәде, «Урыныңда ят!»— дип тамак төбе белән бер генә эндәште дә урам буйлап йөгереп китте.

Таң атып килә. Иртеш өстеннән рәхәт, салкынча җил исә, шул җил аның йокысын ачып җибәрде, тәненә көч-егәр бирде.

Мәүлияләр йортында җан иясе барлыгы сизелми, ул иплэп кенә тәрәзәгә чиртте, бер чиртте, ике, тәрәзә озак көттермәде, ачылып китте. Йосыфны күреп Мәүлия күлмәгенең якасы белән ак муенын каплады.

— Чык әле монда, Мәүлия!— диде Йосыф шактый тавышланып.

— Ни булды?

— Чык.

— Хәзер чыгам.

Йокыдан уянып өлгергән Йомабикә абыстай куркып кына сорап куйды:

— Кем килгән анда? Кем йөри?

— Йосыф. Йокла, әни. Мин хәзер керәм.

Йокы күлмәгенең өстенә плащын салып Мәүлия урам якка ук чыкты. Егетнең күзләренә тулган ят ут аны сискәндереп җибәрде.

— Абау, карамачы шулай итеп?

— Ничек итеп?

— Куркытып!

— Мәүлия! Кеше арасында сөйләшеп булмас, әйт әле: син мине көтәрсеңме?

— Исән йөреп, сау кайт. Шунда үзең күрерсең.

— Юк, син әйт!

— Нигә мондый шикле уйлар килде әле синең башыңа? Әллә бер сүз ишеттеңме тагын?

— Юк, мин бу хакта күне буе уйлап йөрдем, әйтергә базмаган идем, әлерәк кенә, безнең тиздән аерылышуыбызны, минем тиз генә сине күрә алмавымны төбе-тамыры белән аңладым! Мәүлия! Син кыз кеше, сылу кыз, укыган, матур, акыллы.

— Җүләрем син минем, Йосыф!

Тәрәзә пыяласы шакылдап куйды, бу Йомабикә абыстай, пошынып, пәрдә күтәреп, тикшереп маташа икән.

Йосыф пәрдә төшкәнне генә көтеп торды да Мәүлиясен кулларына күтәреп алды.

— Кая алып барасың мине?

— Изге урынга!

— Мәчеткәме?— дип тыелып кына көлде кыз.

— Юк, мәктәпкә! Эссәт әкә Фәтхуллин хатирәсенә үзебез утырткан яшь кедрлар сагында бу сүзләреңне әйтерсең. Алар да шаһит булсыннар! Тик бер шартым бар: син инде хәзер Ялан мәктәбеннән китмисең!

— Мин монда кала аламмы?

— Син фашизмга каршы сугышка киткән Йосыф Сакинның кәләше булып каласың. Ишетәсеңме, вәгъдәләшкән кәләше. Бу турыда бөтен авыл белә! Әгәр берәрсе шуны онытып сиңа кыек сүз әйтсә, әгәр берәрсе сине хаксызга кимсетергә уйласа, мин ул кешене җиде җир тишегеннән дә эзләп табачакмын. Монысына да ышан, Мәүлия!

Йосыф кызны мәктәпкә җиткәнче кулыннан төшермәде. Мәүлия ике кулы белән аның көчле, тыгыз муенын кысып алды, бер үпте, ике, өчен-

чесендә егетнең иреннәреннән аерыла алмады. Алар шул хәлдә мәктәп ишегалдына барып керделәр. Җиргә баскач, Мәүлия плащ итәге белән тезләрен каплады:

— Мине берәрсе бу хәлдә күрсә! Укытучы Мәүлияне!

— Күрмәсләр, мин күргән дә җиткән,— диде Йосыф олыларча.

Алар Эссәт әкә истәлегенә утыртылган, кыю гына үсеп, калкынып килгән кедрлар арасына барып та җиттеләр. Кинәт, сискәндереп ишек шыгырдады, ишектән мәктәп директоры Мөхәммәт Уразаев килеп чыкты. Ул ялгызы иде, башы түбән иелгән, җилкәсе бөкрәя төшкән, йокыдан уяткан авыр уйлар йөген чак күтәреп мәктәптән, үз мәктәбеннән чыгып килә иде...

* * *

Уразаевның йокысы кыска булды, ятты да, уянды да. Хәзер озаклямый Шамил чыгып китәргә тиеш, аның артыннан ук бераз соңрак Сания да юлга чыга. «Врачлар җитешми, комиссия әгъзасы буларак чакырыласыз, алай да үзегез дә әзерләнә башлагыз!»— дигән өстәмә телефонограмманы соң гына, алар ятыр алдыннан гына китерделәр...

Сания дә бик соң ятты, ул йоклый әле, йокыга киткән. Мөхәммәт аны уятмаска тырышып, иплэп кенә баса-баса башта ишегалдына чыкты, аннары урамга ук атлады.

Таң аткан...

Таң...

Яше олыгайган саен ул таңнарны аерым бер куаныч, сөенеч белән каршылый. Ходай белән алыш-биреше булмаса да, балачактан өйрәнелгән гадәт буенча: «Шөкер!— дип куя.— Бу таңны да исән-аман күрдек!»

Таңнар... Иртеш таңнары... Елның дүрт фасылында да ул, таң атар да бәхетле көн китерер, дип ышанып яшәде. Алда бары тик бәхет-шатлык кына көтте. Һәр туачак көн ил өчен дә, үзе өчен дә, туган ягы өчен дә бәхетле булачак, дип ышанды. Илнең ныгыганын, яңа калалар төзелүен, юллар салынуын, көнкүрешнең яхшыруын ул күзеннән читтә калдырмады, укучыларын да шуңа гадәтләндерергә тырышты, аның мәктәбен тәмамлап чыккан укучылар алдагы буыннардан әйбәтрәк, матуррак, яхшырак булыр, дип бөтен барлыгы белән ышанды. Ул үзендә булган бар яхшы сыйфатларны балаларга бирергә омтылды, җаны ачык, күңеле һәркемгә киң иде...

Бәлки, ул ялгышкандыр? Бәлки, аның ышанычы балаларчарак булгандыр? Мәсәлән, аның авыл егетләрен, кызларын җыеп Күчем хан хәзинәсен эзләргә чыгып китүен «хата», «балалык», «сукырлык!» дип бәяләмәделәрмени? РОНО буенча аңа каты шелтә чәпәгәннәрен Дәүләтша әкә белә дә, Сания белә... Бүтәннәргә моны кайтып әйтергә оялды ул... Һәм үз яшәеше турында беренче тапкыр шикләнеп уйлады. Дөрес яшиме ул, дөрес укытамы?

Төнге йокысызлыктан уятып алып чыгып киткән аяклары аны шул ук күнегелгән урынга — мәктәпкә алып килделәр.

Ишегалды буш. Малайлар мәж килеп атына торган турник та буш, куш боҗралар җансыз асылынып тора. Кызлар чыр-чу килеп «сызыклы» уйный торган почмак та буш... Беркем юк, бер җан иясе. Ул үзенең йөрәге какканын ишетеп, тынлыкны бозарга курыккан сыман, аяк очларына баса-баса класска керде. Истәлекле класс... Беренче буын укучыларын ул шушында ничә еллар укытты! Үзе шушыннан аларны ШКМга илтте, интернатка урнаштырды.

Буш класс...

Әмма өлкән укытучы Уразаевның күңеле буш түгел, ул хәзер тоташ истәлекләрдән тора.

Әнә тегендә, арткы партада Ташкәй белән Үлмәс утыралар иде... Алардан алда Йосыф... Монда Мәүлия... Мондарак Шамил... Маннур, Сәлимә...

Бер авыл балалары. Ата-бабалары туганлашып беткән. Бер-берсен әллә кайчаннан беләләр, йөрешәләр. Бөтен гомерләре бер-берсенең күз алдында. Балалар ничә айлар Мөхәмматнең тигез тавышын тыңлап яшәделәр, ул ни белсә, барысын да аларга бүлеп бирде. Һәммәсен тигез яратты. Шамилне үз улы дип аерып куймады, Мәүлия аның җан җимеше булса да аны аерып куймады, һәркемгә тигез булырга тырышты. Һәр-берсенә! Өйләрендә хәсрәт булса — бүлеште, авырсалар — йортларына барып йөрде, артта калсалар булышты, бер чакта да вакыт белән исәпләшеп тормады, язгы карлы-бозлы яңгырларда шәһәрдән бәләкәй чанашкә белән китап тартып кайткан чаклары булды.

Һәр таңны зур өмет, җылы хисләр белән каршылады. Балалары белән уртак таңнарны, өмет таңнарын...

Хәзер йомгак ясарга була, ярый, рөхсәт. Хезмәтенең җимешләре күз алдында. Агачта кортлы алмалар булган кебек, аның җимешләре дә төрлечә булды. Ул монысын көтмәгән иде. Ялгыштымы? Дөньяны балаларча кабул итеп гел яхшыга гына өметләндеме?

Кичә шул агым укучыларыннан беренчесен җир куенына тапшырдылар... Берсен, беренчесен. Җир юмарт. Үлмәсне ыңгырашмыйча гына кабул итеп алды... Сыйдырды. Бер кабул иткәч, шәт, куып та торгызмас... Икенчесен моннан көнярым элек Тоболдагы таш төрмәгә илтеп тыктылар. Кеше үтерүче дигән кара тамга салып... Уразаевның икенче укучысы...

Өченчесе чак үлемнән калып, адәм балаларының кыргыйлыгы аркасында акылына зәгыйфьлек килеп больницада ята. Ул да аның якыны, йөрәк янында йөрткән Сәрвәре, вакытсыз дөнья куйган көрәшче Эссәт Фәтхуллин кызы!.. Дүртенчесе, Мәүлиясе! Әллә ул беренчесеме?.. «Кызым!»— дип бер мәртәбә дә аркасыннан кагарга база алмыйча үткән гомер... Үткән көннәр...

Берсе гүрдә, берсе төрмәдә, берсе больницада...

Ә менә күпчелек сау-сәламәт, укып, белем алып кайттылар. Арадан иң асыллары дошман явына каршы чыгалар... «Сугыш, сугыш куркынычы»,— дип сөйләсәләр дә, ул ничектер аны еракта, килеп җитмәс кебек еракта дип уйлый иде. Монда да ялгышынган. Дөньяны беркатлырак кабул иткән, ышанган, гел яхшыга юраган... Яхшыга гына юрап яшәргә ярамый икән! Һәр аткан таң артыннан көләч, кояшлы көн килми! Юк! Таңнарны давыллар сагалап тора, кар-яңгырлар көтеп ала, таң артыннан ишелеп-ишелеп кайгы-хәсрәт тә килә икән!

Моннан ары ул ничек яшәр? Балаларга, укучыларына ничек дип эндәшер? Үзен газаплаган уйлардан арына алырмы? Белгән юк!

Мөхәммәт Уразаев авыр адымнар белән мәктәп ишегалдыннан чыгып китте, Мәүлия белән Йосыф аны күз белән озатып калдылар. Мәүлия шул чагында: «Мин аңа барыбер «әти!» дип эндәшәм... Барыбер аңлашам мин аның белән!»— дип уйлады һәм Йосыфка борылып:

— Йосыф, мин авылдан китмим, монда калам,— диде.

Егет дәшмәде, аны кочып алды, алар шулай кочаклашкан килеш Мәүлияләргә кайттылар. Сүзләр кирәкми, сүзләр артык, аңлашу булган, шул аңлашу егеткә бик җиткән иде...

Бүтән авылларда ничек булгандыр, Ялан авылыннан олаулар төрле вакытта кузгалды. Иң әүвәл Шамил, тагын ике ир китеп бардылар. Алардан соң күп тә үтмәде Мөхәммәт Санияне арба түренә утыртып алып чыгып китте. Тирә-күрше, Мөхлисә әби, йокысыннан чак күзен ачкан Фаягөл җылый-җылый аны озатып калдылар. Аннан олылар, яшьләр, шаулаша-гөрләшә кузгалды...

Тоболга барып җиткәч тә Йосыф, Маннур, тагын берничә егет больницага кагылдылар, Сәрвәр белән саубуллашып чыктылар. Сәрвәр янында утырган Шамилне дә үзләренә иярттеләр. Сәрвәр аларны коридорга кадәр озата чыкты, җыламады, ишек янагына сөялеп, хәле китеп, шактый озак басып торды.

Ташкәй янына егетләрне кертмәделәр. «Суд булганчы аның белән күрешергә рөхсәт юк!»— диде кырыс төрмә сакчысы. Егетнең: «Мине дә сугышка җибәрегез! Сугышка!»— дип тимер ишекне төя-төя илереп кычкырганын Ялан авылы яшьләре белмичә китеп бардылар. Моны соңыннан, бераз вакытлар үткәч, Уразаевка Данилов сөйләде...

Киттеләр. Шәһәргә төрле яктан боргаланып килгән юл тузаннары басылды. Авыллар тынып калды. Дөньяның авырлыгы хәсрәт, кайгы булып йөрәкләргә генә сарылды...

* * *

Урман-кыр юллары тынгач, аулак урман сукмагыннан як-ягына карана-карана бер кеше бара иде. Ашыкмый, бара-бара да, туктап тыңланып тора, күз өстен кашып карый, тагын кузгала. Юл иң тарайган бер урында, агач куелыгында ул нидер көткән кебек озаграк торды, колагын төрле якка куеп нидер тыңлады.

Җиңел генә киенгән, алган әйберләрен үзе белгән аулакка яшереп өлгергән бу кеше — Чырык Абдрахман иде.

Дәү кәүсәле кедр артыннан боерулы тавыш яңгырады:

— Әй, кеше! Тукта!

— Туктадым,— диде Чырык исе китмичә генә.

— Мондарак кил. Кая барасың? Каян киләсең?

Монда җавап бирергә кирәклеген Чырык бик яхшы аңлый иде.

— Авылдан мин, Ялан авылыннан. Урманга качтым.

— Сугышка барудан качтыңмы?— Озын, ябык кеше аның каршысына чыгып басты.

— Нинди сугыштан?!— Чырыкның күзе шар булды.

— Германия белән сугыш башланды.

— Белмәгән идем.

Алар бер-берсенә якынрак килделәр, ят этләр сыман иснәшеп тордылар, ниһаять, колгасар елмайды.

— Ялгызлык туйдырган иде, әйдә, иптәш булырсың,— диде.

Колгасар кеше әлеге дә баягы Рәхмәтулла белән Күчем хан хәзинәсен эзләп чыккан элеккеге ак офицер Михаил Сорокин иде.

— Әйдә,— дип ризалашты Чырык.

— Хәзер бәлки иптәшләр артыр!— дип канәгатьлек белән көлеп куйды Сорокин.— Без аларны каршыларга әзерләнә торыйк.

Алар бер-бер артлы, шыпырт кына сөйләшә-сөйләшә агач арасына кереп югалдылар. Чыгып килгән кояш нурларында, ботак арасында, ялтырап-ялтырап, ук шикелле атылып тиен уйнады.

*Беренче китап тәмам.*

## ПОЭЗИЯ

# Клара Булатова

## Югалтмаска!

«Яңа!
Яңа!
Яңа!» дип янабыз.
Гел яңага таба барабыз.
Ә үткәндә бар да искергәнме?
Ни калдырган ата-бабабыз?
Искергәнме туган туфрагыбыз,
Мәңге яшәр-агар елгалар?
Кан кардәшләр,
тамыр дусларыбыз,
Җырлар,
туйлар,
гадәт-йолалар?
Мине, зинһар, ялгыш аңламагыз.
Яңалыкка каршы чыга, дип.
Үзгәрешкә безнең, тизләнешкә
Иярүдән куркып тора, дип.
Юк, яңарыш кирәк һәм табигый:
Яшәешнең шунда үсеше.
Үзгәрешләр зарурлыгын аңлый
Аек фикер йөрткән һәр кеше.
Әмма бездә кайчак чиктән чиккә
Ташланулар була капылдан.
Бер заманда манаралар кырып
Йөргән кебек, шашып акылдан,
Ашыгабыз, уйлап җиткермибез,
Кул изәү дә бик тиз иртә.
«Чү, ашыкмыйк, уйлыйк!» — дияргә дә
Батырчылык җитми кирәктә.
Ашыгабыз, аннан акланабыз:
«Машиналар, тизлек заманы...»
Кайвакытта хәтта аера алмыйбыз
Нәрсә иске, нәрсә яңаны.
Искелекме икән исереклек?
Ата-бабам минем эчмәгән.
Җил кумаган,
хатын аермаган,
Сүгенмәгән,
илдән китмәгән.
Туган җирдә табыныр кайбла тапкан.
Хәтта кара чорда торганда,
Күңелендә Өмет учак яккан,
Тугры булган Идеал-Иманга.

Һәрбер иске — изге түгеллеген
Тукайдан ук белгән хәлемдә
Изгесенә иске гадәтләрнең
Мин табынып яшим әле дә.
Мин табынам Ата-ана хакын
Олылауны бурыч санауга,
Гаиләне Дәүләт эчендәге
Дәүләт итеп җитди карауга,
Ана сөте,
Бишек җыры белән
Сабыйларга әхлак бирүгә.
Борынгыдан килгән гаделлекне,
Тугрылыкны олы күрүгә
Мин табынам.
Чордашларымны да
Шул фикерне өндим якларга:
Аларны бит яңартырга түгел,
Бөтен килеш кирәк сакларга.
Сакланганын югалтмаска кирәк,
Кайтарырга — юкка чыкканын.
Элеккедән халык хак санаган —
«Изге» диеп мөһер сукканын.
Яңа тормыш яңа сулыш өреп
Яңа дөнья туган көнгә бит
Әле җитмеш кенә ел ләбаса!
Кай арада тузып, үзгәреп,
Искереплэр бетсен бөтен нәрсә?
Тузып бетсен төптән, тулаем?
Бу сорауны биргән башларда да
Юк түгелдер хаклык, мөгаен...
Якты, яхшы яңалыкны яклыйк,
Саклыйк агын иске гадәтнең.
Безгә Ленин үзе шулай кушкан,—
Боза күрмик аның васыятен!

*

Бер төш күрдем әле яз башында,
(Бу хәл калсын бары төшләрдә!...)
Телдә, имеш, бер генә сүз калган,
Инфинитив-боерык: эшләргә!

Тирәбездә, имеш, «яратышу»,
«Уйнау», «уйлау» кебек фигыльләр
«Сез эшләрсез, без нишләрбез?» — диеп
Югалыплар калып йөриләр.

Моңа кадәр сөеп торган ирем
Шул бер сүзне теркәп миенә:
«Бәхет бары эштә, хезмәттә!» — дип,
Кайтып кермәс булган өемә.
(Үзем моңарчы да кайтмый идем.)
Шул рәхәттән торган дөньяның
Ләззәтеннән тәмам иза чигеп,
Иөрәк чире белән уяндым...

Кайберәүләр мине ялгыш аңлап
«Курыктыңмы эштән?» — диерләр.
Эш яшәсен, әмма янәшәдә
Яшәсеннәр, берүк, «шатлан» дигән,
«Сөй» һәм «яшә» дигән фигыльләр!

## Фирая Зыятдинова

### Хөкемдар

Кайчакларны, ят бер кеше булып,
Мин үземә читтән карап торам.
Хисап биреп кылган гамәлләргә,
Яхшы-яманлыкны барлап торам.

Игелек өчен мактап куям «мин»не,
Ялгыш адым өчен тетеп салам.
Әкрен-әкрен шулай яхшылыкка
Якыная бара бугай арам...

### Кышларның бураннары...

Мәхәббәтнең ялкынына
Чорнадың-урадың да,
Алып кереп киттең мине
Кышларның буранына.

Сүрелер ул бураннарда,
Сүнәр, дип белгәнсеңдер;
Уралсын бураннарга да
Сыналсын, дигәнсеңдер...

Уралдым бураннарга да,
Сыналдым, сынатмадым.
Үзем дә югалмадым мин,
Сине дә югалтмадым!

*

Суга туймас гөлләр сыман
Кыз баланың күңеле:
Таңнар туса, җир йөзендә
Сөю эзләгән көне.

Гөлләргә дәшеп бага ул,
Сандугач баласына.
Эзли ялкынлы хисләрне
Җыр юлы арасыннан.

Бәхет өчен, сөю өчен
Яратылган кыз бала.
Дөньяга дәшеп бага ул,
Кояшка дәшеп бага...

Эзләсен, әйдә, бәхетен,
Эзләгән генә таба,
Суга туймас гөлләр сыман,
Назлар көтә кыз бала.

Төнне тизрәк уздырасы,
Таң аттырасы килә.
Тимәгез сез кыз балага,—
Ярattырасы килә!

## Җилкән

*Луизага*

Зәңгәр киңлек. Ап-ак ялгыз җилкән.
Үзе белән шатлык-сагышы.
Киерелеп алга томырыла,
Нинди булыр икән язмышы?

Алда — алтын сукмак. Җилкән оча,
Матур көннең белеп кадерен.
Давыл чыкса, авып калмас микән,
Кара кыяларга бәрелеп?

Бу — хакыйкать: шатлык белән сагыш,
Җиңү белән җиңелү янәшә.
Ни бәясе җиңү шатлыгының,
Җиңелү әченүен белмәсәң?

Аумас әле җилкән, юлларында
Кара авыз — упкын тормаса...
Җыр булганда берни юкка чыкмый,
Җилкән юлдашы да җыр ласа!

Җиңү! Җиңү! Алда бары Җиңү!
Давыл аша Кояш елмая...
Елый-көлә, җиңелә-җиңә генә
Яшәү язган безгә дөньяда!

# Бикә Рәхимова

## Яшьләр

Кояш кебек елмаючы,
Тулган айдай нурланучы
Сөйкемле яшьләр бит сез!
Өметле яшьләр бит сез!

Дуслашырга ашкынучы,
Берләшергә ашкынучы
Эшлекле яшьләр бит сез!
Эчкерсез яшьләр бит сез!

Яхшылыкка ышанучы,
Начарлыкны күрәлмаучы
Көрәшче яшьләр бит сез!
Бик гадел яшьләр бит сез!

...Бер сулыштай туплансагыз,
Бер сулыштай берләшсәгез
Куркыныч килмәс Илгә!
Куркыныч килмәс Җиргә!

*

Авыр уйларым йөри,
күңелне сызып-тырнап,
илһамлы җиңел очышка,
юлымны ябып, чынлап,
нидер тота, нидер кыскан,
нидер канатны кисә...
Җил чакырам, давыл сорыйм,
иссен давыллап, иссә.

Өскә менәм, күтәреләм
бөркет очкан биеккә.
Таш булып төшү кирәкми,
ташлангандай киеккә,
кирәкми аулау хаҗәте...
Кирәк бары күзләргә:
тигез төшкәнме яктылык,
төшкәнме бар йөзләргә?!

## Сөюләрнең чиге буламыни

Сөюләрнең чиге буламыни?
Сөю бит ул очсыз-кырыйсыз.
Сөю китсә, аны бетте диеп,
Үлде диеп, юкка уйлыйсыз.
Илаһи бер коштай баш очында
Оча әнә, оча югары.
Чын йөрәктән аны чакырганда
Килеп кунмаганы юк әле.
Тик бер шарты аның, бер шарты бар.
Шул бер шарты безгә гел дәшә:
Булудыр ул — йөрәк очышының
Кош очуы белән янәшә.

# Сәйдә Зыятдинова

## Сөю туганда

Тып-тын калды бу төн.
Тынып калды.
Вакыт бирде безгә аңлашырга.
Мәхәббәткә шундый инанган чак! —
Мөмкин түгел кебек адашырга.

Тып-тын калды урам.
Хәтта инеш
Суламыйча гына ята кебек.
Тик тынлыкта күренә бу аерма —
Инеш түбән. Ярлар шундый биек.

Күкрәктәге хисләр давылыдай
Су өстеннән күтәрелә томан.
Җанда сөю барда
Дөнья үзе
Мәхәббәттән янган учак сыман.

## Мин — марттан

Мин — марттан. Сакла яттан —
Иөрәгем ачык яктан.

Сагышым ташып аккан —
Дәрьяларда моң арткан.

Кар яна, сыза эчтән...
Җир ята өнсез —
Хистән.

Каршыла син. Мин — марттан,—
Ташкын ярде арттан.

Кар аслары — кайнарлык,
Дәрьяларга агарлык.

Мин — март дигән агымнан,—
Тере агым шавыннан!

Сиңа киләм. Мин — марттан,
Бар дөньяма ут капкан...

Кар эчендә — умырзая...
Түзмәгән —
Чәчәк аткан!

## Әйтәм дә бит...

«Чиксезлекнең зәңгәр кочагында
Без бер нокта кебек... Бер нокта...
Киңәйми дә дөнья, тараймый да —
Бәргәләнмә, йөрәк, һич юкка...» —

Димен дә бит... Әмма йөрәгемнең
Һич тыңлыйсы килми шул аны —
Бертуктамый үзгәртәсе килә,
Зурайтасы килә дөньяны!

## Табигать ул юмарт...

Табигать ул юмарт: жәлләмәгән,
Матурлыгын биргән, сәләтен...
Һәм ул көтә безнең күзгә карап,
Сәләтләрнең ачылу сәгатен.

Табигать ул бирә сәләтләрне...
Әмма күңел... көтә игелек!
Кешеләрнең барлык сәләтеннән
Без игелек эзлик
Иң элек!

Табигать ул юмарт. Һич жәлләми
Матурлыгын бирә, сәләтен...
Һәм ул көтә
Ачылуын бездә
КЕШЕ дигән бөек сәнгатьнең!

## Фирүзә Җамалетдинова

### Яшәү

Ташны ярып яшь үсенте чыккан,
Үзе күрергә дип үз көнен...
Кырык якта кырылып эшләр кетә —
Дөнья, гүя, мәңге яшь килен...

Карт көтүче төссез эшләпәсен
Кояш нурларыннан яшергән.
Ә кояшның — төсе уңасы юк,
Күлмәк тегә язга, яшелдән...

Каерылган каен кайрылары,
Тузларына кадәр тузганнар.
Чәчләренә бөре-бантлар тагып,
Апрельләрдән кат-кат узганнар.

Бакырланып толымнары уңса,
Авыр булмас көзгә сүтүе.
...Бер яшь килен сарык куып килә,
Каты йоклап, калган көтүе.

Алсу таңы киткән көтүченең
Чыбыркысын иш дип, ияреп.
...Кайчак мин дә иртәм эзләп чыгам,
Төнге сагышларга сөялеп.

Башлап ачкан олы капкаларым,
Ал таңнарым өчен куанам.
Минем дә бит килен чагым җирдә,
Үтә серле яшәү — «кайнана»м.

Яшь үсенте ташны ярып чыккан,
Үзе күрергә дип үз көнен.
...Без кояшны каршылыйбыз икәү,
Дөнья һәм мин — ике яшь килен.

## Фәйрүзә Мөслимова

### Сиңа

Төшләремә керәсең син
Кыйссадагы Иосыф кебек,
Таң атканда юк буласың
Үзәгемне өзеп-өзеп...

Заман бүтән, уйлар башка,
Ерак калган кыйссалар да...
Юк, кабатлый алмам, ахры,
Зөләйханың дәртле җанын:
Күреп туймас сурәтеңне
Хыялымнан куам тагын.

Сине күрсәм тетрәп китәм:
Иосыф бугай син чыннан да.

Учка кысам йөрәгемне...
(Син чыннан да Иосыф бугай!)
Тик эндәшмим. Сине даулап
Кыю булмам Зөләйхадай.

Безне кемнәр җырга салыр?!
(Кичер мине, вакыт-хаким.)
...Төшләремә керәсең дә:
«Саумы, Иосыф!» — дип кабатлыйм.

## Дания Салихова

❀

Син әллә кеше диденме?
Мин куктән төштем, куктән...
Беркөнне гашыйк булдым да
Өзелеп зәңгәр җептән —
Таш кебек җиргә атылдым,
Ут сулап пешә-пешә,
(Чынга аша икән теләк
Канунны узган төштә...)
Сөю булып сиңа килдем,
Кеше кебекмен күптән.
Ташлый күрмә — тик таш калыр...
Мин куктән төшкән, куктән.

❀

Бу минутта ничә җирдә
Бер үк сүз кабатланды:
«Язмыш! Булдымы күргәнең
Минем кук яратканны?»

### Китәр алдыннан

Әлегә — кочагында...
Җил инде очкын туздыра
Сагыну учагында.



# ПРОЗА

## Нияз Акмалов

# КИМ, ГЫРЛАМА!

хикәя



Ишегалдын себереп йөргән дворник хатын, коты алынып, себеркесен югары күтәрде:

— Фу, куркыттың бит, шайтан! Котырдың мәллә?

Ким бу хатынга гаҗәпләнеп, аптырап карап торды. Аннан соң, үзе атылып чыккан ишеккә таба төртеп күрсәтеп, өзек-өзек сүзләр әйтте:

— Сөйләшә... Гырламаска куша...

— Кем? — хатын, себерке сабын асфальтка бәреп алды да ашыгып-ачуланып себерергә кереште.— Эчә-эчә акылдан яздың инде әллә?

Юк, Ким үз акылында иде. Урамга чыгып, күкрәк тутырып һава сулагач, ул моңа үзе дә ныклап ышанды. Ә өйдә чакта, «Марта»ның күзләренә карап торган чакта... Ким, шул мизгелне күзаллап, бөтен тәне белән калтыранып куйды, җилкәсе буйлап салкын чымырдау йөгереп үтте.

— Сатарга кирәк,— дип уйлады Ким һәм бу уйны кычкырып әйткәнен сизми дә калды. Ул ашыга-ашыга атлый, әмма үзенең кая таба юл тотканын да белми иде әле. Ниндидер бер курку, күкрәккә кереп оялаган шомлану хисе аны өеннән читкәрәк, еракрак куа иде.

— Сатарга кирәк! — дип кабатлады Ким һәм, кинәт тукталып, якягына каранды. Шунда гына ул үзенең әле айнып җитмәгәнлеген, кичәге хәмернең тәнендә, күзәнәкләрендә яшәвен, гәүдәсенең, буыннарының тәмам ватылган, хәлсезләнгән булуын аңлап алды. Әмма боларның барысын да бүтән бер авырлык, бүтән бер хәлсезлек — шомлы курку хисе басып тора, шул хис Кимнең сулышында, кан тибешендә, күзәнәкләрендә тыпырчына. Әнә шул халәтендә — буталган һәм тәмам өркенгән зиһене белән — Ким тагын бер нәрсәне аңлады: көн кичәге көннән бик нык аерыла, бүген ул «Марта»ны — бердәнбер ышанычлы дустын, үзенә якын булган, аның үзен якын иткән соңгы җан иясен югалткан.

«Марта» — инде яшь тулып узган киң күкрәкле, зур гәүдәле, сабыр һәм акыллы карашлы нәселле овчарка иде. Әлеге дустын Ким моннан нәкъ бер ел элек тапты. Ләкин әле аңынчы, «Марта»ны тапканчыга кадәр, ул бик күп нәрсәләрне югалтырга өлгерде.

Яраткан эшеннән китәргә мәҗбүр булды: авыр кичерде, иләште. Башка бик күпләр кебек үк, Ким дә үзенең югалтуларына нәкъ менә эчү сәбәп булуын аңлый, төшенә, әмма үзен һич тә эчкечегә санамый

иде. Әйе-әйе, бер көн килер дә кинәт барысы да үзгәрер, яңарыр, тормыш кабат башланыр кебек иде аңа. Бүтән бик күпләр кебек үк, Ким үзен яшьләргә, эшләргә, тормыштан, фани дөньядан матурлыклар һәм рәхәтлекләр табарга хаклы саный, әлеге матурлыкларның хәмер рәшәсе аша юкка чыгып баруын күреп, аңлап тора, кайчан да булса аларны куш учлап табасына ышана иде. Әмма көн артыннан көн үтә, ай артыннан ел үтә торды. Кимнең эш урыннары, яшәү шартлары, кием-салымы яңарды, бары тик ул көткән үзгәреш кенә күренмәде: ул көткән матурлыклар гына табылмады.

Буй җиткән кызын кияүгә бирүне ул зур югалтуга санады. «Кызны югалту» авырлыгын озак кичерде, шул авырлыкны «юу» хакына шактый чыгымнар тотты. Әмма кызының кияүгә китүе әллә ни зур югалту булмаган икән әле. Кемнең бәхетсезлегенәдер, Ким кияве белән уртак тел таба алмый интекте: автобус йөртүче егет бөтенләй эчми-тартмый торган кеше булып чыкты. Кунакка килсә, бабасы сыеннан авыз итмәде, хатын-кыз сыман, тәм-том белән чикләнде. Киявенең бу гадәтенә ата буларак шатланса да, ниндидер бер үҗәтлек Кимнең эчен гел тырнап, борчып торды: «Бабай» дип, янында сайрап-гөрләп, чөкердәшеп-чәкештереп тә утырмагач, нинди кияү була инде ул тагын? Торабара иләштеләр: табынга куелган шешәне Ким үзе генә бушатты. Әмма, ул кәефләнгәнгә карап, кияү белән тел ялганмады. Моны сизеп үртәлгән Ким янә стаканга үрелде, табынның ямен җибәргәләде. Андый чакта кызы, аны бер читкә дәшеп алып:

— Эти дим! Эчмә инде ул барында, ичмасам?! Күреп торасың бит, күңелсез аңа, эчкән кеше белән күңелсез! — дип, яшь аралаш ялвара иде. Тик андый чакта Ким сүзне кесәдән эзләмәде, җавапны әйләндереп кенә салды:

— Ә миңа?.. Миңа айнык кеше белән утыру күңеллеме?

Кияү белән кыз бу йортка сирәкләделәр. Тора-бара бөтенләй күренмәс булдылар. Бу хәлне Кимнең хатыны авыр кичерде, үзе кияү йортына, кызы янына ешлады. Аның бәхетенә, кыз кайнанасыз-кайнатасыз йортта, иркен фатирда яши иде. Хатын ял көннәрен, буш вакытларын шунда үткәрде, атналар буена шунда яшәде.

Ким ялгыз иде. Әнә шул ялгыз көннәренең берсендә ул үз өенә «Марта»ны — йомшак борынлы, сөйкемле карашлы, кәкре тәпиле бер көчекне алып кайтты.

Ул көнне Ким башы чатнап уянды. Күпме генә тырышса да, кичәге төнне ничек үткәргәнен, өенә ничек кайтып егылганын хәтерли алмады. Хатыны өйдә юк иде. «Тагын шунда киткән», дип уйлады Ким, өйдә тормаган, өйдә кунмаган хатыннарның барчасына ләгънәт укып, урыныннан кузгалды. Эчке бер сусау, эчке бер таләп аны караватбашында яткан чалбары янына алып килде. Кичәге аванстан җиде сум акча калган иде.

Ким ашыгып киенде. Аны кузгалырга, ашыгып киенергә мәҗбүр иткән әлеге эчке таләп хәзер инде урамга, яшелчә кибетендәге таныш йөкчеләр янына ашыктыра иде. Ким белә: аларда бар, әлбәттә, икеләтә бәягә, әмма бар. Һич югында, үзара кушылырга мөмкин. Тик менә башны гына ничектер җиңеләйтергә, кибет янына барып җитәргә генә кирәк.

Таныш йөкче аның гозерен ярты юлда бүлдерде:

— Хана, туган! Кичә койрыкка бастылар. Минем напарник кунакта әле, следователь янында...

Нәкъ менә шул чакта (алла юк диген!) аның янында Шәүкәт карт пәйда булды. Әлеге картның Шәүкәт исемле булуын, үз фатирында бер ялгызы яшәвен Ким соңыннан белде. Ә ул чакта әлеге карт аның җиңеннән тартты:

— Туган, хәлең начар бугай. Үзең әйбәт кеше күренәсең. Хакын түләсәң, өлешкә кертәм,— диде.

Ким картка иярде.

Ике бүлмәле зур фатирның алгы ягында алагаем зур гәүдәле эт ята, үзе тирәсенә елышып, чинашып уйнаган көчекләрен сак кына күзәтә иде. Кимнең шуларга карап торуын күргән Шәүкәт карт яратып сукранды:

— Тәмам урам маржасына әйләнде. Тагын алып кайткан менә... Элек нәселле нәрсә иде үзе, югыйсә. Сөт каян житкерим мин хәзер аларга? Йә, ярар, аларның — үз сөте, безнең — үзебезнеке.

Шулай таныштылар.

— Син Ким буласың инде, алайса,— диде карт.— Исемеңнең каян чыкканын беләсеңме соң? «Ком-мунисти-чески интрнасионал»дан, туган. Белеп тор, син — җирдәге бөтен яшьләрнең бер вәкиле. Әйдә, шуның өчен берне күтәрик әле...

Ул көнне Ким өенә көчек күтәреп кайтты.

— Сиңа сатмыйм, син — әйбәт кеше, бүләк итәм,— диде аңа Шәүкәт карт.— Исемен «Марта» дип кушарсың. Минем өченче хатынның исеме шулай иде.

Әнә шулай итеп, Ким «Марта»лы булды. Аның тормышында кинәт кенә пәйда булган шушы җан иясе бу тормышны шактый үзгәртеп җибәрә язды. Әйе, Ким моны үзе дә сизде: шушы кәкре тәпиле, ялагай һәм тугры карашлы, яклауга һәм кайгыртуга соң чиктә мохтаҗ булган нәни көчекне багу аның бушап калган күңел түренә бер мәгънә төсмере, яшәү мәгънәсе төсмере салды. Ким эштән соң өенә ашыкты, «Марта»ны күрергә, аның уйнавын, шаяруын күрергә, әчкерсез карашын тоярга ашыкты. Аның бу «йомшаклыгын» шешәдәш дус-ишләр, таныш-белешләр таныды, хәтта ниндидер бер хөрмәт белән карады. Шуңа күрә дә, уртакка акча җыешканда:

— Кимгә тиеннәр калдырыгыз, аның сөт алып кайтасы бар,— дип кисәтә башладылар.

Әйе, «Марта» Кимне үзгәртә язды, әмма үзгәртә алмады. Билгеле, әлеге сөйкемле көчек Кимнең иң якыны, кадерлесе, бердәнбере булудан туктамады. Бигрәк тә, Кимнең хатыны, бу йортны бөтенләйгә калдырып, кияве һәм кызы янына күчеп киткәч, «Марта» Ким өчен сулар һава, аралашыр җан иясе булып калды.

Кимнең хатыны киткән чакта:

— Туйдым, арыдым, Ким, бу эчүләреңнән. Ачуланма да, рәнҗемә дә, китәм,— диде.— Әгәр эчүеңне ташласаң, хәбәр итәрсең: шунда гына кире кайтачакмын,— диде.

Кимнең хатыны китте. Өй эче әрнү-сукрануларданм, үпкә-рәнҗүләрдән «Авансыңны алып кайтмадың! Квартплата түләнмәгән! Кухня тәрәзәсенең тупсасы купкан, бәдрәфтәге торбадан су ага, кыргаяк оясына әйләнүен күрәсеңме? Үзең булдыралмасаң, слесарь чакыртыр идең, эчмасам!..» кебек иңәлүләрдән бушап калды. «Үзең ташлый алмасаң, дәваланып кара!» дигән җан әрнеткеч сүзләр ишетелми башлады.

Йорттагы, Кимнең тормышындагы, күңелендәге бушлыкны «Марта» биләде. Ул тугры һәм ышанучан иде, үз хуҗасын ташлап китә белми иде...

«Марта»ның бу тугрылыгы, акылы, зиһене аның үзе белән бергә үсте. Ким хәтерләми, әмма күршеләре аңа шулай сөйләде: өенә кайтып җитәрлек булмаган Ким, исереп егылган. Бер милиционер белән ике дружиначы аны айныткычка алып китмәкче булган. Хуҗасының баш очында утырган «Марта» якын җибәрмәгән тегеләрне. Хәтта күршеләргә дә якын килергә рөхсәт итмәгән. Ким айнып аякка басмый торып, урыныннан кузгалмаган.

Моны Ким Шәүкәт картка әйтте.

Картның күзләренә яшь килде.

— Эт бит ул, туганкаем, эт бит ул! — дип кабатлады Шәүкәт

карт.— Хатының ташлап китә, балаларың йөз чөерә — ә эт ул, туган, синең өчен җанын ярып бирергә дә әзер тора.

Очрашкан саен, «Марта» турында сөйләшми калмыйлар иде. Әмма Шәүкәт карт фәлсәфәне киңәйтергә, тирәнәйтергә ярата:

— Мин, туган, өч хатын алып карадым, өчесеннән дә рәхәт күрмәдем. Берсен алдым — бүтәнгә ияреп качты, икенчесен алдым — эрәмтамак булып, миннән дә күбрәк эчте; өченчесе, әйтсәм-әйтим инде, мине мәҗбүри дәвалауга тыгарга маташты. Куып чыгардым пумала башны... Менә хатыннар хәзер нинди, туган...

— Минеке дә шулай диде, дәвалан, дип теңкәгә тиде. Барып чыккан алкаш син, имеш.

— Вәт! Әйтәм бит мин сиңа, әйтәм бит! Хатын-кызның җелегендә әшәкелек ята. Алкаш син, имеш. Алкаш булыр өчен, беләсең килсә, төп-төгәл өч шарт кирәк, туганкаем. Беренчесе: көн саен килеп, сине сыйлап торырлык дусларың булсын — шунсыз пычагым да акчаң җитмәячәк. Икенчесе: синең көн саен эчеп йөрүеңә риза булып, участковыйга тапшырмый торган хатының булсын. Өченчесе инде, кем, туган, иң мөһиме: аракының бөтен хәшәрәтлегенә, ямьсезлегенә-тәмсезлегенә, йөрәк белән бавырны, җан белән бәгырьне алмаш-тилмәш тукмавына бирешми торган сәламәтлек кирәк. Ә бармы соң шул шартларның берәрсе бездә? Юк! Шуңа күрә дә, туганкаем, чын алкаш чыкмый тек чыкмый инде бездән. Әйдә, шуның өчен берне күтәрик әле...

Шәүкәт карт, күтәреп куя да дәвам итә:

— Кешенекен эчмибез. Мин — үз пенсиямә, син — эшләп тапканыңа эчәсең. Качып түгел, үз өебездә рәхәтләнеп утырабыз, аяк тибеп. Теге кем әйтмешли, сүзебез эштән аерылмый — ничек әйтсәк, шулай эчәбез. Ә бит аның, туганкай, качып эчүчеләре дөнья тулы. Эшендә алар «аракы — дошман» дип кычкыра, җыелышларда өстәл төя, аннан соң, качып-посып, аулак урын эзләп, шешә башын ялый. Эчкәнен туганнарына, хатынына, дусларына күрсәтергә курка. Эт тормышы инде ул туган, эт тормышы. Ә без алай түгел, безнең сүз эштән аерылмый. Әйдә, шуның өчен берне...

Шәүкәт карт яныннан Ким төнлә генә кайта, лаякыл исереп кайта иде. Эшләп тапкан акчасы белән бергә саулыгын да туздырып, рухын сындырып йөргән көннәрендә Шәүкәт карт яңа яшәү дәрте, көч бирә сыман. Кичә дә ул Шәүкәт картта булып кайтты. Иртәнге өчләрдә кинәт саташып уянды. Күкрәге оеган, йөрәге тибүдән туктаган кебек иде. Тәнне басып, кысып торган авыр хәлсезлек кулны-аякны кузгатырга ирек бирми. Иреннәрдән каядыр эчкә, тирәнгә кадәр сузылган сусау сулышны тыя. Ким, үлем алды куркуын тоеп, кычкырмакчы булды — тавышы чыкмады. Күз алдыннан бер мизгел эчендә хатыны, кызы, кияве, инде күптән вафат булган әнисе үтте. Шушы мизгел аны коткарды: йөрәге еш-еш тибә башлады. Һәм ул, үзендә көч табып, янәшәдәге, шушы өйдәге бердәнбер җан иясен дәште:

— «Марта»... «Марта»!..

Хуҗасының төнге саташуларына, төнге укшуларына ияләшкән эт бу хәлсез тавышны ишетте. Ишек төбендә йоклап яткан җиреннән атылып килеп, ал аякларын ятакка куйды, сораулы карашын Кимгә төбәде. Ким кулын этнең башына куйды. Шушы минутта янында җан иясе булу аның өчен әйтеп бетергесез юаныч иде. Кимнең күзләрендә кайнар яшь тамчысы пәйда булды. Әлеге яшь тамчысы аның күкрәген ачты, сулышын җиңеләйтте. «Вакыт күпме икән?»— дип уйлады Ким. Аның ишеткәне бар иде: «Әгәр кеше иртәнге дүрткә кадәр үлмәсә, дүрттән соң инде махмырдан үлми икән...

Ким йоклап киткәндә яктыра башлаган иде инде. Кинәт ул сискәнде. Үз-үзен аңышмыйча, тынлыкка колак салды һәм аермачык итеп ишетте:

— Ким, гырлама...

— Кем бар анда?! — дип кычкырды Ким һәм, бөтен тәне белән калтыранып, урыныннан сикереп торды. Бүлмәне, кухня ягын — барча урынны карап чыкты. Ишек төбендә йокымсырап яткан «Марта»дан башка өйдә беркем дә юк иде. «Саташам бугай...» дип уйлады Ким. Яңадан йоклап китәргә тырышып, башын юрганга төрде.

— Ким, гырлама!..

Ким юрганын атып бәрде. Тавыш килгән якны чамаларга тырышып, як-якка каранды. Тавыш якында, бик якында яңгырый, ә бүлмәдә беркем дә юк иде. Кинәт аның карашы: «Марта»га төште. Эт тә, хуҗасына төбәлеп, туп-туры карап ята иде. Үз-үзен белештермәс дәрәҗәдә курыккан Ким этенә җикерде:

— Нәрсә кирәк сиңа?!

Бу тавышка «Марта» сикереп үк торды. Аннан соң, башын чайкап, әлеге сүзне кабатлады:

— Ким, гырлама!..

Әнә шуннан соң өеннән бәрелеп-сугылып килеп чыкты Ким. Ул үз-үзен белештермичә атлады. Шактый баргач кына, үзенең Шәүкәт карт янына ашыгуын төшенде. Әйтерсең, аны бүгенге хәлендә, бүгенге халәтендә бары тик Шәүкәт карт кына яклый ала, курку-шомланудан йолып кала ала иде.

— Адәм кыяфәтләре калмаган үзеңдә,— дип кеткелдәде Шәүкәт карт. Ким аңа «Марта» белән булган хәлне сөйләп биргән иде.— Этнең телгә килүеннән коты алынган берәүнең! Хи-хи-хи, туганкаем, этеңне түгел, колагыңны гаеплә, колагыңны! Тавыш гәлүтсинатсиясе ул, беләсең килсә. Мин үзем тавышныкына гына төкереп тә бирмим. Менә идәндә җен-шайтаннар йөгерешә башласа, анысы инде интектерә, туган, анысы җелеккә төшә...

— Мин бит саташып кына ишетмәдем. Туп-туры карап әйтте: «Ким, гырлама!» ди.

— Син, туган, болай гына рәтләнерлек түгелсең бугай. Хәзер терелтәм мин сине. Авыр чакта бер-береңә ярдәм кулы суза белү кирәк. Иртән пенсия китергәннәр иде...

Шәүкәт карт белән бергә баш төзәткәндә Ким үзенең иртәнге куркуын, бөтен шомлануын онытты. «Марта» турында сүз кабатланган чакта, йодрыгы белән өстәл төеп янады:

— Хәзер, кайтам да тотып ярам мин аны! Карале син аны, ә? Хуҗасына «гырлама» дип җикерсен әле?!

— Минем өченче хатын да, сабакы, кычкырырга ярата иде,— Шәүкәт карт хатыннарының һәрберсенә бәя биреп чыкты. Аннан соң, күңеле нечкәреп, башын өстәлгә салып үкседе.— Этне гаепләмә син, туган, гаепләмә этне! Аракы аркасында этеңнән дә колак кагарсыңмыни?!

Инде кичкырын, өенә таба кайтып барганда, Ким иртәнге шомлануларыннан арынган иде. «Башта тотып ярам, аннан соң куып чыгарам мин аны! — дип үзалдына сөйләнеп кайтты.— Алай бик хуҗасына җикеренә торган булса, йөрсен шунда урам себеркесе кебек өстерәлеп...» Әмма, өйгә якынлашкан саен, Ким үзенең ирексездән айный баруын, күңеленә яңадан курку, шомлану тула баруын сизде. Ул кинәт «Марта»ның төбәлеп торган карашын күз алдына китерде һәм бүген шул караш белән бергә очрашасы барлыгын исенә төшерде. Башта ул караңгы тәрәзәләргә карап торды. Аннан соң баскычтан әкрен генә күтәрелде. Ишекне япмыйча, бикләмичә чыгып йөгергән иде. Һәрхәлдә, аның үзенә шулай тоелды. Әллә япты микән? Ким, ниндидер бер угры кебек, әкрен генә атлап, ишеккә таба якынлашты. Эчтә ни барын белергә, ишетергә теләгәндәй, колагын ишеккә терәде. Һәм шунда ук, «Марта»ның еш-еш сулавын, чак кына аваз чыгарып, сулкылдап куюын ишетте. Күрәсең, эт аның аяк тавышларын, баскычтан атлап менүен сизеп, ишек төбенә үк килеп утырган. Аның сулкылдап куюында таныш тавышлар — сагынганлык, тугрылык, көтеп алганлык авазын ишетте Ким. Тик

ул ишекне ачарга ашыкмады. Менә шушы ишек ачылуга, «Марта» аңа төбәлеп карар да, «Ким, гырлама!..» дип кычырыр кебек иде аңа.

Ниһаять, ул ишеккә кагылды. Аз гына, ярык булып кына ачылырлык итеп, ишекне этте. Әчкә карады һәм нәкъ шул минутта үз биеклегенә кадәр күтәрелеп, арт аякларына баскан «Марта»ның карашы белән күзгә-күз очрашты.

Ким куркудан кычкырып җибәрде. Баскычлар буйлап түбән таба йөгергәндә аны кемдер арттан куып килә һәм: «Ким, гырлама!.. Ким, гырлама!..» дип кабатлый кебек иде.

* * *

Бу вакыйгадан соң атна-ун көн чамасы вакыт үткән иде.

— Әйтегез әле, утыз өченче квартирага каян килеп була?

Дворник хатын, себеркесенә таянып, сынаулы карашын килүчегә төбәде:

— Кем кирәк иде анда сиңа?

— Миңа... Мин белергә теләгән идем... Анда эт булырга тиеш, «Марта» исемле...

— Эте бар барын да, хуҗасы менә әллә кая китеп олакты, шайтан! Үзе ник шунда кадалып кына китми, исерекбаш. «Марта»сы жәл бит, эте жәл. Беркая да чыкмый, шул дуңгызны көтеп утыра бит. Үзе беркемне дә өйгә якын җибәрми. Хатыны килгән иде — аны да кертмәде. Мин инде, кызганып, ит-мазар ыргыткалыйм үзенә. Башта гел авыз да итмәде, ашамады, мескенкәем, шыр сөяккә калды. Кая олаккандыр теге мөртәт, алла белгән?

Хатын, әлеге ир кешенең өс-башына, килеш-кыяфәтенә тагын бер кат карап алды да, ышанып булса кирәк, Кимнең фатирына илткән баскычка таба ымлады:

— Әнә шунда тора иде Ким...

Ир кеше баскычлар буйлап күтәрелде. Дворник хатын, себеркесен тоткан килеш, аның артыннан иярде.

Ир, ишекне аз гына ачып, бүлмәгә күз салды. Анда, ишек төбендә, хуҗасы кайтса — каршыларга, чит-ятлар килсә — юлга каршы төшәргә әзер булып, ябыккан, хәлсезләнгән «Марта» утыра иде. Эт урыныннан кузгалмады, өрмәде, әмма үзенең өй сакчысы икәнен белдереп яшьле, сораулы карашын ишек ачучыларга туры төбәде.

— «Марта»,— дип эндәште ир кеше,— «Марта», син көт, кайтачак синең хуҗаң, кайтачак. Тиздән, озакламый...

«Марта», ирнең сүзләрен аңлагандай, алга талпына төшеп, сылкылдап куйды. Ир, кесәсеннән төргәк чыгарып, эт алдына колбаса кисәге куйды:

— Кайтачак ул, кайтачак, «Марта», көт! — аннан соң, ул кесәсеннән егерме бишлек акча чыгарып, дворник хатынга сузды.— Сез, авыр булмаса, «Марта»ны ашаткалап торыгыз инде? Хуҗасы кайтачак аның, кайтачак...

Хатын, башта аптырап, гаҗәпләнеп, әлеге кеше артыннан карап калды. Аннан соң гына, исенә килгәндәй, баскыч буйлап ашыкты:

— Карале, син үзең кем буласың соң? Ким үзе кайда соң?

— Кайтачак ул,— дип кабатлады ир һәм китәргә ашыкты. Үзенең нарколог-врач булуын, Кимнең әлеге шомлы төннән соң туп-туры диспансерга килүен, «Марта» белән булган вакыйганы дәвалау барышында елый-елый сөйләвен әйтергә аның хакы юк иде.

# ПУБЛИЦИСТИКА

## Мәгъсүм Насыйбуллин

# ХӨКЕМ

### 1

Вакыйга җәй аенда була. Уралдан Казанга баручы поезд ике яклап сузылган урман эченнән алга ашыга. Ул корыч күперга килеп кергәндә тын гына аккан Вятка елгасы куркып уянгандай тоела.

Вагоннарда исә һәркемнең үз хәле хәл. Әнә почмакта баручы өч пассажирның колгадай озын буйлысы тәрәзә янына килде. Күпердән ерак түгел, яр кырыенда утырган дүрт-биш балыкчыны күргәч, ул:

— Егетләр, карагыз, балык чиртә бит! Закуска дисәң дә закуска, ичмасам! — диде.

— Шәп сүз бу, Бөдрәчәч! — диде аңа каршы йокымсырап утырган такыр башлысы һәм, эскәмиядән торып, тәрәзәгә капланган акбашлы үсмергә эндәште.— Марат, әйберләрне җый! Төшәбез.

Күп киракмени кызган башка!? Кизнерда бер шешә аракы белән кызыл шәраб бушатканнарына күп тә үтми, өч юлдаш кабат хәмер, закуска турында кызыксына башлый. Поездның Вятские Поляны станциясенә җитеп туктавы була, өчәве дә җиргә сикерә.

Елга буйлап күпме теләнеп йөрсәләр дә, балык сатучы табылмый. Шулай да боларның моңа әллә ни исе китми, яр буенда табын корып җибәрәләр. «Тамак чылатабыз»,— дип башланган мәҗлес, Марат исемлесе исереп, суга егылгач кына, тәмамлана. Алар кузгалып, станциягә киткәндә, яр буенда тырпаеп ике буш шешә кала. Арчага бара торган поездга кереп утыргач, тагы бер шешәне бушатып ташлыйлар. Моны күргәч, бер вагонда баручы ике карчык тәшвишкә төшә. «Мондый имансызлар белән урының түгел, каберең янәшә булмасын»,— дип, алар алдагы вагонга күчеп утыруны хәерле күрә.

— Револьвер, каля-баляны туктат! — дип бакыра Пеләшбаш Бөдрәчәчкә, арырак удмуртча сөйләшеп барган ике хатынга күрсәтеп.

Колга буйлы Бөдрәчәч хатыннар каршысына барып сүгенергә керешә. Хатыннар янында утырган кыз баланың кулыннан шешәсен тартып алып, лимонад эчә башлый, куркыта. Хатыннар ярдәм сорап кычкыра башлагач, ике студент йөгереп килеп, Бөдрәчәчкә тыелырга, хатыннар яныннан китәргә куша. Бөдрәчәч, сүгенеп, студентларга ташлана. Студентның берсе хулиганның кулын эләктереп ала, икенчесе — аягын. Шул чак, әлеге исерекләрнең калган икесе, арттан килеп, студентларны тукмарга тотына. Күрше вагондагы дисталәгән кеше белмәмешкә сабыша. Белмәгәннең беләге авыртмый, янәсе. Арадан ике генә кеше — егет белән кыз моңа түзә алмый. Берничә кеше туктатмакчы булып караса да, егет, тәвәккәлләп, күршедәге җәнҗал купкан вагонга атлый. Таныш кызы да ияргәч, егет тагы да кыюланып, батыраеп китә. Моны күреп, ике студент та ярдәмгә килә. Шунда ук кыскача акт языла, шаһитлар имза куя. Каенсар станциясенә килеп җиткәч, кыю егет, «Маяк» колхозы яшьләре белән бергә, өч хулиганны поездан төшереп, милициягә хәбәр итә. Кыю егет үзе шушы төбәктә туып үскән, балачактан ук сабан туйларында көрәшеп чыныккан, хәзер чик сакчысы, армиядән илга кайтып килә икән. Бу очраклы халдә дә Мансур сынатмый...

Хөкем залы. Гаеплеләрнең башлары иелгән. Каш астыннан гына халык судьясына, утырышчыларга сөзеп-сөзеп карыйлар.

— Гаепләнүче Смешнов, исемегез ничек? — Судья Рәшит Маликов, хөкем утырышын ачып, гаепләү нәтиҗәсен укыганнан соң, әшне, гадәттәгечә, җавапка тартылганнарны өйрәнүдән башлап җибәрә.— Ничә яшь?..

— Смешнов Геннадий Фомич,— пассажирлар Пеләшбаш дип атаган хулиган аягүрә баса,— 1946 елда Курск өлкәсендә туганмын. Кырык яшьтә. Милләтем рус. Өйләнмәгән. Балаларым юк. Әти-әниемне дә белмим. Туу белән ташлап киткәннәр. Курск балалар йортында үстем, шунда сигезьеллык мәктәп бетердем. Хәзер өченче ай Саба районы Шәмәрдән станциясендә яшим. Газүткәргеч торбалар сала торган оешмада тракторчы мин. Менә шул. Биографиям кыска. Шуның белән тәмам.

— Ашыкмагыз,— ди аңа судья.— Ничә мәртәбә, кайчан, кайда, нәрсә өчен хөкем ителдегез?

— Биш мәртәбә,— ди Смешнов, исе китмәгәндәй.— Беренчесендә унбиштә идем, квартира баскансың дип бәйләнделәр. Уналтыда, юлбасарлыкта гаепләп, ике ел чәпәделәр. Мин иреккә чыккан елны Мәскәү өлкәсендә такси шоферын чәнчеп акчасын талаганнар. Мәскәү җулигы белән мине дә утырттылар. Тагы тугыз ел заяга китте. Аннары, Алма-Атада ювелир әйберләр кибетен баскансың дип, биш елга озаттылар. Чыгып, эшкә урнашырга өлгермәдем, Ташкент милициясе тотып судка бирде. Бер үзбәкне, яралап, талагансың дип, тугыз елга утырттылар...

— Әйе, сезне иректән мәхрүм итү җәзасы егерме алты ел тәшкил иткән шул,— ди судья Маликов. Ул әйтелгәннәрне СССР эчке эшләр министрлыгы белешмәсе белән чагыштыра.— Нишләп соңгы мәртәбә чыккач, дүрт ай эшләмәдегез?

— Алмадылар, гражданин судья,— ди Смешнов ихластай итеп.— Хөкем ителгәнне белгәч, алмыйлар.

— Ничек көн күрдегез? Нәрсә исәбенә яшәдегез?

— Безнең ишегә ипилек-тозлык вак-төяк эш бетәмени?

— Ничек Татарстанга киләсе иттегез?

— Револь чакырды,— дип, Смешнов янында утырган Бөдрәчәч кушаматлы гаепләнүчегә күрсәтә.— Револьны мин Ташкент вокзалында очраттым. Аның армиядән кайтып килеше иде. Таныштык. Ресторанга өндәде. Юлга дип әнисе ике йөз сум акча җибәргән. Рәхәтләнеп ашадык, эчтек. Ул миңа бер күрүдә үк ошады. Тап-таза, чибәр егет. Буе гына ни тора бит аның! Чәче бөдрә! Чем-кара! Борынын бөркет томшыгыннан аерып булмый. Буе-сыны, төсе-кыяфәтенә игътибар итегез!..

Рәшит Маликович, халык утырышчылары ялыкмады микән, дип, якягына каранып ала. Мавыгып тыңлаганнарын күргәч, Смешнов сөйләгәнне бүлдерми.

— Револьнең бер генә килешмәгән җире дә юк. Хатын-кызны акылдан яздыра торган. Татарстанга чакыргач, башта риза булмадым, чөнки кар-боз ята торган, ерак җир. Исеменә кадәр шөбһәле. Ә ул һаман үзенекен тукый: әйдә дә әйдә. Аның туган төбәге менә дигән, имеш. Ямь-яшел урман. Саф һава. Йорт-куралары үзләренеке. Мал-туарның саны юк. Ит, май, сөт, йомырка — бар да буа буарлык, янәсе. Умарталары да бихисап: егермеме, утызмы... Өч-дүрт көн буе сыйланып йөри торгач, тәмам дуслашып киткәнне сизми дә калганбыз. Күрәм, Револьнең акчасы да кимегәннән-кими. Өченче көнне тәки күндерде бит. Шулай итеп мин ул туган Иштуган станциясенә килеп җиттем. Револь мине бергә эшләгән иптәше дип таныштырды.

— Иштуганда нишләп ай ярым эшләмәдегез?

— Револь белән ял иттек.

— Алай икән,— ди судья.— Гаепләү нәтиҗәсен алдыгызмы? Үзегезне гаепле дип санныйсызмы?

— Гражданин судья, минем бернинди гаебем дә юк. Алар үзара сугышты, мин аларны аермакчы булдым.

— Аңлашыла, Смешнов, утырыгыз,— ди судья.— Корбанов, Смешнов дөрес сөйләдеме?

— Әйе, дөрес,— ди гаепләнүчеләрнең Бөдрәчәч дигәне аягүрә басып. Аның бөдрә чәченнән җилләр искән, такыр башында биш-алты яра эзе генә күренә. Ул судья сорауларына җавап бирә.— Корбанов Револь Радикович мин, 1966 елда Саба районы Иштуган авылында тудым, егерме

яшьтә, милләтем татар, белемем урта, газүткәргеч торбалар сала торган оешмада шофер булып эшлим. Хөкем ителгәнем юк.

— Үзегезне гаепле саныйсызмы?

— Минем гаебем юк. Зыян күрүче мин, дүрт кабыргамны сындырдылар. Аяк сөягем чатнаган. Тәнемдә уналты җәрәхәт бар. Чишенеп күрсәтимме?

— Кирәкми, Корбанов, суд-медицина экспертиза нәтиҗәсе бар монда.

— Васиков, торыгыз әле,— ди Маликов Акбаш кушаматлы гаепләнүчегә.— Үзегез турында сөйләгез!..

— Васиков булам мин, Марат Уразович, 1969 елда Кукмара районы Кнә Юмья авылында сигез балалы колхозчы гаиләсендә тудым, хәзер унҗиде яшьтә, милләтем удмурт, белемем тугыз класс, узган ел эти үлгәннән соң укуны ташлап, Шәмәрдәнгә эшкә кердем. Газүткәргеч торбалар салабыз. Хөкем ителгәнем юк.

— Ни өчен гаепләнгәнегезне беләсезме?

— Беләм.

— Үзегезне гаепле саныйсызмы?

— Әйе, үземне гаепле саныйм,— ди Васиков, судьяга туп-туры карап.— Анда язылганнар бар да дөрес. Кичтән хезмәт хакы бирделәр. Смешнов Револьдән күпмедер әче бал таптырды. Бригададагы бөтен кеше җыелып эчте. Мин, эчем авыртa, дип, читтә утырдым, чөнки Смешновның ниндидер ак порошок сыман ят нәрсә салганын күреп калдым. Башкалар моны белмәде ахрысы. Әз генә эчсәләр дә, бригада кешеләре тиз исерде. Шундук акча җыеп, аракыга поезд белән Кизнерга барырга сөйләштеләр. Акчаны Смешнов Корбановтан җыйдыртты. Сумка-портфельләр әзерләтте. Акча күп җыелган иде. Аракы күтәрешеп кайтыр өчен мине дә ияртteләр. Кизнерда бер әрҗә аракы, ике әрҗә шәраб алдык. Куаклыкка кереп, Смешнов берәр шешә аракы, шәраб ачты. Вятка ярында да эчтек. Шунда Смешнов эчке кесәсеннән алып, шешәгә әллә нәрсә салып болгатты. «Шифалы үлән» диде. Револь бервакыт сер итеп «Смешнов Урта Азиядән шифалы үлән алдырта ул», дип мактанган иде. Минем дә шул серле үләнне татып карыйсым килде. Эчтек. Башта көләсе, биисе килде. Аннары нәрсә булганын рәтләп белмим. Зыян күрүчеләрдән, судтан гафу үтенәм...

Васиковка — нибары унҗиде, Корбановка егерме яшь.

Судья Рәшит Маликов, бу яшүсмерләр язмышын уйлап, ихтыярсыздан, үз тормышын күз алдыннан уздырды. Аңа шәраб әзләп кибеттән-кибеткә, районнан шәһәргә чабып йөрергә туры килмәде. Агы да, кызылы да яшьләрнең исенә дә кереп чыкмый иде. Ул вакытта Рәшит көч-гайрәтен ата-ана йомышына, колхоз хезмәтенә юнәлтә. Армиядә дә булды, читтә дә йөрергә туры килде. Әмма исерткеч эчемлек, акылдан яздыра торган наркотик эзләп, сәламәтлеген, вакытын юкка-барга әрәм итмәде. Колхозына, туган авылына ашкынды, хезмәткә, гыйлемгә омтылды. Читтән торып укыды. Тырыш егет мәктәптә дә эшләде. Рәшит укытучылыкка гаять җаваплы карый иде. Район башкарма комитетына культура бүлеге мөдире итеп куйгач та сынатмый ул. Эшли, укый торгач, югары белемле юрист дипломына ия була. Тырыш, гадел егетне халык судьясы итеп сайлыйлар. Егерме биш елдан бирле Рәшит Маликов Кукмара районы халык судьясы булып эшли. Роза, Ләйлә, Алсу исемле кызлар тәрбияләп үстергән гаилә башлыгы да ул...

Хәзер аңа гаделлек өчен көрәшне җитәкләү тапшырылган. Бүген дә ул кеше язмышын хәл итә. Смешнов, Корбанов, Васиков кылган җинаятьнең очына чыгарга, аңа этәргән сәбәпләрне дә ачыкларга тырыша ул.

— Бригадир Галәветдинов, ни өчен Смешнов, ике яшь эшчегезне ияртеп, Кизнерга киткән, эш вакытында эчү оештырган?

— Эштә булган хәл түгел бит, иптәш судья,— дип тиз генә котылмакчы була бригадир.

— Смешнов, Корбанов, Васиковларның тормыш шартлары, буш вакытларын ничек үткәргәннәре сезгә танышмы?

— Ю-у-к,— дип суза Галәветдинов.

Ваемсыз бригадирны гаепләнүчеләрнең ата-аналары алыштыра.

— Иптәш Корбанов, ни өчен улыгыз Револь эчүгә сабышкан?

— Иптәш судья, Револьнең үзеннән сорагыз. Ул үзе гаепле. Хәерсез бер хөрәсән ияртеп кайтты, аны бездән кадерлерәк күрде. Үзбәкстаннан посылка алдырдылар. Агу әчәргә сабыштылар...

Улының әчүеннән гарык булган ата тагы нәрсә әйтә алсын соң?! Судья өчен бөтенесе ачык. Сакаллы сабый үзе утырган ботакны үзе кискән. Бу хөкем карарында да искә алына.

— Смешнов, Корбанов, Васиковларны тупас рәвештә тәртип бозуда гаепле дип санарга. РСФСР җинаять кодексының... нчы статьялары нигезендә Смешнов белән Корбановны бишәр елга ирекләреннән мәхрүм итәргә... Васиковны өч ел сынау шарты белән эш урынында калдырырга, сак астыннан азат итәргә...

Хөкем ителгән Смешнов, Корбановларны алып киткәч, Маликов халык утырышчылары белән үз бүлмәсенә кереп, хат язарга керешә. Аның берсе — Саба район башкарма комитетына, икенчесе — газүткәргеч төзелеше идарәсенә. Борчулы хат була алар. Хатның бүтәннәрен Рәшит Маликович — хәрби часть командирына, икенчесен төзүче инженерлар институты ректорына яза. Кыюлык, батырлыклары һәм хулиганнар өере белән көрәшеп, аларны милициягә тапшырганнары өчен, Мансур исемле чик сакчысына, ике студентка халык суды исеменнән рәхмәт белдерүләрен үтенә.

Хөкем итү — Маликовның төп вазифасы. Әмма ул хөкемнең тәрбия чарасы икәнен дә бервакытта да истән чыгармый.

2

Рәшит Маликов чишкән тагын бер четерекле мәсьәләгә тукталыйк.

«Гайбәтчелек — җинаятьме, түгелме?» — дип сорасаң, кешедән бер төрле генә җавап ишетермен димә. Законда исә гайбәтчелек, яла ягу җинаятьтән санала.

Бервакыт Кукмара район халык судында утырыш барган чакка туры килдем. Хөкем алдында — гайбәт сөйләп кешегә яла ягучы җинаяьчеләр.

Мәһинур Галләмова, карап торырга, җиләк кебек, теле — пычаксыз суя икән. Элекке иреннән көнләшеп, Тәкәнеш ягындагы авылларның берсендә торучы Галия Ногманова турында тузга язмаган гайбәт чәчеп йөргән.

— Беренче очракта утыз сум штраф! — ди судья Маликов хөкем карары укыганда.

Манзарас тирәләрендә Хәтимә Кадыйрованың гайбәт сатучы буларак даны чыккан. Тегүче Гәүһәрия Һидиятуллина хакында нинди генә ялган таратмаган?! Ярый әле Гәүһәрия сабырлыгын, түземлеген җуймый, Кадыйровага ияреп, сугышып-талашып йөрми, бәхәскә керми. Акыллы юл таба ул — үзләре судья итеп сайлап куйган Рәшит Маликович Маликов янына киңәшкә бара. Кадыйрованы җавапка тартуны сорап, гариза яза. Халык судьясы гаризаны җентекләп өйрәнә, мәгълүматлар туплый, шаһитлар таба. Шуннан соң җинаять эше кузгатыла, аны хөкем утырышына куя. Беренче сафта — җинаятьчеләр эскәмиясендә Хәтимә Кадыйрова. Судья авызын ачып сорау бирергә өлгерми, гаепләнүче йөз җавап яудыра. Аны тыңласаң, Һидиятуллина — җир шарындагы иң явыз зат икән. Урамнан узганда, кеше белән исәнләшми, дорфа, поселокта мал-туар асрый, салам-печәнне күрше колхозлардан ташый, мех фабрикасыннан затлы тиреләр урлый...

— Кадыйрова,— судья гаепләнүчене урынына утыртты.— Сез монда да намуслы кешегә яла ягуны дәвам иттерәсез. Сезнең имзалы һәм имзасыз хатлар буенча Кукмарада дүрт-биш комиссия эшләгән, хәбәрләрегезнең барысы да ялган булып чыккан.— Маликов алдында яткан томнарның берсен алды.— Менә сезгә Мәскәүдән җибәрелгән җавапның бер нөсхәсе!

— Мәскәүлеләрне кем дип беләсез? Бар да бер чыбыктан сөрелгән...

— Иптәш Һидиятуллина, зыян күрүче буларак, сез нәрсә әйтәсез?

— Теләгем гаризага язылган. Бу гайбәтләрнең сәбәбе бер генә — көнләшү. Башка бернинди сәбәп тә юк. Ирем белән тату яшибез. Ул — тол хатын. Безнең дүрт улыбыз бар, өлкәннәре җәен колхозда да эшли, йөгейөге белән салам-печән алабыз. Ике малай үстереп, берсеннән дә игелек күрмәгән Хәтимә апа моңа да тыныч кына карый алмый.

— Кадыйрова, торыгыз әле! — дип, судья гаепләнүчене кабат бастырды.— Сезне кат-кат кисәткәннәр дә бит инде: социаль-тәэминат бүлегендә, поселок Советы башкарма комитетында. Милициядә ничә кисәттеләр?

— Хөкем чыгарыр өчен суд киңәшкә юнәлә,— дип, игълан иткәннән соң, судья белән ике утырышчы махсус бүлмәгә керделәр.

— Я, Кадыйровага нинди җәза билгелибез? — дип сорый Маликов иптәшләреннән.

Беренче утырышчы үз тәкъдимен әйтә: «Ирегеннән мәхрүм итәргә!»
— Ничәмә кат кисәтелгән, иптәшләр судына тартылган бит инде,— дип, икенче утырышчы да сүзгә кушылды.— Андый гайбәтчегә ун ел да аз.
— Ун ел — законга сыймый, иптәшләр. Бу статьяда иң зур срок — биш ел. Менә, карагыз,— Маликов җинаять кодексын ачып, гайбәтчеләргә җәза билгеләүне күздә тоткан статьяны күрсәтә.
— Биш ел, алайса! — диләр утырышчылар.
— Шулай да...— судья каршы төшә.— Кадыйрова — өлкән кеше, алтынчы дистәне куа.
— Бәлки ул акылдан да ычкынгандыр әле? — дип, икенче утырышчы шөбһә сала.
— Бу хакта борчылмагыз, иптәшләр,— ди Маликов, тикшерү эшендә бер битне ачып аңлатып бирә. Суд-психиатрия экспертизасы үткәрелгән. Психиатр врачлар комиссиясе Кадыйрова үзе кылган җинаятьләре өчен җавап бирерлек дәрәҗәдә сәламәт дип тапкан. Картлыгы бар барын.
— Карт булса да, теле агулы.
— Ул кисәтелгән инде, иптәшләр судында да каралган,— ди Маликов.
— Ул гына бик аз! — Икенче утырышчы да иптәшенең фикерен куәтли.— Кадыйрова язган хатларны тикшерүдә генә утыз ике кеше катнашкан бит.
— Шулаен шулай, дөрес әйтәсез,— судья һәр сүзен үлчәп әйтә.— Әмма биш ел күп булмасмы? Ел әйләнәсе генә дә өч йөз алтмыш биш көн бит ул.
— Сезнеңчә, ничә ел дөрес булыр соң?
— Менә шул өч йөз дә алтмыш биш көн житеп торыр.
Ниһаять, хөкем карарына кул куела: «...Кадыйрова Хатимәне бер елга ирегеннән мәхрүм итәргә! Суд залыннан кулга алырга!..»
Бу эшне төгәлләгәннән соң Рәшит Маликович район газетасына мәкалә язды. Гайбәтчелеккә каршы көрәштә бу чара аеруча әһәмияткә ия. Бөтен кеше белеп торсын: гайбәтчелек — мәгънәсез лыгырдау гына түгел, ул — җинаять! Мәкерле җинаять!

### 3

Бүлмәсендә тып-тын гына эшләп утырган халык судьясы Маликов ишек шакыган тавышка, каләмен куеп, аягүрә басты.
Судьяның ишеген шакучы кеше аның иске танышы, коммуналь оешмалар комбинаты директоры Петр Иванович Каргин иде.
Судьяның аягүрә торып каршы алуы, аннары илтифат белән олылап «Петр Иванович» дип эндәшүе Каргинга уңай тәэсир итте.
— Иптәш судья, йомышыгыз булгач,— дип басым ясап башлады ул сүзен,— повестка җибәрү нигә кирәк булды соң?
— Йомышыбыз юк,— диде Маликов сабыр гына.— Судта сезгә каршы эш кузгатылды.
— Минем өстән? — Каргин урыныннан сикереп торды.
— Прокуратура аша дәгъва керде.
— Нинди дәгъва ул, Рәшит Маликович?
— Сездән 330 сум акча түләтү турында. Мәгез, танышыгыз!
Дәгъвада исә мондый юллар бар иде:
«Мин, Халикова Рәүфә Әмир кызы, кырык бер яшемә җитеп, шикаять язганым юк иде. Бүген мәҗбүрмен. Эшнең асылын аңлатып китим. Мин Кукмара коммуналь оешмалар комбинатында (директоры Каргин Петр Иванович) контролер булып эшлим. Өч ел буе бернинди кисәтү, шелтәсез әйбәт кенә эшләп киләм. Мактанып әйтүем түгел, яраттым мин хезмәтемне. Аның кешеләргә файдалы булуы миңа юаныч-сөенеч бирә иде. Тик минем бу сөенечемне көенечкә китереп җиткерделәр. Июльнең 21 ендә булды бу хәл. Комбинат башлыгы Каргин мине урамда очратып, аяктан егарлык сүз әйтте: «Үзегезгә башка эш табыгыз, мин сезне хезмәттән бушатам»,— диде ул. Ни әйтергә белми, ык-мык итеп тордым. Аннары: «Ни өчен?»— дип сорадым.
Каргин:
— Бик беләсең килсә, райбашкарма комитетына бар!— диде.
Райбашкарма комитетындагы иптәшләр чыннан да халне аңлатып бир-

деләр. Безнең комбинаттагы «бакчачы» штатын яртыга гына калдырырга кушылган икән. Мин — нәкъ шул бакчачы хисабына алынган хезмәткәр. Димәк, кыскарталар. Аптырап-йөдәп, председательнең үзенә кердем. Ул мине зур диккать белән тыңлады, рәхмәт үзенә.

«Сезне берничек тә эштән чыгара алмыйлар»,— диде ул.

Әмма моның да файдасы тимәде, чөнки Каргин кеше сүзен тыңлаудан узган иде инде. Рәсмиләштереп, гариза яздым, үзебезнең профсоюз комитетына мөрәҗәгать иттем. Местком председателе Дегтярев, гаризамны укып чыккач, башын чайкап куйды.

— Рәүфә апа, хуҗа ни кушса, шуны эшлим инде мин,— диде.

Шуннан соң күп ишекләрне шакыдым, дистәләгән җаваплы урын биләгән иптәшләрне борчыдым. Татарстан АССРның коммуналь хуҗалыгы министрлыгында да булдым. Министр урынбасары белән сөйләштем, файдасы тимәде. Мине эшкә кайтармадылар.

Бердәнбер юл, судка мөрәҗәгать итү генә калды...»

«Халык судына. Кукмара поселогы, Лев Толстой урамы ...нчы йортта яшәүче Р. Э. Халиковадан гариза.

Мин сездән... хезмәт турындагы бәхәсне, Совет законнары нигезендә тикшереп, хәл итүегезне сорыйм.

22 июльдә... мине эштән бушаттылар. Ләкин сүз бакчачы штатын кыскарту турында бара, ә мин өч ел буе контролер булып эшләдем.

Комбинатның профсоюз комитетында бу мәсьәлә мине эштән азат иткәннән соң, бер атна үткәч, үзем гариза биргәч кенә тикшерелде. Моны мин закон бозу дип карыйм.

Судка үтенечем шул: закон нигезендә, мине үз хезмәтемә кайтарыгыз, ирексездән эшләми йөргән көннәрем өчен хезмәт хакымны түләтегез. Р. Халикова».

— Халикованың дәгъвасы белән комбинат килешә алмый,— диде Каргин.— Мин шуны гына әйтә алам. Контролер вазифасын үтәсә дә, Халикова эшкә бакчачы итеп алынган иде. «Бакчачы» штатын кыскарту турында башкарма комитетның карары бар. Без шул карарны үтәдек. Коммуналь хуҗалык министрлыгында да аңлаштык, министр урынбасары, дөрес, дип тапты.

— Халикованы эштән бушату турындагы мәсьәләне профком карадымы? — Утырышчыларның берсе сорап куйды.— Сезгә рөхсәт бирдеме?

— Бирмичә! Әлбәттә бирде. Менә ул! Профком җыелышының беркетмәсе!

— Профком утырышы кайчан булды?

— Егерме тугызынчы июльдә.

— Ә иптәш Халикованы эштән бушату турындагы боерыкка имзаны егерме икесендә куйгансыз. Шулаймы? Сез, җитәкче буларак, РСФСРның хезмәт турындагы законнар кодексы белән таныштыр бит? Ялгышыгызны, закондагы кайсы таләпне бозганыгызны аңлыйсыздыр инде? — дип кызыксынды икенче утырышчы.

Каргин кабат әүвәлге рәвешенә керде.

— Нәрсә әйтергә теләгәнегез аңлашыла,— судья буш сүзне бүлдерде.— Кабатлап тору — артык. Соңгы сорау: ирексездән эшләмичә йөргән көннәре өчен Халиковага хезмәт хакы түләргә ризасызмы?

— Мин миллионер түгел, түли алмыйм.

— Хәзергә комбинат исәбеннән.

— Мин барыбер риза түгел.

Хөкем утырышында Халикова дәгъвасының нигезле икәнлеге тулысынча дәлилләнде. Суд закон сүзен әйтте. Хөкем карарында һәр нәрсә үз исеме белән аталган иде. Менә ул юллар:

«...РСФСРның хезмәт законнары турындагы кодексның 33 статьясы һәм РСФСРның гражданлык-процессуаль кодексының 14, 50 статьялары нигезендә Халикова Рәүфә Әмир кызын кире Кукмара коммуналь оешмалар комбинатына контролер итеп урнаштырырга, илле көн буе ирексездән ясалган прогул өчен комбинаттан Р. Ә. Халикова файдасына аның уртача хезмәт хакын юллап алырга...»

Ун көн вакыт үтте. Ике яктан да дәгъва-фәлән булмады. Шулай итеп, суд карары закон көченә керде. Хәлбуки, Рәүфә Халикова эшкә кайта алмаган. Ни өчен? Халикованың тагын бер хатына әйләнеп кайтыйк.

«Судта үзенең оттырганын төшенгәч, Каргин миннән үч алу юлларын

эзли башлады... Ул барлык контролерларга катгый боерык биргән: «Халикова эшләгән дәвердә булган бөтен кимчелекләрне ачыкларга!» Алар тапканмы, юкмы — анысы миңа караңгы. Ә баш бухгалтер Гвоздева тапты. Беркөнне ул миңа:

— Ведомостьларны төзәтеп, җиде сум ун тиен акча үзләштергәнсең — димәсенме?!

Моны ишеткәч, исем-акылым китте. Ул әйткән, «үзем төзәткән» ведомостьны күрсәтүне үтенгәч, Гвоздева:

— Моннан тизрәк ычкын! — дип акырынды.

Бик гарьләндем. Адым саен диярлек кимсетү, урынсыз рәнҗетү, ямьсез кычкыруларга тап булгач, гайрәтем чигә башлады. Шулай да үземдә бу буталчык уйлардан арынырлык көч таптым. «Хокукың башка кешеләрнеке белән тигезме? Тигез! Гадел законнарыбыз бармы? Әйе, илебезнең законнары гадел». Шуларны уйладым да яңадан комбинатның профсоюз комитетына килдем. Местком председателе иптәш Дегтярев, комбинат директорының әмере белән, кабат профком утырышы җыя. Әмма шунда исәптә торучы Халикованы чакырырга «оныта». Үзем катнашмаган утырышта «Халикова контролер булып эшләрлек түгел, миңа хакы юк», дигән карар язып куялар.

Шуңа нигезләнеп, Каргин мине 1 октябрьдә яңа оештырыла гына башлаган электр челтәре конторасына күчерә. Әлеге оешмада эшләү өчен, бердән, махсус белем кирәк, икенчедән, анда хатын-кызларны, гомумән, эшкә алмыйлар икән. Шулай итеп, мин 24 сентябрьдән бирле, суд карарын куен кесәмә салып, җир белән күк арасында йөрим...

Хөрмәтле иптәшләр! Сездән совет законын тормышка ашыруда ярдәм итүегезне сорыйм».

Халикованың хаты Татарстан АССР прокуратурасына юлланган иде. Шул көнне үк Казан белән Кукмара арасында сөйләшү булды:

Казан: Республика прокуратурасыннан бу. Кем тыңлый?

Кукмара: Район прокуроры.

Казан: Коммуналь оешмалар комбинатында эшләгән Рәүфә Халиковадан дәгъва бар. Нишләп эшкә урнаштырмыйсыз?

Кукмара: Урнаштырдык, күптән инде... Әйе, 24 сентябрьдә суд булды, анда прокурор ярдәмчесе дә катнашты.

Казан: Гариза судтан соң, бер ай узгач, язылган.

Кукмара: Суд карарына каршы төшүче дә, жалоба бирүче дә булмады. Карар 4 октябрьдә закон көченә керде.

Казан: Шулай булгач, нишләп ул карарны тормышка ашырмыйсыз?

Кукмара: Бүген үк тикшерербез, хәбәр итәрбез.

Казан: Яхшы, сезгә ике көн вакыт бирелә.

Рәүфә Халикова директоры белән суд залында кабат очраша. Судья Маликовның хөкем карары исә Халиковага чыннан да гаделлек, дөреслек җиңүе булып тоела.

«Кукмара халык судының 24 сентябрьдә чыгарылган карары нигезендә Халикова Р. Ә. кире үзенең эш урынына кайтарылырга тиеш иде. Комбинат җитәкчеләре моны үтәми. Шул сәбәпле Халикова ике ай буе эшләми торырга мәҗбүр була, матди зыян күрә. РСФСРның хезмәт турындагы законнар кодексының 214 нче статьясы нигезендә, суд коммуналь оешмалар комбинатыннан Р. Ә. Халикова файдасына аның эш хакын юллап алырга карар чыгара. Судья Р. Маликов, халык утырышчылары С. Гыйльмуллина, Н. Шакирова».

Кулына суд мөһере сугылган карар алса да, Халикова бу юлы куанырга ашыкмады. Кем белгән, бәлки карарның монысы да утәлмичә калыр? Хәлбуки, Халикованың шөбһәсе урынсыз була. Беренче карардан соң «авызы пешкән» Рәшит Маликович бу юлы дилбегәне кулыннан ычкындырмый. Халикова кире үз эшенә кайтартыла. Икенче көнне үк суд башкаручысын җибәреп, эшсез йөрергә мәҗбүр булган көннәр өчен Рәүфә Әмировнага тулысынча хезмәт хакы түләтә. Зыян тулысынча Каргинның үз кесәсеннән алына. Озак та үтми, ул директорлыктан да колак кага.

Бу эш бер кеше язмышы өчен барган көрәш кебек кенә күренсә дә, халык судьясы Рәшит Маликов аның тирәндә яткан мәгънәсен яхшы аңлый. Шунлыктан, һәрвакыттагыча, ул бу юлы да совет законын боздыртмау чарасын күрүдә җаны-тәне белән тырышты.



*Татарстан — туган төбәгем*

**М. Ш. Хөсәенов,**

КПССның Питрәч райкомы беренче секретаре

# ЛЕНИН ЮЛЫННАН

Сүз башында ук бөек юлбашчыны телгә алуымның аерым мәгънәсе бар: Володя Ульяновның революцион көрәшкә беренче адым ясавы районыбыз тарихында иң мөһим сәхифә булып тора. Владимир Ильич 1887 елның 7 декабреннән 1888 елның 15 сентябренәчә хәзер безнең районга караган Кокушкино авылында сөргендә була. Монда Володяның әнисе Мария Александровна Ульянованың яшьлек еллары узган. Ул унике яшеннән алып 28 яшенә кадәр әтисенең шушы авылдагы утарында тәрбияләнә. Мария Александровна белән Илья Николаевич Ульяновның никахлашуы да Кокушкинодан ерак булмаган Черемышев чиркәвендә теркәлә.

Мәгълүм булганча, күптән түгел Казан университетында студентларның Володя Ульянов катнашында үткән революцион сходкасының 100 еллыгы ил күләмендә билгеләп узылды. Бу уңайдан без Ленино-Кокушкино авылындагы В. И. Ленин музей-йортын өр-яңадан яхшыртып куйдык. Хәзер музей, В. И. Ленинның беренче политик сөрген урыны буларак, мемориаль заповедник хәленә китерелде. Аның мәйданына утар үзе дә, XIX гасырга караган берничә йорт та, авыл да, юлбашчының якыннары күмелгән каберлек тә керә.

Кокушкино соңгы елларда танымаслык үзгәрде. Яңа ташпулатлар, кунак йорты, һөнәр училищесы, зур мәктәп, культура һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү биналары үсеп чыкты. Олы юл, авыл ямен җибәреп тормасын өчен, ындыр артыннан уратып салынды.

Кокушкиноның тагын бер мактанычы бар әле. Бу — аның Шушенское авылы белән элемтәсе. Кокушкино һәм Шушенское Ленин биографиясендә әһәмиятле сәхифәләр: аларның икесендә дә юлбашчы сөргендә булган. Безнең дуслык күптәннән килә. Питрәч районы Шушенский районы белән, «Ленино-Кокушкино» совхозы Себердәге В. И. Ленин һәм Н. К. Крупская исемендәге совхоз белән ярыша. Аерым кешеләребез дә үзара ярышалар. Бу күренеш дуслыгыбызны тирән эчтәлекле, эшлекле, иҗади итә. Район хезмәт ияләре планнарын, тәҗрибәләрен үзара уртаклашалар, хат язышалар, кунакка йөрешәләр.

Питрәч кешеләре В. И. Ленинның революцион эшчәнлегендә районның билгеле бер урын тотуы белән горурланалар. Бу — күп еллардан бирле халыкның канына сеңгән тойгы. Кокушкинодагы музей-йорт 1939 елның 22 апрелендә үк ачыла. Аңа ел саен җитмеш меңләп кеше килә. Кунаклар арасында илебезнең һәр ягында яшәүчеләр генә түгел, чит ил кешеләре дә шактый.

22 апрель саен районыбыз хезмәт ияләре музейга митингка җыелалар, юлбашчы туган көнне тантаналы төстә билгеләп үтәләр. Хезмәт коллективлары Ильичка уңышлары турында рапорт бирә, яшь егет-кызлар монда комсомолга керә, мәктәп балалары пионер галстугын беренче мәртәбә монда бәйли. Аларны, яшь ленинчыларны, хезмәт һәм сугыш ветераннары котларга килә. Эш кешеләре исә, социалистик ярышта җиңеп чыксалар, музейга килеп, Ленин хөрмәтенә төзелгән экспонатлар белән кабаттан очрашу мөмкинлеге алалар.

Ленинга биргән антыбызны әледән-әле шулай яңартып торгангамы, эшләребез гел алга бара кебек. Билгеле булганча, Питрәч районы — республикабызның төньягына урнашкан, шәһәр яны районнарының берсе. Ул 1930 елның 10 августында оештырыла. Мәйданы — 1362 квадрат километр, халык саны 28 меңнән артыграк. 52 процентын — татарлар, 46 процентын — руслар, башка милләт вәкилләре ике процент тәшкил итә.

Район халкы, башлыча, авыл хуҗалыгы белән шөгыльләнә: басуларыбызда бөртекләләр, кузаклылар, азык чөгендере, бәрәңге һәм яшелчә гөрләп үсә, фермаларыбызда

утыз меңләп мөгезле эре терлек бар, дуңгыз симертәбез, җиде йөз меңнән артык кош-корт асрыйбыз.

22 колхоз-совхоз арасында җиде хуҗалык махсуслаштырылган. Кощак совхозы җәнлекчеләренең даны республикадан ерак-еракларга мәгълүм. Моннан тыш нәселле кошчылык белән шөгыльләнүче, бозаулар үстерүче, дуңгыз симертүче, мөгезле эре терлек асраучы, бөртекле ләрне орлыкка үстерүче, шәһәр өчен җиләк-җимеш өлгертүче махсус хуҗалыкларыбыз бар. «Казан» совхозында, мәсәлән, елга 300 тонна җиләк-җимеш суы әзерли торган цех төзелде.

Кошчылык фабрикабыз, республикада иң алдынгылардан саналып, ел саен 63 миллион йомырка, 800 тонна кош ите җитештерә. Хуҗалыгыбызда, башка төбәкләрдән аермалырак, тагын бер тармак — балыкчылык тармагы бар. «Үшнә» балыкчылары ел саен 250 тонна карп сата. Казан атлар заводының безнең райондагы бүлекчәсендә исә тәнгә сихәт бирүчән һәйбәт кымыз әчетәбез.

**Туган җиребезнең иң матур почмагы итеп Мишә су буйларын күрсәтер идем.** Монда безнең табигый болынлыклар җәелеп китә. Ярларында мәһабәт наратлар, таллыклар, карлыган куаклары тезелгән. Алар арасында киек рәхәтләнә. Шунлыктан бу тирәләрдән балыкчылар, аучылар, гөмбә-җиләк, дару үләннәре җыючылар өзелеп тормый.

Төбәгебез табигатендәге һәм хуҗалыгындагы муллыктан бигрәк уңганнары, күренекле шәхесләре белән горурланып яши. 1941 ел вакыйгаларына кайтып, «Брест крепосте»н искә төшерсәк кенә дә якташыбыз, татар егете Петр Михайлович Гавриловның тиңдәшсез батырлыгы турындагы бай хатирәләр эченә кереп чумар идек. Ул үзенең «Брест крепосте» китабында мондый юллар язган: «...Мин еш кына кулларыма крепость стенасыннан фашист снаряды кыеп төшергән кирпеч кисәген алам. Брестка бер баруымда истәлеккә алып кайткан идем. Карыйм да күз алдымда ут дәрьясы, бомбалар шартлавы, үлем сибүче кургашын яңгыры, крепостьны саклаучыларның шул дәһшәт астында атакага ташлану күренешләре яңара. Миңа да крепость оборонасында катнашырга туры килде. Бу бәрелеш Бөек Ватан сугышы елъязмасына алтын хәрефләр белән язылган».

Безнең Әлбәдән авылы егете Петр Михайлович бу коточкыч сугышта, тәмам хәле китеп, аңын югалткач кына тынып кала. Фашистлар үзләре дә аның фидакарьлегенә хәйран калалар. Бу кыюлыгы өчен П. М. Гавриловка Советлар Союзы Герое исеме бирелде. Хәзер аның туган авылындагы колхоз П. М. Гаврилов исемен йөртә, Әлбәдән мәктәбендә аңа багышланган музей эшли.

«1939 елда мин, Армиягә китәр алдыннан, В. И. Ленин музей-йортына килеп, Кызыл Армиягә тугры хезмәт итәрмен, дип, юлбашчы истәлеге алдында ант эчтем. Бөек Ватан сугышы башлангач, антымны яңартып, явыз дошманнан үч алырга ашкындым.

Менә мин кабат синең каршыңа килдем, рапорт бирәм: без җиңдек, иптәш Ленин! Мин гади колхозчы идем, сугыштан Советлар Союзы Герое булып кайттым. Гомерем буе илгә тугры хезмәт итәргә кабат вәгъдә бирәм!»— Бу юлларны 1945 елда музейдагы дәфтәргә Кокушкино авылы егете Галимҗан Камалиев язган. Ул әле дә исән-сау, пенсиядә. Аны яшьләр арасында бик еш күрергә мөмкин. Геройлар ял итеп ятамы соң?! Галимҗан ага зур тәрбия эшләре алып бара.

Неялово авылыннан киткән егетебез Василий Осиповка Герой исеме һәлакәтеннән соң бирелә. Днепрны беренчеләрдән булып кичеп чыкканы һәм батырларча сугышкан өчен Советлар Союзы Герое булган бу каһарманыбызның яу кырында үлеп калу хәбәрен ишетү аның әти-әнисенә аеруча авыр тәэсир итте, чөнки моңа кадәр дә аларның ике уллары батырларча һәлак булган иде инде.

Яу батырларыннан тагын бер батыр якташыбызны, танк дивизиясе командиры, генерал А. Т. Мишанинны да күрсәтеп китәсе килә. Могилев шәһәрен азат итүдә катнашып даның бөтен илгә тараткан унсигез яшьлек егетебез Федор Ионовны да әйтми ярамас. Ул Могилевка беренчеләрдән булып барып керә һәм берүзе фашистларның штабын әсир төшерә. Штаб белән бергә ике генерал да кулга төшә. Тиңдәшсез батырлыгы өчен Федорга сугышчан Кызыл Байрак ордены бирәләр.

Районыбызда туып-үскән язучылар Сафа Сабиров, Камил Кәримов, җырчы Зөфәр Хәйретдинов — безнең горурлыгыбыз.

Питрәч яклары хезмәт батырларына да бай. Мәрфуга Шәйхиева белән Надежда Галочкинаның тырышлыгы Социалистик Хезмәт Герое исеменә лаек булды. Алардан башка уңганнарыбызның орден-медальләрен санап чыгу өчен бик күп вакыт кирәк. Шулай да кайберләрен телгә алмый мөмкин түгел. Әйтик, егерме сигез ел буе «Россия» колхозын җитәкләүче тәҗрибәле председатель, ТАССРның атказанган агрономы Иван Федорович Ларионов. Игенче баласы ул. Электромонтер булып та, агроном булып та эшләде. Ленин ордены, Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары бар. Партиянең XXV съездына делегат итеп сайланды, ТАССР Верховный Советы депутаты. Кешеләрнең кадерен белә, өйрәтә, үзе дә өзлексез өйрәнә. Хәзер бу колхозда гектарыннан егерме бишәр центнер

уңыш алалар, һәр сыердан савылган сөт елга дүрт мең литрга якынлашып килә.

Кощак совхозы директоры, РСФСРның атказанган зоотехнигы, авыл хуҗалыгы фәннәре кандидаты Нәгыйм Вәлиев, «Татарский» һәм «Казан» совхозлары директорлары Равил Шәрипов белән Валентин Кулагин турында да җылы сүзләрне һич кызганмый әйтергә мөмкин.

Хәзер районда, илебезнең һәр ягындагы кебек үк, тормышны үзгәртеп кору өчен көрәш бара. Социалистик ярыш шартларын яңарттык. Ни дисәң дә, тырышлыкның нәтиҗәсе ярышта ачык күренә, шунлыктан бу мөһим чарага җитди карарга кирәк. Хәзер без сыйфат ягына аерым басым ясыйбыз. Мәсәлән, сөтнең кимендә 90 проценты беренче сортлы булмаса, күпме сатуына да карамастан, хуҗалык җиңү Байрагыннан мәхрүм ителә.

Ункөнлекләрдә җиңеп чыгучыларга Социалистик Хезмәт Герое Мәрфуга Шәйхиева исемендәге күчмә кубок тапшырыла. Вахитов исемендәге колхозда сыер савучы, тракторчы, шофер һәм дуңгыз симертүчеләргә билгеләп куелган дүрт күчмә кубок бар. Җиңүче, кубок белән бергә, Мулланур Вахитов исемендәге премияне дә ала. Башка хуҗалыкларда да үзләренә генә хас ярыш шартлары һәм бүләкләр билгеләнгән. Төрле һөнәрләр буенча махсус исемнәр, дәрәҗәле дипломнар бирү, конкурслар оештыру гадәткә әйләнеп китте.

Хезмәт коллективларының иҗат отчеты кебек бик җаваплы чара уздыру район тормышын тагын да җанландырып җибәрде. Отчет район культура йортында мәртәбәле кунаклар алдында ясала. Аңа хуҗалыклар бик бирелеп әзерләнәләр.

«Беренче көлтә», «Беренче буразна» бәйрәмнәре дә кешеләребезнең күңелен күтәрә, аларны фидакарь хезмәткә дәртләндерә. Башлангыч партоешмалар бу чараларны уңышлы уздыру өчен бөтен сәләтләрен эшкә җигә. Партиянең район комитеты исә, үз чиратында, башлангыч оешмаларга ярдәм итәргә әзер тора. Шул рәвешле без һәр кеше белән элемтәдә булуга ирешәбез.

Үзгәртеп коруларга бәйле төстә без авыл хуҗалыгы эшенең кайбер якларын башка юнәлешкә боруны кирәк таптык. Игенчелектә дә, терлекчелектә дә интенсив технологиягә йөз тотабыз; хуҗалык исәп-хисабына эшләүче һәм уртагыннан түләүле хезмәттәге коллективлар барлыкка килде. Кырчылык, дуңгызчылык, сарыкчылык тармаклары тулаем уртагыннан түләү ысулына күчтеләр. Сөтчелекнең 84 проценты ике сменалы эшкә көйләнде.

Менә шушындый чаралар аркасында районның хуҗалык эшләре сизелерлек алга китте. Бөек Октябрь социалистик революциясенең 70 еллыгын лаеклы каршы алу өчен оештырылган социалистик ярыш нәтиҗәсендә район уникенче бишьеллыкның ике елы планын вакытыннан алда үтәп чыкты. Хәер, башкача булырга мөмкин дә түгел. Без бит — Владимир Ильич Ленинның якташлары, аның идеяләренә тугрылыгыбызны бары тик намуслы эш белән генә раслап күрсәтә алабыз.

# ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

*Бәхәс дәвам итә: «Заман һәм шигырь»*

## ҮЗЕҢНЕ ТАП, ШАГЫЙРЬ!

Татарстан китап нәшриятының баш редакторы В. Нуруллин белән тән-
кыйтьче Р. Мостафинның матур әдәбият әсәрләрен бастырып тарату һәм
китапларыбызның рухы, матди кыйммәтләренә кагылышлы борчулы
әңгәмәсе безне үсеш процессындагы проблемалар турында җитди, зур
уйлануларга чакыра. Шунда ук әдәбиятыбызның үрнәкләрен дөньяга чыгаруда нәш-
рият эшендәге оешмаганлык фактларының, принципсызлыкның, кода-кодагыйлык-
ның зарары, матбугат һәм китап басу эшендәге работникларның тормыш белән бергә
атлау зарурлыгы турындагы сөйләшүләр дә килеп кушылырга тиеш. Һәм сөйләшү-
ләребез электәге байтак дискуссияләрдәгечә формаль булмасын, ә конкрет рәвеш
алсын, күренерлек нәтиҗәләр дә бирсен иде.

Чынлап та, кемнәр укылмый, кайсы язучыларыбызның китаплары пәрәвез җебе-
нә уралып ята? Кемнәр һәм нигә чыгарганнар ул макулатураны? В. Нуруллин хаклы,
иң укылмаганы — шигырь китаплары. Ләкин монда да ачыклык кертү кирәк. Мо-
раль тузудан Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил яисә Ф. Кәрим, Х. Туфан китаплары
түгел, ә башлыча күп санлы замандаш шагыйрьләрнең җыентыклары җәфа чигә.
Уфадагы Н. Крупская исемендәге республика китапханәсендә татар шагыйрьләре-
нең ничек укылуы белән кызыксынган идем. И. Юзеев, Ш. Галиев, Зөлфәт, М. Әгъ-
ләмов, З. Насыйбуллин, Р. Миңнуллин кебек шагыйрьләрнең китаплары укучылар
кулында йөрсә, байтак авторларныкына онытылганда бер кул тия икән. Ә дистәләрчә
татар шагыйрьләренең җыентыкларын формуляр куяр өчен генә ачып япканнар...
Ник болай бу? Хәзерге халыкның рухи кыйммәтләргә игътибары җуелганмы? Матур-
лыкка, әхлаки сафлыкка, хакыйкатькә омтылышлары зәгыйфьме безнең замандаш-
ларның? Юк, әлбәттә! Халык шигырь яратмый дип кенә котылып булмый. Сүзне
фәкать байтак шагыйрьләрнең халык зәвыгына туры килерлек, омтылышларын ка-
нәгатьләндерерлек иҗат юлында булмавы турында гына алып барырга кирәк.

Хәзерге күп шагыйрьләрнең иҗатларында торган төп мәсләге, язу манера-
лары, принциплары турында уйланганда мин бик еш Р. Фәйзуллинны, аның бер
фикерен искә төшерәм. Әдәбият галиме И. Нуруллин белән булган билгеле бер әңгә-
мәсендә ул: «Шагыйрьләр әүлия түгел. Абсолют хакыйкатьне әйтергә алынучылар да
түгел. Алар халык алдында үз-үзләре белән сөйләшә», дигән иде. Шулай микән,
шагыйрь өстенә төшкән бурычларны төгәл аңлап эш итү микән бу? Атаклы Пушкин,
Лермонтов яисә үзебезнең Тукай, Такташ, Җәлил һәрчак үз сүзләрен укучыны истә
тотып, укучыга төбәп әйттеләр. Хәтта вакыты-вакыты белән бу янәшәлек хисе Ту-
кайдагыча тышка да бәреп чыга иде: «Аз гына сабрит әле, и кариэм (укучым)!
Хәзер язам... Кариэм, күрдеңме инде яшь җегетнең кармагын!..»

Билгеле инде, шагыйрь һәм укучы берлеге кайбер тышкы чагылышлары белән
генә түгел, ә шагыйрь каршына эчке, нигез таләпләр куюы белән кыйммәтле булды.
Укучысын якын тойган шагыйрь, һичшиксез, конкрет халык массасын, аның мән-
фәгать-омтылышларын, сыйфатларын бик яхшы белергә һәм, иң мөһиме, әйтәсе уй-
фикерен уйлап, шуларның әһәмиятен ачыклап, сәнгатьчә төгәлләнгән халгә җитке-
рергә тиеш. Шунсыз әсәрләрнең халыкка барып ирешмәячәген нечкә аңлап иҗат
иттеләр мәшһүр шагыйрьләр.

Бүгенге шигырь авторлары исә конкрет укучы белән гәп алып барудан бигрәк,
үз-үзләре белән сөйләшәләр, шуңа омтылалар. Моны хәзерге поэзия тәнкыйте дә
ачык раслый: «Татар поэзиясендә хәзер лирика хакимлек итә. Бигрәк тә уйланулар,

лирик «мин»нең кичерешләрен ачып салу рәвешендәге шигырьләр аеруча күбәйде»,— дип яза, мәсәлән, Ф. Зөлкарнәев. Яхшымы бу, начармы? Мондый омтылыш Р. Фәйзуллинның үзе һәм бик күп яшь каләм ияләре тарафыннан безнең поэзиядә интим лириканы, самимилык, әчкерсезлек, ихласлылык кебек макталган байтак сыйфатларны үстерергә ярдәм итәргә тиеш, дип фараз итеlә. Әйе, күпмедер дәрәҗәдә бу шулай. Безнең соңгы еллар лирикасы чиксез интимлашты...

Ләкин изге ниятнең үзенә башка нокталардан торып, текәлебрәк карасаң, күп авторларның укучыларын җуюы нәкъ менә үз шәхесләре белән мавыгып, җавапсыз сөйләшкә чумуларында түгелме соң? Андыйларда темалар ваклана, сүзнең иҗтимагый җегәрлеге кими, аныксыз тойгылар, чәбәлчек хисләр өстенлек ала. Әйе, үз-үзе белән сөйләшкән шагыйрь барысын да кәгазьгә сибәргә, димәк ки, шигырь итәргә хаклы. Монда иң аяныччлысы шагыйрьне азган-тузган хәлдә күрү, синең белән сөйләшүгә әзер булуын тоймау түгел әле. Күңелне әрнеткәне бүтән: шигырь дигән олы, изге төшенчә ваклана, көндәлек, гадәти күренешкә, күпләр өчен кәсепкә әйләнеп китә ул. Соңгы еллар поэзиясендәге: «Тел очымда — шигырь, баш очымда, шигырь булып күренә тирә-юнь» (Ф. Гыйззәтуллина) кебек раслауларны яисә «Һәр хыялны, уйны, шикне җыр итү» (Р. Гатауллин) омтылышларын шәхсән бүгенге шигырьнең ваклану, абруе төшү факты дип исәплим. Өстәп шуны да әйтергә кирәк, вак масштаблы, күп санлы шигырьләр йөрәк кичерешләре, чынбарлыктан килгән катлаулы тойгылар булудан бигрәк уйланма, бүлмә әсәрләре төсендә дөньяга килә башладылар.

«Ни өчендер соңгы вакытларда «сюжетлы» шигырьләр кимеде. Һәрбер шагыйрь — һәм олысы һәм кечесе — үзен тәкъдим итәргә, үзенең уй-фикер хәзинәсен укучыга тагарга тырыша. Ярый ла, ул кызыклы шәхес булса, хәзинәсендә игътибарга лаеклы «энҗеләр» табылса...» — дип пошынып язды бертөрле, уйланма шигырьләр турында профессор И. Нуруллин.

Бертөрле шигырьләр белән бертөрле шагыйрьләр күбәйде бездә. Шагыйрьлек төшенчәсе, шулай ук, гадәтиләнде, төште. Күреп, сизеп торабыз, күп авторлар хыялда йөрткән шагыйрь образына туры килә алмый, җавап бирми бу изге исемгә. Шуңа да күңел Р. Фәйзуллинның «Шагыйрьләр әүлия түгел. Абсолют хакыйкатьне әйтергә алынучылар да түгел», дип күрә торып шуларны яклаган, аклаган тезисы белән килешми. Шагыйрь шагыйрь инде ул! Үз халкының, заманының рухын, уй-омтылышларын, зәвыгын гаять нечкә тойган һәм шуларны башка бер кем дә ирешмәслек итеп шигырь, җырларында гәүдәләндерә алган кеше. Чын шагыйрьлек халык рухындагы кабатланмас һәм онытылмас бер хатирә, әз бит ул!..

Р. Фәйзуллин белән бәхәсләшүем юкка түгел. Күңел иҗат эшенә кагылышлы төп мәсьәләләрдә, нигез эстетик фикерләүләрдә әлекке әдәби казанышлардан күп кенә читкә тайпылулар, ташламалар барлыгын сизә.

Хәзерге шигырь китапларының бәясен һәм популярлыгын күтәрү эшен шагыйрь җилкәсе өстенә төшкән катлаулы бурычларны һич компромиссыз, дөрес һәм нечкә аңлаудан башларгадыр бәлки?

Шагыйрьлекне нечкә аңлау... Бу — әлбәттә, зур, көчле талантлар өлеше. Талантларга акыл бирү омтылышы юк миндә... Шулай да хәзерге поэзия вәкилләренең акланмас дәрәҗәдә фәлсәфә белән мавыгуларын, уй-фикер чыгарырга тырышуларын күрү тагын тәүбәне бозып куя. Бүгенге байтак рационалистик шагыйрьләр борынгы татар шигыре һәм Г. Тукай, Һ. Такташ, М. Җәлил, Ф. Кәрим традицияләре җирлегендә үскән сюжетлы, конкрет картиналы, образлы милли шигырь белән янәшә ясалма рәвештә верлибрны яшәтергә тырышалар. Хәтта аерым яшь шагыйрьләрдә лириканы «хис шигыре», «акыл шигыре» кебек аерым кырларга бүлгәләп, соңгысының бик күп өстенлекләрен раслап, бары верлибрга гражданлык хокукы бирү омтылышы да булмады түгел. Хәер, боларны хәзер аерым шагыйрьләрнең үсү юлындагы мавыгу, ялгышулар итеп кенә кабул итәбез. Ләкин барыбер күп шагыйрьләрдә, юшкын кебек утырып, акыл культы хуҗа булып калды. Мондыйларда шигырь төшенчәсе иң әлек фәлсәфә белән ассоциативлаша. Әмма бары тик фәлсәфә сатып шигырьдә уңыш казанырга җыенган авторга шикләнеп, өметсез карыйм мин. Юк, бу минем хәзерге татар поэзиясендәге һәм тәнкыйтендәге агымнарны яклауга яки инкяр итүгә кушылырга тырышуым түгел, бәлки үземнең эчке уйлануларым, ышануым нәтиҗәсе.

Сәнгать минем каршымда сурәт, образлар ярдәмендә кешедә билгеле бер тойгы, хисләр хәрәкәте барлыкка китерүче һәм шуларны үстерергә, тәрбияләргә мөмкинлек бирүче рухи өлкә булып тора. Хисләр хәрәкәтенең төп чыганагын драматизм — чынбарлыктан килгән хәл-вакыйгалар киеренкелеге һәм кискенлеге үти. Драматизм — ул хисләр генераторы. Драматизмның укучыда танып-белү омтылышы уятуда һәм тәрбия бирүдә әһәмияте ифрат зур. Кеше үз тормышында очраган социаль һәм рухи кыенлыкларны, фаҗигаларны ничек җиңеп чыга, моның өчен нинди көчләргә ия

була ул?.. Кешенең сәнгать белән кызыксынуында, сәнгатькә тартылуында төп нигез сәбәпләр булып менә шулар ята һәм алар ук сәнгатьне иҗтимагый әһәмиятле итә.

Чын шагыйрьләрнең кайсына гына мөрәҗәгать итсәң дә, әсәрләрендә тарихи конкрет, иҗтимагый-политик ситуацияләрдән килеп туган драматизм чагылышы сизелер. Катлаулы шартлардагы рухның теге яки бу сыйфатлары балкыр, алар сине сокландырыр һәм үзеңдә дә шул сыйфатларны тәрбияләү ихтыяҗы тудырыр.

Кайбер яшьләр мөкиббән киткән акыл шигыре шул хасияткә ияме соң? Мөгаен, юк! Чөнки бу шигырьдә драматик ситуация корырга мөмкинлек биргән җанлы чынбарлык — сюжет, образ, картина юк. Ә фәлсәфә ярдәмендә драматизм тудыру мөмкинлеге бөтенләй чикле. Димәк, бу очракта укучыда хисләр хәрәкәте дә кузгалмый дигән сүз. Бу мөнәсәбәттә арабыздан бик иртә, таланты чәчәк аткан вакытта киткән башкорт тәнкыйтьчесе Ким Әхмәтьяновның «Матурлык. Батырлык. Шигърият» китабыннан бер өзек китерәсем килә: «Философик лирика дип алдану лирик герой белән укучы арасына киртә булып килеп баса. Шагыйрь шатлык чәчә, ә укучы ваемсыз кала. Автор моңсулана — укучы кәефле. Шагыйрь уйлана — укучы моңсыз кала... Монда бернинди дә парадокс юк, лирик геройны уйланырга-хисләнергә мәҗбүр иткән тормыш факты үзе әсәрдән читтә кала. Поэтик сөземтә бар, шул сөземтәгә китерүче факт яки хәл-вакыйга юк. Сөземтәдә философик лирика урынына акыл сату килеп чыга».

Әйе, хәзерге формасындагы акыл шигырендә хисләнү хасияте чикле. Сәнгать законнарына артык буйсынмый верлибр. Әмма минем шәхсән акылга каршы кеше булып күренергә һич исәбем юк. Шигырь өчен акыл, фикер, уй бик-бик кирәк. Уйсыз шигырь канатсыз кош кебек тәмам гарип бит ул... Әмма минем фикерләүләрем җепнең ике очын да кулында тотып ямау салырга тырышкан кешене хәтерләтә түгелме соң? Андый гаҗизлек юк. Шагыйрь акылы укучыга сәнгать чаралары аркылы барып ирешсен — бөтен таләп бары тик шунда. Ягъни шагыйрь уй-фикерен атап түгел, бәлки тасвирлап бирсен. Идеяләрен ул укучыга көчләп такмасын, ә образлы сурәт, дулкынлану, хисләнү аша алар аңа үзләре юл ярсыннар...

Фәлсәфи шигырь, верлибр — бездә әле яңа жанр. Ул татар поэзиясенең үзенең эчке үсеш таләпләреннән бигрәк, башка әдәби җирлектән күчерелде. Хәзерге татар шигыре сәнгатенең сыйфатын күтәрү, популярлыгын арттыру, минем уемча, һичшиксез, иң әлек, акыл шигыре проблемаларын хәл итүгә бәйле. Безнең шагыйрьләр менә шушы хәлне бик истә тотсыннар иде. Шигырьнең укучыны җәлеп итү, тарту көче бөек, катлаулы яки сенсацияле идеяләр, фикерләр әйтүдә түгел, ә иң әлек сәнгатьчәлектә, дулкынландыру һәм эстетик зәвык бирү хасиятендә! Сорау һаман шул килеш кала: бездәге шигырь язган һәрбер автор да шагыйрьлекне нечкә аңлап эш итәме икән?

Әмма шагыйрьләр хакында уйлануларым бетмәде әле. Дөрес аңласам, В. Нуруллин нәшрият кешесе буларак, үзләрендәге аерым көйсезлекләрне бетерүнең һәм чыгарган китапларының дәрәҗә-бәясен күтәрүнең төп юлын Язучылар союзы членнарының санын чикләүдә күрә шикелле. Янәсе, Союзга һәр ел саен унар кеше алмасалар, нәшрият тирәсендә уралучылар азрак булыр иде... Юк, яшьләрнең профессиональ иҗатка килү юлын ясалма киртәләр корып тоткарлау дөрес булмас. Без әдәби талантларга мохтаҗбыз. Безнең сатириклар һәм трагикларга да, юмористлар һәм лирикларга да ихтыяҗыбыз бик зур әле. Безгә политик шигырь, фәлсәфи шигырь, мәхәббәт, пейзаж шигыре өстендә эшләүчеләр дә, җыр язучылар да, поэма, баллада, либретто иҗат итүчеләр дә, хәтта шигъри повесть, шигъри роман бирүче эпик колачлы шагыйрьләр дә, тәрҗемәче шагыйрьләр дә кирәк. Тик аларның һәрберсе кабатланмас каләм осталары гына булсыннар!

Хәзергә исә татар поэзиясе бары тик бертөрле шагыйрьләр — лириклардан гына гыйбарәт. Хәер, бу хакыйкатьне бик төгәл итеп Ә. Баянов әйткән иде инде:

«Шигырьгә яшьләр соңгы елларда бертөрлерәк килә. Биографияләре, темалары, тойгылары, хәтта сурәтләү алымнары, детальләре бер үк. Фамилияләрен күрсәтмичә, кулъязмаларын бергә куйсаң, болар бөтенесе бер авторныкы дип уйларга мөмкин».

Безнең җитмешенче елларда шигырь мәйданына килгән дистәләрчә авторларның китаплары да, ике тамчы су кебек, бер-берсенә охшашлар. Китап киштәләренә менеп кунаклый барган кайсы гына шигырь җыентыгын кулыңа алып укый башлама, сине инде күңел кайту биләп ала. Әйтелгән иде бу... Монысы да булган иде бит!.. Лирик геройның янып яшәргә ант итүләре, романтик хыял-ашкынулары, ярату-нәфрәтләнүләре яисә сагышланулары әллә кайчан таныш бит сиңа. Син аларда безнең заманның стандарт бүлмәләрендә йөргән кебек баш әйләнү, адашу хисе кичерәсең.

Әнә Р. Низамиевның лирик герое сине туган йортына чакырып ала:

*Әнкәй мичтән ипи алган ич,*
*Ак җәймәгә тезеп салган ич!*

Дәшкәч, З. Мансуровның героена да кунак булып керәсең:

*Мичтән ипи чыгаргандыр әни —*
*Мендәрләргә тезеп салгандыр.*

Һәй, Р. Миңнуллинда да шул ук хәл-күренеш икән!

*Өйдә рәхәт,*
*Өйдә — ипи исе.*

Ипи исләре бик татлы, әниләре бик мөлаем, сөйкемле кешеләр булса да, үзеңне төлке кунагы торна хәлендә хис итеп, тыштан рәхмәтләр әйтеп,ә эчтән тәмам гарьләнеп автордан китеп барасың. Һәм синең мондый алдануларың яшьләрнең китапларын укый барган саен көчәя, арта гына бара. Әйтик, Ф. Кәрим, И. Юзеев кебек остазларыннан алып, Х. Әюпов та, З. Мансуров та, Р. Низамиев та, Ф. Сафин да, тагын әллә кемнәр дә «күңелләрне айкап», «залны телсез калдырып» гармуннарда уйнаган иделәр инде. Әмма боларның уйнавы гына җитми икән, Р. Миңнуллин да килеп кушыла:

*Мин дә гармунчы малае,*
*Миңа да гармун таныш.*
*Җанымны ташлый актарып*
*Гармуннан аккан тавыш...*

Гармун шул кадәр сихерле нәрсә күрәмсең, кыз башы белән булса да, шуны күтәреп-кычкыртып Н. Измайлова да сызланмый калмый:

*Гармун тартам, гармун тартам,*
*Көй чыкмый гармунымнан.*
*Күздән яшьләр генә чыга*
*Сыгылып йөрәк моңыннан.*

Поэзиядә мондый гармун кычкыртулар эче пошкан кешенең клавишларга баскалап алуы кебек ясалма һәм буш, әлбәттә.

Ярый, гармун халыкның уен коралы, аңарда һәркемнең уйнарга хакы бар, ди. Әмма поэзиядә шундый деталь, образлар була ки, алар бары тик аерым шагыйрь табышы һәм хокукы итеп кабул ителә. Аларга кагылу «гөнаһ». «Сөн буенда бөдрә урман, Агыйделләргә җиткән...» дип Сөнне безнең поэзиядә, ялгышмасам, М. Ногман ачкан иде. Әмма дистәләрчә шигырь, җырларында җырлап, бу чишмәне Р. Миңнуллин үзенеке итте. Сөн — Миңнуллинныкы! Тик нинди хаҗәт тапкандыр — һәм күргәнмедер әле үзе Сөнне, юкмы?— Башкортстандагы бу инешкә Мамадыш егете З. Мансуров та барып чума:

*«Яратам!» дип язып куйдым*
*Сөннең соры комына...*

Бу инде иҗат этикасын бозу. З. Мансуровка үз инешен табарга кирәк.

Һәер, бер шагыйрьдән икенче шагыйрьгә күчкән тулпарлар, сандыклар, җил тегерменнәре, бабайлар, әниләр һәм тагын әллә нәрсәләр, әллә кемнәр, ә гомумиләштереп әйткәндә, детальләр, образлар, мотивлар турында яза башласаң, аерым матбугат чыгышы кирәк.

Бер шагыйрь тапканны икенчеләрнең кабатлавы, стандарт, стереотип әдәби фикерләүләр, һичшиксез, безнең хәзерге шигырь китапларының укучы каршында дәрәҗәсен төшерә. Миңа калса, үзен хөрмәт иткән шагыйрь шәхси иҗат кыйбласын табу, үзенең жанрын, тема һәм мотивларын булдыру турында уйланмый калмас...

Һәер, бу инде тагын аерым бер четерекле мәсьәләгә килеп кагыла икән. Кеше әйткәнгә игътибарлымы, тәнкыйтьне кабул итәме, күтәрәме шагыйрь?

Тагын Р. Фәйзуллинга, аның профессор И. Нуруллин белән булган әңгәмәсенә кайтырга туры килә. «Мин үзем бүгенге поэзия тәнкыйтьчеләренең фикер ярлылыкларына хәйран калам... Тәнкыйтьченең шагыйрьне ничек язарга өйрәтә алуына шикләнәм мин»,— дигән иде шагыйрь.

Моңа охшаш фикерне тагын да кискенләштерә төшеп, 1985 елда чыккан «Заман сурәтләре» дигән китабында Ә. Баянов та кабатлады:

«Тәнкыйтьчеләрдән ярдәм көтмим. Предметны белмиләр».

Ачыктан-ачык, декларатив белдермәсәләр дә, байтак яшь шагыйрьләрнең үзләрен тәнкыйтьтән өстен куюлары, шулай ук хак. Бу аерым сизенү генә түгел. Әдәбиятыбызның аксакалы Гомәр ага Бәширов «Социалистик Татарстан» газетасындагы (1987 ел, 1 февраль) чыгышында соңгы еллар татар әдәбиятының зәгыйфьләнүенә китергән бер зур сәбәпнең «тәнкыйтьнең әдәби иҗатка уңай тәэсирен бөтенләй диярлек инкарь итүебездә» булуын ачык күрсәтеп бирде.

Бөек Тукайның «Тәнкыйть — кирәкле шәйдер» дигән акыллы гыйбәрәсен, КПСС Үзәк Комитетының тәнкыйть турында әледән-әле искәртеп килгән мөһим доку-

ментларын искә төшерү белән чикләнеп һәм аерым авторларның тәнкыйтьне тану-танымавы турында җитди сүз алып бармастан, бары тик бер сорау тирәсендә уйланасы килә. Тәнкыйтьнең бурычларын, язучы белән тәнкыйтьче арасындагы бәйләнешләрне һәркем дөрес күзаллыймы?

Соравым бик урынлы. Чөнки шул ук Р. Фәйзуллинның поэзия тәнкыйте шагыйрьнең әсәрләрен популярлаштыруга «ярдәмгә килергә тиеш. Киң катлау укучыларга акны карадан аерырга булышырга тиеш...» кебек сүзләрен искә алганда, аның тарафыннан тәнкыйтьнең бары тик бер ягы — халыкка матур әдәбият үрнәкләрен пропагандалау ягы гына күздә тотылуын күрү кыен түгел. Болай фикерләгән шагыйрь, әлбәттә, тәнкыйтьче каршына бары тик таләпләр кую белән генә чикләнергә, хәтта теге яки бу әсәрендәге нечкә ишарәләрне, сурәтләр, образларны укучыга аңлатуҗиткерүдә үз калыпларыннан читкә тайпылу күреп, сине әдәби зәвыксызлыкта, томаналыкта гаепләргә мөмкин...

Ә бит тәнкыйтьнең икенче, җитдирәк вазифасы да бар. Тәнкыйтьче массаларның эстетик омтылыш һәм әдәби зәвыкларын үз карашларында гәүдәләндереп, автор каршына аерым таләпләр һәм бурычлар да куя. Нәкъ шул мөһим хасияте аркасында тәнкыйть әдәбиятка, иҗат процессына актив йогынты ясаучы, хәтта әйдәп баручы көч булып ук күтәрелә. Атап әйткәндә, тәнкыйть иҗтимагый мәнфәгатьләр, партиялелек, халыкчанлык, сыйнфыйлык, гражданлык кебек зур төшенчәләргә туры китереп, әдәбиятның үсеш юлын билгели, иҗат көчләрен мобилизацияли.

Ни өчен тәнкыйтьнең бу ягы да һәркем тарафыннан истә тотылмый? Һәм нәрсә нәтиҗәсе ул? «Мин-минлекме», каләмдәшләре каршында поза алумы, бәлки иҗтимагый мәнфәгатьләргә төкереп, бары үз кабыгына бикләнеп яшәү омтылышыдыр?

Үзеңне тап, чын асылыңны тап, шагыйрь!..

Монысы да сер түгел, соңгы елларда поэзия тәнкыйте дә күпне югалтты. Н. Юзиев кебек талантлы шигырь белгеченең тәнкыйтьтән китүе һич акланмый. И. Нуруллинның проблемалы мәкаләләре күптән күренми. «Үткен тешле» Р. Мөхәммәдиев, М. Вәлиев, С. Маннапов, Ф. Зөлкарнәев шикелле тәнкыйтьчеләрнең каләме пассивлашу да поэзия файдасына түгел. Күптәннән инде поэзия тәнкыйтенә яшь көчләрнең килгәне юк. Татар поэзиясенең масштаблылыгын, популярлыгын һәм куәтен күтәрү, һичшиксез, поэзия тәнкыйтенең сугышчанлыгын, активлыгын күтәрү дә дигән сүз ул.

В. Нуруллин һәм Р. Мостафин иптәшләр әңгәмәсе уңае белән башланган сөйләшү җитди проблемалар, уйланулар кузгатып, укучы каршында әдәби китапларның дәрәҗәсен сизелерлек күтәрергә ярдәм итәр, дип ышанасы килә.

**Сәгыйть ХАФИЗОВ.**
Уфа шәһәре.

# Уфада культурабыз истәлекләре



**Элеккеге Дворяннар собраниесе урнашкан бина**

*А. Тимергалина рәсеме.*

# ИСТӘЛЕКЛЕ БИНА

Уфаның үзәк өлешендә, В. И Ленин (элекке Центральная) һәм А. С. Пушкин урамнары чатында урнашкан ике катлы, архитектурасы белән әллә ни күзгә бәрелеп тормаган бер бина бар. Узган гасыр урталарында нигез салынган бу бинада революциягә кадәр «Дворянское собрание», ягъни аксөякләр катлавының: алпавыт һәм дәрәҗәле түрәләрнең җирле үзидарәсе урнашкан булган. Бу бинаның яңа гасыр таңында зур үсешкә ирешкән татар мәдәнияте тарихы сәхифәләрендә дә якты эз калдырган урын икәнен күпләр белми әле.

Россиядәге беренче буржуаз-демократик революциянең шифалы җилләре тәэсирендә Уфа татар яшьләре монда әдәбият, музыка һәм ял кичәләре уздыра башлыйлар. Әлеге мәшәкатьле һәм игелекле эшне оештыручылар Сәетгәрәй Еникеев, Исмәгыйль Терегулов, Фатыйма Басимовалар була. Әлбәттә, губернатор канцеляриесендә эшләгән действительный статский советник Әхмәтсолтан Терегуловның әчкерсез ярдәменнән башка яшьләр бу эшләрне башкарып чыга алмаган булырлар иде. Чөнки дворяннар өчен махсус салынган бинада татарча кичәләр оештыру, спектакль һәм концертлар куерга рөхсәт алу ифрат дәрәҗәдә кыен эш була.

...1913 елның 29 январь киче. Дворяннар собраниесе залында өч бүлектән торган зур әдәби-музыкаль кичә бара. Сәхнәдә бер-бер артлы һәвәскәр артистлар алмашына. Татарча, русча шигырьләр, Г. Тукай, С. Рәмиев, М. Гафури әсәрләре яңгырый, хор һәм аерым һәвәскәрләр башкаруында халык моңнары, татар, башкорт көйләре агыла.

Исмәгыйль Терегулов җитәкчелегендәге хор һәм кыллы оркестр мондый кичәләрнең йөзек кашы була. Аның репертуарында халык көйләре белән беррәттән, булачак атаклы татар композиторы Солтан Габәши әсәрләре дә урын алган.

Бу бинада кичә-концертлардан тыш, һәвәскәрләр тарафыннан татарча спектакльләр дә куела. Алар еш кына берәр мәдрәсә яки җәмгыяте хәйрия файдасына уйнала. Мәсәлән, 1911 елның 3 гыйнварында бу бинада «Уфа мөселман ханымнар җәмгыяте» файдасына Г. Камалның «Беренче театр» һәм В. Апанаев русчадан тәрҗемә иткән «Хатыннар эше» комедияләре куела. Шул ук җәмгыять файдасына 1915 елның 4 гыйнварында Г. Кәрам тәрҗемәсендә Н. Камалның «Гыйшык бәласе» һәм «Хатыннар эше» пьесалары уйнала. Болар барысы да «мөселман ханымнар җәмгыяте»нең спектакльләр куюга зур әһәмият биргәне хакында сөйли. Бу спектакль-кичәләрдән кергән акчаны җәмгыять Уфадагы ятимнәр йорты, кызлар мәктәбе файдасына тота.

1912 елда Уфада татар сәхнәсе кояшы С. Гыйззәтуллина-Волжская татар артистларыннан «Нур» труппасын оештыра. 1914 елның 20 сентябреннән 1915 елның 13 мартына кадәр, алты ай эчендә «Нур» труппасы уналты әсәрне сәхнәгә куя. Спектакльләр еш кына Дворяннар собраниесе бинасында уздырыла. «Нур»ның даими репертуары үзәгендә Г. Камал, С. Рәмиев, Н. Вәзиров, А. Н. Островский, Ф. Шиллер әсәрләрен күрәбез. «Нур» труппасы составында С. Гыйззәтуллина-Волжскаяның турыдан-туры иҗади җитәкчелегендә, татар театры үсешенә зур өлеш керткән күренекле артистлар тәрбияләнде.

1912—1914 елларда бу бинаның заллары мәшһүр татар җырчылары Фәттах Латыйпов, Камил Мотыйгыйларның көчле, моңлы тавышларына күмелә.

Уфа каласының үзәгендә урнашкан бу тарихи бина әле дә булса халыкка, культурага хезмәт итә: хәзер анда Уфа сәнгать институты урнашкан.

*Х. Гобәйдуллин һәм Җ. Миңнуллин тексты*

## Мөхәммәт Мәһдиев

# ДАВЫЛ ХӘБӘРЧЕСЕ — ИДЕЛДӘ

М. ГОРЬКИЙНЫҢ ТУУЫНА 120 ЕЛ

1

Төз, җыйнак гәүдәле, кайшалган калын чәчле егерме алты яшьлек егетне 1906 ел җәенең тупыл яфрагы исенә томылып утырган бер көнендә Федосеев урамының Кремль янындагы төрмәсенә китереп ябалар. Егетнең «төрмә» дигәнне әле беренче күрүе. Үзе эшләгән «Таң йолдызы» газетасында патша төрмәсе, анда ябылган революционерлар турында байтак сүз язылса да, төрмәгә үзе дә килеп керер дип башына да китермәгән була егет. Менә хәзер — чынбарлык! Җитмәсә, беренче көнендә үк — ялгыз камера. Куркыныч! Өч адымга өч адым киңлектәге таш капчык. Салкын. Кирпеч араларындагы ком, цемент коелып уентыклар ясалган. Әтисе — сал агызучы Лотфулла әйтә иде: безнең Рәсәйдә төрмәдә утыручыларның саны төрмә стеналарындагы кирпеч саны белән бер, дип. Шулайдыр, бу кирпечләрне дә, штукатуркасын куптарып күпме-күпме кеше санагандыр. Менә тимер ишек янагына якын гына бер урында ашъяулык кадәр штукатурка исән калган. Тоткыннар моны файдаланганнар, исем-фамилияләрен, ел, ай, көннәрне тырнап язганнар. «Мин монда булдым»... Йә, нәрсәгә кирәк инде? Күңел юатыр өченме? Көн уздырыр өченме? «Мине Фопс... кына сатты. Аны юк итегез...» «Монда эләккән кеше өметен җуйсын...» Өстән, дәфтәр бите кадәр зурлыктагы тимерле тәрәзәдән төшкән яктылыкка болар җан өшеткеч авазлар булып, тарих булып яңгырыйлар иде.

Камерага кергәндә, бәхеткә каршы, надзиратель карандаш, чәч тарагы, блокнотка кагылмады. Егет стена язуларын укып бетерде, китапларда тасвирланганча өч адымлы бүлмәдә диагональ буенча ишекле-түрле йөри башлады. Күңелне нәрсә беләндер мәшгуль итәргә, юатырга кирәк иде. Нәрсә белән соң? Тукта, бу арада гына бит ул ялгыз калган чакларында Максим Горький әсәрләрен яттан укып мавыга иде. Әле узган атнада гына «Жизнь» журналында «Давыл хәбәрчесе турында җыр»ны укып, берничә көн шуның тәэсирендә йөргән иде. Әле бүген, жандармнар керер алдыннан гына, үз бүлмәсендә шуны яттан кычкырып укыган һәм авыр уйлардан бушанып калган иде.

«Над седой равниной моря ветер тучи собирает. Между тучами и морем гордо реет Буревестник, черной молнии подобный...»

Тукта, дөньяда шундый күңел күтәрерлек әсәр барында нигә әле җебеп төшәргә? Син бит шагыйрь кеше! Әле күптәнме, сәяси эш белән төрмәдә утырып чыккан бер танышыңның язмышына кызыгып, аның белән төн буе сөйләшеп чыккан идең. Син шагыйрь бит, ал кулыңа каләмеңне!

Һәм шагыйрь штукатурканың аның өчен махсус калдырылгандай буш урынына иелеп, күкрәк кесәсеннән карандашын алды. Нәрсә дип язарга? Менә болай дипме: «1906 ел 21 июль. «Таң йолдызы» газитәсе мөхәррире Сәгыйть Рәмиев». Ә нигә кирәк бу? Жандармерия кәгазьләрендә болай да язылган бит инде ул... Тукта, болай итсәк: Горькийның «Тормыш төбендә» әсәрендә гаҗәеп бер җыр бар. Менә минем халәткә бик туры килә ул... Кояш нурлары кичкә таба авышып саргая башладылар. Камера әче тагы да куркынычрак булып китте. Горький ничек ди:

*Солнце всходит и захо-оди-ит...*
*А в тюрьме моей темно-о!*

*Дни и ночи часовые — э-эх!*
*Стерегут мое окно...*

*Как хотите стерегите,*
*Я и так не убегу;*
*Мне и хочется на волю... эх!*
*Цепь порвать я не могу...*

*И-эх вы, цепи, мои цепи,*
*Да вы железны сторожа...*
*Не порвать мне, не разбить вас...*

Җыр шагыйрь күңелен тагын бер тапкыр тетрәтте. Җырның инде көе дә күңелдә яңгырый башлады. Сүзләре татарчага әйләнеп яңгырый иде. Менә болай... Караңгы төшкәнче язып калырга кирәк. Менә болай...

*Кояш чыга да, бата да...*
*Төрмәм мәңге караңгы...*

Була, болай булгач шәп инде! Йә әле, алга таба...

*Көннәр, төннәр зобанилар,*
*Эх!*
*Тәрәзәмне караулый.*

Тизрәк, караңгы төшкәнче, тизрәк! Төнгә бәлки, гомуми камерага күчерерләр. Бу — мине куркытыр өчен генә. Мин бит әллә нинди партияләр, үзәкләр белән бәйләнгән кеше түгел. Мин редактор гына... Алга таба болай:

*Караулагыз теләгәнчә,*
*Мин барыбер качалмыйм,*
*Бик шат качар идем дә шул...*
*Эх!*
*Богавымны ачалмыйм.*

Таш коридорда дагалы итек, винтовка затворы, чылбыр тавышлары яңгырады. Шагыйрьнең ашыгудан куллары калтырый иде. Тизрәк...

*Эх, сез богаулар, богаулар!*
*Сез тимер зобанилар...*
*Сезнең тырнаклар аякны*
*Эх!*
*Рәхимсез сызгалыйлар.*

Нәкъ шул урында карандашның очы бетте. «Сызгалыйлар» сүзен карандаш агачы белән тырнап язарга туры килде. Шулай да эш эшләнде. Өлкән Плиний хаклы! Nulla dies Sine linea... (Бер көн дә сызык сызмыйча калмаска, ягъни шөгыльсез бер көнне дә уздырмаска (латин).

— Арестованный Рамеев! С вещами! С вещами на выход! Живо на выход!..

Шагыйрь айныды... Кичкә авышкан кояшның саргылт нурлары инде ишек өстенә үк менгән. Тимер ишек зыңгырдап авыр ачылды. Алда билгесезлек көтә иде.

Ни булса да булыр, әмма тәрҗемә ителгән шигырь юллары аның күңелен биләп алган иде инде.

Нәкъ бер тәүлек дигәндә шагыйрьне азат иттеләр: тоткынлыкта асрар өчен җитәрлек дәлил юк иде. Шагыйрь төрмәдән кайтышлый ук туп-туры редакциягә керде: тәрҗемәне мөмкин кадәр тизрәк дөньяга чыгарасы килә иде аның. Иптәшләре иртәгә чыгасы санны әзерләп утыралар икән! Хәл-әхвәл сөйләшкән арада шагыйрь газета өчен ашыгыч рәвештә бер мәкалә язып ташлый һәм, әлбәттә инде, уңаен китереп әлеге тәрҗемәне текст эченә урнаштыра. «Таң йолдызы»ның 23 июль саны Шагыйрь бәхетле дөньяга чыгу белән Казан яшьләре Горький сүзләрен ятлап алалар. Шагыйрь бәхетле көннәр кичерә...

Горький җырының татарча тәрҗемәсенә Г. Камал да игътибар итә. «Бәхетсез егет» драмасының икенче вариантын эшләгәндә ул өр-яңа бер бүлек — Уфа шәһәреннең кайбердәге бер притон күренешен өсти. Сәхнәдә — караклар, сукбайлар. Күрәсең, кайберләре инде төрмәнең дә нәрсә икәнен белми түгел. Өченче пәрдә ачылганда караклар Горький җырын хор белән җырнакъ менә шул әсәрне — С. Рәмиев тәрҗемәсендәге Горький җырын хор белән җыр-

лыйлар. «Бәхетсез егет» драмасы аерым китап булып 1907 елда басылып чыга һәм китап аша бу җыр халыкка тарала (башка бик күп халыклардан аермалы буларак, татарлар пьеса китапларын, нәкъ проза әсәре укыган кебек, калдырмыйча укып баралар). Бераз вакыттан соң бу җыр сәхнәдән яңгырый: 1908 елның январь аенда Уральск шәһәрендә «Бәхетсез егет»нең яңа варианты сәхнәгә куела, артистлар шау итеп «Кояш чыга да, бата да»ны җырлыйлар. Җыр бераздан Казан сәхнәләрендә яңгырый — Горький иҗаты безгә шулай җыр булып килеп керә.

Нәкъ шул көннәрдә генә «Әхмәтгәрәй Хәсәни ширкәте» Г. Коләхметовның «Яшь гомер» драмасын басып чыгара (1908 ел, март). Яңа фикерле яшьләр сизәләр: Коләхметов әсәрендә дә Горький бар, аның аһәңнәре бар... Дистәләрчә еллар үткәч, совет чорында бу турыда тәнкыйтьче Г. Нигъмәти яза. Ул башта «Яшь гомер»дән мондый өзек китерә:

«Урыс... әмма төрмәләрдә утырсам да, төрмәләрдән чыктым исә, һавадагы кош кеби, иркендә торам. Теләгән җиремә барам. Теләсәм кайда торам. Эшлисем килсә— эшлим, урлыйсым килсә — урлыйм, әмма һичбер кемгә дә кол булып тормыйм!»

«Бу,— ди Г. Нигъмәти,— Горькийның босяк типларын хәтерләтә. Горький босяклары белән монын арасындагы аерма тик моның кайбер мәсьәләләрдә сыйнфый карашлар әйтүе, сәяси көрәш мәсьәләләре белән кызыксынуында» (Нигъмәти Г. Гафур Коләхметов һәм аның иҗаты.— «Яңалиф», 1930, 5 сан).

Монысы совет чорында язылган. Ләкин татар әдәбиятында Горький традицияләренең чагылышын гасыр башында ук эзләргә керешәләр. К. Камалның «Бәхетсез егет» драмасында ук инде театр тәнкыйтьчесе Г. Кәрам рус әдәбиятының, башлыча Горькийның, йогынтысын билгеләргә тырыша. «Бәхетсез егет» исемле «театр китабы»на рецензиясендә ул, әсәрнең «бәгъзы бер сүзләрендә Максим Горькийга тәкълид итдеге (ияргү) хис улынмактадыр» дип яза (Камал Г. Әсәрләр. 3 томда. 1 том. Казан, 1978, 389 б.).

Шулай, татар реалистик әдәбиятына Горький килеп керә. Матбугат аның исемен еш телгә ала. Горький — кем ул? Ул ничек яза? Матбугатның бит әле яшисе дә бар, аның «подписчиклары» бар. Нигә әле язучының иҗат лабораториясе белән дә кызыксынмаска? Һәм «Вакыт» газетасы «Оренбург укучыларына хәбәр итә: Горький, ди, «үз бүлмәсендә бик тынычта гына яза ала. Язуы — кызларныкы кебек нечкә. Язганда бөтен дөньясын оныта, бөтен күңеле илә шул әсәренә бирелә» («Вакыт», 1907, № 252).

1908 елда Горькийның «Ана» романы төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә басылып чыга. Татар матбугаты моңа зур игътибар бирә, бу турыда газеталарда информация күренә. Татар зыялылары арасында фикер уяна: ни өчен әле без, татарлар, үзебездә яшәгән, безне яраткан, ихтирам иткән Горькийны татарчага тәрҗемә итмибез?

1909 елда Горькийны тәрҗемә итү эшен яшь талант — Тукайның дусты Солтан Рахманколый башлап җибәрә. Ул Горькийның «Дружки» хикәясен «Ике сукбай» исемен куеп тәрҗемә итә. Бу әле, әлбәттә, бик иркәле тәрҗемә, ләкин инде — Горькийны тәрҗемә итә башлау.

«Аң» журналы бу тәрҗемәгә С. Рахманколый үлгәч, мондый бәя бирер: «Болардан тыш аның (С. Рахманколыйның — М. М.) Тургеневтан, Толстойдан вә Максим Горькийдан дәхи гаять матур тәрҗемәләре... бардыр». («Аң», 1916, № 6.)

Газеталар татар әдәбиятының үсеше турында язганда әледән-әле Горький иҗатына килеп чыгалар. «Әдәбиятта тәбдил (үзгәреш)» дигән имзасыз мәкаләдә «Йолдыз» газетасы болай яза: әдәбият, гомумән, сөйләнгән әсәрләрдән, урам бәетләреннән башлана. Шуннан башлап ул хәзер театрда куела торган мөкәммәл пьесаларга кадәр килеп җитә. «Башта һәр милләттә «Бүз егет» вә «Җантаһир» хикәяләре кебек падишаһзадәләрнең гыйшкы тасвираты алда йөри. Соңра гади кешеләрнең мәгыйшәте тасвир кыйлына башлый. Ахырда Максим Горькийның мещаннарына, аннан соңра, эштән чыккан хулиганнарына нәүбәт килә». («Йолдыз», 1910, № 503.) Либераль-буржуаз газетаның «аннан да соң пролетарийлар образына нәүбәт килә» дип әйтергә, әлбәттә, кыюлыгы җитми...

Горький иҗаты — Г. Ибраһимовның да игътибар үзәгендә. Рус әдәбияты — ул нәрсә? Ул кемнәрнең иҗатыннан гыйбарәт? «Йолдыз»ның 1910—11 елгы саннарында алып барган «Әдәбият мәсьәләләре» дигән циклында ул татар укучыларына аңлата: «Рус әдәбияты дип мотлак әйтелгәндә, бу тәгъбирдән дини, гыйльми вә әдәби булган һәммә русча әсәрне аңлау җаиз исә дә, әгъләбтә Пушкин, Гоголь, Тургенев, Лермонтов, Горький, Андреев... кеби әдип — шагыйрьләрнең шигырь, роман вә драмга гаид әсәрләре... ирадә кыйлынадыр» (Г. Ибраһимов. Әсәрләр. 8 томда. 5 том. 1978, 21 бит. Сүзлек: җаиз — дөрес; әгъләби — иң күп; гаид — бәйләнешле; ирадә кыйлыну — күздә тотылу).

«Тәрҗемә һәм аның шартлары» дигән мәкаләсендә Г. Ибраһимов, «гыйлемгә яңа

кәрә башлаган», татар милләте өчен чит телләрдән тәрҗемә итүнең әһәмияте аеруча зур икәнлеген әйтә: «Горькийның «Ана»сы, түгел башка Европа телләренә генә, хәтта төрек вә гарәп телләренә дә тәрҗемә кыйлынмыштыр» (шунда ук).

1914 елның башында М. Горькийның Капридан Россиягә кайту вакыйгасына татар вакытлы матбугаты зур игътибар бирә. Шул чорга кадәр берниндн дә рәсем басмаган диярлек «Вакыт» газетасы Горькийның рәсемен бирә, берничә санында рәттән аның тормышы, иҗаты турында сүз алып бара. Газета аны «рус мөхәррирләренең беренче сафында булган» язучы дип атый. Горькийның әсәрләре бик күп телләргә тәрҗемә ителүен әйтеп, газета аның иҗатын татарчага тәрҗемә итү мәсьәләсен күтәрә. Шунда ук Горький иҗатының төп сыйфатын ачарга омтылыш ясала. «Аның бар хасияте,— ди газета,— бәхетсез, гаиләсез вә йортсыз кешеләрнең яхшы якларын, яхшы күңелләрен тасвир итүендәдер. Максим Горький хәзерге исән рус мөхәррирләре эчендә халыктан иң күп хөрмәт күргән, яшьләрнең иң күп ихлас куйганы кешедер» («Вакыт», 1914, № 1387).

Әйтергә кирәк, Горький иҗатын татарчага тәрҗемә итү мәсьәләсен күтәрүдә «Вакыт» газетасы ялгыз булмый. Моңа «Йолдыз» да туктала. Россия мөселманнары арасында рус классикларының тәрҗемәсен сорау арта бара, дип яза «Йолдыз». Казан китапчылары яңа тәрҗемәләр бастырып чыгарырга карар биргәннәр. Гасыр башында Пушкин, Лермонтов, Тургеневлардан тәрҗемә булган инде, хәзер аларны яңадан бастырырга җыеналар. Ләкин хәзер тәрҗемәчелектә яңа этап башланырга тора: китапчылар Куприн, Л. Андреев, Горький, Толстой әсәрләрен тәрҗемә иттерергә карар кылганнар» («Йолдыз», 1913, № 1044).

Кызганычка каршы, Казан китапчылары матбугат күтәргән бу мәсьәләгә тиешенчә игътибар бирмиләр һәм революциягә кадәр Горькийның прозасы бөтенләй юк дип әйтерлек тәрҗемә ителми... Моны совет чорында Г. Нигъмәти билгеләп үтә: революциягә кадәр татар наширләре Горький иҗатын яратмадылар, аны тәрҗемә итмәделәр, ди (Нигъмәти Г. Максим Горький — «Яңалиф», 1932, 8 сан).

«Вакыт» һәм «Йолдыз» газеталарының Горький иҗатын пропагандалаулары мактауга лаек эш. Бу газеталар Горький турында мәгълүмат бирү максатында еш кына рус матбугатына мөрәҗәгать итәләр, шундагы материалны күчереп басалар (татар газеталарының рус матбугатыннан нинди характердагы материал сайлау, нинди максатта күчереп басу мәсьәләсе бер дә, бер дә өйрәнелмәгән әле). «Вакыт», мәсәлән, рус газетасы мөхбиренең Горький белән булган әңгәмәсен күчереп баса. «Максим Горький ни сөйли?» дигән баш астында газета Горькийның түбәндәге сүзләрен урнаштыра:

«Без, русларның, бөтен гаебемез шунда: яшәү тугърысында күп сөйлимез, амма яшәмимез, яши алмыймыз, бу чаклы мескенчелекне бетерергә кирәк. «Дөнья — зиндан, канатсыз җан да оча алмый гына тора» дигән сүзләрне ташларга вакыт инде. Ул иске сүзләрне Аурупа күптән онытты, без һаман шул фикер илә яшимез.

Аурупа бездәге бик күп нәрсәне яратмый. Аурупа безне бик аз белә. Достоевский, Толстой кебек олугъ мөхәррирләремезгә дә Аурупа бер дәрвишкә караган кеби генә карый. Аларны яраталар, ләкин алардан бер нәрсә дә өйрәнергә теләмиләр. Менә Художественный театрның, Шаляпинның безне Аурупага таныштырга хезмәтләре күп тиде. Алар Аурупаны безнең хакта күп сөйләттеләр, күп яздырдылар». («Вакыт,» 1914, 1394 сан.)

Мәгълүм булганча, Россиягә кайтуга Горький рус мәмләкәтендә яшәүче милли әдәбият үрнәкләрен туплап аерым җыентыклар чыгару идеясен күтәрә. Аларны «Парус» нәшриятында бастырып чыгару турында эш башлый, төрле милләт язучылары белән контакт урнаштыра. Бу аның күптәнге — әле Каприда яшәгән вакыттагы ук — хыялы була. Аның бу юнәлештәге эшчәнлеге татар әдәбиятына да кагыла: Горький шул чорда татар прозаигы һәм драматургы Г. Исхакый белән сөйләшү алып бара. Нәтиҗәдә, татар әдәбияты альманахын төзү, бу җыентыкка Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, Ф. Әмирхан, Р. Фәхретдинов һәм Г. Исхакый әсәрләрен кертергә булалар. Гонорар шартлары да якынча сөйләшенә. (Ф. Әмирханга адресланган Г. Исхакый хатларының төп нөсхәләре И. Нуруллин кулында саклана. Хатларның берсендә мондый юллар бар: «Хөрмәтле Фатих! Мин сиңа бу хатны зур йомыш берлән язам. Максим Горький «Алдым-бирдем» вә башка минем берничә нәрсәләремнең тәрҗемәсен җыеп, шуңарга тагын берничә татар мөхәрриренең әсәрен, шигърене кушып «Татар мәҗмугаи әдәбияты» исемендә бер китап бастырырга димләп хат яза»).

Горький бу мәсьәләдә С. Сүнчәләй белән дә сөйләшкән (С. Сүнчәләй аның янына барганмы, әллә хат алышканнармы — ачыклап булмады). Бу турыда безнең кулда әлегә бер генә мәгълүмат бар. Ул да булса — газета хәбәре. «Шагыйрь Сагыйть әфәнде Сүнчәләйнең идарәмезгә язып белдерүенә күрә,— дип яза «Йолдыз»,— мәшһүр мөхәррир Максим Горькийга мөрәҗәгать итеп, аның «На дне» исемле пьесасын

татарчага тәрҗемә итәргә рөхсәт сораган икән. Горький аңа мәгальмәмнүния рөхсәт биргән вә «минем пьесам татар сәхнәсендә үзенә урын алса, бик шатланыр идем» дигән. Янә Горький Сүнчәләйне русча чыгачак «Татар әдәбияты мәҗмугасы»на иштиракъ итәргә өнди икән. Бу мәҗмуга Горькийның үз идарәсе астында... чыгачак, ди». («Йолдыз», 1916, № 1726. Сүзлек: мөгальмәмнүния — шатланып; иштиракъ — бергәләп эшләү, катнашу.)

Мәҗмуга, шулай да, чыкмый кала, ләкин идея үлми: 1923 елда Җ. Вәлидинең Мәскәү-Петроград нәшриятында чыккан «Очерк образованности волжских татар» дигән хезмәтенең беренче кисәге — революциягә кадәр үк әзерләнеп, аз гына төзәтүләр белән басылган хезмәт — Горький идеясенең нәтиҗәсе.

Революциягә кадәрге татар әдипләре, журналистлары Горький шәхесен, аның иҗатын җае чыккан саен телгә алып торалар. Оренбург матбугаты бу өлкәдә аеруча актив: Горькийның «Дружки» хикәясен татарчага тәрҗемә иткән С. Рахманколый үлгәч, аның биографиясенә тукталып «Кармак» журналы Рахманколыйның фаҗигасенә социаль эчтәлек бирә: С. Рахманколый машина урынына эшли, әмма наширләр аңа бүген тамагын туйдырырлык кына гонорар түлиләр. Шуның өстенә Солтанның реакция елларында иңләнеп алган эчкечелеге көчәя. «Шулай итеп, мәрхүм көннән-көн чокырга якынлаша, көннән-көн «На дне» каһарманнары сафына аяк атлый иде». («Кармак», 1916, № 8—9.)

Горький каһарманнары белән татар язучысын чагыштырып язу очраклы түгел. Ул елда Оренбургта Малиновскаяның драмтруппасы тарафыннан Горькийның «На дне» әсәре куела. Әсәрдәге татар ролен уйнарга театр Мохтар Мутинны чакыра. Пьеса бернычә тапкыр куелганнан соң «Оренбургская жизнь» газетасы спектакльгә рецензия бирә. Рецензияне исә «Вакыт» тәрҗемә итеп баса. Газета спектакльне бик нык тәнкыйть итеп, арадан ике артистны аерып алып мактый. Болар: Мендельсон (Лука) һәм М. Мутин (Татарин).

«Татарин ролен бу рәвеш яхшы итеп татар гына уйнарга мөмкин. Мутин әфәнде бу рольне шулкадәр дөрес һәм художестволы матур итеп уйнады ки, берсенә дә ялган вә гайре табигый булган ноктасы булмады. Максим Горький үзе булган вакытта да бу уенга шуннан артык бернәрсә дә арттыра алмас һәм теләмәс тә иде. Хөләсә, әгәр Малиновскаяның труппасында шушы ике артист (Мендельсон белән Мутин) булмаса, без бу пьесаны уйнарга түгел, уйнау хакында уйлап карарга да тәүсыя кыйлмас идек» («Вакыт, 1916, № 2127. Сүзлек: хөләсә — йомгак итеп; тәүсыя — киңәш бирү.)

Әдәбият тарихында инде язылган: Октябрь революциясенә кадәр Горький исемен Тукай, Г. Ибраһимовлар үз иҗатларында, тәнкыйть, публицистик мәкаләләрендә телгә алалар. Тукай иҗатында Горький исеменең чагылышына беренче мәртәбә Г. Нигъмәти игътибар юнәлтә. «Татар әдәбиятында,— ди Нигъмәти,— Горькийның танылуы, Горькийның татар язучыларына йогынтысына килгәндә, революциягә кадәрге татар әдәбияты һәм тәнкыйте бу хакта тулы бер караш хасил итәрлек материал калдырмаган. Шулай да, ул вакыттагы татар интеллигенциясе Горький белән таныш булганлыгы һәм кайбер язучыларның вакыты белән аның тәэсиренә бирелгәнлеге мәгълүм (Нигъмәти Г. «Максим Горький» — «Яңалиф», 1932, 8 сан.) һәм Г. Нигъмәти Тукайдан мисал китерә: шагыйрь авылдан Казанга кайткач, номерга төшми, шәһәр читендә бүлмә ала һәм Горький тасвирлаган мещаннар арасына эләгә. Мещанка хатыннарга мөнәсәбәтен ул ике юллык шигырендә белдерә:

*Максим Горькийны укыганда — шуларга нәфрәтем,*
*Кнут Гамсунны укыганда — шуларга ләгънәтем.*

Дөрес, Тукай 1910 елда ук Горькийны Россиянең «Мөбарәк тәсбиханнән «өзелеп төшкән бер төймә» дип билгеләп куйган иде инде (Тукай Г. Әсәрләр. 5 томда, 2 том. 1986, 142 б.).

## II

Бөек Октябрь революциясеннән соң Горький иҗатын өйрәнү, тәрҗемә итү һәм, ниһаять, Горький белән контакт урнаштыру, киңәшү, өйрәнү мәсьәләләренең яңа этабы башлана.

Горький кем? Әдәбият дөньясында ул кайсы сыйфаты белән мәшһүр? Бу мәсьәләне егерменче еллар башында Г. Ибраһимов күтәрә һәм әлеге сорауга җавап бирергә омтыла. Революция көннәрендә сыйнфый көрәштән читтә торган яки революция дошманнары ягына чыккан рус интеллигенциясенең тарихи хаталарын яки җинаятен

күрсәтеп Г. Ибраһимов «тормышның төбеннән, ярлы халык эченнән күтәрелгән Максим Горький кебек әдипләр»нең ачыктан-ачык пролетариат хәрәкәтенә кушылуларының әһәмиятен билгели. Билгеле булганча, Г. Ибраһимов Октябрь революциясеннән соң язган тәнкыйть мәкаләләрендә әдәбиятның иҗтимагый- икътисадый нигезе турындагы фикерләрен һәрвакыт беренче планга чыгара. «Шагыйрьнең, әдипнең кемгә, нинди әмәлгә, кайсы сыйныфка хезмәте» мәсьәләсен алга куеп, Г. Ибраһимов «бер якка мәшһүр даһи аристократ лорд Оскар Уайльдның гаҗәеп тасвирларын, икенче якка... Горькийларның әсәрләрен» куя да, «әдәбиятның хезмәте нинди юл белән» бәйләнгәнен әйтә» «...буржуа шагыйре, эшче-крәстиян әдибе кебек аеруларның төп үлчәве — менә шул ноктададыр». (Ибраһимов Г. Әсәрләр, сигез томда, 5 том, 1978, 242—313 б..)

Горький иҗатының иҗтимагый-социаль эчтәлекле булуына Г. Ибраһимов кат-кат туктала. «Бар шагыйрьләр: алар матур яр җырлый, сандугачка кушылып, табигать күрекләрен мактый, язмышы, бөтен әсәрләре, үзенең күңел дөньясы — шул сөюләр, сөелүләр, өмидләр, өмидсезлекләр, күктә эзләнүләр белән генә тулы була...

Бар шагыйрьләр: алар тормышның иҗтимагый фаҗигаләре белән агуланганнар. Алар авыр көрәшләр, канлы сугышлар, һәлакәтле хезмәт трагедияләрен җырлыйлар. Эмиль Верхарн, Гауптман, Кольцов, Некрасов, Максим Горький, Демьян Бедныйлар, үзләренең әдәби дәрәҗәләренең төрлелегенә карамастан, һәммәсе менә шул икенче сафның гаскәрләре эчендәдер» (шунда ук).

Бу фикерләр Г. Ибраһимовның 1920—22 елларда язган хезмәтләрендә урын алган.

Шулай, совет чорында татар әдәбиятында Горькийның яңа тормышы башлана.

1923 елда «Безнең юл» журналының 12 санында, һич тә көтелмәгән тәрҗемә күренә: Н. Думави — «Кеше». «Әсәр — Горькийның «Человек» исемле философик поэмасының ирекле тәрҗемәсе булып тора» диләр Н. Думавиның «Тормыш сәхифәләре» исемле китабын төзүчеләр.

Н. Думави кыю рәвештә Горькийның «Кеше» хикәясен ирекле тәрҗемә иткән. Тәрҗемә иткән? Юк, үзе күрсәткәнчә, Думави аңа «ияреп» язган. Һәм әсәрдә Думави үзен ирекле тоткан.

Горький һәм татар әдәбияты дигән мәсьәлә бик тирән, бик кызыклы. Горький бит Казанда яшәгән. Яңа Бистәне — татарлар төбәген — яраткан. «Алёшу тянуло уйти в Татарскую Слободу к «добродушным ласковым людям, говорящим смешно искаженным русским языком, живущим какой-то особенной, чистоплотной жизнью». Алеше казалось, что у татар вся жизнь построена по-иному, незнакомо для него». (Климентовский В. А. Русские писатели в Татарской АССР. Казань, 1960, 90 б..)

1944 елда М. Гайнуллинның рус телендә «Горький и татарская литература» дигән кечкенә генә китапчыгы Казанда дөнья күрә. М. Гайнуллинның бу хезмәтендә тарихи информация күп, тирән, сокландыргыч. Горький һәм татар әдәбияты турында авыз тутырып сөйләргә тели ул, ләкин сталинчылык аңа мөмкинлек бирми. М. Гайнуллин, архив һәм элеккеге матбугат информациясенең кадерен белә торган кеше— әлеге хезмәтендә Горький турында Г. Нигъмәти язган мәкаләләрне «Бер мәкаләдә әйтелгәнчә» дип билгеләп барырга мәҗбүр. 1927 елда Горькийның «Макар Чудра» әсәре Казандагы кооператив нәшриятта Садри Җәләл тәрҗемәсендә чыгуын М. Гайнуллин искә ала. 1944 елда С. Җәләл исемен телгә алу — ул чорда зур батырлык сорый иде. Г. Нигъмәтинең — Совет чорында Горький иҗаты буенча иң беренче тикшеренүләр алып барган кешенең — исемен атарга ул вакытта бер генә галимнең көче дә, куәте дә җитми иде.

М. Горький әсәрләрен татарчага тәрҗемә итү мәсьәләсе Татарстан Дәүләт нәшриятында 1926 елда карала. Нәшрият түбәндәге язучыларның әсәрләрен тәрҗемә итүне планлаштыра: М. Горький, Л. Сейфуллина, И. Эренбург, В. Шишков һәм А. Луначарский. «Дәүләт нәшриятының мадди хәле хәзергә бик шәп түгел,— дип яза нәшриятның җаваплы кешесе Г. Латыйпов,— бу планның үтәлүе, әлбәттә, акча мәсьәләсе белән бик нык бәйләнгән. Ләкин мондый мөһим эшкә партия һәм хөкүмәт органнары тиешле әһәмият бирерләр һәм аны үтәр өчен кирәк булган шартны тудырырлар дип өмет итәбез». (Латыйпов Г. Матур әдәбият һәм Татарстан Дәүләт нәшрияты.— «Безнең юл», 1926, 9 сан.

М. Горький иҗатын татар матбугатында иң актив пропагандалаучы галим, әлбәттә, Г. Нигъмәти. «Максим Горькийның беренче әдәби хезмәт еллары» исемле мәкаләсе белән Г. Нигъмәти татар филологиясендә «Горькийны өйрәнү» дигән юнәлешкә нигез сала.

Совет чорында, яңа шартларда Горькийны кем тәрҗемә итә башлаган дисезме? Егерменче-утызынчы елларның рәхимсез тупас тәнкыйте астында изелгән, кыйналган, «милли демократизм»да, «черек либерализм»да гаепләнгән Садри Җәлал 1927—1928 елларда ул М. Горькийның «Макар Чудра» һәм «Мальва» хикәяләрен

татарчага тәрҗемә итә һәм аерым китап итеп чыгара. 1928 елда «Эшче» газетасы (Мәскәү) Некрасов, Серафимович, Горький иҗатлары турында искиткеч күп материал урнаштыра, аларның иҗат методлары турында сөйләшү алып бара. Моның сәбәбе ачык: 1928 елда Горький чит илдән Советлар Союзына кайта һәм матбугат җәлык-ларының үзәгендә була. Татар әдәбияты дөньясында язучының кем малае, нинди гаиләдән чыкканлыгын җиң сызганып тикшереп кызган вакыт бу. Хәсрәт тәнкыйть-челәр әдәбият дөньясыннан Дәрдмәнд, Ф. Кәрими, С. Рәмиевләрне генә түгел, Тукай, Бабичларны гына түгел, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирханнар иҗатына каршы штык кай-раган, кайберләре исә Лев Толстойны «алама философ» дип сүгеп мәкаләләр язган чор бу. Әдәби багажың нинди, син — художникмы, түгелме, алары икенче планга чыга-рылып, ата-анаң кем булуы мәсьәләсе әдәбиятта төп критерийга менгерелгән еллар бу. Бәхетебезгә каршы, тәнкыйтьчеләр арасында тотнаклы кешеләр бер Г. Нигъмәти генә булмый. Әдәбиятта мирасы әлегә аз өйрәнелгән, ләкин мәкаләләре бүгенге көндә дә заманча яңгыраган Х. Ишбулатов бар. Әдәби псевдонимы — «Ишби». М. Горький ватанына кайткач, Ишбинең «Эшче» газетасында «Максим Горький турында» дигән кызыклы гына мәкаләсе күренә.

1928 елның август башында М. Горький Идел буенча пароходта йөргәндә Казанда туктала. Идел пристанендә Горькийны Казанның рәсми делегациясе каршылый. Салонда җанлы әңгәмә башлана. Әдәбият тарихы өчен бу әңгәмә, бу очрашулар кызыксыз булмас дип уйлыйбыз: 1928 елгы Казан газеталарының төпләмнәрен китап-ханәгә кереп һәркем укый алмый.

...Делегация кергәч, капитан салонны бушатып, сөйләшү өчен шартлар тудыра. Горький туп-туры конкрет мәсьәләләргә күчә. «Наши достижения» дигән киң планлы журнал чыгара башларга кирәк, ди. Төрле милләтләр тормышыннан алып әдәби аль-манах чыгарырга кирәк. Татарларга яхшы тәрҗемәче кадрлар булдырырга кирәк, татар тормышыннан рус телендә оригинал әсәрләр кирәк. Шуның өчен бая сөйлән-гән альманахны ашыктырырга кирәк. Әңгәмә вакытында сораулар бирелә:

— Сез бит «На дне» дә татарны яшь белми торган, намаз укучы итеп кенә күрсә-тәсез...

— Мин татарларны бик яхшы беләм: алар вөҗданлы халык, батыр йөрәкле халык, һәрбер каһарманлыкка сәләтле халык.

Горький үз тормышында очраган хәлләрне сөйләп югарыда әйтелгәннәрне исбат-лый. «Хәзер,— ди,— йөзне Шарыкка борырга кирәк, мин сезнең белән бик нык кызык-сынам».

М. Горький Казанда күп җирләрдә була. Газеталарда, мәсәлән аның «Октябрьнең ун еллыгы» поселогында (Җылан Тавы янында) эшчеләр белән очрашуы, Татар раб-факында булуы турында языла. Рабфакта Горький татарларның ничә процент тәшкил иткәне белән кызыксына.

Горький Казанда хезмәт иясләре белән театрда очраша.

Күп санлы тәбрикләүләргә Алексей Максимовичның җавап чыгышы матбугатта зур урын ала: һәр хәбәрче бу чыгышның аерым якларына игътибар бирә. Горький әйтә:

— Мин Россияне беләм дип йөри идем, хәзер инде миңа төзәтмә кертергә кирәк: «белә идем» дияргә кирәк. Минем Казанда күргәннәремнең барысы да китапка кер-мәгән. Минем моннан кырык ел элек Казанда күргәннәрем китабымда язылганнан бик күпкә начаррак иде... Ләкин мин ялгыз түгел... Шул вакыт күргән авырлыклар, кыенлыклар өчен сез мине бүген бүләкләдегез, мине лаек булган дәрәҗәмнән дә артык итеп бүләкләдегез... Минем язган әсәрләремдәге идеал — чын кеше иде. Һәм ул кеше элек вакыт тормышта очрамый иде. Мондый хәл (ул вакыттагы тормышта булмаган кешеләрне алу) табигый нәрсә.

— Бүген шушы җыелышта күргәннәремне, башыма килгән уйларны хәзер дө-рес итеп ачып бирерлек бүяулар, шундый тирән мәгънәне аңлатырлык киң сүзләр таба алмыйм мин. Боларны бер ай, ай ярым аулак җиргә барып, бикләнеп язсаң яхшырак булыр.

— Пәрдәсен ташлап җәмәгать тормышына омтылган татар хатыны — сезнең тормыш юлында зур кыюлык белән эшләвегезнең җимеше...

С. Фәйзуллин биргән репортажда Горькийның татарчага тәрҗемәләре, аерым язучыларга йогынтысы турында әйтелә. «Дәрдмәнднең «Кораб»ында, Шәриф Камал-ның «Акчарлаклар»ында, Ф. Сәйфи-Казанлының «Крушниклар»ында... Г. Ибра-һимовның кайбер нәрсәләрендә Горький йогынтысы бар», ди мәкалә авторы.

Горькийның Казанга килүе уңае белән Г. Нигъмәти газета өчен махсус «Лев Толстой һәм Максим Горький» дигән мәкалә яза. 1928 елда аның «Максим Горький» исемле китабы да чыга. Бу татар телендә Горький биографиясе һәм аның иҗаты

турындагы беренче зур хезмәт. Әйтергә кирәк, Горький турындагы Ленин фикерләрен татар телендә беренче яңгыратучы кеше дә Г. Нигъмәти була.

Горький иҗатына игътибар көчәю, аның әсәрләрен план буенча тәрҗемә итү утызынчы елларга туры килә. Бу елларда аның әдәби әсәрләре, мәкаләләре татарча дөнья күрә. Мәсәлән, 1931 елда аның «Бер минутка да онытылмасын» исемле мәкаләсе тәрҗемә ителә («Колхоз яшьләре», № 9), аерым китаплар күренә: «В. И. Ленин»— 1931 елда, Ш. Самат тәрҗемәсе; «Ана»— 1933, Ф. Бурнаш; «Егор Булычев һәм башкалар»— 1934, Х. Сәлимҗанов; «Хикәяләр»— 1935, И. Гази; «Минем университетларым»— 1932, Х. Кәрим; «Әдәбият һәм әдәбият техникасы турында»— 1933, К. Нәҗми; «СССР — сакта» (мәкаләләр җыентыгы)— 1933, Ш. Рәмзи һ. б. М. Горькийны тәрҗемә итү эшендә И. Рәми, Г. Лотфый, М. Максуд, Г. Хәбиб, Г. Камал, З. Солтанов һ. б. катнаша. Горький әсәрләрен татарча яңгыратуга соңгы заманда иң зур көч куйган кешеләр — С. Әдһәмова һәм И. Гази.

Совет чоры татар язучыларының Горький белән кызыксынулары көннән-көн көчәйгәнлекне 1929 елгы очрашу да күрсәтеп тора. Көньяк республикаларыннан сәяхәттән кайтышлый Мәскәүдә Герцен исемендәге язучылар йортында татар язучыларының Горький белән очрашуы була. Бу турыда байтак истәлек язылган. Бу истәлекләрнең кайберсе шактый кечкенә детальләргә кайтып кала, кайберләре соң язылган һәм очрашуның әһәмиятле эчтәлеге төссезләнеп калган. Ләкин арада бер истәлек аеруча кыйммәтле: ул — яшь язучы М. Әмир язмасы. Егерме ике яшьлек егет бу очрашуда менә нәрсәләргә игътибар иткән. Горький залга килеп керүгә татар язучылары дәррәү кул чаба башлагач, Горький аларга әйткән:

— Кирәкми, кирәкми, кул чабарга кирәкми, язгыз күбрәк... Сез — язучылар, төп эшегез — язу. Никадәр күп һәм яхшы язсагыз, минем өчен шулкадәр зуррак хөрмәт күрсәткән булырсыз... (Горькийның бу киңәше бүген — сиксәненче еллар язучылары өчен дә заманча бит! Күпме язучы үзенең юбилеен артистлар, композиторлар чакырып филармония концертына әйләндермимени?! Гомеренең яртысын кул чаптырып залдан-залга күчеп чыгыш ясап уздырган язучыларыбыз азмыни?)

«Татар язучыларының кыйммәте,— дип дәвам итә Горький,— татар тормышыннан язылган художество әсәрләре тудыруда. Мин татар язучыларыннан кайбер иптәшләрнең әсәрләрен укыганым бар. Алар үзләренең татар язучылары икәнлекләрен онытып ялгыш итәләр. (Горький монда, күрәсең, К. Нәҗминең «Шобага» хикәясен күздә тота, ул аның тәрҗемәсен 1928 елда укып чыккан була — М. М.). Татар тормышына хас булган специфик моментларны художество сурәтләре аркылы күрсәтү, формасы белән милли, эчтәлеге белән советчыл булган татар әдәбияты тудыру, шундый әдәбият аркылы татар тормышы белән бөтен дөньяны таныштыру — татар язучыларының төп бурычлары».

1932 елда Советлар Союзында А. М. Горькийның иҗат эшчәнлегенә кырык ел тулу билгеләп үтелә. Бу кампания Татарстан тормышында да зур чагылыш таба: шул елны Татарстан Матбугат йортына, оешып яткан Культура төзелеше институтына «Максим Горький» исеме бирелә. Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты юбилей уңаеннан М. Горькийның сайланма әсәрләрен һәм публицистик мәкаләләре җыентыгын чыгарырга карар бирә, Татарстан китап нәшрияты бу эшкә керешә дә. «Яңалиф» журналының бөтен бер саны диярлек бу юбилейга багышлана: анда Ленин һәм Горькийның 1922 елгы рәсемнәре бирелә. Горький турында Ленин сүзләре титул битендә китерелә. «Давыл хәбәрчесе» (Х. Т. һәм Ф. М. тәрҗемәсе. Хәсән Туфан түгелме?— М. М.): «Данко», «Кеше» әсәрләре, «Клим Самгинның тормышы» әсәреннән өзекләр тәрҗемә итеп урнаштырыла.

Ләкин мәсьәләнең бер ягы бар: 1932 ел — әдәбиятка сталинчылык шаукымының инде сизелерлек зур зарар сала башлаган чоры. Әдәбиятта художество осталыгы, чынбарлык, эстетика, халыкчанлык мәсьәләләре онытылып, «социализм нигезен саен ил эчендә көннән-көн кискенләшә барган сыйнфый көраш» мәсьәләләренең беренче планга чыга башлаган чоры. Талантлы гына яшь язучылар Сталинның шул концепциясенә ышанып бөтен иҗатларын шул булачак канлы көрәшкә таба борып шактый поэтик-эстетик көчне әрәм итәләр. Сталин әлеге Горький юбилеен да шул концепциягә көйли. Юбилей уңае белән Горькийга биргән телеграммасында ул аның иҗатын бары тик бер генә юнәлештә күргәнлеген аңлата. «Эшчеләр сыйныфы дошманнары куркынычына эшләвегезне телим»,— ди. («Яңалиф» 1932, 8 сан.) Бу тенденция Татарстан Совет язучылары Союзын оештыру комитеты котлавында да ярылып ята: «Син безнең өчен кадерле һәм без шуңа күрә дә Синеңчә көрәшергә, Синеңчә эшләргә һәм сыйныф дошманнары йөрәгенә Синеңчә төзәлмәслек җәрәхәт сала белергә өйрәнербез».

Бу — матур әдәбият өчен шактый хәтәр, хәвефле юнәлеш иде. Күрәсең, Г. Нигъ-

мәти бу шаукымны сиземләгән һәм журналның шул ук санында «Максим Горький» дигән зур мәкалә урнаштырып, анда безгә башка чыганаклар буенча мәгълүм булган йогынтылар (Г. Коләхметов, Г. Камал, С. Рәмиев, Г. Ибраһимовлар иҗатына кагылышлы алдарак китерелгән мисаллар белән) турында фикер йөртеп болай ди: «Безнең язучылар Горькийдан күп нәрсәләргә, әлбәттә, и *беренче нәүбәттә* (курсив безнеке — М. М.) язучылыкка өйрәнергә тиешләр».

Горький иҗатының әһәмияте турында сүз алып барганда яшь М. Әмир дә шулайрак уйлый. М. Әмир аның шәхесендә ил эчендә «киләчәктә күтәлгән» канкойгыч көрәшне түгел, зур тарих, бөтен бер дөньяны күрә: «Баскычтан төшкән вакытта мин аның метрлап үлчәрлек киң иңбашларына карап төштем... Пинжәк белән капланган киң арка, әйтерсең, экранга әверелде дә, анда Макар Чудралар, Челкашлар, Мальвалар, Фома Гордеевлар һәм алар тирәсендәге дөнья, бөтен бер эпоха күренде... безнең татар әдәбияты өстенә күз йөртеп чыксаң, Горький сүзенә тиешенчә колак салмаганыбыз күренә. Без күп вакытта үзебезнең татар язучылары икәнлегебезне онытабыз, кул чабуларга, тантаналы сүзләргә бирелеп язучылар икәнлегебезне дә онытып җибәргәлибез әле» (Әмир М. Горький безгә ни әйтте? «Яңалиф», 1932, 8 сан).

Горький иҗатыннан **осталыкка, халыкчанлыкка, гомумән, сәнгатьчә уйларга, фикер йөртергә өйрәнергә кирәк иде,** тарих моны исбатлады.

...Заманнар, җитәкчеләр, кануннар үзгәрә, карарлар чыга, ә Горький һаман бөек булып кала. Инде без аңа шулкадәр ияләнгәнбез, ул гомер буе безнең арада яшәгән, безнең телдә язган сыман тоела безгә. Моның хикмәте нәрсәдәдер, без ул турыда уйлап та тормыйбыз, әмма интуитив рәвештә сизәбез: Горький олы җанлы кеше булган. Бөек рус язучысы дигән мактаулы исем йөртсә дә, милли әдәбиятларның барысын да тигез күргән, елгалар, каеннар, ашау-эчү әйберләрен, мунчаларны да милләтләргә бүлеп өләшеп язмаган. Кайта-кайта әсәрләрен укысаң, тагы да ышанасың: Горький бөтен иҗаты белән кешеләрне олы җанлы булырга өндәгән икән һәм, *олы җанлылык язучыларыбыз арасында дефицитка әйләнә башлауга,* мәһабәт, саллы гәүдәсе — иҗаты белән безнең алга Максим Горький килеп баса икән.

Элекке Лаеш урманнары, куаклыклары өстенә җәелеп яткан кояшлы, чал Идел өстендә акчарлаклар уйнаганда да, җилле-давыллы көннәрдә карачкыл-кургаш дулкыннар куптарып, безнең җаннарыбыздагы ваклыкларга рәнҗегәндәй, ул мәһабәт елга дулаганда да, безгә бөек язучының авазы ишетелә. Давыл хәбәрчесе дигән кош авазы белән кисәтә ул безне:

— Әдәбият — кеше турындагы фән, сәнгать ул. Әдәбият кәсеп түгел, талант иясенең җан авазы ул! Чын мәгънәсендәге әдәбият — батырлык, үз-үзеңне мәҗнүннәрчә шуңа сарыф итү ул! Ә батырларның мәҗнүнлегенә без дан җырлыйбыз...

Идел өстендәге Давыл хәбәрчесе кошы шулай һәрчак безнең белән...

# ГАЙ ТАҺИРОВ ҺӘМ ТАТАР БАЛЕТЫ

Татарстан хөкүмәте карары белән 1931 елның җәендә республика районнарына беренче тапкыр фольклор экспедициясе чыгып китте. Аның сәяси җитәкчесе итеп авыл хуҗалыгы институты студенты Габделхак Бадыйгов (соңрак ул партия эшлеклесе буларак танылды), ә административ җитәкчесе итеп җырчы Газиз Әлмөхәммәдов билгеләнде. Алардан тыш группада композитор Солтан Габәши, ул чакларда инде танылып өлгергән җырчы Наилә Рәхматуллина, хореограф Гай Таһиров һәм рәссам Усман Мусин бар иде.

Экспедиция халыкның музыкаль, вокаль һәм хореографик иҗаты үрнәкләрен җыярга тиеш була. Моннан тыш, Мусин милли кием-салым, көнкүреш һәм халык бизәкләрен өйрәнергә тели.

Баштарак халык иҗатын өйрәнүчеләрне авылларда ышанмыйчарак каршылыйлар: музыканы яисә башкаручы тавышын ничек язып алып булсын ди инде?! Әмма экспедициядә катнашучылар югалып калмый. Беренче эш иттереп, алар урам уртасында таклардан сәхнә сыман нәрсә оештыралар, театр пәрдәсенә охшатып, аны чаршау белән каплыйлар. Авыл җирендә моңарчы күрелмәгән бу хәл турындагы сүзләр колактан-колакка китә, һәм күз ачып йомганчы халык җыелып та өлгерә. Шул чакта инде сәхнәгә Бадыйгов күтәрелә һәм халыкара хәл турында лекция укый башлый. Соңыннан исә профессиональ артистлар көче белән концерт күрсәтелә. Менә шушы хәл авыл халкы белән үзара аңлашуга ярдәм итә дә инде. Экспедиция урнашкан йортка бер-бер артлы җыр һәм бию осталары килә башлый. Искереп беткән фонографтан үз тавышларын-җырларын ишеткән картларның, карчыкларның никадәр гаҗәпләнүен күз алдына китерү кыен түгел. Гай Таһиров исә аерым бүлмәдә эшли, биючеләрнең һәр хәрәкәтен, үзенчәлеген, милли биюдәге һәр «па»ны кәгазьгә төшерә, аларның мәгънәсе һәм килеп чыгышы белән кызыксына.

Шулай итеп, беренче тапкыр буларак, Гай Таһиров гыйльми экспедиция составында республикада хореографик фольклорны өйрәнергә керешә. Ләкин халыкның бию иҗаты белән таныша башлавы элегрәк, 1926—1927 елларда, Татар театр техникумында укыган чакларда ук була. Татар дәүләт академия театры еш кына иң яхшы укучыларны спектакльләрдә катнашырга чакыра. Ул бәхетлеләр арасына Гай Таһиров та эләгә, драма актеры һәм биюче буларак чыгыш ясый.

1926 елда театр Мәскәү, Оренбург, Бохара, Әстерхан якларына гастрольгә чыга. 1927 елда тагын Мәскәү, аннары Нижний Новгород, Омск, Чиләбе, Петропавловск... Кайда гына булмасын, Таһиров илнең теге яки бу төбәгендә яшәүче татарларның бию фольклоры белән кызыксына, охшашлыклар һәм аерымлыклар таба, драма театры сәхнәсендә кирәк булырдай һәр нәрсәне исендә калдыра. Ул вакытта биюче, һәм бигрәк тә балетмейстер эшчәнлеге турында әле хыялында да булмаганлыктан, табигый ки, милли бию үзенчәлекләрен өйрәнү шактый дәрәҗәдә стихияле бара.

Шуңа да карамастан, аңа инде 1927 елда беренче тапкыр балетмейстер эшен алырга туры килә. Фәтхи Бурнашның «Таһир һәм Зөһрә» спектаклендә композитор Салих Сәйдәшев музыкасына балетмейстер Юлий Муко куйган «Шәрык сюитасы»н кыскартырга, ягъни аның гастроль вариантын эшләргә кирәк була. Таһиров бу эшне уңышлы башкарып чыга. Сүз уңаеннан шунысын да әйтергә кирәк: Ю. А. Муко егерменче-утызынчы еллар татар хореографиясе тарихында мәгълүм урын били. М. Фәйзи, Ф. Бурнаш, К. Тинчурин, Т. Гыйззәт һәм башка авторларның музыкаль драмаларындагы хореографик күренешләрне нәкъ менә ул әзерли. Ю. Муко татар милли характерын җанландыручы биюләрне дә уңышлы куя. Әмма ул куйган биюләр, гомумән, шәрык шартлылыгы буенча оештырыла, һәм шулай итеп, чын татар милли биюеннән ераклаша башлый.

Мондый хәл, әлбәттә, озак дәвам итә алмый. Кыенлыктан чыгу юлын эзләү, фольклорга нигезләп татар халык сәхнә биюен тудыру һәм күрсәтү юнәлешендә беренче адымнарны ясау Гай Таһировка насыйп була.

1928 елда Татар театр техникумын тәмамлаганнан соң, Г. Таһировны академия театрына драма артисты һәм балетмейстер Ю. Муконың ассистенты итеп билгелиләр. Килү белән үк аңа В. Виноградов, С. Габәши, Г. Әлмөхәммәдовларның «Сания» операсында хореографик күренешләрне кую йөкләнә. Бу — яшь балетмейстерның беренче зур эше була.

Операның премьерасы 1930 елның 3 гыйнварында куела һәм республика культура тормышында әһәмиятле вакыйгага әйләнә. Дирижер пульты янына беренче тапкыр опера дирижеры сыйфатында татар профессиональ музыкасына нигез салучыларның берсе, талантлы композитор Салих Сәйдәшев баса һәм катлаулы эшне зур уңыш белән башкарып чыга.

Операның беренче пәрдәсендә Гай Таһиров тарафыннан куелган биюләр дә уңыш казана. Алар әлегә пластик мотивлар байлыгы һәм башкару камиллеге белән аерылып тормый, ләкин биюнең милли үзенчәлекләрен фольклор нигезендә реалистик гәүдәләндерүдә, татар халык сәхнә биюен тудыруда сайланган юлның дөрес булуын күрсәтәләр. Ә инде 1930 елның җәендә Мәскәүдә үткәрелгән Бөтенсоюз халык иҗаты олимпиадасында «Сания» операсы һәм Кәрим Тинчуринның «Ил» драмасы, аларда Г. Таһиров тарафыннан куелган биюләр яшь хореограф эзләнүләренең дөреслеген тагын бер кат раслый.

Мәскәүдән кайтканнан соң Гай Таһиров академия театрында балетмейстер булып эшли башлый һәм зур дәрт белән эшкә керешә. Г. Әлмөхәммәдов, С. Габәши, В. Виноградовның «Эшче» операсындагы биюләрне зур осталык белән яңадан куя. Ә Ю. Муконың бу опера өчен әзерләгән хореографик күренешләре Бөтенсоюз Олимпиадасында тәнкыйть тарафыннан тискәре бәяләнгән була.

Ул чорда, ягъни егерменче еллар ахырында, утызынчы еллар башында Казанда гастрольдә төрле балет труппалары, бию ансамбльләре һәм студияләре еш була. Аларның репертуары, кагыйдә буларак, бию сәнгатенең сынландыру чараларын яңача, заманча пластика белән җанландырырга тырышучы әсәрләрдән тора. Аларның һәммәсен дә игътибарга лаек дип булмый, әлбәттә. Ул эзләнүләр, ялгышулар һәм табышлар чоры. Шул күпсанлы гастролерләр арасында, табигый ки, сәнгатьтә үз юлын, үз йөзен тапканнары да бар. Әйтик, «бөек яланаяклы» дип дан алган Айседора Дункан шәкертләре... Бу эзләнүләр балетмейстер Таһиров иҗатына тәэсир итми калмый, әлбәттә. К. Тинчуринның пьесасы нигезендә куелган «Кандыр буе» спектаклендә динамо-машинаны сурәтләүче, салмак кына кызулый башлаучы «машина биюләре»,— әйтик, әнә шундый тәэсир нәтиҗәсе. Шушы ук күренешкә ул вакытларда модага кергән, шатлыклы, якты өмет һәм дәрт белән сугарылган физкультура биюләре дә кушылып китә. Болар ниндидер вакыйга уңае белән башкарыла торган кәеф биюләре, кеше рухының халәтен тасвирлаучы биюләр.

Ә сюжетлы татар биюенә килсәк, ул соңрак барлыкка килә. Дөрес, академия театрында С. Сәйдәшев музыкасына Гай Таһиров куйган хореографик күренешләрдә сюжетлы бию элементлары күренә башлый.

Музыкаль драма жанры татар халык сәхнә биюен булдыруда, милли башкару стилен тудыруда гаять зур роль уйнады. Бу өлкәдә композитор Салих Сәйдәшев һәм балетмейстер Гай Таһиров хезмәтләрен тәкъдир итәргә кирәк. Шуның өстенә, музыкаль спектакльләр Татар дәүләт опера һәм балет театрын ачу өчен җирлек тә әзерләделәр.

1933 ел ахырында Гай Таһиров СССРның Зур театры каршындагы хореографик училищеда укый башлый. Күренекле хореограф-педагоглардан алган дәресләр биючөнең башкару осталыгын тагын да үстерә, балетмейстер сәнгатен тирәннән үзләштерергә ярдәм итә. Гай Таһиров Мәскәүдән 1938 елда кайта һәм ачылырга әзерләнүче Татар дәүләт опера һәм балет театрына баш балетмейстер итеп билгеләнә.

Театр беренче сезонын 1939 елның 17 июнендә, Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсы белән башлап җибәрә. Вакыйга Пугачев восстаниесе елларында усал алпавыт хатын Бикә утарында бара. Икенче пәрдәдә буа янында ял итеп ятучы кызлар янына эштән кайтып килүче егетләр җыела. Пугачевның көрәштәше Булат күренүен барысы да куанып каршы ала, күңелле, тормыш сөючән бию башланып китә. Дәртле кумәк биюнең милли матурлыгы нәфис хәрәкәтләр һәм башкару манерасы белән генә түгел, ә балетмейстер тарафыннан татар халык орнаменты рәвешендә оештырылган тышкы сурәт белән дә билгеләнә. Бу биюдә Таһиров хореографик полифониягә дә омтыла: биючеләр ансамбленнән сәхнә уртасына бер-бер артлы яңа парлар чыга. Аларның һәркайсының үзенә генә хас хореографиясе бар, һәм ансамбль, пластик аккомпанемент кына булып калмыйча, мәгънәви төсмерне баетучы катлаулы бурыч та үти.

Бу чорда Таһиров театрда П. Гертельнең «Юкка шикләнү» балетын, П. И. Чайковскийның «Евгений Онегин», Ш. Гуноның «Фауст» операларындагы биюләрне, һәм шулай ук М. Мозаффаровның «Галиябану» операсында халык биюләрен куя.

1940 елның 30 августында Мәскәүдә татар сәнгате декадасы үткәрү турында карар кабул ителә. Республиканың барлык әдәбият һәм сәнгать көчләре зур күтәренкелек белән шушы иҗади отчетка әзерләнә башлый.

Таһировка Нәҗип Җиһановның «Алтынчәч» операсында хореография өлешен әзерләү йөкләнә. Яшь булса да инде шактый тәҗрибә туплап өлгергән балетмейстер зур һәм катлаулы бурычны уңышлы хәл итә. Бер үк вакытта халык биюе өлкәсендәге эзләнүләрен дә туктатмый, биюгә көнкүреш әйберләрен, сугыш коралларын да кыю кертә. Мәсәлән, Тугзакның уллары сөңге, җәя, камчы белән биләр. Бу атрибутлар гаять оста файдаланыла һәм милли хореографиягә яңа элементлары өсти. Элегрәк мондый биюләр кемдәдер милли тәгаллеккә, ышандыру көченә ирешүдә шикләнү тудырса да, хәзер инде аларны һәркем бәхәссез кабул итә.

...Бөек Ватан сугышы барлык уй-планнарны пыран-заран китереп ташлый. Гай Таһиров хореографиясе белән куелган милли опералар, беренче татар балеты — Фәрит Яруллинның «Шүрәле»се күрсәтелми кала. Әмма республикада милли балет булдыру идеясе инде өлгереп җиткән һәм чынлап тормышка ашырырдай була.

Шуңа күрә, фронтларда туп авазлары да тынып өлгерми, 1945 елның 8 мартында Татар дәүләт опера һәм балет театрында күп пәрдәле «Шүрәле» балеты күрсәтелә. Аның I һәм III пәрдәләрен РСФСРның атказанган артисты Леонид Жуков, II пәрдәсен Татарстанның атказанган артисты Гай Таһиров куя.

«Шүрәле» — Таһировның иҗади омтылышларының таҗы. Фольклор нигезендәге профессиональ балет хореографның бөртекләп җыйган тәҗрибәсен, халыкның күңел байлыгын аңа яңа сыйфатта кайтарып бирү кебек яңгыраш ала.

1940 елда Татар дәүләт филармониясенең җыр һәм бию ансамбле Ерак Көнчыгышта озакка сузылган гастрольләрдә йөреп кайта. Кайтуга ук Мәскәүдәге декадага әзерлек башлана һәм ансамбльне җырчылар һәм биючеләр белән ныгыту көн тәртибенә беренче мәсьәлә итеп куела. Шул максатларда иң яхшы үзешчән сәнгать көчләренә республика смотр-конкурсы игълан ителә, ә Гай Таһиров ансамбльгә хореограф итеп чакырыла, артистларга классик бию дәресләре бирә башлый. Бөек Ватан сугышы башланганчы ул ансамбльдә беренче хореографик әсәрен — Сара Садыйкова музыкасына «Өч кыз» биюен куя. Бу инде «шәһәр биюе» һәм «авыл биюе»ннән аермалы була, аңа акрын темп, салмак хәрәкәтләр хас. Ул озак еллар буе тамашачылар күңелен җәлеп итеп килде. Моннан тыш Таһиров «Кияү каршылау», «Өч ахирәт» кебек сәхнә күренешләре тудыра. Бөек Ватан сугышы елларында гына түгел, аннан соң да филармония белән иҗади бәйләнешләрен өзми.

Әмма аның җыр һәм бию ансамблендә иң актив һәм нәтиҗәле эшчәнлеге 1952 елда, филармониягә балетмейстер итеп эшкә чакырылганнан соң башлана. Аңа кадәр ул фольклор экспедициясендә йөреп кайта. Тупланган гаҗәеп бай материал — барысы 52 бию үрнәге язып алынган була — балетмейстерда кадриль формасындагы хореографик номер әзерләү фикере тудыра. Постановкага «Түгәрәк уен», «Йолдызым», «Кул сугып уйнау», «Станок» кебек кыска фольклор биюләрен нигез итеп алып һәм, бераз соңрак аңа «Тимерчеләр» дигән яңа бию өстәп, Гай Таһиров «Колхоз яшьләре биюе» дигән милли сәхнә номеры иҗат итә. Татар профессиональ хореографиясе өчен гадәти булмаган күренеш ул. Яңалыкны бөтен сәнгать белгечләре дә яратып каршы ала дип әйтеп булмый, әмма иң гадел хөкемче — вакыт эзләнүләрнең дөрес юлда булуын, экспериментның барып чыгуын раслады.

Илленче еллар,— гомумән, татар сәнгатендә сюжетлы биюләрнең чәчәк аткан чоры. Таһиров иҗат иткән хореографик композицияләр ансамбльнең репертуар политикасын билгеләп кенә калмый, аның үзенә генә хас йөзен дә булдыра. Шул чорда һәм бераз соңрак Таһиров «Кош караучы һәм сыер савучы», «Башмагым», «Зәңгәр шәл», «Тракторчы» һәм башка бик күп сюжетлы биюләр тудыра.

«Батраклар» биюе дә шундыйлардан. Биредә ярлыларның байларга каршы көрәше кебек социаль гаделлек темасы күтәрелә. Усал хуҗабикә үзенең ялчыларын мәсхәрәли. Баштарак баш иеп торган ялчылар, ниһаять, үзләрен изүче белән ачыктан-ачык көрәшкә күтәреләләр. Шушы бию озак еллар буе репертуардан төшми, 1959 елгы гастрольләр вакытында Корея Халык Демократик Республикасында да күрсәтелә. Ә инде 1960 елда Кытай Халык Республикасында кытайлылар аны хәтта «күз биюләре» итеп кабул итәләр.

Таһиров әдәбият геройларын хореографик сәхнәгә күтәрүдә дә уңышлы эшли. Мәсәлән, 1952 елда сөекле шагыйребез Габдулла Тукайның «Таз» шигыре геройлары биюдә җанландырыла. «Мәдрәсәдәге хәл» исеме алган бу шаян бию әле хәзер дә Татар дәүләт Җыр һәм бию ансамбле игъланнарын бизәп тора. Алтмышынчы елларда Муса Җәлилнең «Хәдичә» шигыренә нигезләп яңа бию куела. Сатирик рухтагы бу күренеш гаять заманча булып чыга, тамаша залында һәрвакыт көлү тавышлары яңгырый. Шуның өстенә Таһиров, сюжетны кинәйтә төшеп, биюгә тагын яңа образлар — үтә модный өч егет тә кертә.

Милли хореографик репертуар тудыру өстендә эшләгәндә Гай Таһиров һәрвакыт халык иҗаты материалына таяна. Аның иҗатында ул яңартыла, хореограф-рәссамның дөньяга карашын аңлату чарасына әверелә, шул ук вакытта тирән дәрәҗәдә халыкчан

һәм аңлаешлы булып та кала. Татар дәүләт филармониясендә эшләгән елларында балетмейстер җитмешкә якын хореографик композиция иҗат итә. Алар арасында украин, рус, башкорт һәм башка халыклар биюләре бар. Бер үк вакытта ул үзешчәннәр белән эшләүгә зур көч куя. Бу исә, үз чиратында, аңа эзләнү һәм күп төрле эксперимент алып барырга, яңа табышлар һәм ачышларны профессиональ сәхнәгә күчерергә мөмкинлек бирә. Еш кына биюләр тамашачыга гадәти булмаган формада тәкъдим ителә, алар байтак бәхәс тудыруга сәбәп була.

Еллар үтте. Хәзер әнә шул биюләр татар милли хореографиясенең алтын фондын тәшкил итә, алар халык бию ансамбльләрендә генә һәм Татарстанда гына түгел, башка тугандаш республикаларында да зур уңыш белән бара. Гай Таһиров, мәсәлән, Игорь Моисеев җитәкчелегендәге СССР Дәүләт халык бию ансамблендә (1949), Әзербайҗан дәүләт җыр һәм бию ансамблендә (1969), Чуваш дәүләт җыр һәм бию ансамблендә (1956, 1982 еллар) татар биюләрен куйды. Шәкертләре исә Гай Таһировның хореографик эшләрен илебездәге башка бик күп сәхнәләрдә һәм чит илләрдә яңарттылар. Һәркайда татар биюе тамашачыны әсир итә икән, монда аның тамырлары белән халык иҗатына барып тоташуын да, үз заманының, иҗтимагый мөнәсәбәтләрнең чагылышы булуын да, шуларның художник күңелендәге балкышы икәнен дә истән чыгармаска тиешбез.

Хәзер фольклор белән кызыксыну артканнан-арта бара. Бу табигый күренеш, чөнки халыкның мәңге яшь күңеле нәкъ менә шул әсәрләрдә яши дә. Татар хореографиясе практигы һәм теоретигы Гай Таһировның бөтен иҗат юлы фольклор белән тыгыз бәйләнгән булуы бер дә гаҗәп түгел. Ләкин бу балетмейстер бары тик татар халык биюе белән генә шөгыльләнгән дигән сүз түгел. Аның тарафыннан П. Гертельнең «Юкка шикләнү», Р. Глиэрның «Кызыл мәк» балетлары, башка күп спектакльләр куелды, Европа һәм рус композиторларының классик опералары өчен оригиналь хореография барлыкка китерелде, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә СССР халыкларының бик күп биюләре әзерләнде. Идел буе халыкларының бию культурасын яхшы белгән Гай Таһиров инде күп еллар дәвамында Казан дәүләт культура институтының хореография кафедрасында махсус курс укыта, яшьләргә үзенең белемен һәм бай тәҗрибәсен тапшыра. Ләкин ничек кенә булмасын, аның иҗатында төп урынны татар сәнгате били. Төрле елларда ул куйган һәм иҗат иткән 365 хореографик эшнең байтагы туган халкы хәзинәсенә карый.

Күп еллар дәвамында эзлекле рәвештә алып барылган эзләнүләр, бай тәҗрибә Гай Таһировка хореография буенча кулланма булырдай китаплар язарга мөмкинлек бирде. Аларның беренчесе — «Татар биюләре» — 1960 елда дөнья күрде. Анда Җыр һәм бию ансамблендә куелган җиде әсәр тасвирлана. Ә 1984 елда чыккан китапта автор инде унбиш композицияне сурәтләп кенә калмый, татар бию хәрәкәтләре һәм милли киемнәре турында бай мәгълүмат та бирә. Аның байтак кына эшләре шулай ук күмәк җыентыкларда һәм сәнгать журналларында басылып чыкты. Тиздән Татарстан китап нәшриятында аның яңа хезмәте дөнья күрәчәк.

Бию сәнгате... Халыкның рухи тормышында аның үзенә хас тоткан урыны, мәгънәви төсмере бар. Чын талант иясе фикере һәм иҗат фантазиясе белән кушылып, ул йөзләрчә яңа төсләр балкышы тудыра, тагын да баеп, матурланып, халыкның үз хәзинәсенә әйләнә. Бу хәзинәгә беренче профессиональ татар балетмейстеры Гай Таһировның да фидакарь хезмәте кергән.

**Владимир ГОРШКОВ.**

### библиография

# ХӘТЕРДӘ САКЛАП

Татар әдәбиятында биографик жанр тагын бер китап белән тулыланды[1]. Анда Муса Җәлилнең сугышка кадәрге тормышы һәм иҗаты яктыртыла. Китап рус телендә язылган һәм ул киң катлау укучылар массасына Җәлил каһарманлыгын тудырган чыганаклар, аның героик характерын тәрбияләп үстергән мохит белән танышырга мөмкинлек бирә.

Әдипнең портретын тудырыр өчен аның әсәрләрен, аның турында язылган әдәбиятны белү зарур. Әмма әле болар гына җитми. Чын мәгънәсендә җанлы портрет тудыру өчен әдип яшәгән чорга колак салу, мөмкин булган кадәр аның чордашларын, якыннарын, дусларын тыңлау кирәк. Р. Мостафин М. Җәлилнең сугышка кадәрге тормышын һәм иҗатын тулаем алып тикшерә. Каһарман Мусаның бөеклеге китапның анализ логикасын да билгеләгән. Давыллы бишьеллыклар, яңа төзелешләр, җәмгыятьтә тамырдан борылыш, иске белән яңаның кискен көрәше М. Җәлилнең редакторлык, журналистлык, язучылык һәм гомумән иҗтимагый эшчәнлеген билгели. Шәхес һәм тарих мөнәсәбәте — китапның буеннан-буена сузылган, әсәр структурасын тудырган төп тема.

Без сүз алып бара торган бу китап «Батырлык шагыйре», «Балачак һәм үсмерчак», «Комсомол яшьлеге еллары», «Иҗади өлгергәнлеккә ирешү юлында», «...хезмәт миңа татлы булды», «Гражданин, художник, шәхес», «Күпкырлылык», «...Алган һөнәр — тәнкыйтьче», «Йомгак» дип исемләнгән 9 бүлектән тора. Мондый бүленешнең һәм отышлы, һәм кимчелекле яклары бар. Уңай ягы шунда: автор М. Җәлилнең тормышын һәм иҗатын аерым-аерым чорларга бүлеп, тәфсилләп, шәрехләп күзәтә. Әмма, безнең карашка, хронологик принцип үзмаксатка, фактлар җыелмасына әйләнмәсә генә үзүзен аклый ала. Кайбер очракларда хронология тәртибе проблемаларны тотып алырга комачаулый, кабатлауларга китерә.

Шуңа да карамастан, Р. Мостафин үзен комплекслы анализ остасы итеп таныта, вакыт-вакыт ул я тарихчы, я тәнкыйтьче, я әдәбият-сәнгать белгече, хәтта художник булып та күз алдыбызга баса.

Тарихчы буларак автор М. Җәлил эшчәнлеген һәм аның даирәсен илдәге тирән процесслар (Гражданнар сугышы, 1921 нче елгы ачлык, индустрияләштерү һәм коллективлаштыру, культура революциясе) белән үрә. Гомум һәм аерымның үзара бәйлелек диалектикасы китапта яхшы күзәтеп барыла, шагыйрь шәхесе тарих контекстына урнаштырылган. Китапта китерелгән мәгълүматлар арасында әллә ни әһәмияте булмаганнары, хикәяләүне авырайтканы да очрамый түгел — вакыт-вакыт артыгы белән төпченү дә сизелә, ләкин иң кирәклесе — шәхесне тарих яктылыгына куеп карау — китапта сакланган. Автор Февраль буржуаз революциясеннән соң илдә урнашкан ике властьлылык турында, атаман Дутов бандалары, буржуаз милләтчеләрнең «татарларның бәйсез Идел-Урал дәүләте» лозунгысын тормышка ашырырга кечәнеп маташулары, санакчелар, корылык хакында сөйли. Без иҗтимагый вакыйгаларның, чыннан да, М. Җәлилгә турыдан-туры йогынты ясавына, анда сыйнфый интереслар тууга һәм аның тормышта билгеле юнәлеш алуы өчен сәбәпче булуына ышанабыз. «Җәлил редакциядә утырмый, бар булган вакытын предприятиеләрдә, учреждениеләрдә уздыра, гел эшчеләр белән аралаша, аларның ихтыяҗларын, хәсрәтләрен белеп ала, кыю рәвештә кимчелекләрне тәнкыйтьли» (61 б.).

Р. Мостафин республикада барган культура төзелеше панорамасын ачып җибәрә, газета-журналларны, күренекле әдәбиятчыларны санап уза, геройны, Оренбург өлкәсенә күчереп, комсомолның гөрләп торган тормышы эченә кертә, төрле тормыш тармакларында, төрле рольләрдә сынап карый. М. Җәлил Мәскәү дәүләт университетында укый, бер үк вакытта «Кечкенә иптәшләр» исемле балалар журналында җаваплы редактор булып эшли. ВЛКСМ Үзәк Комитеты каршында татар-башкорт секциясенең Үзәк бюросы составына кабул ителә, «Фән һәм дин», «Яшь эшче», «Ударниклар» журналлары редколлегияләренең почетлы әгъзасы була. Мәскәүдә һәм Мәскәү бисталәрендә яшәү-

[1] Мустафин Р. Муса Джалиль. Жизнь и творчество (довоенный период). Казань, 1986.

че татарларга лекцияләр укый. «М. Җәлил дүрт кешелек йөкне бер үзе тарта һәм авыр-сынмый, тормыш тулылыгыннан ямь таба» (128 б.). Бу — мөһим нәтиҗә. Әмма ул М. Җәлилнең рухи-психологик үсешен төсмерләгән күңел диалектикасын ачып исбатлауны таләп итә. Чөнки, китапта күрсәтелгәнчә, шагыйрьнең үсеш юлы шома булмаган, М. Җәлил һәрчак каршылыкларны җиңеп алга атлаган. Тоткынлык, яшерен көрәш, үлемгә хөкем ителгәннәр камерасына ябылулар — боларны, һичшиксез, яшьтән чыныккан, утны, суны кичкән характер җилкәсе генә күтәрә ала. Автор мажор тонда яза. Алай да тормыш дөреслеге һәм биография фактлары шагыйрьнең каршылыклар кичергәнен дәлиллиләр.

Шагыйрь характеры китапта уңышлы ачылган. М. Җәлил көчле шәхес тә, самими, гади, эчкерсез кеше дә булып күз алдына килеп баса: «Аралашучан, гади, ачык характер иясе буларак, ул кешеләр белән тиз дуслашып китә иде — аның янында аларга күңелле иде. Студентлар торак йортының теләсә кайсы бүлмәсендә ул көтеп алынган кунак иде. Еш кына үзе белән иске мандолинасын алып килә, татар-башкорт көйләрен башкара иде» (78 б.).

М. Җәлил — ышанычлы көрәштәш тә. Татарстан Язучылар союзында җаваплы секретарь вазифасын үтәгән чакта ул язучыларның тормыш-көнкүреш шартларын кайгырта, аларга гонорар ставкаларын арттыру мәсьәләсен кузгата, яшь язучыларга карата таләпчән һәм кайгыртучан була.

Р. Мостафин тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече буларак, әсәрләрне анализлаудан тыш, үзенең игътибарын шагыйрьнең иҗат психологиясенә дә юнәлтә. Художникның иҗат психологиясе иҗади биографиянең бер өлкәсе рәвешендә бездә әле сирәк өйрәнелә. Күрәсең, бу өлкә артык катлаулы, ул әле башка милли әдәбиятларда, хәтта рус әдәбиятында да җитәрлек тикшерелмәгән. Күп очракта без әзер текст белән эш итәбез, ә иң мөһим булган нәрсәне, ягъни язучының фикерләү процессын, текстның күпвариантлы органикасын тәшкил иткән идеяләр драмасын читтә калдырабыз. А. С. Пушкин язганча, без «ялкау, кызыксынучан түгел» («мы ленивы и нелюбопытны»).

М. Җәлилнең иҗат психологиясе китапта түбәндәге параметрларда күзәтелә: тормыш йогынтысы, әдәби остаз, авторитетлар, авторның күзәтүчәнлеге, төп фикере, хәтер, прототиплар. Китапта Р. Мостафин биргән бәяләр дә — оригиналь. Мәсәлән, тәнкыйтьче «Җиденче номерлы домна» поэмасы ни өчен, тормышчан һәм эшчеләр темасын үзәккә алырга тиешле булуына да карамастан, язылмый калганын аңлата: «Әле студент чакларда Җәлил (Х. Туфанның «Урал эскизлары» тәэсиренә бирелеп булса кирәк) «Җиденче номерлы домна» исемле поэма язарга уйлаган иде. Надеждинск шәһәренә барып, анда горнда эшләүчеләр, корыч эретүчеләр белән аралашты, эшчеләрнең өйләрендә булды, эшчеләр клубына йөреп кичәләрдә катнашты. Бай материал туплады. Ләкин... аның күп мәртәбәләр сыналган «производство поэмасы»ның тапталган юлларыннан барасы килмәде, ә инде ниндидер көтелмәгән, яңа борылыш таба алмады» (173 б.).

Автор игълан иткәнчә, архивта М. Җәлил әсәрләренең кулъязма вариантлары саклана. Киләчәктә иҗат процессының бу ягы да яктыртылыр дип ышанабыз. Дөрес, монда гаять күп тырышлык таләп ителә, күп тир түгәсе бар: текстларны карап чыгарга, бәйнә-бәйнә чагыштырырга кирәк. Бу ювелир хезмәтедәй вак, ялыктыргыч, әмма ахырында җимеш бирәчәк хезмәт.

М. Җәлилнең искиткеч эшчәнлеге сокландыра. Автор аның кайбер серләрен ача: М. Җәлил төнге сәгатьләрдә эшләргә күнеккән. Ә көндезләрен буш минут табылдымы, шунда ук язарга-сызарга тотына (Г. Әпсәләмовка, Г. Ибраһимовка да бу сыйфат — хезмәтне фәнни оештыру — хас иде).

Ләкин иҗади процессның күп яклары әле китапта безнең өчен ачылмаган булып кала. Мәсәлән, шагыйрь ни дәрәҗәдә иҗат дәртен туплый, нинди рәвештә вариантларны хәтердә берәмтекли, сайлый, ничек тормыш күренешен образга әйләндерә? Автор М. Җәлил әсәрләренә һәр җирдә дә тигез анализ бирми. Төгәл характеристика белән бергә китапта «ощущение душевной высоты, чистоты и накала чувств», «углубление психологического анализа» кебек штамплар, артык «шома» урыннар очрый. Әмма, гомумән алганда, анализ алымнары күп төрле, фәнни объективлыкка нигезләнгән. Мин авторга карата «намуслы» дигән төшенчәне дә өстәп әйтер идем, ник дисәң, автор башка белгечләрнең карашларына да колак сала, фәнни оппонентлар белән санаша, М. Җәлил тормышын тикшерүне үз биләмәсе дип кенә карамый.

М. Җәлилнең кайбер әсәрләренә бәя биргәндә автор полемика алымына мөрәҗәгать итә. Мондый алым бик урынлы. Әсәр гүя безгә төрле яклары белән борыла, М. Җәлилнең образлар системасы күп яңгырашлы булып ачыла. Бу — безнең тәнкыйтьтә яңачарак алым. Моңа кадәр аерым тәнкыйтьчеләр, гадәттә, гел үз карашларын гына алга сөрделәр, көчләп дигәндәй, үз фикерләрен генә тактылар. Аңлату, сөйләшү бер төс, авторитар төс ала иде: «Мә, ышансаң ышан, ышанмасаң — юк, әйттем — бетте», янәсе. Бәхәсчеләрнең һәрберсе үзенчә хаклы булырга мөмкинлеген онытмыйк: сәнгать әсәре алдан билгеләнгән, бүтән аңлатуларны кабул итмәгән теорема түгел. Р. Мостафин, бу хәлне аңлап, үз карашын укучыга көчләп такмый, әдәп саклап аңлата. Әйтик, «Хат

ташучы» поэмасында кайсыдыр урыннарны аңлатканда автор Нил Юзиев белән килешми: «Тәнкыйтьче поэманы лирик-психологик характердагы әсәр дип кабул итә. Һәм шул ноктадан геройлар кичерешләренең реальлеге, характерлар чынлыгы, сурәтләүнең тәгәл булуы, хиснең табигыйлеге хакында яза.

Миңа калса, мин поэманы башкачарак тоям. Әйе, әсәр асылда реалистик планда иҗат ителгән. Әмма аның үзенчәлеге психологик дөреслектә түгел. Поэма шартлы-юмористик характерда язылган» (221 б.).

М. Җәлилне тәрҗемәче һәм тәнкыйтьче итеп күрсәткән бүлекләрне зур кызыксыну белән укыйсың. Сер түгел: язучыларыбыз арасында тәрҗемәче хезмәтенә һәрвакытта да ихтирамлы мөнәсәбәт сакланмый. Кайчак талантлы әсәр төпле тәрҗемәче кулына эләкми, начар тегелгән костюм кебек, бөтәрләнеп, ямьсезләнеп кала. «Тәрҗемәче,— дип ассызымлый Җәлил,— әсәрне җанландырып җибәрергә, аны яңача буяулар белән баетырга маһир. Андый тәрҗемә, оригинал белән тиңләшеп, тулы канлы тормыш белән яши башлый» (298 б.).

Бу — бүгенге көн таләпләренә тәңгәл килгән күзәтү. Тәрҗемәче — кол түгел, ә көндәш, ярышташ. Тәрҗемәгә җан өрү — шагыйрь (прозаик, драматург) иҗатыннан башка — аның илен, халкын, милли характерын чын күңелдән ярату, аңа дуслык кулын сузу дигән сүз. Моннан да изгерәк эш булуы мөмкинме! Менә шундый ул Җәлил! Тәрҗемәне ихлас күңелдән яратты, кабул итте, олы сәнгать юлыннан атлады.

Р. Мостафин М. Җәлилнең заманга бәйле кайбер тәгәлсезлекләрен томалап калдырмый. Ләкин, кагыйдә буларак, М. Җәлил объектив, җитди, тарихи анализ куллана. Әдәбият,— ди ул,— чорны чагылдырып кына калмый, җәмгыятькә актив рәвештә йогынты да ясый.

Тулаем алганда, китап уңышлы чыккан. Ул биография жанрының иң гүзәл традицияләрен, беренче чиратта авторның укучы белән диалогын дәвам итә. Андый аңлаешлы, җиңел тел белән язылган, мавыгып укыла торган фәнни хезмәтләр бездә, кызганычка каршы, әллә ни күп түгел. Укырга тотынсаң, кытыршы фразаларны, язылган фәнни терминнарны абына-сөртенә көчкә ерып чыгасың.

Р. Мостафинга тотнаклылык хас. Юк, юк, ул үз сүзен әйтә белә, кирәк чакта кадаклап та куя ала. Р. Мостафин урыны-урыны белән балаларча самими, дустанә күзәтеп кенә калмый, укучы белән җитди әңгәмә дә кора.

Китапның тагын бер кыйммәтле ягы — дәлилләүнең ышандырырлык булуы. Җәлил үткән юллар нык күзәтелгән. Ә инде «ак таплар» очраган урында автор: әйе, бу мәсьәлә әле хәл ителмәгән, өйрәнелмәгән дип икърар итә.

Автор Җәлилне тикшерү эшенә нокта куймас әле дип ышанасы килә. Шуңа күрә алга таба аның кайбер проблемаларны киңрәк яктыртуын телләр идек. Беренчедән, Җәлил социалистик реализм методын конкрет ничек үзләштерә? Китапта аерым әсәрләрне, шигырь циклларын анализлауга чагыштырмача күп урын бирелсә дә, алар әле метод белән йомшак бәйләнгән. Метод — әсәрләрне билгеле бер системага оештыручы иҗат тәрәге. Һәрхәлдә, анализны аерым әсәрләрдән башламыйча, методтан (дөньяга караш, эстетик идеал белән берлектә) башларга кирәк, шул чакта поэтик алымнар һәм чаралар, форма белән эчтәлек бәйләнеше тәзек, гармонияле тәртипкә китерелер. Сүз җаенда, автор анализның философик контрапунктын таба, Җәлил поэзиясенең интеллектуаль-философик башлангычын танып ала: «Шагыйрьнең күп шигырь юллары тормыш һәм үлем, табигать һәм кеше, шәхес һәм җәмгыять диалектикасы хакында уйланулар белән тулы. Җәлил үз фикерен абстракт тезис итеп формалаштырмый, бәлки образ, метафора теленә мөрәҗәгать итә, үз уйлануыннан битәр, укучыда билгеле фикер тудыра, укучыны билгеле нәтиҗәләргә таба этәрә» (235 б.). Чыннан да, Г. Тукай белән бергә рус һәм бөтендөнья поэтик тенденцияләрен дәвам иткән Җәлил җырчы булып кына калмаган (кайбер белгечләр аны шушы рольдә генә күрмәкче булалар), ул — философик диапазонлы, киң колачлы шагыйрь, поэтик үрләрнең берсе.

Икенчедән, М. Җәлилнең иҗади бәйләнешләры турында да күбрәк беләсе килә. Күп очракта автор аларны санап кына үтә, артык төпченми. Ә иҗади мөнәсәбәтләр турында бер детальне дә калдырмыйча сөйләп бирү кирәк. Җәлилнең дуслары, танышлары бик күп була: Х. Туфан, Ш. Усманов, Г. Кутуй, Х. Такташ, Ф. Әмирхан, А. Фадеев, Ан. Тарасенков, А. Жаров, М. Шагинян, В. Финк, М. Бубеннов һ. б. Әнә шундый һәр очрак турында аерым китап язарга була, аларның һәммәсе үзенә бер тема. Культура эшлеклеләре белән аралашуны бер бүлеккә аерып кую кулайрак булыр иде кебек.

Өченчедән, Р. Мостафин сугыш алды еллары турында читләтебрәк әйтеп үтә. Халбуки, ул елларда («Алтынчәч» поэмасы язылган вакытта) дөнья җәмәгатьчелеге, культура эшлеклеләре, киң фронт ачып, фашизмга каршы чыга. Тынычлыкны саклау максаты белән халыкара форумнар оештырыла. Боларга М. Җәлилнең мөнәсәбәте, катнашы ниндирәк булган?

Ниһаять, М. Җәлилнең сугыш алды иҗатындагы мотивлар, идеялар, сурәтләр Моабит циклы белән ничек бәйләнгән — шуны да ачыклыйсы бар...

Энгель **НИГЪМӘТУЛЛИН.**

# ДӘРҖИЯ АППАКОВА

ТУУЫНА 90 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН

Студент халкының китаплар сатып алырлык ук байлыгы юк иде ул елларда. Китаплары да, хәзерге кебек, күпләп басылып тормый иде. Шуңа күрә чыкмый яткан җиребез китапханә булды безнең. Республика үзәк китапханәсе университет каршында гына. Борынгы матур бинаның түбәнге катында, тәрәзәләре Лобачевский бакчасына караган бүлмәсендә, татар китаплары бүлеге. Бүлек мөдире — җан җылымлы Саҗидә апа Сатиева. Картотека тартмаларында гына түгел, китап киштәләрендә дә иркенләп актарынабыз. Саҗидә апа күп язучыларны әсәрләре буенча гына түгел, үзләрен дә якыннан белә, алар турында истәлекләр сөйли. Әдәбият җене кагылган студент яшьләр иялләндек без бу апага.

Шулай бер көнне китап актарып торганда зәңгәр тышлы кечерәк бер җыентыкка юлыктым. Эзләгәнем ул түгел иде, билгеле. Бәлки мин аңар игътибар да итмәгән булыр идем, «Дүрт әкият» дигән бу китапның авторы Дәрҗия Аппакова икәнен белгәч, кулыма алдым. Кылт итеп, «Кечкенә Бануның тарихы» дигән повестьны бик яратып укуым искә төште.

Озакламый, Матбугат йортында мин аның үзен дә очраттым. Фатих Кәримнең хатыны, үзе дә балалар өчен хикәяләр язучы Кадрия Ишукова белән баскычтан төшеп килә иде. Миңа ул олы, олпат күренде. Өстендә, нинди мехтандыр, ул елларда «манто» дип йөртелгән тун, башында каракүл бүрек, бүрек өстеннән кызыл йон шарф салган.

Үзем кебек, буш вакыты булдымы, матбугат йортының дүртенче катындагы консультация бүлмәсенә шигырь тотып йөгергән дус кызым алар үтеп киткәч:

— Дәрҗия Аппакова,— дип пышылдады.

Шуннан соң мин аны еш очрата торган булдым. Ул үзе дә миндәй яшьләрнең бу йорт тирәсендә нинди эш, нинди өметләр белән йөрүләрен төшенә иде булса кирәк, коңгырт күзләрен тутырып карап үтә иде. Аның яше дә, талчыккан түгәрәк йөзен нурландырып караган күзләре дә еракта калган әнине хәтерләтеп, сугыш һәм уку авырлыгыннан өшәнгән күңелне тергезеп җибәрә иде.

Дәрҗия Аппакованың иҗат гомере артык озын булмады. Кырык сигезенче елның маенда фаҗигале рәвештә дөньядан китмәсә, әле бик күп китаплар язар иде ул. Әдәби эшчәнлеге ун-унбиш еллап кына булса да, ул татар балалар әдәбиятында лаеклы урын алырлык әсәрләр иҗат итеп калдырды. Ә аңа кадәр ул, егерменче елларда әдәбиятка кергән каләмдәшләре кебек үк, газета-журналларда эшли, шактый вакытын балалар укытуга багышлый, партия-комсомол эшендә була. Бу хезмәтләрнең барысы да, үз чиратында, Аппакованың язучы булып формалашуына ярдәм итә. Бигрәк тә аның Казанда һәм Урта Азия мәктәпләрендә укытучылык итүе бала күңеленә якынаюга сәбәп була. Кыска гына вакыт эчендә ул балалар өчен «Сәнәкчеләр», «Яшь ударниклар», «Мәмәт һәм Аман карт», «Михнәт», «Лүли», «Кечкенә Бануның тарихы» һ. б. әсәрләр язып бастыра. Аларның күбесе рус, үзбәк, казах, уйгур һәм еврей телләренә тәрҗемә ителә, ә соңгысы инглиз телендә дә дөнья күрә. Бу повесть Бану исемле кечкенә кызның әсрау булып торганда күргән михнәтләрен, Октябрь революциясеннән соң якты хыялларына ирешүен ышандырырлык итеп сурәтли.

Түбән Кама районы Байгол авылының ярлы гаиләсендә туган Дәрҗия Аппаковага ул еллардагы тормыш-көнкүреш хәлләре яхшы таныш була. Бану кебек ярлы-ятимнәр Дәрҗиянең үз тирәсендә дә җитәрлек, аларның уй-хисләрен аңлый ул. Соңыннан Казанга килеп, керәшен татарлары өчен укытучылар әзерләүче мәктәптә белем алганда да өлешсезләрне күп очрата. Ә язучының табигать биргән сәләте, тормыш тәҗрибәсе һәм журналистика мәктәбен узуы көнкүреш детальләрен сәнгать югарылыгына күтәреп, укучы мәхәббәтен казанырлык әсәрләр язарга булыша.

Кая барсаң да бер дөнья дигәндәй, татар кызы Бануның язмышын төрекмән баласы Мәмәт, рус малае Митәй, чегән баласы Люли һ. б. уртаклаша. Халыклар башка, традицияләр үзгә, характерлар төрле-төрле, ә язмышлар бер үк. Әсәрләрендәге нәни геройларның авыр язмышларын Октябрь революциясеннән соңгы тормыш белән контрастта алып, Аппакова социаль гаделсезлекнең сәбәпләрен нәни укучыга җиңел аңлата алды. Төрле милләт халыкларының тормышын сурәтләгән бу повестьлар интернациональ тойгы тәрбияләүгә дә зур ярдәм итте.

Дәрҗия Аппакова китаплары баланы әдәпле, гадел, ярдәмчел, батыр булырга өйрәтте. Фикерләрен укучыга җиткерү өчен әдәбиятның төрле алымнарын, төрле жанрларын файдаланды: повестьлар, кыска хикәяләр, әкиятләр, пьесалар язды. Аппакованың әсәрләрендә педагоглык такты нык сизелә. Ул бер вакытта да кискен нәтиҗә ясамый, бу четерекле эшне китап укучының үзенә калдыра. Ләкин моңар карап кына язучының үз позициясе ачык түгел дип әйтеп булмый. Авторның фикере ачык һәм аңлаешлы. Ул бары тик укучы баланың мәктәптә дә җанына тиеп беткән дидактик алымнардан гына кача. Аның гадәттә, «кире тип» дип йөртелә торган геройлары да гел кире генә түгел, кылган яман эшләрдән ояла, үкенә беләләр, ничек тә бер яхшылык эшләп үзләрен акларга тырышалар. Язучының шушы иҗат принцибын раслау өчен «Сараның башыннан үткәннәре» дигән әкиятне искә аласы килә. Беркадәр Бажов әкиятләрен хәтерләткән бу әсәрдә Сара исемле ялкау һәм кире кыз турында сүз бара. Бервакытны ул әтисенең пыяла кисә торган алмазын югалта һәм шуны эзләп китәргә мәҗбүр була. Бара-бара җир астына төшеп җитә, андагы алтын-көмешләрнең, төрле-төрле минералларның матур төсләр белән җемелдәвен күреп, күңелендә гүзәллек хисе уяна. Җир катламнары арасында чишмәләр яралуын карап, эшкә дәрте кузгала. Ләкин ул берничә дә тотына алмый, бер нәрсә белән дә булышырга көченнән килми. Чөнки аның кулы эш белми, җир өстендә эшкә өйрәнмәде. Бу гүзәллеккә кагылды исә ватып куюы бар.

Менә шуннан соң инде балаларга тегеләй бул да, болай бул дип акыл өйрәтүнең кирәге калырмы икән?

Аппакова әкиятләрне күп яза. Аларның кайберләрендә татар, үзбәк, төрекмән халык әкиятләрендәге геройларны күрергә мөмкин. Мәсәлән, «Сөмбел»дә төрекмән халкының әкият герое һәд-һәд кошы белән очрашабыз. Татар Академия театрында берничә сезон уңыш белән барган «Тапкыр егет» драма әсәре татар халык әкиятләренә нигезләнеп язылган. Безгә бик таныш Шүрәле, айдагы ятим кыз Зөһрә, авыл малайларының мәңгелек юлдашы Акбай, халкыбызның батырлыгын, тапкырлыгын, лирик җанын гәүдәләндергән Әхмәт һәм Галиләрнең сөйкемле образларын тудырган автор. Шулай да Дәрҗия Аппакованың үз фантазиясенең җимеше булган «Иске чиләк», «Гөлчәчәк белән Сандугач», «Сараның башыннан үткәннәре» дигән әкиятләре оригиналь, бала мохитенә якынрак булулары һәм Алиш традицияләрен уңышлы дәвам итүләре белән күңелгә ятышлы дип әйтәсе килә.

Гомеренең соңгы елларында Дәрҗия Аппакова нәниләр өчен кечкенә хикәяләр язды. Артык зур булмаган бер мәйданда укучыга фикереңне җиткерү, характер бирү һәм тормыш-көнкүреш картиналары белән таныштыру, шуның өстенә укырга кызыклы да итеп язу — талантлы әдипләр кулыннан гына килә торган эш. Бу өлкәдә безнең Идрис Туктар, Абдулла Әхмәт, Әминә Бикчәнтәева кебек язучыларыбызның уңышлы гына тәҗрибәләре бар иде. Шулар янына һич икеләнүсез Дәрҗия Аппакова исемен дә куярга була.

Ул елларда сугыш авырлыгыннан һәм ятимлектән интегеп беткән сабыйлар күңеленә бәхет, шатлык, матурлык дигән төшенчәләр тансык иде. Сугышның иң каты чагында, мең тугыз йөз кырык өченче елны, хөкүмәтебез балалар өчен китап бәйрәме үткәрергә дигән карарны юкка гына чыгармады. Язучылар иҗатында да әтиләрнең сугыштан җиңеп кайтулары, чыршы бәйрәмнәре, чаңгы ярышлары кебек күңелле вакыйгалар ешрак очрый башлады. Аппакованың «Сөяк саплы пәке», «Йолдызкай», «Елка бүләге» дигән хикәяләрен укучы әнә шундый матур бүләк дип кабул итте. Ләкин анда да әле хәсрәт җиле исүдән туктамый, әле бер, әле икенче ишекне килеп кага. «Шыгырдавык башмаклар» хикәясе тормышның әнә шушы ачы хакыйкате турында сөйли.

Авторның иҗаты жанры белән генә түгел, тормыш хакыйкате, географик киңлеге, тәрбия алымнары ягыннан да төрле-төрле. Ләкин шунысы аяныч, бу хезмәтләрнең берсе дә профессиональ тәнкыйть тарафыннан бәяләнмәгән. Китапларының да күбесен, бигрәк тә сугышка хәтле чыкканнарын, табуы кыен. Табасы иде аларны, бер җиргә туплыйсы иде. Татар балалар прозасы дигән кыйммәтле хәзинәбезнең бер бөртеге бит ул.

**Ләбибә ИХСАНОВА.**

# ЧИШМӘЛӘРНЕҢ САФЛЫГЫ...

## РӘИС ДАУТОВКА 60 ЯШЬ



Нәшрият редакторлары, аларның эшләре исемә төшкән чакларда җир йөзенең гаҗәп бер могҗизасы — чишмә чыгу күз алдыма килеп баса. Белмим, чишмә чыгуны башка нинди күренеш белән чагыштырып була торгандыр? Тау итәгендәге ташлар арасыннан гайрәтле дәрт белән, сулкылдап, тере су агымы ургыла. Шушы дәртле терелектә, кабатланмас моңлы тавышта табигатьнең мәңгелек булуы, тереклек дөньясының рухи бер көч иканлеге яңгырый. Чишмә чыкканын караганда, кайвакыт күңелгә шөбһәле бер сорау килә: «Әгәр шушы саф көмеш су сазлык җиргә юлыккан булса!..» Сискәнеп китәсең. Чыганак сазлык җиргә юлыкса, чишмә тавышы сүнәр, су пычраныр, баткаклыкта калып югалыр иде... Иҗат чишмәсе дә шулай бит, нинди урыннан чыгуына карап, кызганычка каршы, кайчакта укучыга чисталыгын югалткач барып җитә, кай вакытта бөтенләйгә югалып, юкка да чыгып куя...

Рус совет әдәбиятында XXVII съездан соң кайбер чишмәләрне чистарту, аларны укучыга җиткерү процессы башланды. Михаил Булгаков, Андрей Платонов, Николай Заболоцкий, Борис Пастернак, Владимир Дудинцев... Санарга тотынсаң, бу исемлек бик озынга китәр иде. Безнең татар әдәбиятында, кызганычка каршы, чыгудан туктаган иҗат чишмәләрен чистартып, аларның шифалы суын укучыга җиткерү эше ни сәбәптер бик сүлпән бара. Әмма үзгәртеп кору һәм хакыйкать чоры безгә әле өметне өзмәскә куша.

Минем бу мәкаләм иҗат чишмәләренең пакьлеген, аларның иминлеген саклаучыларның берсе — нәшрият редакторы Рәис Нәүширван улы Даутов турында. Аның белән мин Эрнест Хемингуэй әсәрләре аша таныштым. Бәлки язучыларның күбесе, бигрәк тә иҗат аренасына алтмышынчы елларда чыккан әдипләр, бөек америка язучысы белән мавыгу чорын үткән булганнардыр? Хемингуэйның татарчага тәрҗемә ителүен ишетү белән мин ул җыентыкны эзләп таптым. Тормыш реалийларының кайберләре бары тик милли мохитта, шул милләтнең туган телендә генә яши ала. Хемингуэйның «Килиманджаро карлары»н гына алыйк. Әсәрнең герое — йөз процентлы янки, акчалы хатынының күңелен күреп, гомерен Африкада сафарида яндыручы тормыштан гарык булган күркәм кыяфәтле бер циник. Шушы образның татар телендә яңгырый алуына шөбһәм көчле иде минем.

«— Иң гаҗәбе шул: минем бер җирем дә авыртмый,— диде ир».

Әсәрне менә шушындый сүзләрдән бары тик Эрнест Хемингуэй гына башлый ала һәм шушы язучының үзенчәлеген Рәис Даутовтан башка тәрҗемәче саклый алыр идеме икән? Рәис Даутов тәрҗемәсендә «Килиманджаро карлары»ның төгәл саклануы мине чын-чыннан тетрәндерде. Шушы җыентыктан соң мин Даутов тәрҗемә иткән китапларны рәттән укып чыктым. Купринны, Фенимор Куперны, О'Генрины татар телендә бирергә тәрҗемәчеләрнең күбесенең көче җитә торгандыр. Ә менә Достоевскийны бозмыйча һәм саектырмыйча тәрҗемә итәргә, Мәхмүт Галәү әсәрләрен кире туган телгә кайтарырга,— башка талантлы тәрҗемәчеләрне кимсетмәм дип ышанам,— Даутовтан башка кешенең көче җиткән булыр идеме икән?

Якыннанрак танышкач, Рәис Даутов өчен тәрҗемә эше һәрвакыт икенче урында кала

килүен аңладым мин. Ул — редактор. Нәшрият редакторы. Татар әдәбияты, язучыларның бәхетләренә каршы, гомумән, талантлы редакторларга бай. Яхъя Халитов, Кыям Миңлебаев, Сания Сибгатуллина, Фәния Гайнанова, Марс Шабаев, Равил Кукушкин. Бу исемлекне теләгән чаклы озайтырга була. Кызганычка каршы, без, язучылар, аларны сирәк искә алабыз. Аларның эш ысуллары, алар туплаган тәҗрибә турында шушы көнгә кадәр бернинди фәнни эш, бернинди кулланма язылмаган. Аларның әдәбиятка керткән өлешләре шундый зур, эшләре кирәкле һәм шул кадәр җаваплы. Әдәбиятның язмышы, аның сыйфаты редакторларның һәм нәширләрнең әдәбият яратуына, аларның аңына, культурасына бәйле. Әдәбият тарихындагы бер генә шәхесне — Риза Фәхретдиневне генә алыйк. Ә Дәрдмәнд?

Татар әдәбиятын тирәнтен аңлавы, аны чиктән тыш яратуы Рәис Даутовны бүгенге көннең гомуми өянәге булган язучылыкка омтылудан коткарып калгандыр. Кем генә язмый хәзер. Хикәя белән ваклашып тормыйча, кулга каләм алу белән сандык зурлыгы роман яза башлау гадәти хәлгә кереп китте. Күләм файдасын аңлау әдәби сүз нечкәлеген аңлаудан алда бара. Менә нинди чорда яшибез без. Һәм бу процессның трагедиясе — халтурага каршы көрәш бернинди нәтиҗә бирми башлады. Чөнки — көрәшчеләрнең иң алдынгы сафында, ыштанын сызганып, халтурщик үзе йөгерә! Әдәбиятның пәйгамбәрлек вазифасы булуын Рәис Даутов шикелле фидакарьләрнең эше, аларның әдәбиятка керткән өлешләре аша гына аңлатып була торгандыр.

Р. Даутовның сәләте, аның таланты, билгеле, күктән төшмәгән. Ул — галимнәр арасында да татар әдәбиятының катлаулы проблемаларын, аның тарихын, нечкәлекләрен тирәнтен белүе белән ихтирам яулаган кеше. Шуңа өстәп, редакторлык эшендә озак еллар тел, фикер йөртү алымнарын, логика законнарын аңлау сәләтен туктаусыз камилләштереп килгән әдәбиятчы. Шуңа өстәп, иҗат эшендәге иң кыйммәтле, иң кирәкле сыйфат — үз эшен риясыз, ихлас ярату — менә аны уңышка һәм ихтирамга ирештергән нәрсәләр. Кол Гали, Габделҗаббар Кандалый, Утыз-Имәни, Дәрдмәнд, Акмулла, Габдулла Тукай, Галиәсгар Камал, Галимҗан Ибраһимов әсәрләре Рәис Даутов редакциясендә бер-бер артлы басылып чыга тордылар.

Кайчакта бу кеше миңа Кол Гали һәм Утыз-Имәниләрнең үзләрен күреп, алар белән сөйләшеп йөргән шикелле тоела башлый. Шул чорның телен, ул гасырларның мохитын, социаль сулышын өйрәнү һәм аңлау белән генә чикләнмичә, Рәис тугандаш халыкларның шул чордагы әдәбиятларын да ныклап өйрәнгән. Кеше күңеленең катлаулы юлларын, шәхестәге талантны үлчи һәм аңлата алырлык фән дә, методик кулланма да табылмаган әле. Бүгенге көн кешесенең күбесе белемнең берничә бөртеген эләктереп алу белән шул бөртекләрне тизрәк диссертациягә әйләндереп, фәнни дәрәҗә алырга, шул дәрәҗәне кафедра биеклегеннән байрак итеп болгап, дан нурларына коенып яши башларга ашыга. Бу очракта да шушы тапталган юлдан барудан Рәис Даутовны татар әдәбиятын чиктән тыш яратуы саклап калган булса кирәк. Белемен күрсәтмичә, яшереп саклау гадәте — безнең чорда сокландыргыч бер матур сыйфат.

СССР Язучылар союзының чит илләр белән элемтә итү бүлегендә эшләүче Камрон Хакимов үзенең татар язучылары белән Төркиядә йөрүе турында сөйләгәндә болай диде: «Ул төркемдә төрле кеше бар иде. Хәтта кибет витриналарыннан күзен ала алмыйча йөрүчеләр дә... Шулар арасында Герман Мелвиллның «Моби Дик» әсәрендәге капитан Ахавка охшашлы бер кеше хәйран калдырды мине. Бер-ике көн ул шундый көчле дикъкать белән төрекләрнең сөйләшүләрен тыңлап йөрде. Төрекчә язылган аңлатмалар янына туктый да, һәр сүзне күзе белән ашый, укый, иҗекләп кабатлый. Шул сүзнең туган телдә тәрҗемәсен табып, ат башы чаклы алтын тапкан кеше шикелле куана. Өч-дүрт көннән бу рәхәтләнеп төрекчә сөйләшә башлады. Төрек язучылары бу татар безнең борынгы телебездә сөйләшә дип үзен мактадылар. Шунысы кызык, ул кеше төрек телен беркайчан да махсус өйрәнмәгән булып чыкты». Өч көн эчендә төрекчә сөйләшергә өйрәнгән кешенең Рәис Даутов булуын шундук абайлап алдым мин.

Рәис Даутовның әдәбият яратуында, шул яратуны беренче урынга куеп, башка нәрсәләрне читкәрәк этәреп яши белүендә урта гасырда яшәгән дәрвишләргә охшашлык бар. Алар да бит мавыгуларын тормыш ыгы-зыгысыннан саклау өчен дан-шөһрәт куркынычыннан читтәрәк яшәргә тырышканнар.

Күп кенә кешенең төп эшеннән тыш аның байтак вакытын алган ниндидер бер мавыгуы була. Бәхетенә каршы, Рәиснең мавыгуы — шул ук борынгы кульъязмалар актару, туган телнең матурлыгыннан ләззәт табып яшәү. Менә ул кайда — чын, озак еллар таушалмаслык романтика! Бер тапкыр мин аннан: «Сигез сәгатьлек эш көне эчендә син ничек шул таушалудан төсләрен югалткан борынгы кульъязмаларны өйрәнеп бетерергә, аларга аңлатмалар әзерләргә өлгерәсең?» — дип сорадым. Рәис тыйнак кына елмаеп алды:

— Нәшрияттагы бүлмәдә мин авторлар белән сөйләшергә, эшләргә кирәкле материалларны җыеп, әзерләп куярга гына өлгерә алам. Төп эшемне мин үз өемдә, төнге

тынлыкта башкарам. Үземнең яраткан китапларым арасында. Ә стенадан үзешчән художник язган Галиәсгар Камал портреты, Кол Гали рәсеме карап тора. Төннәр буе без бергә эшләп утырабыз.

Ярату, хезмәткә сәләтеңнең соңгы бөртеген корбан итү эшне иҗат биеклегенә күтәрә. Рәис Даутовның редакцияләве, минемчә, иҗатның иң югары ноктасы. Җөмләдәге бер генә сүзне үзгәртеп куя ул. Яисә сүзләрнең бары тик урыннарын гына алыштыра. Җөмләдә гаҗәеп бер үзгәреш барлыкка килә: фикернең мускулы нығый, сүзләрнең яңгырашында мелодия барлыкка килә. Әдәби әсәрнең бу берәмлеге шуннан соң инде яңа сыйфатка күтәрелә. Камилләшкән җөмлә тойгыларны җанландыра, ачыкланган, көчәеп киткән фикерне акыл рәхәтләнеп кабул итә. Матур әдәбият бит ул соңгы чиктә — сүз белән аңлатып булмаслык илаһи бер тылсым. Редактор Рәис Даутов шул тылсымның серен белүче шаманга, камга охшашлы.

Бу елның 15 мартында Рәис Даутовка 60 яшь тула. Юбилей шаблонында алтмыш яшьлек кешегә комплиментлар әйтү гадәткә кереп киткән. «Алтмыш яшь — иҗат кешесенең әле яңа өлгереп җиткән чагы, алда Сезне яңа үрләр, яңа уңышлар көтә...»— дип әйтәләр. Алтмыш яшькә җиткән кешегә пенсия түли башлыйлар. Әгәр син егермеләр тирәсендә эшли башлаган булсаң, бу инде җәмгыятькә кырык ел көч түктең дигән сүз. Җәмгыятькә кырык ел гомерен бүләк иткән кешегә үз иркенә, үз мавыгуларын алга куеп яшәргә шактый аз кала. Кайберәүләр пенсиягә чыккач бакча үстерә, икенчеләр шырпы тартмасына ябыштырылган этикетка җыялар. Пенсионерлар арасында кая борын төртергә белмичә йөреп, редакцияләргә аноним хатлар, югары инстанцияләргә жалобалар язу белән шөгыльләнүчеләр дә очрый. Рәис Даутовны мин үзен кая куярга белми йөрүче итеп күз алдыма китерә алмыйм. Аның мавыгуы шул кадәр көчле: без аннан озак еллар буе безнең борынгы әдәбиятыбызны укучыларга җиткерү өстендә эшләве турында мемуарлар язуын көтәргә хаклы. Ул әле озак еллар туплаган тәҗрибәсен яшь редакторларга тапшырырга да тиеш. Рәис Даутов иҗат чишмәсенең илаһи дәрт белән сулкылдап чыгуының серен белә. Шул серне ул яшь көчләргә тапшырырга тиеш.

**Миргазиян ЮНЫС,**
Мәскәү.

# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

21 январьда Татарстан Язучылар союзы партия оешмасының чираттагы ачык җыелышы үткәрелде. Җыелышта иҗат секцияләренең әдәбиятыбызның идея-художество үсталегеи күтәрүдәге роле турында сөйләшү булды.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе урынбасары Г. Рәхим иҗат секцияләре эше турында чыгыш ясады.

Фикер алышуларда секция җитәкчеләре М. Галиев (проза), Р. Гатауллин (поэзия), Ф. Мусин (тәнкыйть), М. Зарипов (очерк һәм публицистика), Р. Миңнуллин (балалар әдәбияты), әдипләр М. Хәсәнов, М. Хәбибуллин, Ә. Рәшитов, Р. Мингалим, М. Вәлиев һ. б. чыгыш ясады.

## Ш. МӘРҖАНИНЕҢ ТУУЫНА 170 ЕЛ

14-15 январьда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында күренекле татар галиме, фикер иясе һәм мәгърифәтче Шиһабетдин Мәрҗанинең тууына 170 ел тулуга багышланган региональ фәнни конференция үткәрелде.

Конференцияне Институтның директоры, профессор М. З. Зәкиев кереш сүз белән ачты.

Философия фәннәре докторы Я. Г. Абдуллин үз докладында Ш. Мәрҗанинең биографиясен һәм галимнең иҗтимагый фикер тарихындагы урынын яктыртты.

СССР Фәннәр академиясенең Гуманитар фәннәр буенча фәнни информация институты хезмәткәре, танылган философ А. В. Сәгадиев Ш. Мәрҗанинең гарәп философиясенә карашларын яктырта торган доклад ясады.

Казан университеты проректоры, профессор М. Г. Госманов күренекле галимнең халык мәгарифе өлкәсендәге эшчәнлеге ача торган яңа материаллар белән таныштырды.

Казан университетының фәнни китапханәсе хезмәткәре А. Фәтхиев галимнең татар язма культурасын өйрәнүгә багышланган эшчәнлеге турында сөйләде.

Р. Нәфыйков, М. Юсупов, А. Халиков, Ә. Хәйруллин, Р. Фәхретдинов, М. Гайнетдинов, Р. Мөхәммәтдинов, Н. Гәрәева һәм башка докладчылар Ш. Мәрҗанинең татар җәмгыятендәге ролен һәм галимнең татар халкы һәм көнчыгыш халыклары культураларына караган хезмәтләрен анализладылар. Чыгыш ясаучылар күп кенә сорауларга җаваплар бирделәр. Докладлар буенча фикер алышуларда язучы Ә. Еники, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Ш. Сарымсаков һ. б. катнашты.

Ш. Мәрҗанинең оныгы Н. Ильясова үзенең истәлекләре белән уртаклашты.

Ш. Мәрҗани истәлеген мәңгеләштерү өчен галимнәр һәм җәмәгатьчелек тарафыннан төрле тәкъдимнәр әйтелде.

## ЧОРДАШЛАР ШИГЫРЬ СӨЙЛИ

23 октябрьдә Казанның Актерлар йортында «Чордашлар» дигән әдәби-музыкаль кичә булды. Анда шагыйрьләр Л. Шакирҗанова, Ж. Дәрзаман һәм Х. Әюпов үзләренең әсәрләрен укыдылар. Татарстанның халык артистлары В. Гыйззәтуллина, Н. Әюпов, җырчылар К. Хәйретдинова, Г. Сафиуллина, артистка Луара Шакирҗанова катнашында концерт булды.

## М. СЕСПЕЛЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

13-15 октябрьдә Чувашия АССРда чуваш поэзиясе классигы Михаил Сеспель истәлегенә багышлап, яшь язучыларның әдәби форумы үткәрелде. Әдәбият бәйрәменә Идел буе автономияле республикаларыннан, шулай ук Латвия һәм Мәскәүдән яшь язучылар килгән иде. Алар милли әдәбиятлар арасындагы бәйләнешләр турында фикер алыштылар, эшчеләр, авыл хезмәтчәннәре, студентлар алдында чыгышлар ясадылар. Әлеге бәйрәмдә республикабыздан яшь шагыйрьләр Р. Зәйдуллин, Г. Моратов, Р. Насыйбуллин катнашты.

## ӘЛМӘТ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

18 ноябрьдә Әлмәт шәһәре Төзүчеләренең техника йортында атаклы шагыйрә Саҗидә Сөләйманова истәлегенә багышланган «Кызыл каурыйлар» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды.

Кичәдә шагыйрьләр Г. Афзал, Ә. Маликов, Э. Мөэминова, К. Булатова, Р. Рәкыйпов һәм «Кызыл каурыйлар» әдәбият берләшмәсе членнары, үзешчән артистлар чыгыш ясады.

Декабрь аенда Н. Әхмәдиев, Ф. Гыйльми, И. Лимонова составындагы иҗат бригадасы «Татнефть» берләшмәсенең Төмән өлкәсендәге нефтьчеләре янында булып кайтты. Алар Лангепас шәһәрендәге Урьев һәм Ласъеган нефть һәм газ чыгару идарәләре цехларында, эшчеләр тулай торакларында нефтьчеләр, төзүчеләр белән очраштылар, мәктәпләрдә чыгыш ясадылар.

5 декабрьдә Лениногорск шәһәренең Техника йортында язучы А. Хәсәновның тууына 50 яшь тулуга багышлап иҗат кичәсе уздырылды. Язучының иҗаты хакында Р. Төхфәтуллин сөйләде.

19 декабрь көнне Зәй-Каратайда Фазыл Туйкинның йөз еллыгына багышланган әдәби кичә булды. Ф. Туйкинның тормыш һәм иҗат юлы хакында юбилярның туганы, заманында аңарда укып белем алган Татарстанның атказанган укытучысы М. Х. Туйкина сөйләде. Үзенең истәлекләре белән колхозчы Фәрхетдин ага Батталов уртаклашты. Бөгелмәдән укытучы Ә. Сафина шәһәр музеенда Ф. Туйкинга кагылышлы материаллар белән таныштырды. Мәктәп балалары аның шигырьләрен укыдылар.

Юбилей кичәсендә язучы Ж. Рәхимов чыгыш ясады.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Совет әдәбияты, татар сәнгате өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм 70 яше тулу уңаеннан язучы Сәет Шәкүров Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 11 декабрь Указы нигезендә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет эстрада сәнгате өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен Г. Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең музыкаль-әдәби лекторие артисты Айрат Арсланов Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 11 декабрь Указы нигезендә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет театр сәнгате өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен һәм 60 яше тулу уңаеннан Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры режиссеры Празат Исәнбәт КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

Совет әдәбияты өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен язучы Мәхмүт Хәсәнов, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1987 ел, 24 декабрь Указы нигезендә Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Мактау грамотасы белән бүләкләнде.

## ТӨЗЕЛЕШ ЕЛЪЯЗМАСЫ

Татарстан АЭСы төзелешендәге штаттан тыш хәбәрчебез Роберт Талиповның чираттагы язмасында мондый яңалыклар турында белдерелә.

Күз алдына китерергә тырышыгыз әле: ул плитәнең авырлыгы 14 мең тонна, күләме биш мең кубометр. Татарстан атом электр станциясенең бер блогы әнә шушындый нигезгә утыртыла. Махсус составлы бу бетон изма алты тәүлек эчендә җәелеп бетәргә һәм 180 тәүлек ныгырга тиеш. Моның өчен төзелешнең буеннан-буена 72 метрлы эстакада салынды. Автоматик болгаткычлар измәне, шуның өстендә торып, ярдәмче җайланмаларсыз гына бушаттылар.

В. Назаров житәкчелегендәге бригада бу җаваплы эшне, гаҗәеп катлаулылыгына карамастан, ике көн алдан тәгалләде. Комсомол яшьләрнең әлеге бригадасы Владимир Правик исемен йөртә. В. Правик — Чернобыль АЭСындагы аварияне бетерү вакытында һәлак булган егет. Бригада 1986 елның маенда В. Правикны үзенә почетлы член итте. Аның айлык хезмәт хакы Тынычлык фондына күчерелә.

Узган елның өченче кварталында комсомол яшьләрдән генә торган бригадалар арасында оештырылган ярышта «Спецстрой» бригадасы җиңеп чыкты. Моның өчен бригадага чираттан тыш бер квартира бүләк ителде. Аны кемгә бирү — коллективның үз карамагында.

---

**Тышлыкның беренче битендә:** **«Кыйссаи Иосыф» поэмасына иллюстрация. Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык рәссамы Тавил ХАҖИӘХМӘТОВ эше.**

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстан Композиторлар союзы бинасы.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.

## *Журнал укучылар игътибарына*

«Кызганычка каршы, үз вакытында «Казан утлары»на язылa алмый калдым. Инде хәзер миңа нишләргә? Ярдәм итә алмассызмы?» Соңгы вакытта редакциябезгә шундый эчтәлекле хатлар килә башлады. Шул уңайдан, хөрмәтле укучылар, исегезгә төшерәбез:

Журналны агымдагы елның теләсә кайсы аеннан башлап алдырырга мөмкин. Моның өчен «Союзпечать» оешмаларына, элемтә бүлекләренә, уку яки эш урынындагы җәмәгать тәртибендә матбугат таратучыларга мөрәҗәгать итәргә кирәк.

Бер елга язылу бәясе 10 сум 80 тиен; ярты елга — 5 сум 40 тиен.

«Казан утлары» газета һәм журналларның Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Аңа илебезнең бөтен төбәкләрендә чикләүсез язылырга була.

Индексы — 73210.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210




# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал.
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)